# казан утлары

7

ИЮЛЬ-1976

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

**7**

ИЮЛЬ


## Бу санда


Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Ак диңгездә алтын балык. Хикәя 3
Г. РӘХИМ. Галәм гражданины. Шигырьләр . . 12
Ш. РӘКЫЙПОВ. Кипарислар җыры. Повесть . . 18
Г. АФЗАЛ. Борылам да карыйм... Шигырьләр . 74
Г. КАШАПОВ. Сәмум җиле. Повесть . . . . . 80
З. НАСЫЙБУЛЛИН. Кыюлар кимеми. Шигырьләр 116

ОЧЕРКЛАР

КамАЗ елъязмасы . . . . . . . . . . . . 119
М. МИНШИН. Канәфер чәчәге . . . . . . . 121
В. ЛУЦЕНКО. Якташыбыз «Мишка-татарин» . . . 127

ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ

В. ПОПОВ. Биосфера һәм аны саклау чаралары 137
Э. КАСЫЙМОВ. «Тын таулар» итәгендә . . . . 147

ТЕАТРНЫҢ 70 ЕЛЛЫГЫНА

И. ИЛЯЛОВА. Халык артисты . . . . . . . . . 157

ИСТӘЛЕКЛӘР

Ф. ИЛЬСКАЯ. Үткәннәрдән берничә сәхифә . . 168

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Тормыш һәм әдәбият . . . . . . . . . . . . 173

КИТАП КҮЗӘТҮ

Р. МОСТАФИН. Үлән яфраклары . . . . . . 179
Р. ВӘЛИЕВ. Иҗат һәм хезмәт активлыгы . . . . 180

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Г. ГАТАУЛЛИН. Бабай, Нәкыйп, мин һәм вакыт. Хикәяләр . . . . . . . . . . . . . 183



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

**Ә. РӘШИТОВ. Траллэлули-траллэлэй.** Шигырь . . 187

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

**А. ГОМӘР** . . . . . . . . . . . . . . . . 189

**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 190

**Редакциянең адресы:** Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

**Редколлегия:** **Әхсән Баянов, Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Аяз Гыйләҗев, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/IV-1976 ел. Басарга кул куелды 8/VI-1976 ел. ПФ 01015. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 91944 экз. Заказ К-143. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе, Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1976 ел.

Габдрахман Әпсәләмов

# АК ДИҢГЕЗДӘ АЛТЫН БАЛЫК

хикәя

*Фронтташым Каюм Иманкулов истәлегенә*

Һәй, заманалар! Еллары шундый кызу чабалар, пар атларда куып җитә алмассың. Хәер, бу әйтем без үзебез таякка атланып ат-ат уйнаган исәр малай чакларга гына яраган. Хәзер тизлек чагыштырулары башка инде. Ә ул вакытта гомер буе авылдан чыкмаган, кояш баешында кырыкилле чакрымдагы су тегермәненә, кояш чыгышында егерме биш-утыз чакрымдагы тимер юл станциясенә бер генә тапкыр да бармаган әби-бабайлар күпме иде әле! Алар күп йөрмәгән, әмма күп яшәгән. Без, малай-шалай, аларның чишмәдәй гөрләп аккан әңгәмәләрен, авызларыбызны ачып, дөньябызны онытып тыңлый идек. Яңа туган ай шикелле көмеш сакаллы, әлсерәп беткән бабай, өргә өстенә утырып, ялпәк кәпәч каплаган башын селкә-селкә:

— Һай, оланшак, оланшак, дөнья киң ул, зур ул, аның кырыена Микулай солдаты да барып җитә алмаган дип сөйлиләр. Заманалар үтәр, дәрзаманнар килеп җитәр, ә кеше дигәнең һаман йөрер. Язмышы шундый аның, тәкъдирендә шулай язылган,— дип куя.— Җәяү генә йөрмәс, тимер айгырларга гына утырып йөрмәс, тимер кошларның канатларына атланып очар. Монысы инде дәрзаманнарда булыр. Сез үзегез дә илгизәрләр булырсыз әле. Ак диңгез ярларына барып чыгарсыз, алтын балык тотарсыз.

Алтын балыгына исебез китми, диңгездә ни булмас, диңгез бит ул, ә менә диңгезнең ак булуына ышанып бетмибез. Ул Микулай солдатлары да:

> Күгелҗем диңгез, аппак пароход,
> Безне озаталар на Дальний Восток,

— дип җырлаганнар. Алар инде күреп, белеп җырлаганнар, диңгезне күгелҗем дигәннәр, ак димәгәннәр. Диңгез генә түгел, ак төн-

нәр дә була әле дисәләр, без тәгәрәп көләр идек, чөнки бездә айның ундүртенче кичәсендә дә төн ак булмый, зәңгәрсу була...

Бабай дөрес әйткән, ахрысы, без чыннан да дәрзаманнарда яшибез икән. Тимер кошларга — самолетларга утырып очтык, Ак диңгез ярында булдык, ак төннәрен дә күрдек. Бөек Ватан сугышы солдатларын язмыш кая гына илтеп ташламады!

...Менә төнге сәгать икеләр. Карелиядә ак төннәр вакыты. Дөресрәге, төннәр бөтенләй булмый, кояш батмый, шуңа күрә яп-якты, тик тәүлек исәбе буенча гына хәзер көн түгел, төн икәнен беләсең. Ике еллап алгы сызыкта булу дәверендә ак төннәрне җитәрлек күрдек. Хәзер инде алар, беренче вакытлардагыча, чиксез кызыксыну уятмыйлар, ияләштек. Карелиянең карурманнары да хәзер котны алмый, без аларны тәмам айкадык. Тик бер нәрсә гаҗәпләндерүдән туктамый. Бездә борын-борыннан «тайга» сүзе булмаган. Бабайлар аның өчен яңа сүз уйлап тормаган, иске ике сүзнең бер авазын кыскартып, бер сүзгә калдырган да «карурман» дигән. Нәтиҗәдә гаҗәеп матур яңгырашлы, тулы мәгънәле сүз барлыкка килгән. Моның өчен бәлки бик күп еллар кирәк булгандыр. Сүзләрнең төсмерләре халык күңелендә озак чарлана. Хәзер карурман дигәндә аның ераклыгы, караңгылыгы, каралыгы, керсәң, әйләнеп кире чыгалмаслык чытырманлыгы — барысы бар. Бер генә энҗесе дә коелмаган.

Без газетаның наборын, төзәтеп бетереп, басар өчен печатникларга тапшырдык та Ак диңгез ярына чыгып утырдык. Диңгез безнең типографиядән нибары кырык-илле адымда гына. Форсаттан файдаланып, әзрәк саф һава сулыйсың, диңгез матурлыгы белән хозурланасың — мин редакциядә күптән түгел, диңгезнең мәһабәт гүзәллегенә сокланып туйганым юк әле, — иң мөһиме, кирәк була калса, күз ачып йомганчы дигәндәй, типографиягә кереп чыга аласың. Хикмәт шунда, безнең барлык наборщик, печатниклар руслар, татарча белмиләр. Ә кулдан җыелган полосаларны баскан чагында кырыйдагы хәрефләр оядан чыгучан, я сынучан булалар. Татарча укый белмәгән кешегә моны тотып алуы һәм төзәтүе кыен. Шуңа күрә корректор газетаны басып бетергәнче типографиядә булырга мәҗбүр. Миңа, редакция секретарена, кайтып йокларга мөмкин, ләкин Каюмны ялгыз калдырасым килми.

Диңгезгә карап, әкрен генә сөйләшеп утырабыз. Бу сәгатьләрдә суның кимегән чагы. Су артканда күренми торган эреле-ваклы ташлар хәзер, юеш яннарын кояшта ялтыратып, җемелдәшеп яталар. Бераз читтәрәк авыл өе хәтле зур-зур ташлар да күренә. Сугышка кадәр монда нindидер порт корылмалары булган диләр. Сугыш башында дошман аларны бомбага тотып, пыран-заран китереп бетергән, якындагы Беломор—Балтик каналының шлюзларын да ваткан.

Керосин, машина мае, буяу исләре белән тулы шау-шулы типографиядән соң тып-тын һәм салкынча диңгез ярында утыру үзе ни тора! Сулыш киңәя кебек, арганлыклар онытыла, ә тынлык шундый сихерле, син хәтта үзеңнең кайда икәнеңне истән чыгарасың. Гүя сугыш инде беткән, җиргә күптән көтелгән тынычлык иңгән. Кайдадыр әкрен генә гөрелте ишетелә, әйтерсең поезд узып бара. Ләкин берничә минут үтә, гөрелте якынаймый да, ерагаймый да. Ниһаять, син аңлап аласың: Беломорск шәһәре уртасыннан Ак диңгезгә таба елга шаулап ага. Аның төбе таш, үзе баскыч-баскыч бусагалы, шуңа күрә елга өзлексез гөрләп тора.

Беломорск нигездә агач шәһәр, хәтта тротуарлары да агачтан. Тик вокзал тирәсендә генә таш шәһәр башлана, урамнары матур, йортларының тәрәзәләре ак яңаклы, балконнары бар. Шәһәрнең иске өлеше ничек туры килсә шулай төзелә биргән, урамнарында

эреле-вaклы ташлар тулып ята — әйтерсең ниндидер шаян малай чиләк белән Бәрәңге алып кайтканда яртысын юлда шулай чәчеп калдырган. Тик «бәрәңгеләре» зур кисмәкләргә дә сыймас зурлар.

Диңгезгә карап, үзенең ниндидер бетмәс уйларына чумган Каюм кинәт әкрен генә җырлап җибәрде. Моңарчы мин ишетмәгән моңлы һәм матур көй иде бу:

Бардым суга, салдым кармак,
Безгә балык эләкми.
Иөгереп китәрдәй булам ла,
Кайтып җитәрдәй булам —
Туган-үскән илләргә лә
Көзге ачы җилләрдә...

— Нинди җыр бу? — дип сорадым.

— «Көзге ачы җилләрдә» дип атала бугай. Безнең Бәрәңгедә бер карт солдат җырлый торган иде, кып-кызыл кояш баешына карап. Беренче дөнья сугышында татар сугышчылары окопларда җырлый торган булганнар, ди. Хәзергесе заман булса, язып алып газетага басар идек. Югыйсә, юлларын да, сүзләрен дә бутый торганмындыр. Хәтердә калган аерым җирләрен генә шыңшыган булам. Күрәсең, үзем солдат булмагач, бар сагышын аңлап бетермәгәнмен, мәгънәсенә дә төшенеп җитмәгәнмен. Ә солдат җырлары бик моңлы алар, күздән яшь чыгара, мәгънәләре бик тирән, үзең солдат булгач, төшенәсең икән. Мин оста җырчы түгел, әмма кайчак, бик сагышлансам, шуларны әйттергәләгән булам. Әле Бәрәңгедә, педучилищеда укыган чакта, бер китап кулыма эләккән иде. Кайсыдыр җырчымы, философмы, диңгез ярына чыгып, дулкыннар белән ярыша-ярыша җырларгамы, оста ораторлар кебек сөйләргәме өйрәнгән булган. Мин дә тырышып карадым, ләкин миннән чыкмый. Ахрысы, буем кәрләгәдер, — дип оялчан гына көлемсерәде Каюм.

Мин дә елмайдым һәм фронтташыма карап алдым. Бәләкәй буйлы, каратут йөзле, кылыч борынлы, урман чикләвеге төсле карасу-саргылт күзле бу егетне фронтта чакта әрмәннәр — әрмән, грузиннар — грузин, яһүдләр — яһүд дип йөри торган булганнар. Тик холкы гына ул халыкларныкы шикелле артык кайнар түгел, — ул сабыр, ул тыйнак, хәйлә-мазар белми, бары-югы белән уртаклашырга һәр вакыт әзер, чәнечкеле сүз әйтсәләр оялып кызара. Андый чакта битендәге берничә бөртек шадрасы беленә башлый. Редакциядә аны, яратып-шаяртып, күбрәк Яманкулов дип йөриләр, хәлбуки аның чын фамилиясе бер дә алай түгел. Кулларын яманларга да нигез юк, киресенчә, аның куллары кызларныкы кебек нәфис, әйтерсең бу куллар әле күптән түгел генә мылтык та тотмаган, граната да ыргытмаган, җан тиргә батып окоп та казымаган. Бары тик наборщиклар гына бу кулларны яманларга хаклы, чөнки гранкаларны тәмам буяп бетерә, полосаларга да җитәрлек кала әле. Редакциядә язу машинкасы юк, ә редакция кешеләренең кулдан язулары татарчаны белгән кешеләргә дә бер табышмак була, ә наборщиклар, алда әйткәнемчә, руслар. Кыскасы, корректорның кулын яманларга теләсәң күпме нигезе бар аларның.

— Каюм, сезнең Бәрәңге авылы кай тирәдәрәк? Сугыштан соң, исән калсак, бер барып карыйсы иде.

— Әллә Бәрәңгедә булганың юкмы? — дип гаҗәпләнде корректор, — Татарстанның ут күршесе — Мари республикасында гына. Бик знаменитый авыл ул: педучилищесында дөньядагы иң матур кызлар укый, бер күрүдә гашыйк буласың! — Каюм астан гына карый, ә үзенең күзләрендә шаян мутлык түгел, ярылып яткан моңсулык. Бу күзләр иясен үчекләргә яки шаяртырга ничектер тел бар-

мый. Нәрсәдән бу? Педучилищесын яки мәктәбен сагынуданмы — анда, бәлки, Каюмның йөрәген өзгән бер чибәр укытучы калгандыр? Әллә бер-бер нәрсә сизенүдәнме? Кайчак кешенең эчке сизенүләре искиткеч көчле була, шаккатарлык. Әмма үземнең ихтыярсыз туган уйларым белән иптәшемне шомландырасым килмәде. Гомумән педучилище турындагы сүзне өзәргә булдым. Кешенең эчке дөньясында нинди генә серләр булмас.

Каюмның күкрәгендә бернинди орден-медальләр юк әле. Ләкин сул як күкрәк кесәсе өстендә яралану билгесе бар. Бу инде күп нәрсә турында сөйли. Димәк, ул передовойда булган, туган ил өчен канын койган. Шул турыда сакланып кына сорадым.

— Булды инде, — диде ул гадәтенчә тыйнак кына. Ләкин шунда ук тавышында әллә нәрсәдәндер канәгатьсезлек, әллә нигәдер рәнҗү яңгырый башлады кебек. — Мин бит, кайберәүләр уйлаганча, тылдан туп-туры редакция шәрәфләренә очып килмәдем. Армиягә 1939 елда ук алындым. Аңарчы укытучы идем.

— Бәрәңгедәме?

— Булса... Авылның исемендә эш түгел, аның менә дигән урта мәктәбе бар. Мин татар телен һәм әдәбиятын укыттым. Безнең үзебезнең сәләтле шагыйрьләребез дә үсеп килә иде.

— Мәсәлән?

— Мәсәлән, Мансур Гаяз.

— «Совет әдәбиятында» шигырьләрен күргәнем бар. Хәзер кайда ул егет?

— Ил өстенә яу килгәндә ир-егетнең урыны — фронт.

— Сезнең частьны туры Карелиягә озаттылармыни? — дип сорадым сүзне алмаштырып.

— Турыдан ук түгел дә, ну, аннары Карелиягә эләктек. Күптән түгел генә сугышлар барган урыннарга. Монда бит кругом урманнар, сазлыклар. Зур авыллар, шәһәрләр аз, сугыш эзләре әллә ни күренми, барысын яшел саз суы йоткан. Имгәтелгән гүзәл карел наратлары гына йөрәкне өзә. Мин Куйто күле тирәсендә сугыштым. Ленрот нараты турында ишеткәнең бардыр бәлки?

— Карелиядә булып да Ленрот нараты турында ишетмә, имеш! Мәшһүр шагыйрь аның төбенә утырып карел картларыннан Калевала дастанын язган. Димәк, Масельская юнәлешендә. Айталамба авылын хәтерлисеңме?

— Әллә син дә анда булдыңмы?

— Солдат кайда булмый, — дип көлемсерәдем мин.

— Без менә шул җирләрдә инде беренче башлап сугышка кердек. Чын урман сугышын шунда күрдем. Галәмәт ул урман сугышы — күк яна, җир яна, сазлык яна — баш тыгар урын юк. Ачы төтеннән күзләр атылып чыгардай. Татыдык инде шүрәле газапларын, эчтек Лаеш шулпасын. Түш белән шуыша-шуыша актык төймәләрне коеп бетердек. Шулай да күп чигенмәдек. Масельскаяның водокачкасын хәтерлисеңме? Шәһәр тәмам җимерелгән, ә водокачка, язмышка үч иткән кебек, әле дә калкып тора. Без дә шуның шикелле... И-и-и, сүзгә мавыгып, газетаны бөтенләй оныткანмын.

Каюм урыныннан сикереп торды һәм типографиягә таба йөгереп китте. Мин утырган урынымда — диңгез ярында калдым. Ә уйларым... кайларда гына гизмәде. Дөрес, мин инде урман сугышларын күреп беләм, ләкин чигенү газапларын безгә бөтенләй татырга туры килмәде. Аларны шул Каюмнар төбенә кадәр эчкән, дошманның алга килүен туктаткан, ел әйләнәсендә туңмый торган Мурманск портын тоташтыручы Киров тимер юлын саклаганнар. Безнең бәләкәй Каюм ул чакта укчы ротаның солдаты һәм парторгы булган — бу турыда ул нигәдер әйтмәде, ләкин мин инде беләдер идем —Карелия

урманнары зур, әмма чигенер урын юк, дигән ул сугышчан иптәшләренә. Ачлыгына да, яралары сызлавына да түзгән.

Гади солдат үзенең батырлыгы турында җәелеп сөйләми, әмма бер-ике сүз белән бик төгәл әйтеп бирә, я берәр көлке эпизод кыстыра, я сүгенеп ала. Аңласаң — аңла, аңламасаң — үзеңә үпкәлә. Ә миңа, язучы кисәгенә, шуларның барысын биш бармагың шикелле белергә кирәк, үз тәҗрибәңә генә таянмассың бит. Аннары Карелия фронты ике мең километрдан артыкка сузыла, һәр җире бик үзенчәлекле.

Каюм озаклады. Мин Ак диңгезне күзәтеп туйдым. Болай карасаң ул гел бер төсле сыман, әзрәк зәңгәрсу, ак түгел, кыш көне генә ак була, диләр. Хәзер дулкыннар юк, су өсте әкрен генә тимгелләнә, әйтерсең көмеш тәңкәле балык, кырын ятып, кояш нурларында кызына. Белмим, Ак диңгездә нинди балыклар бардыр, әмма Карелиянең егерме алты мең күлендә — солдатлар арасында шундый сүз йөри иде — күбрәк навага гына. Без аны җитәрлек күп ашадык, туеп беттек. Солдатлар аны агач балык дип атый башлады. Карап торырга тавык ите сыман ак, капсаң—нәкъ сусыл морошка җиләгедәй.

Ниһаять, Каюм күренде.

— Эшләр ничек бара анда?

— Бара шунда, — диде корректор теләр-теләмәс кенә. — Ә син ник кереп ятмадың?

— Йокыдан кибән куйган кеше юк әле.

— Ә нигә көлемсерисең?

— Мин түгел, син нигә көлемсерисең? Тагын корректор кызлар янына кереп кайнар чәй эчеп чыктыңмы әллә?

— Әйтерсең безгә чәй эчәргә ярамый. Ярый әле, званиең миненнән кечерәк, югыйсә...

— Мин өлкән сержант дип мактанасың инде.

— Как же! Ул исемне миңа кайда булса түгел, передовойда бирделәр. Ә анда тикмәгә генә бирмиләр инде. Бер сәгать эчендә помкомвзвод та, комвзвод та булдым. Раз — помкомвзводың юк. Раз — комвзводың юк. Менә ничек. Ә сугышырга кирәк, җитәкчелек итәргә кирәк.

— Рота парторгы өчен...

— Парторг нәрсә, аны кул күтәрәләр дә сайлап куялар.

— Һай, нинди ансат!

— Ну, ансат булмасын да ди...

Каюм кемгәдер турсайган, кемнәндер хәтере калган тон белән сөйләшә иде. Кемгә ачуланды икән? Миңамы? Мин аңа авыр сүз әйтмәдем бугай. Әллә сержант башы белән майор урынында утыруымны яратып бетермиме икән? Редакция секретаре кимендә майор булырга тиеш. Ә кинәт күтәрелүчеләр, гадәттә, бик эре кылана башлыйлар, шулай итеп кайберләре үзләренең бик булдыклы икәнен адым саен күрсәтергә тырышалар. Әллә Каюм шул гөнаһларны миндә дә күрәме?

Мин аптырадым.

— Кара әле, Каюм, — дидем мин, көлемсери төшеп, — типографиядә сине алмаштырмадылармы? Корректоршалар белән линотиписткалар бик мәкерле халык бит. Бер минутта кешенең...

— Юк, минем башым әйләнми, мин үземнең бәямне беләм. Аннары алар миңа карамый да — буем кәрлә, паегым юк. Ә менә перспективалы сержантларга саклана төшәргә кирәк.

— Рәхмәт, киңәшеңне истә тотармын, ләкин ни өчен ачуланганыңны ачыграк әйтсәң иде. Мин шикләнүчән кеше. Синең мондый карашыңны элек тә сизгәли идем.

— Хәтта? — диде Каюм бик үк ышанмыйча. — Алайса, үзең нигә минем передовойда булу-булмавым белән һәр вакыт кызыксынасың? Әллә син генә алгы сызыкны күргәнме? Майор белән өлкән лейтенант тырнак астыннан кер эзләмиләр бит.

— Егет, ачык итеп әйттең. Минем сине тиң күрүемне төшенеп җиткермәгәнсең. Анысы бәлки әһәмиятле дә түгелдер.

Каюм миңа ышанмыйчарак утырды кебек. Аннары күз карашын каядыр еракка төбәде.

— Әнә күрәсеңме? — диде.

— Берни күрмим.

— Диңгез түрендә дәме?

— Анда су ялтырый.

— Су... Дулкыннар уйный башлаган! Иртәгә шторм көт.

— Диңгез түрендә мондый гына дулкыннар...

— Снайперлыкка губчем ярамыйсың икән? — диде Каюм, кинәт мине шаккаттырып.

Безнең күзләр очрашты. Каюмның карашы, миңа калса, бераз әйле-шәйле иде. Ул гүя: «Менә тик тормас тел, нинди юньсез сүз әйтеп ташлады бит!» дия иде. Шул мизгелдә мин аның эчендә кайнаган серләрен сизеп алдым шикелле. Ләкин моның нигезендә нәрсә ята — төшенмәдем. Каюмны мин эчкерсез-прастуй егет дип уйлый башлаган идем, күрәсең, алай ук түгел. Әгәр ул башкалар данына вакчылларча кызыгучы, адым саен алардан көнләшүче булса, бу яхшыга илтмәс. Офицерлар белән ул әле дистанцияне саклый торгандыр, ә званиесе үзенекеннән түбән кешедән нәрсә куркып торырга?

Каюм сүзне артык дәвам итәргә теләмәде. Аска карап:

— Ярар, типографиягә тагын бер кереп тикшерәм дә... — диде, — түгәрәкләргә вакыт. Син дә бар ят. Ак диңгез ярында барыбер алтын балык көтә алмыйсың. Суы салкын.

Корректор үзалдына сызгыра-сызгыра китеп барды. Мин әле тагын берничә минут диңгез түренә карап утырдым. Иртәнге аксыл рәшәдә дулкыннар уйнавы бөтенләй диярлек беленми. Шулай ук минем күзләр начар күрә башлаганмыни? Әллә Каюм дөресен әйтмәдеме? Мин бирегә снайперлыкка имтихан тотарга килмәдем килүен... Юк, Каюм алай беркатлы уйламагандыр. Ул, мөгаен, шактый хәйләкәр, астыртындыр?.. Элек ничектер игътибар ителмәгән, хәзер кылт итеп исемә төште: әле яңа килгән көннәремдә минем бер мәкаләмдә Каюм ике-өч имла хатасын зур хәрефләр белән төзәтеп, полосаны шул көенчә редактор кулына биргән иде. Ул чакта артык игътибар итмәдем, ә хәзер соңга калып булса да уйладым: «Яңа секретарьне шәп чәпәгән бит, шук корректор!»

Мин тирләп киттем. Үз-үземнән оялдым — кара нинди вак кеше икәнмен... Килсә килер икән шундый шик?

Әле күптән түгел генә безнең татар редакциясендә бик зур үзгәрешләр булган. Сәбәпләре һәм серләре миңа бик үк ачык түгел. Редактор урынбасары майор Александр Герасимовны (редактор булып рус газетасы җитәкчесе санала иде) һәм редакция хезмәткәре капитан Минһаҗ Җамалиевны, эшләреннән алып, резервка җибәргәннәр. Редактор урынбасары итеп шул ук редакция эшчесе (ул яңарак килгән булган) майор Габделбариевны билгеләгәннәр, корреспондент-оештыручы булып Политуправлениедән өлкән лейтенант Мөхәммәтшаһинур Сабаев һәм секретарь итеп алгы кырыйдан мин килдем.

Майор Габделбариев чын газетчы, ул «Кызыл яшьләр»дә һәм «Кызыл Татарстан»да эшләгән кеше, солдат газетасын яхшырту эшенә килгән көненнән үк керешкән. Аңарчы газетабыз ничектер төссез чыгып килгән, дубляж булган. Редактор урынбасары Герасимов — нагайбәк — татарчаны болай бик ару белсә дә, элек журна-

листика буенча эшләмәгән, мәктәп директоры булган. Политработник Җамалиев исә язу-сызу белән эш итмәгән. Аларны дубляж канәгатьләндергән булса кирәк. Майор Габделбариев кыю рәвештә дубляждан баш тарта, редакциянең үз хәбәрчеләрен булдырырга керешә, Казан белән бәйләнешне юлга сала.

Мөхәммәтшаһинурның да газета эшендә әллә ни зур тәҗрибәсе юк югын, авылда политотделлар вакытында район газетасы редакторы булып алган, ләкин озак эшләмәгән, әмма табигате белән чын журналист — кирәк материалны таш астыннан да таба белә, теләсә нинди командир янына керә, хәтта генерал белән сөйләшә, һич тартынмый. Мин кыска гына вакыт эчендә моңа ышанып өлгердем. Каләме, дөрес, бик шома түгел, ләкин тату редакциядә бу кимчелекне бетереп була.

Мин кереп ятканда майор белән өлкән лейтенант йоклыйлар иде. Аларны уятмаска тырышып, сак кына чишендем һәм башымны мендәргә куюга йоклап та киттем.

Уянганда төшке аш вакыты җиткән иде инде. Майор Габделбариев урынында юк — ул ашарга минуты-минуты белән бара, гомумән, ул бик төгәл кеше, йокыдан бер үк вакытта тора, бер үк вакытта эшкә утыра. Тормышны да әйтерсең газета макеты шикелле итеп, төгәл сыза, беркайда, бернинди артык юл юк. Мөхәммәтшаһинур табигате белән нәкъ аның киресе. Менә әле дә, күптән торган булса да, мине көтеп утыра. Үзе Каюм китереп куйган яңа газетаны караштыра.

— Тизрәк юынып ал, югыйсә, ашханәгә кичегәбез, — диде Мөхәммәтшаһинур газетадан башын күтәрмичә генә. — Каюмны уятмыйк, аңа аш калдырсыннар дип әйтербез. Тырыша ул егет. Газета номердан-номерга яхшыра бара. Ә минем мәкалә бүгенге битне прямо бизәгән, — һәм ул үзенә генә хас рәвештә кеткелдәп көлеп куйды. Аның көлүе бик самими, масаюның, мин-минлекнең әсәре дә юк, киресенчә, ул үзен кечерәйтә кебек. Моны бик оста итеп үзенең шаян көлүе белән яшерә.

Ашханәгә барганда, әллә үз уйларым белән артык мәшгуль булгангамы, әллә якындагы аэродромда самолетлар өзлексез гүләгәнгәме, диңгез шаулавын бөтенләй ишетмәдем. Ашханәдән чыкканда диңгез шул кадәр ажгыра иде, мин ихтыярсыздан туктап:

— Әллә шторм башланган инде? — дидем. Чал ялларын кабарткан тау-тау дулкыннар, бер-берсен куышып килеп, ачу белән ярга бәреләләр. Су арткан, баягы эреле-ваклы ташлар инде күренми.

— Кая ул чын шторм. Бу әле яшь килен коймагы гына, ә менә кайнана коймагы кабарса кабара инде ул! — диде Мөхәммәтшаһинур һәм тагын бик үзенчәлекле итеп көлеп алды. Билгеле, бу шаян сүзләр минем игътибарымнан читтә калмады, ләкин мин Каюмның төнге сүзләрен хәтерләдем һәм Мөхәммәтшаһинурга кичә Каюмны үпкәләтә язуымны әйтергә мәҗбүр булдым. Ул мине бик тиз төшенде.

— Әллә Герасимов турында сүз булдымы? — дип сорады ул.

— Шуңа таба бара иде. Мин Каюмны бик аз беләм. Якынрак танышасым килгән иде. Редакциягә ничек эләгүе белән кызыксындым. Ә ул...

— Аңлашыла, — диде Мөхәммәтшаһинур, минем сүзем беткәнен дә көтмичә. — Каюмны редакциягә майор Герасимов тарта. Ул аны кайдадыр передовойда таба. Икесе дә укытучылар — сүзләре килә. Ләкин шулай килеп чыга, Каюм гүя яхшылыкка каршы усаллык эшли. Билгеле, саф вөҗданлы Каюм моны бик авыр кичерә. Ә Герасимов аңа рәнҗүле сүз дә әйтми. Газета өчен редактор җавап бирә ди и вәссәлам...

— Нәрсә була соң? — дип сорадым мин.

— Редакция эшендәге гадәти хәл. Җамалиев Верховный Башкомандующий приказын тәрҗемә итә һәм шунда бер сүз төшеп кала. Шулай китә, берәү дә күрми. Соңыннан Политуправлениеда Герасимовтан сорыйлар: татарча минометчылар ничек була? Минометчылар минометчылар була инде, ди Герасимов, бу сүз тәрҗемә ителми. Шуннан Герасимовтан татарчасын укыталар, ә Политуправление кешесе оригиналын карап бара. Минометчылар сүзе төшеп калган.

Герасимов акланып тормый, мин гаепле, карап җиткермәгәнмен, тиешле җәзасын күтәрәм, ди. Менә шул. Каюм, корректор буларак, партоешмага гариза яза, янәсе бу хатаны ул күрергә тиеш булган, ләкин...

Мөхәммәтшаһинур сүздән туктады. Без, шаулап-бөтерелеп торган диңгезгә бераз карап торгач, редакциягә кердек. Каюмның урыны буш иде. Майор Габделбариев бик җитди кыяфәт белән газетаның чираттагы номеры макетын сыза. Сыза-сыза да, макетны алга сузган кулына тотып, бер күзен кысып, аңа карый, янәсе ничек, симметрия килгәнме?

Озакламый майорны рус газетасы летучкасына чакырып алдылар. Мин Мөхәммәтшаһинур язган заметкаларны редакцияли башладым.

— Мөхәммәтшаһинур,— дидем, соңгы мәкаләне карап бетереп,— бая коймак турында бик матур сүзләр әйттең. Миңа ачуланма, мәкаләләреңдә яшь килен коймагы да, кайнана коймагы да аз кабара. Чүпрәсен кызганасың, ахрысы. Кызганма, уңган хатынны гына түгел, уңган журналистны да килешкән «ашлар» өчен мактыйлар.

— Соң, ни, коймак... Әби-бабай сүзе генә ич ул! Сөйләгәндә уйлап тормасаң, килә шунда тел очына. Уйлый башласам, җилекләре кибә дә китә. — Мөхәммәтшаһинур тагын кеткелдәп көлеп алды. — Бер минут вакытыңны алып сөйлим әле, ачуланма. Хатын гел яратып әйтә торган иде: күп такылдыйсың, шуңа күрә маңгай чәчең коелып беткән. Акыллы кешеләрнең генә башы таз була дип мактанма. Шул, әле Мытыэста эшләгән чагында, бервакытны үземне доклад белән авылга җибәрергә булдылар. Докладның текстын райкомга бирергә кушылды. Тирләп-пешеп яздым, үземчә иң матур сүзләрне сайладым — прямо шигырь. Райком секретаре, укып чыккач, өстәл пыяласын бармаклары белән бик озак дөбердәтте. Мин әйтәм: «Булды, аңладым, дөбердәтәм генә!» «Пычагым аңлагансың! — ди секретарь. — Мин үзем синең белән авылга барам!» «Алай булгач,— мин әйтәм, — бигрәк яхшы, икебезгә дә тимер өстәлләр куйдырабыз, биергә тәк биергә». — Ул эндәшмәде, ә күз карашыннан юк чәчләрем үрә торырлык иде.

— Ну, малай,— диде райком секретаре докладымны тыңлагач,— язганыңны укырсың дип котым очкан иде. Бөтенләй башка доклад сөйләдең бит! Халык авызыңа карап кына торды. Политик сизгерлегең бар, агымдагы политиканы яхшы беләсең, сүз өчен дә күршегә барып йөрмисең икән, әмма язучы синнән чыкмый, анысы факт. — Бу юлы Мөхәммәтшаһинур шактый озак көлде. — Ләкин райком секретареннан да хикмәтлерәк сүзне миңа безнең Каюм әйтте. Тора торгач, аның авыл агае кебек бер кәлимә әйтеп куя торган гадәте бар: исемнең өч катлысын сайлаганнар үзеңә, акылны мул биргәннәр, әкият сөйләргә дисәң, телең дә, аллага шөкер, тик, бисмилла әйтеп, баш астыңа каз кауры куярга онытканнар. Шуңа күрә яза белмисең. Хәзер инде үзеңне яңадан бишеккә салмыйча бер нәрсә дә эшләп булмый. Зәһәрме? Яңадан бишеккә салырга өлкән лейтенантны, ә! Карап торырга, Ардов шикелле, юморист та түгел, чәнечкеле

сүзгә дәгъва да итми кебек, ә нинди усал тешли. Ләкин мин Каюмга һич ачуланмыйм, ник дисәң, аның кәлимәсендә хаклык бар. Хак сүзгә тиле генә каршы.

Шул чакта Каюм үзе кайтып керде.

— Рәхмәт, Мөхәммәтшаһинур абый,— диде ул, майорның урынында юклыгын күреп. Габделбариев алдында ул күп сүзле булудан саклана иде. — Синең аркада коймак белән сыйладылар үземне. Тәмле дә иде соң коймаклары...

Без өлкән лейтенант белән күзгә-күз карашып алдык һәм шаркылдап көлдек. Каюм, аптырап, әйтәсе сүзен әйтеп бетермәде. Һәр вакыт җанлы елтыраган күзләре моңсуланып китте. Мин шуның кинәт таралуын күреп елмайдым да:

— Мин, Каюм, Ак диңгез ярында могҗиза күрдем: диңгезнең суы ак икән, җитмәсә, алтын балыклар йөзәдер анда. Бер бәләкәчен шторм ярга ук чыгарып ташлаган иде, — дидем.

— Кая, күрсәт, — диде ул шаяртуымны аңлап.

— Мин аны кире диңгезгә җибәрдем. Бераз үсә төшсен дидем. Шундый бәләкәч — кызганыч бит.

Каюм елмаюдан туктады.

— Мөхәммәтшаһинур абый такылдагандыр инде. Ә үзе сер саклый беләм дигән иде...

— Үпкәләмә, Каюм. Минем исемем генә түгел, кайчак әйткән сүзем дә өч катлы була, бигрәк тә сүгенә башласам, — диде өлкән лейтенант җитди итеп. — Бүген сүгенергә сәбәп юк. Әнә майорның аяк тавышлары. Бетерик шунда. Югыйсә, ул белсә, яңабаштан кабатларга мәҗбүр итәр. Бел, солдат күңеле — ак диңгез, анда алтын балыклар рәхәтләнеп йөзә.

**Июль, 1975 ел.**

## Гәрәй Рәхим

### Галәм гражданины

Галәм каршысында мин кем генә?!
Бер күзәнәк, микро бер нокта.
Яши бирә галәм мин бар чакта,
Шулай яши бирер мин юкта.

Галактика каршысында ләкин
Мин — бер планета вәкиле!
Махсус атамам бар — Җир кешесе.
Гәрчә ул тик маймыл нәселе.

Ә җирдә мин бик тә зур кешемен.
Гражданинмын! Совет иленнән!
Бу исемне йөртү өчен миңа
Паспорт белән хокук бирелгән.

Татарстан, синдә шагыйрьмен мин.
Бусы минем соңгы исемем.
Шагыйрь — нокта... Шул ноктага сыйган
Галәмемнең бөтен җиСеме.

Шигыремдә мин әледән-әле
Галәмемә карыйм щаккатып.
Мин — ноктада шундый көч бар — җырда
Галәмнәрне йөрим айкатып.

Бар илһамым, бар кылганым белән
Сөям, Ватан, синең даныңны.
Мин галәмдә микронокта түгел,
Мин — Галәмнең гражданины.

### Урак өсте

Башланды инде кырда сары дәвер...
Башаклар бастылар камыл аякларга.
Кызыл комбайннар карап юл алдылар
Сары башакларга — сары маякларга.

Басулар өстендә кибәкләр тузгыды
Ургыч җилләренә ачуланып, дулап.
Кызыл дөяләрдәй барды комбайннар —
Барды кырны урып, коры кибәк сулап.

Ялан кырга шунда даңгыр-доңгыр килеп
Җитез машиналар чабып чыкты кинәт.
Комбайнның биек бункер-кошеленнән
Бөртек акты җырлап, икмәк көен көйләп.

Каты камылларга тырнатып шиннарын
Машиналар чапты амбар якларына.
Тәүге олауларны каршы алды кызлар
Нәни әләм тагып көрәк сапларына.

Яңа уңыш кайтты. Кызлар сөенделәр
Көшелләргә күмеп нәфис аякларын.
Кызыл косынкалар итеп бәйләделәр
Көрәк сабындагы кызыл маякларын.

## Өстәл лампасы белән сөйләшү

Ян, син минем лампам, яктырак ян!
Син бер сердәш миңа бу төндә.
Ерак ГЭСтан килгән якты утың
Йолдыз булып яна күңелдә.

Минем уйлар — синең тогың кебек —
Мизгелләрдә үтә күпме юл.
Я тоташа барып тарихыма,
Я галәмгә менеп китә ул.

Юк, мин ялгыз түгел бу галәмдә,
Ут дуслары чиксез күп алар.
Төннәрендә әнә йолдыз булып
Карап тора миңа дөньялар.

Аларга да балкып күренәдер
Җир-йолдызның якты ялкыны.
Бәлки алар гади йолдыз итеп
Күрәләрдер синең яктыны.

Күрәләрдер! Чөнки яктыңда мин
Җаным белән янып җыр язам.
Шигырь-йолдыз ерак галәмнәрдә
Балкып янар кебек бер заман.

Синең ерак туганнарың әнә —
Сары шәмнәр, сары шәмдәлләр —
Пушкиннарга мәңге сүнми торган
Шигырь-йолдыз табып биргәннәр.

## Кылганнар

Бакча артындагы тау башында
Җилләп утыра ап-ак кылганнар.
Инде декабрь бит, ничек алар
Аягүрә басып калганнар?!

Мин кылганнар арасында йөрим,
Сыйпап йөрим ап-ак башларын.
Мин үзем дә, ахры, кылганнардай
Бераз әрсезләнә башладым.

Ап-ак кылган кебек чәчләремне
Җилфердәтеп кышкы җилләрдә,
Аягүрә басып торам һаман
Туып-үскән шушы җирләрдә.
. . . . . . . . . . . . .

Ачы җилдә кылганнарга кушылып
Сызгырам мин, аваз чыгарам.
Әллә ни моң чыкмый чыгуын да,
Тик аумыйм бит, басып торалам!

Бураннарда шулай торам һаман,
Каршы алам апрель башларын.
Мин үзем дә, ахры, кылганнардай
Бераз әрсезләнә башладым.

## Кил, минем киләчәгем

Кил, минем киләчәгем,
Син — минем күрәчәгем.
Яначагым, көячәгем,
Утларга керәчәгем.

Кил, минем киләчәгем,
Сөя, сөеләчәгем.
Син минем ап-ак чәчләргә,
Нурга төренәчәгем.

Кил, минем киләчәгем,
Үземә тиячәгем.
Бәхетемне даулый-даулый,
Утларга керәчәгем.

Кил, минем киләчәгем.

## Сүз тәме

Сүзләр сүзгә ялгана да китә,
Ялгана да китә — могҗиза!
Кинәт шундый якты җөмлә туа —
Чаткылары чәчри йолдызга.

Күнегелгән көнең илаһи бер
Мизгел булып балкый кинәттән.
Талгын җанда кояш күтәрелә
Шагыйрь биргән җөмлә-бүләктән.

Язгы урман кебек яшь бу җөмлә,
Бөркеп тора аннан саф һава.
Күңелдә дәрт, гүя чиләгеңә
Шашкын кымыз өчен сөт ява.

Һай, сүз тәме! Һай, син татлы тамыр!
Яшәртәсең уйны, җаннарны.
Уйнатасың тәндә яңа каннар.
Алмаштырып иске каннарны.

Шигъри җөмлә! Сине табар өчен
Күпме шагыйрь шаша, яскана.
Сине яклап шагыйрь асыллары
Башын куя балта астына.

Бөек җөмлә балта астыннан да
Чәчрәп чыга — охшап йолдызга.
Төн... Тын бүлмә... Сүзләр бер-берсенә
Ялгана да китә — могҗиза.

## Дүртнең берсе

Шушы озын кышкы төннәрдә мин,
Ялгыз чыгып кухня ягына,
Зур бураннар эчендәге өйне,
Ялгыз әниемне сагынам.

Бу минутта ул йокламый, беләм,
Чалкан ятып иске түшәккә,
Күз йоммыйча сагына, дүрт тарафка
Киткән дүрт баласын.... И әнкә!

Дүрт тарафка киткән дүрт баласы
Дүртесе дүрт төрле бәхетле.
Дүртесе дүрт яктан искә ала
Туган йортны — тәүге тәхетне.

Дүртесе дүрт рәхәт вәгъдә итеп
Ананы дүрт якка чакыра.
Алар дүртәү, ана бер генә бит,
Уйлыйлармы шуны чак кына?!

Дүрт тарафка бүленү мөмкин түгел,
Бер ананы дүрткә ярмыйлар.
Һәм, гомумән, инде карт аналар
Туган йорттан читкә бармыйлар.

Алар бары күз талдырып карый
Дүрт тарафка — юллар ягына.
Һәм төннәрен иске түшәкләрдә
Балаларын өзелеп сагына.

Дүртнең берсе... Озын төннәрдә мин,
Ялгыз чыгып кухня ягына,
Төне буе шигырь язып чыгам,
Әниемне сагына-сагына.

## Су буенда ялгыз тал

Су буенда ялгыз тал үсә.
Тал төбендә тора яшь егет.
Каршысында аның гүзәл кыз,
Яшь егет соң тора ник җебеп?!

Ник әйтми ул кызның толымы
Тал бөдрәсе кебек булуын,
Күзләрендә аргы якларның
Тугайлары чагылып торуын?!

Ник сөйләми кызның буй-сыны
Камышларга тиңдәш икәнен?!
Мондый чакта мин яшь егеткә
Тын тормаска киңәш итәмен.

Югыйсә, бу кызның күзләре
Гашыйк булып куяр ятларга —
Я судагы зифа камышка,
Яки тугайдагы атларга.

Кызның әле шундый яшь чагы,
Гашыйк булыр чагы җилгә дә.
Җилләр инде әнә чибәрнең
Толымнарын җилпеп җибәрә.

Бераз гына кыю бул, егет,
Тын тормаска киңәш итәмен.
Сөйлә кызга аның буй-сыны
Камышларга тиңдәш икәнен.

Дәшми егет. Егет ояла...
Болай булса, калыр ул ярсыз.
Су буенда ялгыз тал үсәр,
Ләкин килмәс анда гүзәл кыз.

# Давылга әверелгән җил

Сезнең авыл аша искәндә
Җилләр сиңа кагылып үткәннәр.
Чәчләреңә синең сарылып,
Битләреңнән суырып үпкәннәр —
Бүген миңа килеп җиткәннәр.

Сезнең яктан килгән ул җилләр
Миңа шундый якын, иркәләр.
Алар бүген безнең авылда
Синең җылың белән исәләр.

Мин битемне куям җилләргә.
Көнләшсеннәр күргән-белгәннәр —
Җилләр миңа синең чәчләрнең
Йомшак назын алып килгәннәр.

Синең иренең тигән саф җилләр
Суырып үбә минем битемнән.
Көнләшсеннәр күргән-белгәннәр,
Җилләр тынмас әле үбүдән.

Сезнең авыл аша үткән җил
Уйнап йөрде безнең авылда.
Урам уртасында бер үптем —
Әверелде кинәт давылга.

Шамил Рәкыйпов

# КИПАРИСЛАР ҖЫРЫ

*Язучы Шамил Рәкыйповның 1973 елда Татарстан китап нәшриятында «Кызлар-йолдызлар» исемле документаль повесте басылган иде. Быел әдип Советлар Союзы Герое очучы Мәгубә Сыртланова һәм аның полкташларын сурәтләүгә багышланган ул повестьның дәвамын — икенче китабын язып бетерде. Бу санда журнал укучыларына шул повестьның берничә бүлеген тәкъдим итәбез. Әсәр тулысы белән Татарстан китап нәшриятында басылып чыгачак.*

**РЕДАКЦИЯ**

## «Керчьта Пушкин булган»...

Бу сүзләрне мин Рудневадан ишеттем. Ләкин башта куанычыбыз турында сөйлим әле.

Ниһаять, сугышчан заданиеләргә оча башладык! Фашистларның Кырымдагы оборона ныгытмаларын, корал складларын бомбага тотабыз. Хәзер күктә тулысынча безнең авиация өстенлек итә. Дошман фронтка кирәк кадәр самолетлар бирә алмый инде. Ләйләнең Әхмәте (безнең полк кызлары шулай диләр) әйткәнчә, сериялэп чыгара башлауга көйләп өлгермәгән, Төньяк Кавказда бер төн эчендә безнең дүрт экипажны һәлак итеп тәмам котларыбызны алган реактив двигательле «Альбатрос»лар, бәхеткә каршы, бөтенләй күренми, «Мессершмитт»лар да чагыштырмача аз оча иде биредә.

Безнең гаскәрләр Кырымда һөҗүм башларга хәзерләнә. Моңа уңай шартлар туды шикелле инде. Дүртенче Украина фронты гаскәрләре, Мелитополь, Запорожье тирәсендә хәлиткеч ударлар ясап, беренче ноябрьга каршы төндә Перекопка килеп чыктылар һәм гитлерчылар, Сталинградтагы сыман, камалыш хәлендә калды. Аерма тик шунда: биредә аларга диңгез уңайлылык тудыра иде.

Көнелләр күтәренке, очарлык һава шартлары булуын гына телибез. Ә менә Кырым һавасы, көйсез-иркә кызлар кебек, ике атна инде елапсыктап тора. Чак кына аяза башлауга — очабыз. Бүген полк Керчь шәһәренең көньяк кырыен бомбага тотачак. Разведка мәгълүматларына

караганда, яр буе урамындагы биналарга һәм аларның әйләнә-тирәсенә Төньяк Кавказдан чигенгән хәрби частьлар, зондеркомандалар нығып урнашкан. Без шуларны юк итәргә тиеш. Ифрат та җаваплы бу заданиегә ныклап хәзерләндек. Марфа әбинең оныгы Шурикны һәм санаторийда дәваланган бүтән сабыйларны газлы машинада тончыктырып һәлак иткән СС зондеркомандасы палачларының исән калганнарын хәзер бик-бик пешекләргә тели идек без. Башта Вера да, Ләйлә кебек үк куанып, учын-учка ышкыган иде (сабыйлар җанын кыючылардан үч алырбыз, дип, Марфа карчыкка сүз биргәннәр иде бит алар!), әмма зондеркоманданың үнҗиденче мәктәпкә урнашуын белгәч, куллары салынып төште, күзләрендәге шатлыклы нур сүнде. Ничек инде мәктәпне бомбага тотмак кирәк? Моңа ничек кулың барсын?

Вера, күңел күзләрен диңгез артындагы туган шәһәренә төбәп, яр читендә ялгызы басып тора. Тулы, йомры тәнле сылу кыз ул. Бил каешын кысып буганлыктан, гәүдәсенең матурлыгы аеруча күзгә ташлана. Вера, кулларын күкрәгенә чалыштырып, үз-үзен кочаклаган. Тойгыларым ташып чыкмагае дигәндәй, иреннәре кысылган. Чырае аксыл, чәчләре саргылт. Кыяфәте кырыс, горур. Мондый кызлар күңел байлыкларын, мәгарәдәге хәзинә сыман саклап, ышанычын казанган кешегә генә һәм аңа да берьюлы түгел, акрын-акрын гына ачалар. Инде бер ачылгач бөтен барлыгын аңа тапшыралар, бүтәнне белмиләр, белергә дә теләмиләр һәм үзләренә дә шуны таләп итәләр.

Хәтерегездәдер, күрше егете Александр Костенконың Верочканы өзелеп яратуы, механик булып эшләгән ул егетнең Вераны эзләп тапканчыга хәтле сакал үстереп йөрергә үзенә сүз биргәнлеге һәм тапкач, күрешү теләгәнлеге итеп, Верага өр-яңа самолет бүләк итүе турында мин сезгә сөйләгән идем инде. Бүген төнлә Вера шул самолеттан Керчьтагы дошманны бомбага тотарга барачак...

Штурманның уйчан күзләре өстендәге кыйгач кашлары тартып-тартып куя. Каш тартуны Вера мең кат сынаганы бар: уң кашы тартса, күңелсез хәл буласын көт тә тор! Элек андый чакта кыз елый торган иде. Сул кашы тартса, шатлыкка була килде. Хәзер менә ике кашы алмаш-тилмәш тарта. Моны ни дип юрарга?

Диңгез өстендә арыган-талган кыяфәтле ялгыз акчарлак оча. Аның тавышы бәгырьгә тия, елыйсыларны китерә. Гүя ул үзе дә шулай елый сыман. Акчарлак, җаным, сугыш азрак тынгач та кабат кайткансың икән бу якларга! Әйт син Верага бер киңәш: нишләргә аңа, нишләргә? Син үз ояңны үзең туздырыр идеңме, аны көл итеп җилгә очырыр идеңме? Юк, моны эшли алмас идең... Сездә, кошларда, нәсел өчен җан атып кайгырту көчле. Кешеләр алай ук түгел кебек. Аларның бит җәмгыять алдындагы бурычлары зур. Шушы бурыч Вераны үзенең туган-үскән өенә, киң дөньяга күз ачтырган мәктәбенә бомба ташларга алып барыр. Һәм Вера бомбаларны нәкъ цельгә ташлар. Чөнки анда дошман...

Акчарлак һава аязуын хәбәр иткән икән. Ялтырап кояш чыкты. Диңгез өстендәге томан, эреп, сыеклана төште. Дулкыннарның арыслан яллары күренә башлады.

Вера уйланып басып торган калкулыкка, бер төркем очучы кызларны ияртеп, полк командиры майор Бершанская килде. Буйга башкалардан калку, җилкәсе киң, адымнары эре һәм салмак. Зәңгәр берет, шундый ук төстәге гимнастерка, галифе чалбар кигән, хром итекләре елкылдап тора. Йөзе ирләрчә җитди, мәшгулиятле. Күкрәгендә орденнар балкый. Зәңгәр береты кырыйларыннан бүселеп чыккан саргылт бөдрәләре булмаса, аны утны-суны кичкән ир уртасы кыю командир дип уйлар идең.

Бершанская, бинокльдән диңгез артына карый-карый, Верага мөрәҗәгать итеп:

— Сез, лейтенант Белик, туган шәһәрегез урамнарында йөрисездер инде. Хөрмәтле гидыбыз сыйфатында, безгә әнә теге Митридат тавы турында сөйләсәгез икән! — диде.

— Гафу итегез, иптәш командир, — диде Вера, командиры килүен сизмәгәнгә уңайсызланып. — Уйга чумып күрми калганмын. Исәнмесез...

Бершанская баш какты һәм соравын кабатлады:

— Так, сөйләгез, Белик, Митридат тавы турында. Карый-карый тыңлыйк, иптәшләр...

Вера биш-алты минутлык нотык тотты, кабаланып, тирләп чыкты. Шулай да аңардан һәммәбез канәгать идек. Миңа Беликның үзе яшәгән каланы бик яратуы, андагы борынгы һәйкәлләргә үлеп гашыйк булуы аеруча ошады. Керчьта әлеге таудан ерак та түгел моннан ике мең ел элек эшләнгән Деметра төрбәсе бар икән. Ул җиргә казып ясалган. Аның гөмбәзендә уңыш алласы Деметраның сыны куелган. Аның янында дүрт ярсу аргамак сыннары да бар, ди... Атлар турында ишеткәч, күңелем әллә нишләде. Бала чагым искә төште, дала... Кем белә, авиациягә килүемә атка менеп җилдерүләр сәбәпче булмадымы икән әле?!. Иптәшләрем шаулатып кул чаба башлагач кына үткәндәге кадерле хатирәләрем бүленде.

Руфина, минә безнең эскадрилья штурманнары нинди дигәндәй карaш ташлап, дустының бәләгән кысты, иреннәрен кызның яңагына тидереп алды. Вера, полк командиры каршында мондый назлауларны һич килештермичә, тәмам югалып калды. Ләйлә тамак кырып куйды. Җайсыз хәлдә идек без. Бу киеренкелектән чыгарга кирәк иде.

Полк штурманы сөйкемлебез Женя Руднева, гадәттәгечә беркатлылыгы, самимилеге белән оялчан гына елмаеп, кулын аксыл бөдрәләренә тидереп (янәсе, честь бирә) алды да:

— Рөхсәт итсәгез, Евдокия Давыдовна, өстәп берничә сүз әйтер идем, — диде.

— Митридат турындамы? — диде Бершанская, кинәт борылып.

— Пушкин турында, — диде Руднева, гимнастеркасының бөрешкәләгән озын җиңнәрен сыпыргалап.

— Пушкин турында? — Бершанская Женяны баштанаяк күздән кичерде. — Кызык... Көндез штабта күренмәдең — шул хакта укып яткансыңдыр, ахры. Әйдә, башла, Руднева!

Женя буйга үсеп киткәндәй булып турайды, каешын рәтләде дә ашыкмыйча гына:

— Пушкин 1820 елның августында бирeдә булган, — диде. — Үзенең туганына ул болай дип язган... — Женя тамак кырып куйды, башын чайкап, бөдрәләрен селкетте дә мөлаем тавыш белән, кулларын артистларча киң җәеп, пафос белән дәвам итте: «Тамань ярым утравыннан, борынгы Тмутаракань князьлегеннән, каршыма Кырым яр буйлары ачылды. Диңгез кичеп Керчька килдем. Бирeдә мин Митридат төрбәсенең калдыкларын күрермен, бирeдә мин атаклы Пантикапей эзләрен табармын дип уйладым, тау өстендәге зиратта яткан таш өемнәренә, кешe кулы түшәп ясаган киң баскычларга карап. Табутмы икән алар, борынгы кирмән-башня калдыкларымы — белмим. Алтын тауга җитәргә берничә чакрым калгач тукталдым. Рәт-рәт тезелеп киткән тигез ташлар, җир өсте белән тигезләнә язган озын тар чокырлар — борынгы Пантикапей каласыннан калган нәрсәләр менә шулар гына бирeдә. Гасырлар монда җир астына күп хәзинәләрне күмгән булуына һич шигем юк минем»... — Женя кулын күкрәгенә куеп баш иде. Без шаулатып кул чаптык.

— Рәхмәт, Женечка, менә дигән иттереп башкарган бу нәфис сүзеңне Керчьны алгач, Митридат тавы ташларына басып сөйләргә насыйп булсын үзеңә! — диде Бершанская. — Ә бүгенгә, Митридатны төп ориен-

тир ясап, унсигезенче, унтугызынчы һәм егерме икенче квадратларны ничек итеп яхшырак бомбалау турында уйлашыйк, иптәшләр...

Мәгубә ханым, ак касәдәге ширбәт суы белән иреннәрен чылатып бермәл тын торгач, бүлмә эчендә кайгылы тавышы яңгырады:

— Полк штурманы, зәңгәр күзле сөеклебез Женя Рудневага, Митридат башларына басып, үлемсез Пушкин сүзләрен кабат сөйләргә насыйп булмады. Митридат бу герой кызның асыл сөякләрен бөек шагыйрь әйткән чиксез кыйммәтле хәзинәләр янына — үз куенына алды. Советлар Союзы Герое Евгения Максимовна Руднева хәзер шунда ята. — Мәгубә ханым күзләрен сөртте, көмештәй чигә чәчләрен төзәтте һәм азрак калтыранган тавыш белән сүзен дәвам итте: — Ә хәзергә хикәятемдә лейтенант Руднева исән әле. Менә ул, Пушкинны хыялында терелтеп, үзен тирәнтен дулкынландырган өчен рәхмәт йөзеннән бәләген кыскан Ләйләгә матур итеп карап ала, Чечневага елмая, нәрсәдер әйтергә теләп пышылдаган Верага баш ия.

Полк командиры, заданиене аңлатып, безне кайтарып җибәрде. Женя белән Вера шунда сөйләшә калдылар.

Кичен мине Таня Макарова урынына бүләк самолетта очарга билгеләделәр. Ә Таня аэродромда очышлар житәкчесе итеп билгеләнгән иде. Кызлар машинаны әзерләп куйган иделәр инде. Гадәттәгечә эчке бер хәстәр белән урыннарыбызга кереп утырдык. Моторны төрле режимда эшләтеп карагач, янибызга Бершанская килде. Аңа заданиене кабатладым. Шул арада старттагы Таня, ак флагын селкеп, кузгалырга боерды. Полк командиры аркадан сөеп читкә тайпылуга, газны арттырдым. Кайчандыр биредә ял итүчеләрнең ялан тәпиләре таптаган ком өстеннән ике-өч йөз метр «йөгереп» баргач, идарә тоткасын җай гына үземә тарттым. Күндәм машина талпынып куйды, дыңгырдау бетте — күтәрелә башладык. Җилгә каршы очарга кирәк булганлыктан, диңгез өстендә текә борылырга да Ахтанизовская, Титарская станицаларына таба китәргә тиеш идек без. Аста дошманнан азат ителгән җирләр. Күңел тыныч — биредә безгә зениткалар атмаячак. Шуңа күрә, Верочка белән гәпләшеп алырга ниятләп, сөйләшү аппаратын тоташтырам. Тамак кырам, ләкин штурманым дәшми. Күзгедә аның агарынган уйчан йөзе генә күренә. Тагын тамак кырам. Вера тагын дәшми. Әле шушы көннәрдә генә безгә күрсәтелгән кинофильмнан отып алган җырның хәзер бик мач килгән сүзләрен такмаклыйм:

Нам было весело, весело, весело...
Что же ты, милая, курносый нос повесила, повесила?..

Вера авыр сулап куя да:

— Кинодагы артистларга рәхәт аларга, — ди. — Җырлыйлар да биниләр, катлаулы мәсьәләләрне хәл кыласылары юк...

— Ә синең, Верочка?

Аста дошманның сакчы корабле эре калибрлы пулеметлардан ут ачты. Яктырткыч пулялар, июль кигәвеннәре сыман, өерләре-өерләре белән оча. Ярый әле, биеклек әйбәт. Шулай да, ут белән шаярмаганың хәерлерәк дип, читкәрәк тайпылам.

— Ә син, Марта, куркасыңмы? Дөресен әйт: син батырмы?

Минем ачуым килә башлый. Ләкин тыелам. Шуңадыр бәлки, яшь очучыларга инструктаж биргәндәгедәй, җавабым корырак чыга:

— Күктә дөресен сөйләмәгән очучы очучы түгел, штурман. Курыкмыйм дисәм, син барыбер ышанмас идең. Акылы зәгыйфь кеше генә үлемнән курыкмаска мөмкин. Курку, икенче төрле итеп әйткәндә, үз-үзеңне саклау кичереше бит ул, сеңелкәем. Барлык тере җан иясе курка. Ләкин кеше булган кеше курку тойгысын җиңәргә тиеш. Ягъни курку белән самолетны идарә иткән кебек идарә итә белергә кирәк.

— Аңлашыла,— диде Вера сузып кына.— Рәхмәт, Марта Хөсәеновна.

Кыз ипләбрәк утырды (моны мин тигезлек руленнән тойдым) һәм тынып калды.

Бераз вакыт сүзсез очтык. Мотор тигез эшли. Тиздән Кырым яр буйлары башланачак. Без Керчька әйләнебрәк килергә тиеш.

Вераның тавышы-тыны юк. Мин, соңгы сөйләшүебезне хәтердән үткәреп, борчылып куям:

— Вера, ә Вера! Син нәрсә дип сәер сораулар бирдең әле бүген? Авырмыйсыңдыр бит? Әллә күңелеңне ни дә булса газаплыймы? Әйт дөресен!

— Мин сау-сәламәт.

— Димәк, борчылыр урын юк?

— Юк кебек...

— Ни өчен «кебек?» Әйтеп бетер.

— Ярый ла, Марта Хөсәеновна, мине дөрес аңласагыз!..

Вәт иске авыздан яңа сүз! Ничәмә-ничә тапкыр бергә очып, төнге күк сәфәрләренең ачысын-төчесен бергә татып, бер-береңнең ни теләвен алдан ук сизенә торган ике җан кинәт кенә аңлашмас булдык та куйдык. Ягъни мин, экипаж командиры, аны аңламыйм. Җен ачуларым чыкты. Ләкин, кинәт дулап китүне килештермичә, эчтән тыну хәерлерәк булыр дидем.

Аста дөм караңгы диңгез. Биеклек үлчәгечкә күз салган идем — чәчләрем үрә торды. Нибары өч йөз метр! Ачу — акыл убыры дигәннәре хак икән ләбаса. Нәләт суккыры Верага үчегеп шулай түбәнгә тәгәрәгәнбез. Менә хәзер күтәрелеп бак инде! Көтмәгәндә аста прожектор кабынып китте. Нурлар бауда җил селкеткән тастымалдай арлы-бирле чайкалышып торалар да самолетны эләктереп алмак булалар. Бер-берсен куып безгә таба алтын төрткеләр оча. Әле алда, әле артта снарядлар ярыла. Бу — фашистларның яр буе сагы корабльләре. Тизрәк болыт астына!.. Без дошман утыннан шулай котылабыз да, буранда адашкан юлчы маяклы олы юлга чыккандай иркен сулап, очышны дәвам итәбез. Вера курсны бик тиз аныклады. Аның өлгерлеге, житезлеге ачуымны басты. Алай ук карачкы түгел лә бу кыз. Киң битенә күзлекле шлемы әнә ничек килешеп тора! Мин, кабинамдагы сферик көзгегә әледән-әле карап, штурманымның асыл сыйфатларын арттыра барам. Ак йөз салкын канлылык билгесе, диләр. Әйе, Вера бая үзен «чеметеп» алгач та дулап китмәде... Зәңгәр күзләр мәхәббәтне тыйнак кичерә, шашынмый, дип әйтәләр. Хак сүздер, ахры, бусы да. Сөйгән егете Александр Костенко үзенә бүләккә менә шушы самолетны китергәч тә кәперәймәде, ач күзләнмәде. Усал кайнанадан һич ким булмаган Себрова сүзләренә караганда, икәү генә калгач, Костенко кочаклый башлауга, кыз, ут капкандай, йөгереп бүлмәдән чыгып киткән. Рәхмәт инде үзенә, арзанаймый. Мәхәббәтнең кадерен белә. Егетләр бит алар үзе белән кырысрак булганны күбрәк ярата. Мисалга әнә минем ташбаш... Әгәр аңа ирек куйсаң, кулларына сукмасаң, күптән... Стартка рөхсәтсез чыгып, чит аэродромга кунаклар иде, шунда ияләшер иде. Ә хәзер аңардан хат өстенә хат килә, жылы сүзе килә, сөйләшергә генә үзе юк!.. Мин жаныкаемның соңгы хатында язган жырын искә төшерәм:

Агыйделгә төшә яздым,
Тотмадың беләгемнән.
Тамыр жәйгән гөлләр кебек,
Китмисең йөрәгемнән...

Шул чак фикерем яктырып китте: бәлки бу кызны егете ташлагандыр? Язган хатларына жавап юкка шулай кәжәләнәдер?

— Вера, ә, Вера! Теге сакалбаеңнан... (тьфү, нәләт, телдән киракмәгән сүз ычкынды!) ПАРМ [1]дагы Александрдан хат киләме үзеңә?

— Килә... Бүген генә алдым.

«Нәрсә яза?» дип сорарга килештермәдем. Сүзебез өзелде. Ни дип кыбырсый икән соң, алайса, бу кыз? Нинди кайгысы бар, нигә кашыкүзе җимерек?

— Ә әниеңнән?

— Әнидән дә бүген хат алдым...

— Анда ул-бу юкмы, тәртипме?

— Юк... Рәхмәт... Тәртип...

Гаҗәп! Борчылырлык, борын салындырырлык берни юк, ә үзе...

— Өч минуттан — цель, иптәш командир.— Вераның тавышы калтыранды, әйтерсең ул йөрәге һич риза булмаган хөкем карарын игълан итте. Кыз кичерешләренең тирәнлеген тулырак чагылдыргандай, аста, төпсез караңгыда, берьюлы дистәләрчә прожектор кабынды, зенит артиллериясе котырып ата башлады. Күктә утлы давыл бөтерелә, әле алда, әле артта дистәләрчә снарядлар ярыла. Самолет тетрәнеп-тетрәнеп куя... Снаряд кыйпылчыкларының берәрсе моторга эләксә?..

Унсигезенче квадратка үтеп булмады. Икенче әйләнешкә китәргә туры килде.

Вера үз кабинасында хәрәкәтсез утыра. Мин аңардан: «Штурман, әллә яраландыңмы?» — дип сорадым.

— Юк,— диде Вера.

— Нишлибез, шәһәр ягыннан әйләникме, диңгез өстеннәнме?

— Үзең кара инде, командир...

Алдарак, Аджимушкай тирәсендә булса кирәк, прожекторлар кабынды. Бу төбәктә җир астындагы таш базларына кереп яшеренгән совет кешеләренең фашистларга бирелмичә айлар буе тоташ сугышулары турында ишеткән идек без. Җир асты гарнизонына каршы көрәшергә китерелгән гаскәр урнашкан корылмалар хәзер һава һөҗүменнән саклану өчен файдаланыла булса кирәк. Әнә прожектор нурлары бездән артта очкан Наташа Меклин самолетын келәшчәгә алды. Түз, Наташа җаным, түз. Хәзер син үз кабинаңда тиен кебек бөтереләсеңдер. Маңгаеңа тир бәреп чыккандыр. Каһәр төшкән уттан исән-сау ычкынсаң иде, җаным! Без хәзер, дошман сине эзәрлекләгән арада, форсаттан файдаланачакбыз... Газны кинәт арттырып, кирәк чаклы биеклек алгач, моторны сүндердем. Планер кебек очып, түбәнәйгәннән-түбәнәя барабыз. Кайда соң унсигезенче квадрат? Шунда туып, шунда үскән Вера үз шәһәрендәге урамнарны танымый. Караңгы шул, аны гаепләп тә булмый. Ниһаять, диңгез яр буйларына килеп чыктык.

— Так держать,— диде штурман, һаман әле аска карый-карый.

Биеклек ике йөз илле метр. Тагын шулай азрак очсак, агачларга бәреләчәкбез... Хәзер зениткалар куркыныч түгел... Әгәр биредә эре калибрлы пулеметлар куелган булса һәм фашистлар без бомбага тота башлаганчы ук сизеп алсалар — эшебез хөрти.

— Унбиш градус уңга!— диде Вера.

— Ни пычагыма унбиш!— дип кычкырдым мин.— Менә ич инде унсигезенче квадрат!.. Ташла йөгеңне, ычкыныйк исән-сау чакта!

— Бу мин укыган мәктәп...— диде Вера калтыранган тавыш белән.

— Булса ни? Анда хәзер фашист!..

— Алар анда мәңге тормас... Һәм мәктәпне бомбага тотарга задание бирелмәде безгә, иптәш командир.

Соры таш бина шактый зур күренә. Әнә аның киң мәрмәр баскычлы парадный ишекләре... Шуннан ничаклы фашист кереп-чыгып йөри.

---

[1] ПАРМ — авиация ремонтлау буенча күчмә мастерской (передвижная авиаремонтная мастерская).

Фашистларның да ниндиләре әле! Әнә агачлар ышыгында җиңел автомашиналар күренә. Штаб бу, әлбәттә, штаб бу. Эх, бомбаларны түбәгә томырсаң! Түшәм ишелеп, тычкан балалары кебек тончыгып үләрләр иде... Без шушы бинаның уң ягындагы көчле ут ноктaларын юк итәргә тиеш. Ни өчен уң яктагыларны? Ни өчен сул яктагыларны түгел? Ни өчен бинаның үзен түгел? Аңламыйм. Ләкин боерык боерык инде ул. Кушылганны эшләми булмый.

Дулап типкән йөрәгем, тәнемдәге барлык күзәнәкләр аста шартлаулар көтә. Шуның өчен килдек, шуның өчен ничаклы тетрәткеч минутлар кичердек бит. Хәйләкәр аучы сыман, җаен да тапкан идек шикелле. Нишләп һаман шартлаулар күренми соң?..

Борчылып, нәрсәдер сизенеп, штурман кабинасына таба борылып карадым. Шул чак аста прожекторлар кабынды, бик яман атыш башланды.

— Ник йоклыйсың? Ташла!— дип кычкырдым мин Верага һәм моторны кабыздым. Нәкъ шул чакта штурман бомбаларны ташлады. Аста, күзләрне чагылдырып, ут чүмәләләре калыкты, янгын чыкты. Көчле һава дулкыны бәрелүдән чалышайган самолетны тигезләдем дә кайтыр якка бордым. Ләкин тизлек чамалы иде шул.

Аста әллә ничә җирдән аталар. Прожекторлар кабынды. Яр буе янәшәдә генә булганлыктан, андагы ныгытмалардан аткан ут аеруча куркыныч иде. Яңа гына туздырып ташланган шөпшә оясына туры килгән юлчылар хәленә калдык. Һәр якта «шөпшә» дә «шөпшә» генә...

Безнең бомбалар шартлавыннан чыккан янгынның һаман зурая баруын күреп, Верага:

— Озак төзәсәң дә туры тидердең. Молодец!— дидем.

Штурман эндәшмәде. Сферик көзгедә мин аның агарынган йөзен күреп калдым. Күзләре йомылган иде.

Мотор төчкерә-төчкерә эшли. Канатта, фюзеляжда, яссылыкларда тишекләр саны артканнан-арта. Үлем, шыр сөякле салкын куллары белән, күкрәкне кыса сыман.

Аста сумала төсле кара төн. Төн куенында диңгез. Ул безне, гипнозы бар елан кебек, үзенә тарта. Атышлар арттa калды. Ләкин бу әле котылдык дигән сүз түгел. Яшәү өчен көрәшнең минуты ел тоелачак өлеше алда әле. Мотор туктап, тәнгә бозлы салкын су сипкән шикелле булган чакларда авыр, очсыз-кырыйсыз тынлык башлана. Түбәнәйгән чакта канатларга кагылган талгын җил: «Бет-те-гез-з-з!» «Бәхилләшегез-з-з!»— дип пышылдый сыман. Биеклек үлчәгеч прибор эшләми. Безне йотачак мәрхәмәтсез дулкыннарга чаклы күпме ара — билгесез...

Моторга шприц белән бензин өрдерәм. Кабынса — яшибез, кабынмаса... Бу хакта уйлыйсы килми. Исән кеше төнлә зират яныннан тизрәк узарга ашыккан кебек, бөтен теләк: моторны кабызу. Ниһаять, аңа җан керә. Борынга бәрелгән әче төтен дөньядагы иң шәп, иң затлы ислемайларыңнан да хуш ислерәк хәзер. Моторның эшләү такты ешая, таныш гөрелте булып үсә. Мин, мөгаен, йолдыз кебек балкыймдыр. Идарә тоткасын җай гына үземә тартам. Самолет борыны өскә таба күтәрелә. Ур-ра! Яшибез! Ләкин куанычымны Верага әйтергә өлгермим, мотор, котны алып, ютәлле картлар сыман, яңадан йөткерә-төчкерә башлый. Шунда үз-үземә нәзер әйтәм: диңгездән исән-сау чыксак, әнкәйгә акча салам. Карчыкларны чәйгә чакырсын, сабыйларга прәннек алып ашатсын...

Шулай мең газаплар белән кайтып җиттек. Кайтып җиттек җитүен, әмма бу төнне минем чигә чәчләремә көмеш бөртекләр тибеп чыкты.

Оеп, урындыкка сеңеп, кабинада утырабыз. Гәүдә бастырыклап куйган кебек. Баш чатный, күз аллары әлҗе-мөлҗе килә.

Вера калтыраган кулын җилкәмә куйды да башын күтәрмичә генә:

— Марта Хөсәеновна, зинһар... рәхимле булыгыз... Мин тырыштым, бомбалар тиеш булмаган җиргә эләкмәсен өчен бөтен көчем белән тырыштым,— диде.

— Нинди «тиеш булмаган җир» ул тагы?— Мин штурманны аңламыйча борылып карадым.

— Деметра төрбәсе, үзебезнең өй һәм...— Менә шушы хатны укысагыз аңларсыз,— диде Белик һәм, күкрәк кесәсеннән алып, миңа бер хат сузды.

Деметра төрбәсе турында Верадан ишеткән сүзләр бөтенләй хәтердән чыккангадыр, ахры, мин, корт чаккандай, сискәнеп:

— Үзегезнең өй? Без аңа бомба ташламаганбыздыр ич?— дип сорадым.

— Юк. Ләкин ут... бу кем өе дип сорап тормас шул.

— Да-а... Вәт ситуация,— дидем мин, безнең бомбалар шартлаудан чыккан янгынны искә төшереп.— Вера, ә Вера, бәлки әле өйгә зыян тимәс?

Техник булып эшләүче кызлар йөгереп килеп җитте.

Вера кабинадан чыгуга, башы әйләнеп егыла язды — ул яраланган булган икән. Аны санчастька алып киттеләр.

Бершанскаяга заданиенең үтәлүен, штурманның яралануын һәм самолетның нык зарарлануын белдердем дә Вера биргән хатны уку өчен КПга юнәлдем.

Хат Вераның Куйбышев шәһәренә эвакуациягә җибәрелгән әнисеннән килгән иде. Ул анда безнең гаскәрләрнең озакламыйча туган Керчьлары өчен сугыш башлаячакларына ышанып торуын, үзләренең исә явыз дошманны изге җирләребездән тизрәк куып чыгаруда фронтка булышуда армый-талмый эшләүләрен белдергән. «Кызым, Вера,— дигән ул,— зинһар, берүк сак була күр, үз-үзеңне сакла, янә дә өебезне дә сакла. Монда Саша Костенко анасының станокка кысылып гарипләнгән апасы Дуся да синнән шуны үтенәләр. Ирле-хатынлы Костенколар, аларның бала-чагасы һәммәсе Керчьта калды бит, син инде анда төнлә ялгышып үз өйләребез өстенә бомба ташлый күрмә. Иптәш кызларыңа да әйтеп куй... Кайтып сыеныр урыныбыз юкка чыкмасын. Бу сугышның җимерекләрен төзәтү җиңелдән булмас, безгә чират та тимәс, кызым...»

Шәмәхә кара белән язылган хатның икенче битендә Костенко Варясының сугыш башланыр алдыннан гына бер очучыга кияүгә чыгуы, иреннән хат килү тукталгач, тегенең бик ямансылавы һәм, ниһаять, яралылар ташый торган поездга язылып фронтка китүе әйтелгән иде.

Мин бу хатта шаккатырлык бернәрсә дә күрмәдем, әлбәттә. Хәзер тылда кем көн-төн эшләми дә кем язылып фронтка китми?!

Ана — ана каз дигәндәй, хуҗа хатынның үз оясы өчен кайгыртуы да табигый хәл. Ләкин нишлисең, кушсалар, үз өеңне дә бомбага тотасың шул.

## Унсигезенче квадраттаниләр бар?

Иртәнге аштан соң Себрова белән мин Армавирга китәргә әмер алдык. Без анда самолетлар илтергә тиеш. Ниһаять, чират җитте. Ремонтка үзебез дә катнашачакбыз.

Стартка рөхсәт көтеп торганда санитар самолеты килеп төште. Вераны алырга килгән. Әнә «Ашыгыч ярдәм» машинасыннан аны алып чыктылар. Кыз дымнан мәхрүм ителгән гөләп чәчкәседәй сулган иде.

Күзләре тагын да зурайган сыман. Миңа бик моңаеп карагач, түзмәдем, янына бардым. Кулын кысып, тизрәк терелеп кайтуын теләдем.

Вера полк штурманы Женя Рудневаны үз янына чакырды, аның муеныннан кочаклап, кайнар маңгаен битенә тидерде дә:

— Женечка, онытма: Коммунальная... Квадрат шул ук,— дип пышылдады.

Ярый әле, еламыйлар... Әһә, киттеләр. Яратмыйм мин озаклап саубуллашуны. Кул селкедең — китте. Әйдә, механик, бор инде винтны!.. Юк, һаман сузалар...

Ләйлә миңа Александр Костенкога адресланган хатны сузып:

— Сөйгән кызыннан кош теледәй хат һәм истәлеккә кульяулык килмәсә, егет вәсвәсәгә калмагае дип яздырып алдым,— диде.— Шушы «кош теле»нең эшегезне дә тизләтүе мөмкин. Верочканы госпитальгә озату турында берни дә әйтмә! Аннары елмаеп өстәп куйды:— Я тагын сакалын кабат кырмый йөри башлар...

Себрова чәнчеми каламы:

— Кәшеләрне кавыштырырга булышлык күрсәтү — яңа уставта языла, ди. Андыйларга полководецлар ордены бирелә, ди...

Ләйләнең бүген кәефе әйбәт иде, әрепләшеп тормады. Төрткеле сүзләргә илтифат итмичә, эчкерсез елмаеп:

— Тукта әле, менә үзең яратып кара, икенче төрле сайрарсың,— диде.

— Сайрамам! Без төче камырдан әвәләгән затлы кенәриләр нәселеннән түгел. Бөркет без, бөркет!

Ләйлә, капонирларга таба бара торган җиреннән борылып:

— Хәтерем ялгышмаса, Себрова, бөркетләрнең дә төрлесе бар,— диде.— Аларның беришләре, әгәр үз парын җуйса, хәсрәтеннән күккә күтәрелә-күтәрелә дә, шуннан уктай түбәнгә ташланып, үз-үзен һәлак итә, ди. Үзеңне бөркет дип санагач, бәлки сиңа да шундый мәхәббәт теләргәдер, лейтенант, ә?

— Авызыңнан җил алсын!

Армавирда төзәттерәсе манометрларны китерделәр. Ни күрим: комсомол секретаребыз Хорошилова, тырыш кырмыскадай, үзеннән зур капчык күтәреп килә.

— Монысы нәрсә тагын?!

— Бүләкләр, — диде ул, еш-еш сулап.

— Бирнә, димәк... Шәп, бик шәп, «биргән — бигә яраган...» Бу тикле бүләк алып баргач, Ирочка, сиңа да кияү табып кайтабыз инде...

— Хаҗәте юк! — диде Себрова.— Вакыты андый түгел.

Очтык. Армавирга шул көнне үк бернинди бәла-казасыз барып життек. Механиклар бригадиры Александр Костенко — хәзер инде орденлы лейтенант — безне ачык чырай белән каршылады. Себрованың гаҗәпләнүенә каршы, Саша шоп-шома битле оялчан һәм чибәр егет икән ләбаса! (Ул, үз сүзенә турылыклы булып, сакалын кырган иде.) Янындагы иптәшләре дә, сайлап җыйган хан егетләре кебек, берсеннән-берсе итәгатьле һәм матур. Ира миңа караганда яшьрәк, матуррак булганлыктан, хөрмәтнең зурысы аңа күрсәтелде. Мин командир бит, документларны рәтләп йөрим. Ә Ира егетләр арасында — мастерскойда. Әйткәнемчә, урыны түрдә, ул сулама дисә, егетләр тыннарын да алмыйлар. Арадан берсе, чегәннекедәй кара бөдрә чәчлесе, кыздан һич күзен алмый... Карап-карап торам да, үзенә игътибар итү ошый башлады бит әле безнең кырыс Ирага. Бүтән вакытта шаяртып тел тегермәне тарттырган өчен иптәшләрен кызган табага бастырган кызыбыз монда йөз сиксән градуска борылды да куйды! Йөрешләре үзгәрде, көлүләре үзгәрде кызыйның. Парикмахерскаяга барып чәчләрен бөдрәләтергә, кашларын каралтырга да вакыт тапкан, иртән үк торып киемнәрен үтүкләп

куйган. Очып кына йөри. Мәхәббәт кешене чыннан да канатлы итә, ахрысы!

Кичен безнең хөрмәткә мәҗлес җыйдылар. Монда мин полк комсомол оешмасы кызлардан җыеп җибәргән чигүле сөлгеләрне, мендәр тышларын, кулъяулыкларны, кыскасы — бүләккә каршы бүләгебезне егетләргә тапшырдым. Һәммәсенә өлеш чыкты, һәммәсе бик канәгать булды. Тостлар әйтелде. Аннары туйганчы танцевать иттек. Күкрәгендә ике орден балкыган Ира кичәнең шаһинәсе иде. Ул хәтта теге чакта пилмәнгә тоз, борыч, күмер салу, сакалы буялсын өчен бал тәпәненә чүмечтәй зур кашык кую кебек шуклыгы өчен Костенкодан гафу үтенергә дә җай тапты. Киң күңелле Александр, әлбәттә, көлә-көлә гафу итте һәм, үз чиратында, бал ашагач әйткән сүзләрен исендә тотуын, ягъни Ира самолетын иртәгә үк төзәтеп бирәчәген белдерде. Әйбәт, бик урынлы килеп чыкты бал вакыйгасын хәтерләү.

Коридорда мин Александрга Вераның сәлам хатын һәм әманәтен тапшырдым. Кызлар гына түгел, егетләр дә вакыт-вакыт ифрат нечкәрәләр, дулкынланалар икән ләбаса! Дөрес, Сашабызның күзләренә мөлдерәп яшь тулмады, ләкин колакларына чаклы кызарды ул. Егетнең керсез тойгылары ташуына сәбәпче булган хатны алданрак тапшыру өчен мөмкинлек чыкмавы ярады тагын: иркенләп сөйләштек.

Юк, хәзер бездә егетләр мәхәббәткә җиңел карыйлар, бу изге тойгының пакьлеген, бөеклеген аңлап-бәяләп җиткермиләр, дип арттырып җибәргәлибез икән без. Күзләрендә нур кабынып, әнә ничек илаһи ләззәт кочагында калды ул. Кеше мондый сәгатьләрдә әллә нинди зур эшләр башкарырга сәләтледер.

Мин ышанам, бик нык ышанам: сугыш бетеп исән-сау калсалар, болар, һичшиксез, кавышачак һәм күгәрченнәрдәй гөлдерәшеп яшәячәк. Чиләгенә күрә капкачы дигәндәй, Вера да егеткә ифрат тиң килгән: тыйнак, сабыр, акыллы, уңган. Шуңа күрәдер инде, Александр, күрше кызы димәгән (гадәттә, күп егетләр күрше кызын санга сукмый торган була), яшьли үзенә яр иткән. Хәер, чиста суны еракка түкмиләр, дип борынгылар тикмәгә генә әйтмәгәндер!..

Тик, кызганычка каршы, Вера белән Александрга кавышу насыйп булмады шул...

— Ул авырыймы әллә? — дип сорады Костенко, хатка күз сирпеп алуга.

Мин Ләйлә кисәтеп әйткән сүзләрне кабатладым. Саша эндәшмәде. Төсе тагын да җитдиләнде, битләренә тимгел-тимгел тап чыкты, күзләрендә моң чагылды.

— Зинһар, әйтегез... Ни булды?

— Юк-юк, борчылмагыз...

— Мин аңа бүген үк хат язарга тиеш, — диде Александр. — Мөмкин дип тапсагыз, зинһар, минем бүлмәгә керик. Сез альбом карый торырсыз.

Саша тумбочка өстендәге бәләкәй рамда Вераның елмаеп торган рәсеменә күз төшереп алды да, моң-зарыма колак салсаңчы дигәндәй, иелеп хат язарга кереште.

Мин альбом актарам. Вераның фоторәсемнәре шактый монда. Менә ул Эльтигенда пионер лагерендә быргычы, менә ул диңгездә коена, менә мәктәптә комсомол билеты ала, чыгарылыш кичәсендә, иптәшләре белән, Мәскәүдә Кремль фонында суратка төшкән һәм, ниһаять, очучы-штурман...

Сашаның әти-әнисе, туганнарының фоторәсемнәре дә шактый иде альбомда.

— Саша, гафу ит, бүлдерәм: Куйбышевта кемнәрегез бар сезнең? — дидем мин, Вера миңа укыткан хатны искә төшереп.

— Әнинең сеңелесе Дуся апа һәм бертуган апам Варя яши анда.

Эвакуациядә. Әти-әни һәм балалар Керчьта калды. Менә алар... Ә менә монысы — Варя ире белән. Җизни дә очучы безнең...

— Апагыз бик тә чибәр икән. (Мин сөрмә тарткан күзле, алтын алкалы, зур гәрәбә кашлы затлы йөзеген ялтыратып торган яшь ханымга хатын-кызларча көнләшеп карадым.)

— Артистка булырга хыялланган иде. Сугыш комачаулады, — диде Саша.

— Сезнекеләр Коммунальный урамындагы тугызынчы йортта торалармы?

— Юк, икенчедә. Тугызынчы йорт Вераларныкы.

Мәсьәлә ачык иде. Миңа хәзер Сашаның сүзләре бик ерактан ишетеләләр кебек тоелды. Вераның полк штурманы Женя Руднева белән саубуллашуы күз алдыма килде. Димәк, унсигезенче квадратны бомбага тотарга кабат задание бирелгән тәкъдирдә, Рудневадан Вера шушы ике йортны саклап калуны үтенгән. Ә мин тагын, ахмак, зур фидакарьлеге өчен аны хөкүмәт бүләгенә тәкъдим итүне кузгатып йөрим. Чын патриот шундый була, Верадан үрнәк алыгыз дип, авыз суымны корытам.

Билгеле инде, кәефнең рәте-чираты китте. Аның каравы, Себрова күкнең җиденче катында иде. Егете Александр Хоменко (хәзер шулай егете дип әйтергә нигез бар дип саныйм) ашыгыч ремонтлаган самолетны өченче көн дигәндә ачык зәңгәр төскә буяп та куйгач, Ира аны кочаклап үбеп алырга да читенсенмәде. Кызның бөтенләй икенче төрле җемелди башлаган күзләрендә, тиз-тиз йөрешендә, күгәрчен күк гөрләвендә егете белән чиксез горурлану, бәхет билгеләре күрдем мин.

Нигә шулай икән бу тормыш: берәүләрне кинәт сөендерә, икенчеләрне шиккә, борчуга сала?

## Бер ярым Иван

Ул полкка без Армавирда чакта килгән иде.

Самолетларны үз урыннарына куеп, штабка күренеп чыктык та өйгә кайттык.

Кызлар, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, соңгы яңалыклар белән таныштырырга кереште:

— Берәр айлык хезмәт хакына заемга язылдык!

— Безнең гаскәрләр Днепрны кичкән!..

— Эльтигенга десант төшерелде...

— Полкка ир женесеннән булган радист кызтәкә килде...

Мин алыптай зур гәүдәле, ирләрнекедәй калын тавышлы, төрле мәзәк уйлап чыгарырга бик һәвәс украин кызы Галя Пилипенконың бу сүзләреннән шаркылдап көлеп:

— Син, Галя, шулай чамалап түгел, чаналап алдашасың инде,— дидем.

Пилипенко, иренен бүлтәйтеп, гөбедән чыккандай калын тавыш белән:

— Грамм да арттырмыйм! — диде.

— Ничек инде ул алай? Үзе ир женесеннән, үзе кыз?..

— Командирыбыз кыз дигәч...

Һәммәсе тәгәри-тәгәри көлә. Хивазга эндәшәм, чыннан да радист килдеме, дим. Ул да көлә, үзе баш кага. Ниһаять, шул билгеле булды: өченче көн кич, сезгә радист җибәрәбез дип, армия штабыннан шалтыратканнар. Исеме Пуршанмы, Раушанмы — телефоннан начар ишетелгән: КПда Ләйлә дә булган. «Раушан — кыз исеме ул, Евдокия Давыдовна, җибәрсеннәр, ризалык бирегез», — дигән.

Иртән иртүк, юл уңаә самолет белән килеп төшә ап-ак керфекле, сап-сары чәчле, кып-кызыл битле бер ярым Иван... Кем икәнлеген, ни өчен килүен белдерә, үзенә аерым бүлмә сорый. Миңа бернинди комачау итүче булмасын, дип әйтә ди. Ул төнлә дә, көндез дә эшләргә тиеш, имеш. «Түзәрсеңме? Безнең кызлар бик зәһәр бит?» — диган Бершанская. «Түзәрмен», — дигән бер ярым Иван, иреннәрен ялмаштырып.

Ошамый полк командирына радистның кыланышы. Бәладән башаяк дип, штабка шалтырата. Аннан: «Сез радист сорадыгыз, беренче класслы радист җибәрелде. Тиешенчә файдаланыгыз!» — дигәннәр дә вәссәлам.

Радист күрә: монда аңа көн дә бәйрәм булачак. Ашханә — каршыда гына, түләүсез тамак чылатырга зәмзәм суы өзелмәгән (очучы кызлар «нарком йөз грамм»ын эчмиләр) тәэминат складына бары тик өч адымда, ә аның янәшәсендә генә берсеннән-берсе чибәр кызлар белә мыжлап торган тулай торак... Шундый рәхәткә исәп тотып, күзләрен май ашаган мәче кебек елтыратып, сызгырына-сызгырына, көязләнеп йөри Иваның. Куллар — кесәдә, авызда — «Казбек».Офицерлар күренгәндә генә төз баса. Кемнең кайда эшләвен бик тиз чамалап, әле берәүгә очрашу билгели, әле икенчесенә. Җае чыгу белән кызларның бил, күкрәк тирәләренә үрелергә дә тайчанмый, мәче сыерчык тоткандагыдай чырылдата тегеләрне. Дөресен әйткәндә, кайберәүләргә ошый бу. Ихахай да михахай киләләр. Кызык! Ләкин күбесенең талканы да коры. Сдача бирергә иренмиләр. Безнең кызлар андый алабай Дон Жуаннарны төпсез чуманга утыртырга дигәндә — хәйлә капчыклары инде алар! Иң әүвәл санинструкторлар, тиф-мазар китермәгәең безгә дип, моны «кияү мунчасына» озаталар. Киреләнә теге. Ләкин бармый кара. Устав — устав инде ул. Сабын-мунчаласын, сөлгесен култык астына кыстырып килә бу поход мунчасына. Персоналга каш сикертеп, мускуллары белән мактана-мактана, душка кереп китә, аркасын юарга чакыра. «Хәзер арканны мунчалалап ышкыйбыз!» диләр кызлар һәм моның эчке киемнәрен, шиген бетерү өчен, кыздырырга тапшыралар. Гөнаһ шомлыгына, бер ваемсызы учакка «ялгыш» күбрәк яккан икән — кияү егетенең эчке киемнәреннән, чалбар, гимнастеркасыннан, экияттәгечә иттереп әйтсәк, тояк та сөяк кенә кала. Моны хәзергә үзе белми — пошкырына-пошкырына юына әле бу. Менә бермәл душның краннары кинәт «бозыла»: әле өтеп ала торган кайнар су килә, әле — Сухуми янындагы Өметкүл суыдай салкыны. Тешләре тешкә бәрелеп, көянтәдәй бөгелеп чыга бу. Ни баксын — киемнәре янган! Күзләре акая егетебезнең. Көндез старшина кызга үрелгән әрсез кулы хәзер сөлге белән тән томалап калтырый...

Старшина бер кочак яңа киемнәр күтәреп керә. Егетебездән исемлегенә имза салдыра. Янәсе, тиешен ала бир, җәл түгел...

Киенә башлагач, егетебез яңа бәлага тап булуын күрә: аңа илле алтынчы үлчәүле комбинация, җиденче үлчәүле бюстгалтер һәм хатын-кызга кирәге чыга торган бүтән нәрсәләр китергәннәр!

Печәнлектә кысылган азгын кәҗә сыман, тәрәзәдән башын тыгып кычкыра бу.

Ә старшина кыз күзен дә йоммый:

— Полкның личный составы исемлегенә кергәнсез икән, рәхим итеп киегез, иптәш радист. Бездә бүтәне юк! — ди.

Егетебез ярыйсы ук басынкыланып, шинеленә төренеп, якасын күтәреп кайтып китә. Ярый, алмашка яңа киемнәре булган. Сер бирмәгән заттай кылана. Борынына чүмеч эләрлек. Тагын азына, тагын кызларны чырылдата. Бершанская чираттан тыш наряд чәпи моңа.

Безнең кызлар сүзләрен сүз итми каламыни?! Аларны Пилипенко җитәкли. Бар шуклык шуннан башлана.

Радистыбызның эчәргә яратуын белеп алганнар: складка өч рәт тә, дүрт тә килә икән. Килгән саен — йөз грамм. Җәлмени, барыбер эчүче

юк. Пилипенконы әйтәм, санчастьтан ничек кулга төшергәндер — аракыга эч йомшарта торган дару салган. Аннары, аның коткысы белән, кызлар кайбер ишекләргә «Ж» хәрефен ак буяу белән зур иттереп язып куйганнар. Нишлисең, полкта хәзер ике җенес кешеләре булгач, язмый чара юк.

Ә мут егетебез, кая гына барып сугылса да, әлеге зур хәрефләрне күрә. Эчен тотып йөри-йөри икән дә, ахыр чиктә, дингез буендагы таллар арасына чаба...

Алга китеп булса да әйтим, радистыбыз озак түзмәде, шылды. Моның өчен Пилипенко күп тырышты. Ни хикмәттер, беренче көннән үк ошатмадык без ул сары шайтанны. Тәмам тешкә тиде, тынычлыгыбызны алды, җен ачуларын кузгатты. Шулай кирәк тә — хатын-кыз хакимлек иткән җиргә килмәсен. Килгәнсең икән инде, ыштыр бит булма, әдәпле кылан. Нервыларда уйнама. Алар корычтан түгел. Иң мөһиме: без бит монда гыйшык-мыйшык уйнарга килмәгән, сугышырга килгән!

«Гыйшык-мыйшык уйнау» Сeброва сүзләре булганлыктан, кызлар ана күз төбиләр, уйланылган чараларны гамәлгә ашыруда аның әүвәлгечә башлап җиң сызганып көтәләр. Кем, кем, ә Сeброва кыстата торганнардан түгел. Бүген исә ул дәшми, кызарып, башын аска иеп тора. Нишләмәк кирәк, иң кырыс хатын-кызның да күңел тәрәзәсе чак кына ябык була, бикләнмәгән була, ае калыккач яки таңы аткач, сандугачлар сайрап торган бермәлне килеп чиртсеннәр генә, ул тәрәзә сизелмәстән ачылып китә, мин сиңа әйтим, һәм гөлләр кырыйгарак күчә — яшьлек, ак кулларын сузып, танышу көтә, кавышу көтә...

Кемгә ничек насыйп бит: сугышта да ай калка, сугышта да таң ата!

Әрсез җан — радистыбызны әйтәм — Сeброва тирәсендә бөтерелә башлады. «Кешесенә туры килде. Ирина әбисенә сәлам әйттерер моның!» диләр. Тик, ни күрик, кумады кызыбыз бер ярым Иванны үз яныннан. Әнә аэродромда янәшә йөриләр... Хиваз егетнең кызга ниндидер карточкалар күрсәтүен абайлап алган, сорашырга өлгермәдек — Иринаны разведкага җибәрделәр. Экипаж дингез өстендә фашист истребителенә туры килгән. Радиодан кыз белән сөйләшүче егетебезнең күзләре шар булып, кәгазь өстендәге карандашы бии башлаган хәтта.

— Фашист атакалый! — дигән Сeброва.

Ә радист үз бүлмәсеннән: «Тизрәк кирегә борылыгыз!» — ди икән.

Кинәт: «Та-та-та-та! — дип, пулемет такылдавы ишетелә һәм аппарат тына. Аппарат дәшми.

— Беттеләр!.. — Шулай дип радист штабка шалтырата.

Шомлы хәбәр минуты белән таралып өлгерде. Ышанасы килми. Ничек инде безнең батыр йөрәкле Иринушкабыз шулай һәлак булсын ди?!

Ләйлә эндәшми. Сәгатенә карап, нәрсәдер көтә. Бер заман аның йөзе яктырып китте:

— Ишетәсезме? Сeброва кайта! — диде ул.

Дингез шаулавы эченнән аермачык булып таныш гөрелте ишетелде.

Күп тә үтмәде, Иринабыз, берни булмагандай сызгырына-сызгырына, кайтып керде. Аңа чишенергә булышабыз, күктәге очрашу турында сораштырабыз. Ул кыскача гына сөйләп бирде һәм: «Минә радистның эшлекле киңәшен тотып борылдык та кайттык!» — дип, елмаеп юынырга чыгып китте.

Бәхет дигәнең шушыдыр инде ул: Энгельста чакта буранда адашып ике экипаж һәлак булды, бу шушы төндә һәлакәткә очрап исән калды. Фронтка килгәч ничә тапкыр җәһәннәм утына эләгеп, самолеты янып, тишелеп кайтты. Бүген менә, самолетны пикега ташлап, истребительдән ычкынган.

Ирина очарлык һава «алып» кайтмаган иде. Дивизиядән кучмә кино җибәргәннәр икән, икенче тапкыр «Два бойца»ны карадык.
Бер ярым Иван, иң алдан килеп, Иринага урын алып куйган иде.
Үлемне алдап кайткан кызыбызның бүген егет белән янәшә утырырга хакы бардыр дип, аларны күрмәмешкә салыштык.



## Үзебезнең егетләргә күчтәнәч

Ничә көн инде менә оча алганыбыз юк. Җил котырынуын дәвам итә, кар катыш яңгыр ява. Болытларны, Ләйлә әйтмешли, үрелеп тотарга мөмкин.

Шул ук урында яшәп ятабыз. Диңгез дуамал ачулы карт кебек: туктаусыз үкерә, ярсый...

Политукулар, җыелышлар булып үтте. Әчпошыргыч НИАС картның әңгәмәләрен тыңлап, зачетлар тапшырдык... НИАС картны беләсезме? Сез тагын әллә ни уйлый күрмәгез. Газетадан килгән бер корреспондент та, безнең сөйләүләргә карап, НИАС картны тере кеше дип уйлаган иде. Чынлыкта бик гади — семинар-наставление по инженерной авиаслужбе[1] дигән нәрсә ул.

Без солдатлар бит. Ә солдат тик ятарга тиеш түгел, тик ятса күгәрә ул дип, сафта йөрергә өйрәнәбез, автомат, пулемет кебек коралларны сүтеп җыябыз. Штурманнарны очучы булырга, корал ташучыларны штурманлыкка хәзерлибез. Тәҗрибәле һәр очучының үз өйрәнчеге бар. Кайберәүләрнең хәтта берәү генә дә түгел. Ләйлә, мәсәлән, ике кызның остазы. Аларның берсе — Валя Лучинкина. Тал чыбыктай зифа буйлы корал ташучы ул чибәр кыз очучы булачак. Озакламыйча Лучинкинаны аттестацион комиссиягә кертергә мөмкин булыр дип исәплибез.

Строевой хәзерлек белән шөгыльләнү үзәккәйләребезгә үтә дип әйткән идем инде. Начальствоның күңеле йомшамасмы дип, җыр чыгарып, шул җыр язылган кәгазьне, күзгә чалынсын өчен, ашханә ишегенә ябыштырып кую кебек шаянлыкка кадәр барып җитте безнең мут халык. Иртәнге «дога» дип атый идек без аны. Сүзләре болай:

Выведи, господи, из ада в рай,
Пошли, господи, бомбить передний край.
Дай нам вместо строевой
Цели на передовой.
Не дай, господи, в наряд идти,
Наставь нас на праведные пути,
Дай нам, бог, боевую задачу
И лунную ночь в придачу.
Аминь!...

Бу дога ходай тәгаләгә атап укылса да, дин белән бер нинди уртаклыгыбыз юклыгын аңлагансыздыр инде. Кызлар булган җирдә уенкөлке, мәзәк дигәнең чишмәдәй ташып тора бит ул.

Билгеле, тәүлекнең егерме дүрт сәгатендә синең нәрсә эшләргә тиешлегең минутына тикле исәпләп язып куелса да, моңаеп, ямансулап алган чаклар да була. Көткән кешеңнән хат озак килмәсә, чәчкә дымга сусаган кебек, боегып-шиңеп каласың.

Хат юк... Нигә юк?.. Билгесезлек йөрәкне талый, сулкылдата, елата.

Кайберәүләр үзенең сагышын җыр белән баса, төрле мәзәкләр куертырга һәвәсләнеп китә — мондыйлар кабыкларына бикләнәләр, алар белән эш итүе рәхәт. Ә менә икенче бер төр кешеләрне сагыш күгәртә, мүкләндерә. Андыйларның чырае һаман караңгы була, аз сөйлиләр, аз көләләр, тора-бара тәмәкесен дә тарта, аракысын да эчә башлыйлар.

[1] Инженер авиахезмәте буенча семинар-өйрәтү.

Алдарак полк «багучысы» турында сөйләгән идем. Соңгы вакытта шуның абруы күтәрелеп китте бит, әй. Себровага, Рудневага, Ләйләгә һәм тагын кайбер кызларга ачкан карталары үткәнне дә, киләчәкне дә дөрес әйтеп бирделәр. Ә бүген менә «багучыбыз» кызларны кабат шаккатырды. Ләйләгә багышлап, карталарын таратып салды да:

— Синең йөрәгеңә, чибәркәем, ике король хуҗа булмакчы — крестовой һәм пики. Син аларның кайсына ризалык бирергә дә аптырыйсың. Крестовый король күңелеңә якынрак. Ләкин аңардан әүвәлгечә үк берниндн хат-хәбәр килми. Ул, үзенең исәнлеген белдереп, сәер бер бүләк җибәргән. Шуңа таянып, син аны хәзер эзлисең, ләкин таба алмыйсың. Пики короле көчлерәк һәм тайрәтлерәк. Бүген-иртәгә ул сиңа тәкъдим ясап хәбәр җибәрә, зар-интизар булуын әйтә, үз биләмәләренә алып китү өчен килеп җитәчәген белдерә!.. — диде.

Без көлештек, әлбәттә.

Ә кичкә таба... йөзе агарынган Ләйлә мине дингез буена барырга чакырды.

— Ни булды? Әллә кайгылы хат алдыңмы? — дидем мин.

— Хат алдым алуын... Әмма кайгылы хат түгел...

— Соң, хода бәндәсе, кайгылы хат булмавы өчен кайгырасыңмы әллә: төсең качкан.

— Сәгать биш тулгач килегез әле, шунда сөйләшербез,— диде. Ләйлә һаман борчылган кыяфәттә.

Аэродром кырыенда диңгез үкерә. Тау-тау дулкыннар, агач ботаклары белән томалап куелган самолетлар янына җитә язып, бер селтәнәләр дә, авыр ыңгырашып, кирегә тәгәриләр. Нининдер шом, хәтәрлек бар бу күренештә. Бәлки шуңа күрәдер, техниклар бәла-каза булмагае дип, самолетлар тирәсендә кайнаша. Ләйлә дә шунда. Ул, мине күргәч, тиз-тиз атлап яныма килде һәм оялып, сүзсез калды.

Мин боргаланып торырга яратмыйм.

— Я, сайра, ни кайгың бар? — дидем.

Ләйлә шинель кесәсеннән дүрткә бөкләнгән шома ак кәгазь алып миңа сузды.

Әхмәттән килгән бу хатта түбәндәге сүзләр язылган иде:

«Гүзәлләр гүзәле, төн кызы, күк кызы Ләйлә!

Давыл сындырган яшь каен янында, салават күперенең житмеш җиде төсе белән, хәнҗәр йөзен үбеп әйткән нәзерләремне үтәр көннәр якынлаша. Шуңа күрә, җаен табып, күктән җиргә төшсәңче, теләгемне хуп күреп эндәшсәңче, назлы гөлчәчәгем! 14 ноябрьда безнең гаскәрләр Керчь кырыендагы Хаҗи Мөшкәй һәм Колонка поселокларын азат иткәннәр. Күп газаплар кичергән туган җирем — Кырымга ишек ачу бит инде бу! Димәк, озакламый гөлле бишегем Алупканың да кара чыбылдыгы йолкып алыныр, Тамань ягыннан күтәрелеп килгән кояш нурлары мәгърур Ай-Петри кыяларында чагылып, «Карлыгач оям»ны да, Бакчасарай манараларын да, әлегә чаклы мул йөзем биргән, тик хәзер кысыр яткан гаҗәеп үзәннәрне дә җылытыр. Ул үзәннәр хәзергә тирән сагышка талган, битеннән челтәрле пәрдәсен ачарга теләмәгән, ярәшелгән сылу кыз сыман, кояш чыгуын көтә. Күксел томаннарга төренгән тау итәкләре, дошман кылган явызлыкка нәләт әйтеп, ярдәм кулы сузганны өмет итеп ята шикелле... Озакламый без ул тирәләргә әйләнеп кайтырбыз. Анда бәлки минем туган саклямны да, бабаларымның кабер ташларын да, җирдә эзләре калмасын, тамырлары корысын дип, шартлатып юк иткәннәрдер инде. Ләкин без барыбер кайтырбыз. Күпне күргән, күп кан коюларга шаһит мәһабәт таулар каршылар безне. Зарема кебек сагаеп аяк басмассың, ә арысланга тиң егетләрдән калышмый, дошман яулары өстенә көн-төн ут яудырган кыю лачындай яшь килен булып төшәрсең син ул газиз җирләргә! Сакля урынына без

яңа өй салырбыз. Нигезе дә, стеналары да мәңге ишелмәслек булыр аның!

Энгельста әйткәнемчә, вәгъдә — иман.

Эшләрең уң булсын. Хуш, күңелем хәзинәсе, сүнмәс йолдызым! Кабергәчә синең тән һәм җан сакчың — Әхмәт-Мәҗнүнең».

— Вәт ситуация, Ләйлә...

— Әкәмәт инде. Нәрсәдер эшләми чара юк.

Мин, самолеты янып төшеп, өч тәүлек буе дошман тылында йөреп кайткач Әхмәттән Ләйләгә килгән хатны да укыган идем. Сүзендә торды егетебез: арысланнарча сугышты, үзенә Герой исеме бирделәр. Сөйгәне алдында да бурычлы булып калмады: һава сугышларының берсендә үзе кысрыклап төшергән өр-яңа «Мессершмитт»ны бүләк итеп китергән иде. Ләйлә алмады гына. Хәзер менә озакламый туй итәрбез дип ишарәли. «Бу Азамат сине тәки сагалый бит, Ләйлә, — дидем мин.— Эльтигындагы гармунчы матростан да өмет өзмисең үзең...»

Ләйлә, соңгы сүзләремне ишетмәгәнгә салышып, акрын гына атлый бирде. Аяк астындагы чуер ташлар «караштыр-караштыр» дигәндәй аны кисәтәләр кебек иде. Ләйләнең чырае һаман ак, җете кара күзләрендә талчыгу чагыла. Ләкин алсу иреннәре кысыла төшкән, башын шаһиннәрчә горур тота.

— Ул көнгә — ун көн әле, дигәндәй, вакыты җиткәч, күз күрер, Мәгубә апа. Без солдат кешеләр. Кырымны азат итү белән генә сугыш бетми,— диде Ләйлә, салкын кан белән фикер йөртеп.

— Кырым җирләренә килен булып төшәргә туры килмәс диюеңме инде бу?

— Шулайрак...

— Аңлашыла: Эльтигындагы дисантчылар арасында гармунчы матросның табылуы ихтимал. Һәм Әхмәткә — крышка. Әйеме?

Ләйләнең керфекләре тетрәнеп куйдылар. Арттан эткән җил сәбәпче булдымы — кыз, чайкалып, беләгемә тотынды.

— Белмим...— диде ул акрын гына. Ләкин аны күрмичә... араны өзмичә мөмкин түгел. Ихтимал, ул хәзер, бәлки, бөтенләй икенче кешедер. Мин шашып сөйгән егет хыялымда гына калган булса... Мин я шуңа ышанырга тиеш, я һәлак булуы турында хәбәр алырга тиеш. Шунсыз...— Ләйлә, үз-үземне нишләтим соң: табигатем шундый дигәндәй, моңсу төстә башын чайкады.

— Димәк, шунсыз Әхмәткә кәләш куенына посадка булмаячак? Хәер, мин үзем дә башкача булдыра алмас идем, Ләйлә. Нәрсә шундый инде безнең: яратсак — мәңгегә... — Без, үз уйларыбызга күмелеп, аэродромга таба атлый бирәбез. Аяк астындагы чуер ташлар, дулкыннар шавы тынган арада элеккегедән дә үзсүзләнебрәк «караштырулары» кабатлап, нәрсәдер искәртәләр сыман. Елыйсыларны китереп, акчарлаклар моңая. Китәсе иде хәзер шул акчарлак кебек еракка-еракка... Су белән күк тоташкан офык артыннан ишетелгән сугыш гөрелтеләре, ташыган тойгыларны бастырып, безне бүгенге кырыс чынбарлыкка кайтаралар.

— Ләйлә, — дим мин, — әйдә без бу мәсьәләнең ахырынача җитик инде, җаным.

Ләйлә үзсенеп, якын итеп миңа карады.

— Нинди мәсьәләнең, Мәгубә апа?

— Менә инде рәхмәт төшкере: оныткан да... Әйтик, көннәрдән бер көнне Әхмәт килеп төште, ди. Аңа да, сиңа да ял биреп куйдылар, ди. Герой кадәр Герой җаен табар, җаным. Сүзен кире какмаслар. Әнә Сивков Рябова янына санаторийга килгән бит. Җаен тапкан.

— Без дә табарбыз...

Сизеп торам: Ләйлә тирәнтен уйламыйча гына әйтте бу сүзләрне. Әнә ул үз дөньясына чумган. Моңа минем ачуым килә башлый:

— Әхмәт, Ләйлә җаным, Сивков кына түгел ул, беләсең килсә. Аның талканы коры булыр. Тау егете диләр аны. Аларның үз гореф-гадәте!

— Зыян юк, — диде Ләйлә, бөдрәләрен төзәтә-төзәтә. — Исән булсак, исермәбез, Мәгубә апа. Бу әле өлгереп җитмәгән мәсьәлә. Кечкенә мәсьәлә...

Мин гаҗәпләнүдән туктап ук калдым: килен булып төшүне кечкенә мәсьәлә ди бит. Әхмәт акка кара белән шулай дип язган икән, ул инде үз сүзеннән кайта торган егет түгел. Әйткәнен үтәү йөзеннән кызга бүләк итү өчен самолет китергәч һәм үзенең соңга калуын белгәч, гарьлегеннән шартлар дәрәҗәгә җитеп, самолетына утырып күтәрелеп китүе һаман әле күз алдымда минем. Утлы каен күмерен хәтерләтә иде аның карашы. Егет бу юлы гамәленә ирешми тукталмас. Ә безнең юләр кызга диңгез тубыктан. Нәрсә сөйли, нәрсә сөйли диген!..

— Хикмәт анда түгел әле, Мәгубә апа. Хикмәт «багучыбызның» карта ачып, ул сөйләгәннәрнең һәммәсе туры килүендә! — диде Ләйлә.— Мин ышанмыйм моңа. Нәрсә бу? Каян белгән ул «багучы» Әхмәтнең миңа тәкъдим ясавын? Менә кайда кордебалет!..

Шул чак дежур офицерның:

— Штаб алдына тезелергә! — дигән катгый боерыгы яңгырады.

Көчәя төшкән җил, кушучлап борчак сипкәндәй, вакыт-вакыт күктән эре яңгыр тамчылары коя. Болытлар тоташ стена булып агыла. Диңгез үкерә, диңгез ярсый...

Тезелдек. Полк байрагын алып чыктылар. Шәмдәй катып, тын калдык.

Бершанская үзе янындагы хәрби кешегә нәрсәдер әйтте дә безгә мөрәҗәгать итте:

— Гвардеец иптәшләр! Эльтигенга десант төшерү операциясен уңышлы башкаруда сез үз-үзегезне аямый сугыштыгыз. Моның өчен армия командованиесе личный составка рәхмәт белдерде.

Без горур төстә:

— Советлар Союзына хезмәт итәбез! — дип җавап бирдек.

Полк командиры сүзен дәвам итте:

— Шушы кыю десантчылар хәзер бик кыен хәлдә: сугыш кирәк-яраклары бетеп бара, азык-төлекләре дә юк дәрәҗәсендә... Фашистлар, безнең десантчы егетләрне диңгезгә чөеп төшерергә теләп, һөҗүм артыннан һөҗүм ясыйлар. Кырым яр буендагы «Утлы җир» исемен алган Эльтиген участогына көн саен егермешәр-утызар танк, шул чаклы ук самолет җибәрелә. Җир снаряд, бомба шартлауларыннан казылып беткән. Көчләр тигез булмаса да, гайрәтле диңгез пехотасы бирешми. Әйткәнемчә, аларга хәзер кичекмәстән күктән ярдәм кирәк. Диңгездә көчле шторм, дошманның күп санлы корабльләре сакта тора, кызу йөрешле зур самолетлар ташлап киткән йөк безнекеләргә эләкми... Очышлар инструкциясе буенча, бүгенге һава шартларында мин сезгә очарга боера алмыйм. Ләкин очарга кирәк. Кем дә кем Эльтигендагы кыю десантчыларга ярдәм кулы сузарга тели, ике адым алга!

Аерым-аерым тезелгән эскадрильялар, һәммәсе ике адым алга атлап, көчле җилдә очынып-очынып җилфердәгән полк байрагына честь бирде.

Чал чәчле диңгезче дулкынланган тавыш белән:

— Рәхмәт, гвардеец иптәшләр, кыю лачынкайлар! — диде.

Самолетларыбыз янына йөгердек. Аэродром читенә йөк машиналары килеп, алардан әрҗәләр, капчыклар бушатылды. Безнең кызлар бу йөкне канат асларына тага башладылар.

Мин очыш хәстәре белән самолеттан самолетка йөргән Ләйләне койрык ягына чакырдым да, битемне планшет белән җилдән томалап:

— Карале, кызый, «сандугачны почта итик арабызда йөрергә», дигән җыр искә төште. Шул җырда әйтелгәнчә, бәлки бу капчыкларны почта итеп файдаланыргадыр, ә? — дидем.

Лэйлә гаҗәпләнеп кашларын җыерды, ләкин нәрсә әйтергә теләвемне шундук аңлап, кызарып чыкты:

— Ике-өч сүз язып капчыкка тыгарга мөмкин, әлбәттә, — диде.

— Әйдә, язабыз!..

Башларыбызны брезент белән томалап, койрык лонжеронын өстәл иттек тә кесә фонаре яктысында десантчыларга кечкенә генә бер хат кисәге сырладык. Хатның ахырына Лэйлә: «Шундый фамилияле кеше арагызда булса, яки аның язмышы турында белсәгез, радио аркылы хәбәр итегез!» — дип өстәп куйды.

— Ә имза? — дидем мин.

— Анысы... мәҗбүри түгел.

— Ник инде, Лэйлә?

— Ул анда булса, үзен кем эзләгәнен болай да сизенер. Ә яңа танышлар миңа кирәкми.

Күндем, нишлисең, холкы шундый инде бу кызыйның. Үзен күрсәтергә яратмый.

Бершанская, Лэйләгә беренче булып очарга боерык биреп:

— Диңгез өстендә чакта мөмкин кадәр өскә күтәрелегез дә ярга җитәрәк, моторны сүндереп, планировать итегез. Безнекеләрнең җирдәге сигналы — өчпочмаклы ут. Кадерле йөк фашистларга түгел, үзебезнең егетләргә эләгергә тиеш! — диде.

Полк командиры, десантчылар арасыннан Лэйләнең кемне эзләвен белгәнгә күрәдер, ахры, «үзебезнең егетләргә» дигән сүзләргә аеруча басым ясап әйтте һәм аналарча мөлаемлылык белән:

— Шушы йөк аларны үлемнән саклаячак, көч-дәрман бирәчәк, — дип өстәде.

Сохари салынган капчыкка кош теледәй хат тыгуыбызны да сизенгән инде әллә?

Лэйлә уңайсызланып:

— Так точно, иптәш командир! Өчпочмаклы кадерле йөк үзебезнең егетләргә тапшырылырга тиеш! — диде.

— Шартлы сигнал — өчпочмаклы ут, Санфирова. Буташтырмагыз, зинһар!..

— Никак нет, иптәш командир. Тыныч булыгыз.

Вәт бит бу кыз нинди! Әле генә соклангыч тыйнак, ачык фикерле иде. Ә хәзер, чынын-ялганын кушып дигәндәй, наянлана. Кемгә диген бит әле — командирына! Лэйләбез ике-өч минут эчендә үзгәрде дә куйды, җитдилеге гүя җилгә очып, гәүдәсе җиңеләеп талпынып-очынып йөри башлады, әле коралчы кызларны, әле механикларны ашыктырды, шаяртты, булышырга килеп ябышты.

Аның бу халәтен аңлый идем мин. Еллар дәвамында җавапсыз калып, йөрәгендә пыскыган мәхәббәткә бүген тагын җил өрде, ул бүген тагын дөрләп кабынып китте һәм кызның соңгы көннәрдә аеруча талчыккан, агарган йөзенә, шатлык күбәләге булып, алсулык кунды, күзләрендә шаян нурлар җемелдәде. Хәзер Лэйләнең үз-үзен тотышында егеткә чакыру ташлау, ялгызлык барлыкка китергән хөсетлек сизелеп тора иде шикелле. Кайнар мәхәббәте җавапсыз калган, үзен башка кешеләр яратуын күреп торган һәр чибәр хатын-кыз бүген шундый хәлдә булыр иде, минемчә. Әй, горур егет, соңгы эндәшү бу сиңа, җавап бир! Сөеклең, син-син дип, нинди кыенлыкларга түзмәде, нинди сикәлтәләрдә үзен сакламады?! Инде менә чик. Алда тирән сулы инеш ята. Аңла шуны: син дәшмәсәң, тар басмадан чыкканда ярдәм өмет итеп кул сузыласын һәм бу нәфис ак кулны бик тиз тотып алачакларын онытма!..

Самолет канатына өчпочмаклы хат та салынган дәү капчыкны асып, давыллы диңгез өстеннән очканда Ләйлә шулай уйлагандырмы, белмим. Штурманы Руфина Гашева әйтүгә караганда, Ләйлә юл буе бер сүз эндәшмәгән. Тик тиешле урынга җиткәч, кыймматле йөкне ташлап өлгергән бер мизгелдә генә ул, аска карап: «Радиодан хәбәр итегез!» — дип кычкырган. Кая инде астагыларга аның тавышы ишетелсен! Ә Ләйлә барыбер кычкырган. Эльтигенга очып килеп, десантчыларга йөк ташлаган саен шулай кычкырган ул...

...Гадәттәгечә, Хиваз белән очабыз. Астан куркыныч янамаганда, гадәттәгечә, гәп куертып алырга ниятлим.

— Хиваз! Дала баласы!..

— Әү, Мәгубә апа-җан? Кем тия асыл кошыма? Ямансылыйммы?

— Ямансылыйм шул, — дим мин сөйләшү аппаратына. — Әйт әле, Хиваз җаным, сине үбеп авыз гармуны биреп калдырган егет безнең Ләйләнең сөйгән яры идеме ул, түгелме?

— Белмәем шул, Мәгубә апа-җан, белмәем. Бәлки улдыр, бәлки түгелдер...

— Иштең ишәк чумарын! Бәлки ул, бәлки ул түгеллеген син әйтмичә дә беләм мин!

— Белгәч, ни дип сорыйсың инде?

Мин эндәшмим. Ачуым чыга. Газны арттырам. Һаман күтәреләбез. Биеклек — мең тугыз йөз метр. Борчылып аска карыйм. Бернәрсә күренми. Болыт та җил һәр якта. Сукыр килеш очабыз. Болай Эльтигенны таба алырбызмы?

— Курс 280,— ди Хиваз.— Ике минуттан моторны сүндерергә була.

— Исәпләүләрең дөресме, төгәлме, штурман?

— Аптекадагы кебек.

Тавышы нык, ышанычлы моның. Моторны сүндердем. Канатларда җил сызгыруы ап-ачык ишетелә. Бөтен ышаныч приборларда. Биеклек кими бара. Шул чак алда прожекторлар кабынып китте, зенит артиллериясе ут ачты.

— Ләйлә самолетына аталар! — диде Хиваз.

— Цельгә җиткәнче үк сизеп алдылар микәнни?

Хиваз үз кабинасында боргалана; линейкасы, планшеттагы картасы белән серләшеп алды бугай, көттереп җавап бирде:

— Исәп буенча, бомбага тоткач сизгәннәр булырга тиеш.

— «Бомбага тоткач» түгел, кыйммәтле йөкне цельгә ташлагач, штурман.

— Так точно, командир! Әнә Ләйлә, моторын кабызып, тиз-тиз диңгез ягына борылды. Цельне тапмаса, качырырсың аны шулай!

Самолет түбәнәйгәннән-түбәнәя. Прожекторлар тасмалары башланган урынга карап фикер йөртсәк, яр буе ерак түгел инде.

Шул чак Хиваз: «Курс 180!» — диде.

Самолетны бора төштем. Без хәзер диңгез яры буйлап очабыз. Шартлы сигнал кабыначак мәктәп ихатасы диңгез читендә булырга тиеш. Әнә ул зарыктырган өчпочмак. Өстенә үк булмаса да, ярыйсы гына төгәл килеп чыкканбыз. Аз гына уңга борылам. Биеклекне үлчәүче приборга күз төшереп алгач, тетрәнеп китәм: җиргә чаклы нибары йөз сиксән метр ара калган. Моторны кабызыргамы? Кабызсаң, дошман прожекторлары келәшчәгә алып, рәхимсез нурлар белән күзне камаштырачак, зениткалар котырып ата башлаячак.

Ә болай зарыктыргыч утка кадәр очып җитеп булырмы? Биеклек — 120 метр, 100... 88...

Колак төбендә җил сызгыра. Йөрәк шомланып, дулап тибә. Нигә инде Хиваз йөкне ташламый? Тиешле вакытыннан ике генә секундка соңласа да... Юк, бу хакта уйлыйсы килми. Көтмәгәндә күңелгә шомлы уй килә. Әгәр мотор кабынмаса? Самолет үзебезнекеләр окобына төшеп

кадалачак... Канат астындагы эрҗәләрдә — миналар... Тәндә тетрәнү, куллар, аяклар токка тоташкан сыман. Аек акыл бирүзе хакимлек итә. Сабыр... сабыр... тагын бераз, тагын бераз гына... Биеклек — 70 метр. Шул чак самолет тирбәлеп куя һәм Хивазның:

— Палундра! Бәрәңге китердек... Фашистны сыйлаганда гвардеец кызларны искә алыгыз! — дигән яңгыравык тавышы ишетелә.

Мин, ашыгып, моторны кабызам. Таныш гөрелте ишетелүгә бөтен тәнемә рәхәтлек тарала, йөрәгем зур куаныч белән тибә. Армавирдагы Костенко һәм аның алтын куллы егетләренә рәхмәт укыйм. Ләкин алар турында озак уйланырга вакыт юк. Аяклар, куллар мең-мең тапкыр кабатланып, гадәткә сеңгән таныш хәрәкәтләрне ясыйлар. Газны арттырып идарә тоткасын үземә тартам... Күзләр шакмактай, караш — ялт-йолт. Нишләп прожекторлар кабынмый әле? Әһә, менә алар, чәнчелгерләре... Мин утлы камчылардан читкә ычкынмакчы булам. Әмма фашисттан тиз генә качу мөмкинме соң?! Мәрхәмәтсез нурлар күзне камаштыра, яшь агыза. Күн бияләйле кулым ирексездән битемне каплый. Очкыч хәзер үз ихтыярында. Акылым битәрли башлый: болай ярамый. Ярамый! Хәзер безне атып төшерәчәкләр!.. Ничек тә түзәргә кирәк... Дошман ата, котырынып, уннарча тупларыннан ата. Без гүя җәһәннәм яшеннәре уртасында калдык. Менә ул бер мизгелгә генә булса да самолетны үз ихтырына куюның нәтиҗәсе.

Самолет, үрмәкүч җепләренә эләккән нәни күбәләктәй бермәл тыпырчынгач, рәт чыкмавын аңлап, тәвәккәлләп моторны сүндерәм дә кинәт аска мәтәләбез. Аннары, снаряд тиеп зарарланган сыман чалышаеп, самолетны диңгез ягына борам. Өйгә таба йөксез очудан да рәхәт нәрсә юктыр. Җиле дә уңайга исә бит андый чакта.

Фашистлар, рус-фанер капут дип уйлап булса кирәк, атудан туктыйлар, ә прожекторлары горизонталь очышка күчкән самолетны әле һаман озата бардылар да, без дулкыннарга җитәрәк, бөтенләй сүнделәр.

Моторны кабызып, күтәрелә башладык: диңгездә дошманның сакчы корабльләре булырга мөмкин.

Бер самолет аэродромга кайтмады. Ләйлә яктырганчы полк радисты янында утырды. Ләкин бәхетсезлеккә очраган экипаж турында да, «Утлы җирдә» сугышучы безгә таныш гармунчы матрос турында да хәбәр итүче булмады.

## Буш эрҗәләр кирәкми

Бүген югалган судноларны эзлибез. Ләйлә, госпитальдән кайтып төшкән генә булуына карамастан, Бершанскаядан барыбер очарга рөхсәт алуга иреште. Алар, гадәттәгечә, Руфина белән очалар. Мин — Хиваз белән. Феодосия юнәлешендә диңгез өстендә «тау» ясап, ягъни әле акрын гына түбәнгә төшеп, акрын гына югары күтәрелеп йөрибез. Тигез генә очар идек, бу тирәләр хәзергә дошман кулында. Карчыга төсле табыш эзләп йөргән «Мессершмитт»ка юлыгуың мөмкин. Кичә әнә Марина Чечнева белән Нина Ульяненконы бер «рама» чак-чак кына «теге дөньяга» җибәрмәгән. Маринаның гадәттәге тәвәккәллеге коткарган. Самолетны кинәт түбәнгә мәтәлдереп, дулкыннарга чумарга нибары дүрт-биш метр чамасы калгач, пикедан чыкканнар да теге карчыга борылып килгәнче болытлар эченә кереп сызганнар...

Кайтып төштеләр болар. Берсенең чигә чәченә кырау суккан, икенчесе усак яфрагыдай калтырый.

— Маринаның хәле ничек? — дим мин Хивазга.

— Бирешерлек түгел, Мәгубә апа-җан. Тик кайгы куй көтүенә иялләшкән бүре кебек бит ул...

— Тагын ни булды?
— Әтисенең үлгән хәбәре килде...
— Ай-яй-яй!
— Бу хакта кичә күрәзәче әйткән иде аңа, «не каркай» дип куйды, ә бүген менә — кара пичәтле хат...

Алда истребитель канатына охшаган нәрсә җемелдәп киткәч, болытларга кердек. Кайтып җиткәнче бер авыз сүз сөйләшмәдек.

Ләйлә самолеты заправкада иде.

Бершанская аэродромда әрле-бирле йөри. Минем рапортны керфеген дә селкетмичә тыңлады да, барыгыз, үз эшегез белән шөгыльләнегез дигәндәй, самолетка таба ымлады.

Полина Белкина белән Тамара Фролова экипажы кайтмаган икән. Ләйлә, полк командиры янына килеп, үз самолетының очышка әзер икәнлеген, күтәрелеп китәргә рөхсәт көтүен белдерде. Бершанская, беркавым икеләнеп торгач:

— Рөхсәт итәм, Санфирова, барыгыз! — диде. — Тик, зинһар, сак була күрегез! — Ул, эре-эре атлап, кабат йөренә башлады.

— Сезнең квадратта да болытлар бик түбәнме? — дидем мин Ләйләгә.

— Бүген диңгез өстендә һәр җирдә шулайдыр инде алар, Мәгубә апа.

— Юкка гына тырышабыз күк тоела...

Кыз иреннәрен бөрештерде, гаҗәпләнгән сыман, күзен тутырып миңа карады, кашлары бөгелеп-сикереп куйды.

— Ә миңа... алар ярдәмгә мохтаҗдыр күк тоела. Их, тапсам...

Бу тавыш мине әллә нишләтте. Мин Ләйләнең югалган судноларны гына түгел, мәхәббәтен эзләвен дә төшендем. Ул һаман өметен өзми иде әле. Табигатебез шундыйдыр инде: кеше үз дигәнен һәр җирдә очратырга хыяллана. Хыял гына түгел, теләк бу. Тынгы белми торган, тукталсаң тизрәк кузгалырга, ятсаң, кулыңны күкрәгеңә куеп, тәрәзә янына яки ишек катына килергә мәҗбүр итә торган зарыгулы теләк бу.

Әнә очып китте.

Без исә икенче очышка кузгалырга өлгермәдек. Дивизия штабыннан эзләүләрне туктатырга, төнге махсус очышларга әзерләнергә боерык килде. Ни өчен махсус очышлар? Хәзергә әле сугыш сере иде бу. Сафта булган барлык самолетларны да әзер тотарга кушканнар...

Кичкә таба Бершанская эскадрилья һәм звено командирларын штабка чакырды.

— Утырышыгыз, командир иптәшләр, — диде ул. — Хәзер оператив бүлек начальнигы сезне махсус задание белән таныштырыр.

Сургучлы пакет ачылды, аннан өчкә бөкләнгән шома кәгазь чыкты.

Махсус задание дигәнебез Эльтигендагы десантчылар участогына буш әрҗәләр, контейнерлар ташлап, мөмкин кадәр күбрәк тавышлы шаукым тудырудан гыйбарәт иде.

Гаҗәпсенеп бер-беребезгә караштык.

— Чын мәгънәсендә һава извозчигына әвереләбез икән! — диде Таня Макарова.

— Чынлап та... нигә буш әрҗәләр?

— Аңламыйсызмыни? — диде Наташа Меклин чегәннекедәй кара күзләрен ялтыратып. — Безнекеләр һөҗүмен яшерер өчен!

— Не обсуждать! — диде полк командиры.— Боерганны үтәргә кирәк. Һәм мөмкин чаклы яхшырак итеп үтәргә! Лейтенант Меклин дөрес фикер йөртә. Эльтиген оборонасы бетә, иптәшләр. Десантчылар Керчька бәреп чыгачаклар. Дошман моны икенче десант дип уйларга һәм Эльтигеннан үз гаскәрләрен алмаска тиеш. Шуңа күрә без, бушап калган окопларга, үткән төннәрдәгедән дә күбрәк итеп, «сугыш кирәк-

яраклары» — буш әрҗәләр ташларга тиеш булабыз. Барыгыз, иптәшләр, хәзергә ял итегез...

Үзебезнең «гүзәл ханша чатырына» кайттык. Ял кая инде ул! Керчьны азат итү куанычыннан беребез дә урынында тик кенә тора алмый. Вераның дулкынлануы хәттин ашты. Кызлар туй төшкәндәге төсле итеп, нәкъ Вералар урамына бер-бер артлы төшеп, нәкъ Костенколар өе алдына (чөнки Веранықылар эвакуациядә) туктарга, аннары самолетлардан (нәкъ бирнә китергән шикелле!) чиккән сөлгеләр белән тотып, азык-төлек, кием-салым ташырга (немецлар кулы астында яшәп газап чиккән кешеләр ач та, ялангач та бит...) план коралар.

Женя Руднева, Митридат түбәсенә менеп, Пушкин «эзләренә басабаса» йөрергә, шуннан торып тирә-якка карарга, барыбызның да күңелләренә хуш килгән «Тамань ярым утравыннан, борынгы Тмутаракань князьлегеннән»... не укырга хыяллана. Ул әле шул араларда гына әти-әнисен, башкаланы күреп, яраткан операсы «Севильский цирюльник»ны тыңлап килде. Юлда һава бозылып самолетлары зарарлангач, госпитальдә бер чибәр капитан белән танышкан. Җиде көн буе бергә булганнар, гыйшык бакчасы җимешләрен татып, вәгъдәләшеп аерылышканнар...

Женя кайтып керүгә үзен ярәшелгән кыз, очучы-капитан фәлән-фәләневнең кәләше дип белдерде һәм каршыма басып:

— Иптәш лейтенант, полкның офицер намусы суды председателе, сезгә үтенечем шул: мин хәзер тырнак очларыннан чәч бөртегемә кадәр аныкы, бары тик аныкы! Әгәр аңа биргән вәгъдәмә үз-үземне тотышым белән, тойгыларым белән хыянәт итәм икән, мине хәрби трибунал судында хөкем иттерегез! — диде.

Себровага аның бу сүзләре аеруча ошады. Кыз нәрсәдер эзләгән кебек як-ягына каранып алды да чигү-кисү белән мәшгуль Хиваз кулыннан кайчысын йолкып тәрәзәгә ташланды. Анда төрле банкаларда Иранның гөлләре тезелеп тора. Ул, һич икеләнеп тормыйча, иң матур кызыл чәчкәне кисеп Рудневага тоттырды, яңагыннан үпте.

Кызлар шау-гөр килә башладылар.

— Күк патшалыгы кануннарыннан чыгып, җир патшалыгында мәхәббәт агачының җимешен татыган бу «сеңелебез» үзең ярлыкауны сорасын!

— Гөнаһларыннан тәүбә итсен!

Кайсыдыр, суга манчып, себерке белән су бөркергә керешге, икенчесе кашыгы белән савыт төбендә «чаң» какты. Тимер мичнең капкачын ачып җибәрделәр, кызны, утка каратып, җырлый-җырлый «тәүбә иттерделәр»...

Комиссар килде, ул да күзләреннән яшь чыкканчы көлде.

— Анакай,— диде Женя, аның каршына тезләнеп,— гөнаһлы мин, гөнаһлы... тәүфыйксыз кызыгыз капитанга гашыйк булды. Сөям, сөям мин аны!

— Әйткән идем ич «Катюша» җырындагыча яр буйлап кына йөрмәссең, шау чәчәккә төренгән күңел бакчаңның бикле капкасын үзең ачарсың дип!..

— Ачтым, анакай, ачтым!.. Гөнаһлы мин, гөнаһлы...

Шактый көлешкәч, комиссар кинәт җитдиләнде дә кесәсеннән «Знамя Родины» газетасын чыгарып Ләйләгә сузды:

— Менә укыгыз, сезнең якташлар турында да хәбәр бар.

Ләйлә укый башлады.

37 нче полк сержанты Хәсәнов Мөхетдин турында иде ул хәбәр. Комсомолец егетнең даны бөтен полкка таралган. Ул КП янына үк килеп җитә язган ике «Тигр»ны танкка каршы ата торган мылтыктан атып яндырган, өченчесен граната белән шартлаткан... Башына бинт

уралган, кулы яралы, ә шулай да медсанбатка киту турында уйламаган. Дошманга каршы көрәшүен дәвам итеп, батырларча һәлак булган.

Шаяруларыбызны дулкын ялап киткәндәй булды. Ләйлә идән буенча әрле-бирле йөренә. Дәшми. Нәрсә уйлый, белгесез.

Эңгер-меңгер куера башлауга төрле буш әрҗәләр, буш контейнерлар китерделәр. Бершанская бу иске-москыны, самолетларга тагарга җайлырак булсын өчен, аэродромга берничә җиргә бушаттырды.

— Фашист самолетларының безнең алгы сызыкка буш мичкәләр ташлап, котны алулары турында ишеткәнем бар, — диде Ләйлә уйчан төстә. — Ә менә үзебезнекеләрнең...

— Кушылган икән — үтибез! — диде аңа Таня Макарова.

Ләйлә аңа каш астыннан текәлеп карады, эндәшмәде.

Таня усал карашка түзмәде, үзенең «Очи черные, очи страстные»н җырлап китеп барды.

— Юкка син аны кыерсыттың, Ләйлә! — дидем мин.

— Ичмаса, кысылмасын иде. Кушылганны гына үтәп, беренче август төнендә дүрт экипажны һәлак итмәдекмени?!

Стартер, ак флагын алга сузып, честь бирде. Самолет, борт утлары белән күз кыскалап алды да, канатларын җәеп йөгергән киек каз кебек як-якка чайкалып, караңгылыкка кереп югалды. Икенче самолет китте, өченчесе китте.. Безнең чират ахырданрак. Көтәбез.

Төн салкынча, аяз. Бөдрә болытлар арасыннан ай күренеп-күренеп китә. Эльтиген күгендә прожекторлар аҗаганы уйный, тонык кына гөрселдәүләр ишетелә. Моторлар тавышын сугыш гөрелтесеннән аерып тыңлый белә безнең халык. Әнә алар берәм-берәм төн караңгылыгында эреп юкка чыгалар.

Ләйлә белән Руфина да китте.. Хәзер менә Руднева белән мин кузгалам. Корал ташучы кызлар канат асларына гадәти булмаган йөкне көлешә-көлешә элделәр. «Самолет түгел, чын мәгънәсендә этажерка булды!» — ди берсе. Икенчесе: «Утильсырьё ташучы»,— дип өстәде.

Тиз-тиз зажиганиене ачтым.

— Контакт!..

— Есть контакт! — ди караңгыда бер тавыш һәм мотор гөрелдәп эшли дә башлый.

Борынга әчкелтем төтен исе килеп керә. Маңгайдан күзлекле төшерәм. Рульләрне, тормозларны баскалап алам.

Штурман кая олакты соң? Әһә, әнә ул йөгерә. Почта килгәнен көткән икән: кулындагы хатны үбеп-үбеп ала...

— Капитанымнан хат! — диде Женя. — Үлеп сагындым дигән.

— Соң, тиле, хатны укымадың ич әле... Анда ни язылганын каян беләсең? — дидем мин.

— Кичә үк күрәзәче әйтте...

Тагын күрәзәче, тагын карталар!.. Ачулануымны белдерергә өлгермәдем (Женя укымышлы кыз ич, ә үзе юк-барга ышана!), кузгалырга боерык булды. Киттек. Очасы маршрут диңгез өстеннән үтсә дә, күңелдә пошаман юк. Күнегелде инде. Күтәреләбез дә күтәреләбез. Нигә бу кыз тынып калды әле? Юк, аны чамадан тыш хыялга чумдырырга ярамый. Буш әрҗәләр генә элеп барсак та, фашист буш снаряд белән атмаячак...

— Женя! Капитаның яныңа килдеме әллә?

— Ах, шулай мөмкин булса?!

— Хыялда барысы да мөмкин...

— Ә дөрес бит, Марта Хөсәеновна... Бик-бик күрәсе килгәндә, күзләрне йомып хыялланам да, ул күз алдыма килә.

Күз йомып очу гына җитми иде инде безгә! Алдыңа бер, артка биш карасаң да чакка гына килә әле. Фашист ул, җаны җәһәннәмгә

киткере нәрсә, өреп тормыйча гына тешли торган эт кебек, көтмәгәндә пәйда була. Сак кыланырга кирәк.

Самолет гадәттәгедән акрынрак оча: килбәтсез зур әрҗәләр һава каршылыгын арттыра.

Мотор тавышын ишетеп, Эльтигындагы фашистлар прожекторларын кабыздылар. Җитез ике ут безне диңгез өстендә үк эләктереп алды һәм төнге күктә дәҗҗал туе башланды.

Штурман ничек күрә торгандыр, мин, күзләрне чытырдатып йомып, аның боерыгын капшанып кына үтим. Болай сукыр килеш очу бик хәтәр.

— Женя, әйдә түбәнәябез, — дим.

— Ярамый: поселок кырыеңдагы тау өстендә пулемет бар...

Нишләргә соң? Снарядлар һаман якынрак шартлый. Самолетка уелап кыйпылчык тиде инде — тетрәнеп куюлар шуның билгесе. Ориентировканы җуям түгелме? Очучы өчен бу — үлем белән бер.

— Биеклек 280 метр, — диде Руднева. — Цельгә хәтле тагын ике минут...

Ике минут! Гадәти тормышта ул сизелмичә үтә дә китә. Ә менә ут давылы котырган, һәр мизгеле үлем белән янаган төнге күктә... аны үткәрү, ай-һай, авыр!

Хәзер иң хәтәр араны үтәсе калды. Тау өстенә куелган пулемет... Әнә ул яктырткыч пулялар белән ата.

Прожекторлардан котылган идек инде.

— Пошел! — диде Руднева һәм буш әрҗәләр мәктәп ихатасындагы сөрелгән җирне хәтерләткән җимерек окоплар өстенә очты. Моторга газ өстәп, самолетны диңгезгә таба бордым.

Окоплардан дошман ягына әледән-әле ракета чөяләр. Безгә игътибар итүче булмады...

Кайтып төшкәч тә, сугышчан заданиеңең үтәлүе турында командирга белдерим дип кузгалырга торганда, техниклар кеше ышанмаслык хәбәр әйттеләр: Ләйлә зарарланган самолетын төзәтеп бетергәч, әрҗәләр ташларга бармаячагын белдергән. Хәзер ул КП да Бершанская белән әрепләшә икән.

Тиз генә КПга йөгердем.

Бершанская иягенә таянып утырган да уйчан, талчыккан кыяфәттә кәгазьләр актара. Ләйлә, мех эчле күн бияләйләрен култык астына кыстырып, өстәлдәге картага төртеп күрсәтә-күрсәтә сөйли иде:

— Десантчылар Чурбаш күле белән диңгез арасындагы шушы участоктан Керчька таба киттеләр. Дошман һичнәрсә сизмәде. Чөнки, — диде Ләйлә һәм тавышы калтырады, эссеәнеп башындагы шлемын салды, гафу үтенеп, чәчләрен төзәтте. Аннары дәвам итте: — Чөнки төнге походка китү мөмкинлеге булмаган яралылар... — Ләйлә кабат тукталды, һава җитмәгәндәй, еш-еш сулый башлады, ашыга-ашыга сөйләргә кереште: — Аңлыйсызмы, Евдокия Давыдовна, анда безнең каты яралы сугышчылар алгы сызыкта хәзер! Алар оборона тота. Һәм без, язмыш ихтыярына ташлап калдырылган шул кешеләргә, буш әрҗәләр ташлап, тавыш эффекты ясыйбыз. Ниндидер... кордебалет бу!..

— Без командование приказын үтибез, өлкән лейтенант! — диде Бершанская. — Онытылмагыз...

Ләйләнең бирешергә исәбе юк иде.

— Уйлап карагыз әле, Евдокия Давыдовна, окопларда, траншеяларда чак-чак кыймылдаучы яралылар... Үзләре теләп чыкканнар бит алар санбаттан. Иң соңгы хәлиткеч бәрелешкә! — Ләйлә, елап җибәрмәс өчен, иренен тешләде, ләкин яңаклары буйлап барыбер яшь тәгәрәде һәм кыз өзек-өзек дәвам итте. — САБ яктысында ап-ачык күрдем... бер яралы матрос, без ташлаган буш әрҗәне сыңар кулы белән

ыргытып бәрде дә... миңа йодрык селекте!.. Теләсәгез нәрсә эшләгез, Евдокия Давыдовна, бүтән буш әрҗәләр ташлый алмыйм мин. Андагыларга патрон, гранаталар кирәк! Сугышып үләргә мөмкинлек бирик, ичмасам, без аларга!..

Ләйлә тукталып калды, Бершанская һаман эндәшмәгәч, куллары белән йөзен томалады.

Әлегә кадәр тыныч утырган комиссар тамак кырды һәм, кулларын артка куеп, әрле-бирле йөрергә кереште. Ләйлә аның үзе яклы булуын сизенде, яклап сүз әйтүен көтте. Эмма Рачкевич хәзергә эндәшмәде.

— Буш әрҗәләр урынына... корал алып барырга рөхсәт итегез, Евдокия Давыдовна!

Бершанская җавап бирмәде. Җавап көткән Ләйләгә ризасыз төстә карап, сабыр гына:

— Өлкән лейтенант Санфирова, сез китә аласыз. Барыгыз, командованиенең боерыгын үтәгез. Һәм борчылмагыз: Эльтигендагы яралыларга ярдәм күрсәтерләр, — диде.

КПдан чыгып үзебезнең землянкага кайттык. Монда якты һәм жылы иде. Идән уртасында, чыртлый-чыртлый, зур тимер мич яна: кайсыдыр уңганы, буш әрҗәләрне ватып, менә дигән утын әзерләгән.

Ләйлә идәндәге такта кисәкләрен, сез шуңа гына ярыйсыз дигәндәй, дыңгычлап мичкә тутырырга кереште. Мин кайнап утырган чәйнектән кружкага чәй агыздым да, өрә-өрә эчеп:

— Син, Ләйлә, командирның ачуын китермә, — дидем. — Нигә әле шулай кодрәясең? Әйтерсең анда...

— Анда яралылар, — диде Ләйлә, усал итеп.

— Һәм алар арасында ул да бар сыман тоела, әйеме? Диңгезгә агып киткән суднолардан аны эзләдең, госпитальдән эзләдең — анда да ул бар төсле тоелган иде. Таптыңмы? Сугышта алай булмый.

— Ничек була?

— Алай булмый. Логикага сыймый. Аның биредә сугышып йөрүе икеле.

Ләйлә, моңлы күзләрендә өмет чаткысы балкытып, үз-үзен ышандырырга теләгәндәй, тиз-тиз сөйләргә кереште:

— Төньяк Кавказда самолетын бәреп төшергән булсалар, җирле халык ярдәме белән ике-өч айда игә килеп алгы сызыкны үтсә, Кырымга һөҗүм башланганда үз частенә кайтып торырмы? Юк, андый түгел ул!

— Тилекәем, юләркәем син минем! — дидем мин, Ләйләне кочып. — Ярый, болар барысы син уйлаганча, ди. Ләкин ул ни өчен Кырымга ашкынырга тиеш әле?

Ләйлә шундук җавап бирде:

— Беренчедән, һөҗүмгә баручыларны төпченеп тормыйлар: Петров дисә, Петров булып китә, Сидоров дисә — Сидоров... Икенчедән, сугышка чаклы аны шул тирәләрдә хезмәт итә дип язганнар иде. Бәлки анда... ике баласы белән хатыны калгандыр?..

Мин үз-үземне сизмәстән аяк өсте басып:

— Һәм син ике балалы шул «егет» өчен шашынасыңмы? — дидем.

— Мин, Мәгубә апа, тормышның чәчкәсенә караганда чәнечкесе турында күбрәк уйларга гадәтләндем, — диде Ләйлә. — Көтелгәннән яхшырагына күңү авыр түгел бит. Дөресме? Ә менә нык беләкле җайдак урынына ишәккә атланган юлаучы тәрәзәңне шакыса?..

— Син... син арысланга тиң Әхмәтне шул юлаучыга алмашыр идеңме?

— Бөтен бәла дә шунда, Мәгубә апа! Миңа аның хәзер кем булуын белергә кирәк. Шунсыз... — Ләйлә өметсез төстә кул гына селтәде.

Землянкадан чыктык. Аэродромда әледән-әле моторлар гөрелтесе ишетелә: бер-бер артлы самолетлар кайтып төшә, самолетлар күтәрелеп китә. Старттагы прожектор, егет көткән кыз тәрәзәсен хәтерләтеп, түземсезләнеп тиз-тиз кабынып ала да, усал күзләр күрмәсеннәр тагы дигәндәй, шундук сүнә... Полк, тавыш эффекты чыгарып, Эльтигенга буш әрҗәләр ташлавын дәвам итә.

Ләйлә беләгемнән кысып тотты:

— Күңелем тоя, күңелем сизә: җилкәсенә гармунын асып, аксыйаксый киткән итекле матрос ул булган, Хиваздан бүрек алгач авыз гармунын биреп калдыручы да ул, Мәгубә апа! Хәзер Эльтигенда яраланып ятадыр шикелле... Һәм мин аңа булышасы чакта буш әрҗәләр ташлыйм!

— Бу — фараз кылуың гына, Ләйлә җаным...

— Булсын! Шулай да булсын, ди. Моңардан кемгә зыян? Миңамы, сиңамы? Башкаларгамы?..

Мин уйга чумдым. Бөтен хикмәт тә шунда шул, рәхмәт төшкере. Кызның сәер мәхәббәте берәүгә дә зыян китерми. Ә үзен, киресенчә, пакь, мәгърур итә, аңа көч бирә. Димәк, әйдә, сөя бирсен, дип нәтиҗә чыгарырга кала. Шушы мәхәббәте хакына бу исәр кыз бүген минә полк командиры белән кычкырышты. Монысы бернинди капкага сыймый. Бершанская дивизия штабы боерыгын үти. Хәер, армия штабы да бар бит әле. Әнә кызларга яңа киемнәр тектерү мәсьәләсендә дивизиядә ни гомер җылы сүз әйтмәделәр. Ә командующий хәл кылды да куйды. Җаен туры китереп, шыксыз шинелен киеп, Ләйлә ялгыш кына күзгә чалынмаган булса, ул аерым парад киемнәре төшкә дә кермәс иде безнең.

Ялгышу... Ялгышуны билгеләп торган критерий ни? Законмы, уставмы? Алары каян килеп чыга? Җәмгыять алдындагы бурычларданмы?

Кыскасы, мин тәмам буталып беттем. Әмма шунсы ачык иде хәзер: әгәр кешенең мәхәббәте аны маяклы олы юлдан читкә этәрмичә уртак мәнфәгатьләргә алып килә икән, яки ул мәнфәгатьләрне үстерә, көчәйтә икән, әйдә, исәнлеккә-саулыкка сөя бирсен!

Ләйлә, очышка хәзерләп куелган самолетыннан буш әрҗәләрне ычкындырып, гранаталар тагарга боерды.

Коралчы кызлар аптырап калдылар.

— Гранаталар... аэродром читендәге складта бит, — диде шөпшә билле Валя Лучинкина.

Караңгыдан, кайдандыр кое төбеннән килгән шикелле, Галина Пилипенко тавышы ишетелде:

— Барлык самолетлар буш әрҗә тага. Приказ...

— Мин дә приказ бирәм: минем самолетка хәзер үк гранаталы әрҗәләр тагыгыз!

— Гранаталар... Кайнана чоланында дигәндәй...

— Бәләкәй арба белән биш минутта алып киләбез.

Пилипенко түзмәде, ирләрчә атлап, самолетның козырыгына таба үтте һәм, учларына төкереп, аны борып та куйды: — Нигә арба — уңынчы гасыр! Самолет үзе склад янына барсын!

— Әйе шул: укасы коелмас! — диде кайсыдыр.

Шул чак очышлар җитәкчебез Себрованың:

— Лелечка, онытма: мин бер нәрсә дә күрмәдем, мин бер нәрсә дә ишетмәдем! — дигән тавышы ишетелде.

— Әлбәттә, ишетмәдең. Моторны кабызмыйбыз ич!..

Кызлар самолетны складка таба этеп алып киттеләр.

Бу юлы мин Хиваз белән очтым. Күңелдә бушлык, үз-үземнән ризасызлык. Әле кайчан гына тигез тарткан мотор да хәзер сулкылдапәрнеп эшли сыман. Биеклекне, тизлекне үлчи торган акыллы приборларның нечкә уклары тетрәнүендә дә ниндидер рәнҗү бар сыман.

Ичмаса, Хиваз эндәшсәче. Юк, дәшми. Сөйләшү аппаратына иелеп тамак кырам. Ул моны үзенчә аңлап: «Курс дөрес, иптәш командир. Цель — тагын унике минуттан», — дип җавап бирде.

Моторга газ өстим. Тирә-юньне күзәтә-күзәтә очам. Әнә аста шартлы сигнал — мәктәп ихатасындагы ут. Димәк, подваллардагы безнең сугышчылар, өмет өзмичә, бездән һаман ярдәм көтәләр икән әле. Шулай булмаса, утны кабызырлар идеме? Буш әрҗәләрнең кирәге юк аларга. Төп көчләрнең Керчька таба кузгалуын дошман күзеннән яшерү өчен кәмит ясап йөрүебезне сизенгәннәрдер, ахры — йөкне каршыларга чыгучы да юк әнә. Ә ут яна, тетрәнә-тетрәнә, диңгез уртасындагы маяк сыман яна да яна... Моторны кабызам. Шуннан артык түбәнгә төшүдән барыбер мәгънә юк. Мотор такылдый башлауга яр өстендәге прожекторлар күкне айкарга, зениткалар ут төкерергә кереште. Куркыныч божра кысылганнан-кысыла бара. Тизлекне арттырып, диңгезгә таба ычкынырга тырышам. Ә Хиваз буш әрҗәләрне ташламый да ташламый.

— Әй, кызый! Әллә син аларны кире алып кайтмак буласыңмы?! — дип кычкырдым мин аңарга.

Текә борылганда көзгедә Хивазның йөзе чагылып китте. Кыз иреннәрен тешләгән, карашы артта тычкан күзе хәтле генә җемелдәп калган сигнал утына төбәлгән иде.

Мин шуны тәгаен аңладым: штурман мәктәп ихатасындагы яралы сугышчыларга буш әрҗәләр ташлап, аларның өметсез һәм рәнҗүле күңелләрен мыскылларга теләми иде. Чынлап та, сугыш кирәк-яракларыннан бүтәнне ташлау хәзер алар җәрәхәтенә тоз салу ич ул. Ләйлә хаклы, мең тапкыр хаклы. Тик полк командирының боерыгын бозган өчен аны нишләтерләр?

Прожекторлар цельгә якынлашкан самолетны тотып алдылар. Зениткаларның рәхимсез уты үрмәкүч пәрәвезенә эләккән чебен күк чәбәләнгән самолетка күчерелде.

— Бу — Ләйләҗан, — диде Хиваз, күктәге дәһшәтле утлардан күзләрен алмыйча. — Эх, ярдәм итеп булса!..

Күңелемдәгене әйтте дә салды бит, рәхмәт төшкере. Борылдык. Прожекторларның алтын тасмалары безгә таба сузылды. Мин качышлы уйнарга ашыкмадым. Тотсыннар, аннары зениткалар безгә төбәп ата башласын. Шунда Ләйләнең хәле җиңеләячәк, миңа шул кирәк. Әнә безгә дә аталар, Ләйләгә дә. Әйләнә-тирәбездә ут бии, ут котырына. Әйтерсең килгән шәпкә көчле янгын эченә чумдык.

Самолетны түбәнгә мәтәлдерәм. Нәкъ зенитка өстенә. Хиваз түзми, пистолеттан ата. Ләкин аның «пушкасыннан» дошманга тамчы да зыян юк. Ичмаса, пулемет булса икән! (Ул чакта безнең самолетларга андый корал куелмаган иде әле.) Тәмам ярсыган Хиваз, патроннары бәткәч, ал, кызыл ракеталар чөйде, аннары үз кабинасындагы әйберләрне томырырга кереште. Буш ракетница аска очты, ветрочет һәм, ниһаять, сыңар итек...

Фашистлар, бу котырган «төн пәриләре» өстебезгә төшеп шартлыйлар дип уйлап булса кирәк, зенитка яныннан шылганнар иде, ахры.

Җиргә илле-алтмыш метрлар калгач машинаны тигезләдем дә, түбәнтен генә очып, диңгез ягына борылдым. Исәпләвем буенча, Ләйлә мәктәп ихатасына йөген бушатып өлгергән булырга тиеш иде.

Мең бәла белән кайтып җиттек. Мотор эшләүдән туктауга коралчы кызлар, механиклар сырып алды.

— Ләйләне күрдегезме?

— Цельгә үтә алдылармы?..

Озакламыйча Санфирова-Гашева экипажы үзе дә аэродромда иде инде. Әйбәт төштеләр, Ләйлә шат, күзләре очкын чәчә, хәрәкәте җитез,

тәвәккәл. Кабина кырыена ике куллап тотынып, җиргә сикерде, нәкъ Себрова каршына килеп төште.

— Бар, аңлаш, Леля. Бәлки җил-давылсыз үтә алырсың, — диде Себрова.

Ләйлә кулларын киң җәеп:

— Давыл икән, давыл купсын, әйдә! Җил котырсын!.. Күңелем давыл тели минем! — диде. Аны, үгетләп, командир янына озаттык. Нишләтер майор, трибуналга бирерме? Комиссар Рачкевич һәм парторг Рунтның хәзер штабта булуы гына безнең күңелгә азрак өмет чаткысы сала иде. Алар бәлешкә тозны кирәгеннән артык сибәргә юл куймас. Чәйнек кайнавын кайнар, әмма дулап ташымас...

Кызлар, давыл алдыннан гына була торган бөркү һавада әлсерәгән тук үрдәкләр кебек, акрын кыймылдыйлар. Аларның күңеле тыныч түгел. Буш әрҗәләр урынына гранаталар тагып җибәргән өчен Бершанская баштан сыйпамаячак...

Минем самолетны, бакча карачкысыдай теткәләнгәнлектән, мастерскойга тәгәрәттек. Яңа агач борыслар куймыйча, очарлык түгел. Яктырганчы, ичмаса, тагын бер очыш ясап булмасмы дип, ремонтчыларга булышып йөргәндә Ләйлә килде. Ярдәм иткән өчен рәхмәт әйтеп, биттән үпте дә:

— Давыл үтте, Мәгубә апа. Бершанская корал тагып очарга дивизиядән рөхсәт алды! — диде.

Җилкәдән тау төшкәндәй булды.

## Сары тау кызы

Болытлы, караңгы төн. Тирә-якта диңгез ыңгырашуыннан башка бернинди тавыш юк. Керчь һәм Эльтиген плацдармнары бетерелгәннән соң, гаскәрләр оборонага күчте.

Әллә ни салкын түгел. Шуңа күрә, һава ачылганны көтеп, кабинада утырам. Бүтән кызлар землянкаларда. Штурманым Хиваз да шунда. Алдан сөйләшенгәнчә, старт игълан ителүгә ул бирегә йөгерәчәк һәм без сугышчан заданиегә беренче булып күтәрелеп китәчәкбез. Көн саен кимендә бер артык очыш дигән сүз бу. Шулай алдынгыларны куып җитеп булмасмы. Койрыкта сөйрәләсе килми бит! Бүгенге очышлар җитәкчесе Ләйлә безнең хәлне аңлады. Аңламыйча: әгәр гозерем вакытында канәгатьләндерелеп, фронтка башкалар белән бергә килсәмме? Күптән ашханәдә кабыгына пычак белән «500» саны язылган дәү карбызны, үз кулларым белән кискәләп, кызларга өләшкән булыр идем инде. (Безнең полкта очышлары биш йөзгә тулганнарны шулай хөрмәтләү йоласы бар.)

Ә Хиваз? Авариягә очрап госпитальләрдә аунамаса, бүтәннәрдән ким очар идеме ул?! Мондый катлаулы ситуацияләрдә безнең бернинди гаеп юк бит. Юк! Димәк, ярышта моны, рәхим итеп, исәпкә алыгыз инде. Без чиратсыз очарга тиеш. Вәссәлам. Бер-ике тапкыр бу номерыбыз шома гына үтте үтүен. Тик менә бүген һава канцеляриясенең йөзе чытык: очарга рөхсәт юк та юк! Тәмам туңып беттем. Барыбер китәсе килми. Менә-менә Хиваз йөгереп килер сыман. Эч пошудан көндезге вакыйгаларны күңелдән кичереп, уйлана башлыйм...

Иртәнге якта Сары тау кызы Рая Аронова ахирәте Гашева янына хат тотып килде.

Руфинадан азрак калку гәүдәле, түгәрәк ак йөзле, шома киң маңгайлы бу сабыр кыз бүген тәмам аптыраган кыяфәттә иде: бөдрә чигә чәчләре тузгып битенә төшкән, зур коңгырт күзләрендә курку галәмәте, матур иреннәре күгәреп чыккан, хәтта авыз кырыена сизелер-си-

зелмәс булып нечкә генә җыерчык төшкән иде сыман. Унтугыз яше дә тулмаган бу чибәр кыз, күрер күзгә басынкы булса да, очышларда курку белмәс затка әверелә. Ул — бик әйбәт штурман, бомба ташлау буенча гына түгел, пистолет, карабин кебек коралларданда төз атучы. Парашют белән сикерү инде аның иң яраткан шөгыле. Итагатьле гаиләдә яхшы тәрбия алып үскәнгә, кайбер ирдабайлар кебек кычкырып көлмәс, сөйләшкәндә әңгәмәдәшен һичкайчан бүлдермәс, күзәтүчән һәм үткен зиһенле, күп укый һәм укыганын сеңдерә барган, хәйлә, мәкер дигәнне белми торган, чын мәгънәсендә табигый асылташ кебек саф бер кыз иде ул. Саратов каласында туган, якташы бөек революционер-демократ Чернышевский әсәрләреннән акыл һәм илһам алган. Башка күпчелек кызлар шикелле үк, университетта укуын сугыш беткәч дәвам итәргә булып, үзе теләп фронтка киткән. 1943 елның азакларына дүрт йөздән артык очыш ясап, инде ике орден белән бүләкләнгән лейтенант Аронова, беренче көннәрдән үк фронтта лаеш шулпасын эчеп ярыйсы ук тәҗрибә тупласа да, хәзерге яшь кызлар күргәнне күрмәгән, алар татыганны татымаган. Бүген аның аптырап-югалып калуына мәхәббәт дигән нәрсә сәбәпче булган иде.

Раечканың бер тапкыр да Леша белән очрашканы юк. Ләкин барыбер аны сөя иде инде ул. Кем белә, бәлки бу — күңелдә, хыялда яшәгән идеалны сөю генәдер. Кыз шуны аңлаганга дулкынланадыр: әгәр ул йөрәктәге егеткә охшамаган булса, очрашу ни алып килер.

Шушы сорау Раяның сабырын төкәндергән, кыз әнә беренче кат күккә күтәрелгәндәге кебек агарынган, ул, кипкән иреннәрен чак-чак кыймылдатып:

— Руфина Сергеевна, нишлибез инде? — диде.

— Ни булды? — Гашева эскадрилья штурманнарының хәрби хәзерлеген исәпкә ала торган кәгазьләрен бер читкә этте дә кызны янына утыртты.

Рая хатны сүзсез генә аңа сузды.

Гашева күзләрен шома ак кәгазь өстеннән йөгертеп чыккач, сызгырып куеп:

— Менә бу номер! — диде. — Вәт Леша, Леша... Ниһаять, тәвәккәлләгән!..

Рая эскадрилья штурманының бүлмәдә сызгырып җибәрүеннән оялып кызарды һәм, нәүмизләнеп, соравын акрын гына кабатлады. «Мәхәббәт! Ник син шинельле бу кызны шул дәрәҗәдә аптыратып калдырдың? Аңа кыюлык бир. Ширбәтеңне татыган адәм балалары шундый. Моны гына читләтеп узма», — диясем килде минем.

Гашева урыныннан торды, бил каешын төзәтте:

— Ничек нишлибез? Тиешенчә каршы алабыз! Кияү егетләренә куярлык сый-хөрмәт юкмы әллә бездә?! — диде.

— Аның... кайчанга килүе дә билгеле түгел бит әле...

Үзенең «Очи черные, очи страстные»н җырлап гимнастерка үтүкләгән Таня Макарова, кинаяле елмаеп: «Багучы»дан кәрт ачтырыгыз. Кыек атып туры тидерүе мөмкин!» — дип киңәш бирде.

Кайбер кызлар «багучы»ның ифрат та алдан күрә белүен, дөрес «багуын» әйттеләр.

— Ул кичә... миңа да хат киләсен алдан әйтте, — диде Рая акрын гына.

— Һәм бүген хат килдеме? — диде яңа гына кайтып кергән Ләйлә, шинелен сала-сала.

— Әйе...

— Хатка язылган сүзләрнең кыскача эчтәлеген дә кичә алдан әйткән идеме?

— Әйе, Ольга Александровна...

— Аңлашыла... — Аннары Ләйлә рәсми төстә: — Мәгубә Хөсәенов-

на, сезгә, офицер намусы суды рәисе буларак, ниһаять, бу эш белән якыннан шөгыльләнә башларга вакыттыр, ахры, — дип, миңа эндәште.

«Башла» дип әйтергә ансат ул! Ә нәрсәдән башларга? Башлагач, ул акыллы башның мутлыгын ничек фаш итәргә? Бөтен бәла шунда: кызларга аның алдан әйткәннәре һәммәсе диярлек рас килә бара бит. Теге чакта Ләйлә үзе: «Мин «багучы»бызның хәйләсен сизендем, без аны ярык тагаракка утыртабыз!» — дип сүз каткан иде дә, мең төрле көтелмәгән мәшәкать чыгып бу эш онытылды. Хәзер менә шул сер йомгагын Мәгубә апасы сүтәргә тиеш. Шул гына җитми иде миңа.

Ләйлә, минем нәрсә әйтергә теләвемне чамалап, бармагын иреннәренә тидерде һәм:

— Ашыккан — ашка пешкән. Сабыр төбе — сары алтын, — дип, татарча көйләп, юынырга чыгып китте.

Мин, буржуйка өстеннән җылы су алып, аның артыннан юнәлдем. Кирәген аңлашканнан соң:

— Үзеңнең хәлең ничек? Артына типкәннән бирле теге чәрелдек кыз сиңа теш кайрый бит, — дидем.

Ләйлә, сөлге белән сөртенә-сөртенә:

— Кайрасын. Барыбер теше үтмәс! — диде.

— Майор кушканга чакыргanмы?

— Юк. Үзе инициатива күрсәтә.

— Сак бул, кызый...

— Безнең эшебез хак, без җиңәрбез! — диде Ләйлә.

Төшке аш вакытында ашханәгә полк командиры Бершанская белән комиссар Рачкевич керде. Дәррәү сикерешеп торган идек, Евдокия Давыдовна: «Утырыгыз, иптәшләр, утырыгыз!» — диде.

Һәммәбезне кызыксыну биләп алды: нәрсә булган, нинди хәбәр китергәннәр?..

Комиссар безне фронтлардагы хәлләр белән таныштырырга кереште. Үзем тыңлыйм, үзем уйланам. Политинформация ясарга ни дип икәүләшеп килде икән болар? Комиссар үзе генә дә укый ала ич соңгы хәбәрләрне. Юк, монда нидер бар... Әнә Евдокия Давыдовнаның чырае нинди җитди. Соңгы вакытта рәтләп ял итмәгәнлектән, күзләре кызарган, янак сөякләре беленеп тора. Маңгай чәче дә агарган дип әйтимме? Агарыр, апаем, шул кадәр хатын-кызның көен көйләп, агарыр. Алар... Чү, Ләйләгә нәрсәдер әйтә түгелме?.. Мин бүленгән уйларыма кире кайтам: әйе, алар, солдат булсалар да, барыбер хатын-кыз бит. Менә аңлы, дисциплиналы командир Ләйлә үзе генә дә тәмам бәгыренә төшмәдемени аның?! Ничә тапкыр сүзгә килештеләр, кычкырыштылар инде алар... Бершанская урынында бүтән командир булса, Ләйләнең кичәге башбаштаклыгын һич үткәреп җибәрмәс иде. Аны кимендә ун тәүлеккә гауптвахтага утырткан булырлар иде. Үз приказын үтәмичә, корал тагып киткәне өчен... Бәлки бүген Санфировага соңгы кат кисәтү ясарга килгәндер? Әйе шул... Наряд булды, өй арестты булды...

Ләкин хәлләр һич тә көтмәгәнчә килеп чыкты: полк командиры Ләйләгә рәхмәт белдерде. «Утлы җир»дә оборона тотып калучыларга корал кирәклеген сәгате-минуты белән командованиегә җиткерүдә ныклык күрсәткән өчен бу.

Эльтигендагы яралылар, фашистларның дистәләгән һөҗүмен кире кайтарып, үз участокларын каһарманнарча саклаганнар. Әлбәттә, күпләре һәлак булган. Мәктәп ихатасы соңгы терәк пунктка әверелгән. Моннан чигенмәгәннәр... Көндезге якта фашистларның һөҗүме тукталган — биредәге частьларны, яңа десант дип кабул ителгән Гладков гаскәрләренә каршы тору өчен, ашыгыч рәвештә Керчька күчерә башлаганнар.

Митридат тирәсендә аяусыз сугышып, дошманны тау өстендәге дотларыннан сөреп чыгарган десантчыларга безнең командование өстәмә көчләр җибәргән. Ә корабльләрнең беришеләре «Утлы җирдә» исән калганнарны үз бортларына алганнар. Алар хәзер Таманьда икән...

Бу яңа хәбәрне һәммәбез тын да чыгармыйча тыңладык.

Төшке аштан соң без дүртәү — Рая, Вера, Ләйлә һәм мин — командир «вилли»сына утырып, Таманьга юнәлдек. Һәммәбезгә нинди дә булса эш йөкләтелгән иде. Дивизиянең кыр почтасына кереп, полкка дип аерып куелган хатлар арасыннан үзебезгә дигәннәрен ачып укырга да ният бар. Иртәгә башка хатлар арасында болар булмаса һәм Таманьда без инде белеп өлгергән хәбәрләрне «багучы»дан кәрт ачтырып сөйләтсәк, аның мошенниклыгы төбенә чаклы фаш ителәчәк. Димәк, үз теләге белән әледән-әле почтальон хезмәтен башкаручы «багучы» кызыбыз, әлеге хатларны беразга үзендә яшереп тота да, укып хәтеренә сеңдергән хәбәрләрне кәрт ачып алдан «белгән» булып чыга...

Бала чакта ук күңелләребезне сихерләгән, Лермонтов язганча, җилле, яңгырлы Тамань бүген актарып ташланган кырмыска оясын хәтерләтә иде. Керчь бугазының көнчыгыш ярына урнашкан бу шәһәрчектә җимерелмәгән бер генә йорт та калмаган. Аның каравы, таш чиркәү белән шәһәр мәйданы уртасына казак атаманы Антон Головатыйга куелган иске һәйкәлгә берни булмаган. Аяк асты лычкылдап гүя боламыкка әверелгән: тот та станга салып кирпеч сук — уалмас, шушы пычракны җәяүле гаскәр изә, атлар изә, машиналар изә. Урамның ике ягында яшел брезент белән томаланган снаряд өемнәре, патрон әрҗәләре, туплар һәм тагын мең төрле бүтән кирәк-ярак. Ярым җимерек биналарда төрле штаблар, политбүлекләр, госпитальләр, мастерскойлар, базалар, кыр почталары.

Үзебезнең дивизия политбүлегендә тиешле инструктаж алганнан соң, Ләйлә бер сәгатькә якын югалып торды. Ул кайткач та кыр почтасына юнәлдек. Ләйләгә хат юк иде. Ул, юл буена бер кәлимә сүз эндәшмичә, вакыт-вакыт авыр көрсенеп, диңгезгә карап кайтты-кайтты да моңлы тавыш белән җырлап җибәрде:

Диңгез читләрендә ак күбек,
Тауларда — күксел томан.
Ник кенә син өнсез,
Ник кенә син телсез
Шушы томаннар сыман?!

Диңгез читләрендә ак ташлар,
Тауларда чат карлы боз...
Ник кенә син истә,
Ник кенә син йөзгә
Сары йоктырасың вакытсыз?!

Диңгез читләрендә ак дулкын,
Таулардан исә җилләр.
Һаман өмет итәм,
Һаман зарыгып көтәм —
Кош теледәй хат җибәр.

Мин игътибар иттем: Ләйлә күзләрен йомып җырлый иде. Ул тукталгач:

— Карале, Ләйлә, ничек күреп өлгердең син һәммәсен, күзләреңне йомган идең ич! — дидем.

— Күңелдә алар, Мәгубә апа җаным, күңелдә, — диде Ләйлә һәм кабат тынып калды.

Мин аның бая сәгать буе госпитальләрдән егетен эзләп йөргән аңладым.

Җинел машина, «кәҗә бәтие» дигән кушаматын аклаган сыман, фронт үткән юллардан сикергәли-сикергәли, диңгез ярлары буйлап Пересыпька чаба...

Төнге сәгать берләрдә инде һава ачылмаячагын әйттеләр. Уйларымнан арынып, унта эчендә булсалар да салкыннан ойый башлаган аякларымны көчкә сөйрәп, тулай торакка кайтып киттем. Рая ятмаган иде әле. Шинелен җилкәсенә салып, стенага аркасын сөяп утырган да уйга баткан. Кулында — дәреслек. Мин аның, пилот булырга теләп, техник әдәбиятны күп укуын беләм. Ләкин бүген кызда уку кайгысы түгел.

— Беләсеңме, Раечка, — дидем мин, — син Саратов кызы. Саратов татарча «сары тау» дигән сүздән. Сары тауда туган кыз булгач, йөземә сары йокса да ярый дип уйлама. Әйдә, безнеңчә куе итеп чәй эчик әле...

## Комиссар шәп оча

Кызлар көн саен урыннан тора-торышка күккә карыйлар: болытлар таралмаганмы, җил басылмаганмы?

Юынып керүчеләр бүген өмет уятырлык сүз әйтсәләр дә, мин башкалар кебек сикереп торырга ашыкмадым. Тән эссе, баш — тубал кебек. Көзгегә караган идем — күзләр кып-кызыл... Бүген дә рәтләп йоклап булмады. Штабтагы сөйләшүләрдән соң, өч төн инде йокысызлык тинтерәтә. Янымдагы кызлар кәеф юклыкны чуаннардан күрәләр. Рәтләп йокламауга чуан гына сәбәпче түгеллеген белмиләр шул алар, белмиләр. Ахмак — теленнән табар дигәндәй, тиктормаслыгым үз башыма бәла булыр микәнни? Нәрсәләр генә дип комиссар белән очарга риза булдым әле мин? Мине сынап карар өчен генә түгелме бу? Яңа ел алды бит. Кызлар әнә ничек әзерләнәләр. Кайсысы шаян такмак чыгара, маска ясый, костюм тегә, кайсысы яңа җыр өйрәнә, бәтиен саклаган усал сарык күк тибенә-тибенә бии... Хиваз булып Хиваз, «багучы» Валяны чеметеп алырга ниятләп, ниндидер кәмит күрсәтергә чамалый. Комиссар да мәзәк ярата. Батыр дигән Сыртлановагыз шүрләде, минем белән очудан баш тартты дип бирәр номер кыландырса — җир тишегенә кер дә кит.

Әллә Ләйләгә чишәргәме? Тел бик кычыта, югыйсә. Ул башлы кыз, бәлки акыллы киңәш бирер? Монда хәзер кәҗә дә тук, кәбестә дә бөтен булырга тиеш. Шундый ситуация.

Үрсәләнеп сикереп торуымны сизмичә калдым. Башым өстәге сәндерә тактасына бәрелгәнгәме, әллә сырхау килеш кинәт аякка басkangамы, күз алларым караңгыланып китте. Егыла язып, сәке кырыена чытырдатып ябыштым. Хиваз йөгереп килеп җитте һәм, әрлиәрли, урыныма яткырды. Үзе миңа таба карамый, үпкәләгән, ахры.

— Ни булды сиңа, Хиваз? — дим.

— Ни булсын, мине резервка куйганнар, — диде Хиваз, эш юктан эш табып, урын-җирен төзәткәли-төзәткәли. Кыштыр-мыштыр килә. Һәм дөя мамыгы тутырылган бәләкәй мендәренә чират җитте: Хиваз бөтен ачуын басарга теләп, мендәрне шап-шап каккаларга керешге. Үзен очышка билгеләмәгән өчен турсая.

— Ә синең урыныңа кем оча? — дидем мин, һаман Хивазны күзәтә биреп.

— Анысы белән кызыксынмадым.

— Вәт кәҗә катыгы!.. Үзем дә үзем... Мине кая куясың, сугышчан машинаны кая куясың? Теләсә кем белән очсак, безне вакытыннан алда списать итмәсләрме?

— Вай-вай-вай... Мин бу хакта бөтенләй уйламаганмын, Мәгубә апа-җан! Сукыр йомран мин... Хәзер йөгереп барып белеп кайтам.

Доспанова томырылып чыгып китте.

Мин кабат уйга чумдым. Әйбәт кыз бу Доспанова! Тик ул шундый икәнлеген аңламый. Үзе өчен генә яшәү, үз тормышы, үз киләчәге өчен кайгырту дигәненнең эзе дә юк аңарда.

Озакламас, Хиваз үзе урынына кем билгеләнүен белеп кайтыр. Бүген кем белән очарга тиешлегемне сизенәм инде мин.

Ләйлә керде. Әүвәлгечә, килмәгән җире юк: шинеле өстенә ятып тора, итекләре ялт иткән, бүрек кыңгыр салынган, ак яка, алма бит, чиядәй иреннәр... Күңеле шат булырга охшый — җырлый-җырлый чишенә:

— Сиңа гына җыйган чәчәкләрем
Сиңа булыр, ләкин ал белеп:
Тәүге чәчәкләрнең гомере кыска,
Мәхәббәтем минем — мәңгелек!

Менә нәфес: мәңге яшәмәкче була бит, рәхмәт төшкере.

— Карале, мәңгелек гашыйк...

— Әү, Мәгубә апа! Хәзер яныгызга киләм. Куанычлы хәбәрләр алып киләм үзегезгә! — диде Ләйлә, көзгегә карап чәчләрен төзәтә-төзәтә.

«Куанычлы хәбәрләр» ди бит. Мөгаен, өченче көнге сөйләшүләрнең бер өлешен Бершанская моңа да ирештергәндер. Яки штабтагылар аркылы саркып чыккандыр.

Ләйлә, килеп, кулларын ияк астына тыкты.

— Һай, кулларың... Салкын, бака кебек!

— Аның каравы, йөрәгем кайнар, Мәгубә апа!..

— Монысын беләм: йөрәгең хәтта кирәгеннән артык кайнар! Сайра куанычлы хәбәреңне...

— Дүртенче эскадрилья оештырыла. Аның парторгы һәм звено командиры... — Ләйлә иелеп кайнар битемнән үбеп ала, — менә шушы усал апа була!

— Китсәнә, булмаганны, — дим, кызның кәефен сакларга теләп. — Миннән тәҗрибәлерәк очучылар беткәнме әллә безнең полкта?!

— Бетүен бетмәгән, ләкин аларга да эш муеннан булачак!..

Ләйлә, минем яныма ук утырып, алда торган эшләр хакында гаять җанланып, тәмләп сөйләде.

Үзем аны тыңлыйм, үзем уйланам: Вера Белик һәм Женя Рудневага карата туган шикне әйтергәме-юкмы моңа? Комиссар белән очуны нәрсә дияр? Хупларммы?

— Хивазны бүген резервка куйганнар. Миңа кемне билгеләүләрен белергә киткән иде, нигәдер кайтмый, — дип, сүзне шул якка борып җибәрәсе иттем.

Ләйлә калкынып куйды:

— Вәт дивана баш... Яңа ел кичәсен хәстәрләшергә җибәрелгән Хиваз үтенечен әйтергә онытканмын бит. Бүген сез комиссар Рачкевич белән очарга тиеш, Мәгубә апа.

— Шундый төндә... бөтенләй диярлек тәҗрибәсез штурман белән...

— Бөтенләй үк тәҗрибәсе юк димәс идем мин Рачкевичның, — диде Ләйлә.

— Ә син үзең... нишләр идең шундый ситуациядә?

— Нинди ситуациядә?

— М-м-м... Катлаулы ситуациядә.

— Чуаннарыгызны әйтәсезме?

Һай, чуаннар гына шөбһәләндерсә иде бүген! Штурман хезмәтлә-

рен бик ук шәптән белмәгән комиссарның төнге очышта бүтән йомышы да бар иде шул. Тик бу хакта Ләйләгә әйтергә тел бәйле...
— Чуаннарда гына түгел хикмәт, — дидем, ниһаять.
Ләйлә, текәлеп, күзләремә карагач акрын гына:
— Аңлашыла, — диде.
— Ә син минем урында булсаң, нишләр идең?
— Белмим, Мәгубә апа... — Ул кабат ак марляларга карап алды.
— Беләсең, Ләйлә. Минем тән дә синең үзеңнеке кебек үк... кирәкле көч-дәрманны таба. Өзлексә — эш беткәч, җирдә өзлегә. Күктә түгел...
— Алайса... очыгыз. Чөнки бу — кирәк.
— Әйе шул. Әгәр...
Ләйлә, нәрсә әйтергә теләвемне аңлап, учы белән авызымны каплады:
— Юк-юк, бу хакта кирәкми, Мәгубә апа! — Ул яңадан күзләремә текәп карады һәм пышылдап: — Ә инде... күңелегез ниндидер шомлану сизенсә, ул чакта... ул чакта комиссар белән үзем очармын, — диде.
— Рәхмәт, Ләйлә, болай булгач, үзем очам.
— Ә мин, интервалны кыскартып, яныгыздарак булырга тырышырмын.
— Яхшы, ускәнем...
Без, кочаклашып, сүзсез калдык.

*
* *

Көттереп кенә караңгы төшә башлады.
Аэродромда гадәти җанлылык. Ботаклар белән томаланган бензовоз, ялкау коңгызны хәтерләтеп, стартка якын торган самолет янына килә. Техниклар, капотны ябып, читкәрәк тайпылалар. Коралчы кызлар агач әрҗәләр янында кайнаша. Берәү мастерскойга таба йөгерә. КП алдына очучылар җыелган. Мин анда бармыйм — сүрән кыяфәтемне күрсәтәсем килми. Самолетыма таба атлыйм. Хиваз белән алдан сөйләшкәнчә, кеше-кара күргәнче, ул миңа кабинага утырырга булышачак. Үзем генә канатка күтәрелә алмыйм. Чуаннар сызлый, бөгелү — әҗәл... Бер кереп утыргач, хәлнең мөшкеллеген сиздермәячәкмен. Күңелем сизә: җиңел булмаячак бу очыш. Җитмәсә, әнә җил дә көчәя бара, кар катыш яңгыр төшкәли. Ләкин барыбер артка юл юк.
Юк сәбәпне бар итеп механик кызны яңа манометр алырга җибәргәч, агачлар арасыннан Хиваз атылып килеп чыкты. Икебез дә мышкылдап бетсәк беттек, әмма механигым кайтканда мин үз кабинамда идем инде. Моторны кабыздым. Коралчы кызлар канатлар астына бомба тагарга керештеләр.
Штурманым — комиссар Рачкевич килде. Коралчы кызлар, техниклар белән исәнләшеп, шаян сүзләр әйтә-әйтә, бомба йозакларын тикшереп чыкты, борт кирәк-яракларын барлады, журналга язып имзасын сырлады. Күз кырыем белән генә күзәтеп торам, һәммәсен җиренә җиткереп, утны-суны кичкән штурманнарча эшли. Менә ул, киледәй юан гәүдәсенең авырлыгын бар дип тә белмичә, ялт итеп кабинага кунаклады. Әйтерсең нирләгән атка сикереп менде. Ни генә әйтмә, заставаларда хезмәт итүнең бер өстенлеге инде бу. Яшь чагында гусар Дурова сыман ияргә чабарга да, тачанкада җилдерергә дә еш туры килгән Евдокия Яковлевнага. Хәзер менә хәрби машинага утырып сугышчан заданиегә оча. Аны моңа һичкем мәҗбүр итми. Комиссарга җирдә дә эш җитәрлек. Ләкин ул үзен очарга тиеш дип саный. Пилотлар белән күк турында сүз алып барганда авызга су кабып тормас өчен тәвәккәллидер, күрәсең.

Бершанская, парторг Рунт һәм тагын берничә кеше озатырга килде. Маршрут кабат анықланды, киңәшләр бирелде. Полк командирының йөзе борчулы иде. Минә ул Рачкевичка якынлашып: «Бәлки очмассың, комиссар?» — диде.

— Юк-юк! Әйткән сүз — аткан ук!

— Алайса, ак юл сезгә! Тишек-тошыксыз кайтыгыз...

— Рәхмәт.

Очтык. Үземнең булдыклылыгымны күрсәтергә теләптер инде, тиешле биеклеккә тиз күтәрелергә булдым. Мотор үкереп эшли. Канатларда җил сызгыра. Авыру икәнем бөтенләй онтылды. Күңел җиде кат күк артында хәзер.

Чу! Сөйләшү җайланмасында җыр тавышы ишетелә түгелме? Әйе. Минем штурман очучы булып тугандыр төсле, рәхмәт төшкере. Кәеф шәп чакта кызларның күбесе күктә артисткага әверелә. Чын очучыларга хас тойгы бу. Очышта җыр төп нәрсә түгел, ләкин ул, подшипникларга салынган май кебек дип әйтимме, хәрәкәтне җиңеләйтә, күңелне күтәрә. Штурманнарның кәттәләре җырлый-җырлый күкне күзәтә, тизлекне, биеклекне үлчәп төгәл курсны билгеләп бара, очышка анықлаулар бирә. Бу нишләр?! Көтәм әле, эндәшмим. Күзгедә Рачкевичның тулы ак бите күренә. Иреннәре кыймылдый. Һаман җыр белән генә мәшгуль микәнни? Урелә төшеп карыйм. Планшетындагы картасына билгеләр куеп, линейка белән үлчи... Канәгать төстә елмаям: ышанырга була бу комиссарга!

— Командир, төп курстан унҗиде градуска читләшкәнбез. Сулгарак тот...

— Евдокия Яковлевна, курсны төзәтәм. Рәхмәт, — дидем мин. — Әйтегезче, алдагы экипажны күрмисезме?

— Юк. Без алардан ике йөз җитмеш метрга өстәге эшелонда очабыз.

— Кара син аны, ничаклы төгәллек! Хәзер түбәнәя башлыйбыз!..

— Барыбер күреп булмас: тоташ болытлар бу районда, хөрмәтлем.

— Керчьтә да шулай булса нишләрбез?

— Моңысы командир хәл кылыр дип уйлыйм,— диде комиссар минем хәйләле соравыма туры җавап кайтармыйча гына.

«Әлбәттә, — дим эчемнән, — шәһәр өстендә болытлар булса, инструкцияне «онытып» торып, бомбаларны ике йөз-ике йөз илле метрдан да ташларга мөмкин. Моны сынап караганыбыз бар. Дөрес, хәтәр эш бу: самолет, нык куркынган яшь ат кебек, кинәт читкә тайпыла. Тезгенне каты тотмасаң, егылып төшеп чәлпәрәмә килүең ихтимал.

— Яңа ел «күчтәнәч»ен ничек тә фрицларга тапшырырбыз анысы, комиссар. Аларны нәүмизләндерү ярамас. Менә махсус задание белән ничек?

Комиссар тамак кырып куйды һәм:

— Мин Белик алдашырга яки хыянәт итәргә сәләтле дип уйламыйм,— диде. Пауза ясаганнан соң сүзен дәвам итте:

— Шулай да, Марта Хөсәеновна, күзәтүдән баш тартмыйк инде без. Бу ничаклы гына авыр булмасын, ләкин барыбер үз күзебез белән күреп инанмыйча ярамый бүген!

Башлаган эшен ярты юлда калдыра торганнардан түгел шул бу. Каты чикләвек...

— Димәк, Евдокия Яковлевна, без цельгә чыкканчы ук Беликларның «койрыгына» тагылырга тиеш булабыз инде?

— Шулай, хөрмәтлем. Алар эшенең эффектлылыгын раслау өчен, без барыбер күзәтергә тиеш.

Белә бит, рәхмәт төшкере, очучылар тормышындагы тәртипләрне әйбәт белә. Хәер, академиядә укыган комиссар ич ул!

Ипләбрәк утырам. Штурманыма ышаныч арта.

Әйбәт очабыз. Тизлек арта бара. Механик Галина Пилипенконы рәхмәт хисләре белән искә төшерәм: шәп эшли машина, болытлар эчендә дә бик күндәм. Мәрхүм әткәй әйтмешли, аргамагың ышанычлы булса, карурманны кичү куркыныч түгел ул. Карурманда элек юлбасар сагаласа, күктә хәзер фашист бәдбәхет шундый. Көтмәгәндә килеп тә чыга, аркаңа пычак кадагандай, пулеметы белән үзеңне иләк ясап, «ә» дигәнче үтеп тә китә. Шушы куркыныч янап торганга, үзебезнең кызлар белән бәрелешмәс өчен борт утларын сирәк-сирәк кенә кабызгалап алам.

Исәп буенча без хәзер диңгезне үтеп, ярга якынлашырга тиеш иде. Аста нәрсә — диңгезме, җирме? Моны ничек белергә? Бер нәрсә күренми. Түбәнрәк төшсәң, Митридат тавына килеп бәрелүең бар.

— Штурман, цельгә күпме?

Евдокия Яковлевна эндәшми.

Мин соравымны кабатлыйм. Ләкин җавап юк. Борылып карасам, штурманым рәхәтләнеп йокыга киткән! Беләгенә кагылуга уянды.

— Нәкъ ике минут черем иткәнмен, — диде комиссар. — Гафу, Марта...

— Без хәзер кайда?

— Исәпләү буенча... килеп җиткән булырга тиешбез.

«Тиешбез»... Ә кайда цель? Кайда Беликлар? Тозлап-борычлап сүгәсем килә штурманны. Ләкин тыелам: штурман гына түгел, комиссар да бит әле ул.

Мөгаен, адаштык. Яктырткыч бомба ташламый чара юк хәзер.

Әһә, без уңгарак каерган икәнбез. Әнә ул атаклы Митридат! Хәзер аңа карап цельне табу авыр булмаячак. Бәхеткә, болытлар да аз бирәдә. Иң әүвәл унсигезенче квадратка чыгарга кирәк, дип хәл кылам.

Штурманым кабинасында тиендәй бөтерелә-бөтерелә миңа әмер биреп бара. Үзем дә күрәм нишләргә икәнен — беренче төн очу түгел... Тәндә зур киеренкелек: нигә прожекторлар кабынмый, нигә зениткалар «чәчәк бәйләмнәре» томырмый. Әллә Яңа ел алдыннан безне көтмәгәнме болар?!

Керчь каласы иңкүлеккә урнашкан. Шуңа күрә кала өстендә болыт юрганы калынрак иде. Газны киметтем. Биеклек алты йөз метрга калды. Ләкин барыбер һични күренми.

Штурманга: «Нишлибез?» — дидем. Инструкция буенча, биеклек алты йөз метрдан ким булса, бомбага тоту рөхсәт ителми. Аэродромга борылып, хәтәр йөк белән кайтып төшәсең.

Штурман эндәшми, иелеп-иелеп аска каравын белә.

Мин соравымны кабатладым.

— Марта, ни дип җанны кыйныйсың әле син?! — диде комиссар. — Мондый чакларда инструкцияне бозуыгыз әйтерсең миңа билгеле түгел. Давай өч йөз метрга чаклы төш!!.

Вәт бу комиссар, вәт бу — безнеңчә! Аска бер-бер артлы ике САБ очты. Өч яклап кабынып киткән прожекторларның зәһәр капшавычлары цельгә якынлашкан самолетны эләктерде. Зениткалар ата башлады. Кемнең тетмәсен тетәләр икән соң шулай? Макарова-Белик экипажы булырга тиеш. Бездән алда алар очты. Хәзер, кызлар, сезгә ярдәм итеп карарбыз. Турыдан-туры килгәч, тәмугның бер өлеше безгә күчерелер дә иркенрәк сулу алырсыз.

— Штурман, әнә теге зур прожекторга төзә! — дидем мин, газны өстәп.

Янәшәдә генә утлы тюльпаннар кабына башлады. Прицельгә эләкмәс өчен төрле хәрәкәтләр ясап очам. Шартлаулар арта бара.

Зур прожекторга таба барыбер үттек. Комиссар аңа ике бомбаны чәпәде. Тиепме, тимичәме — прожектор уты сүнде. Күктә иркенрәк булып китте. Тик нишләп Макарова экипажы унсигезенче квадраттан читләшә? Хәзер нәкъ вакыты. Ә алар суза...

— Штурман! САБны ыргыт! Аста — безнең квадрат.

— Күрәм, командир! Һәммәсен күрәм: Макарова экипажы бомбаларны читкәрәк ташлады!..

— Гаҗәп бу! Гаҗәп... — дидем мин, үзебезнең калдык ике бомбаны берәгәйлерәк итеп шартлатыр өчен урын эзли-эзли. Менә тыкрык.— Танклар ич анда! — Ташла! Ташла, штурман, күчтәнәчләреңне!

Чак-чак кына соңладык бугай: аста зур шартлаулар булмады. Зыян юк, бездән соң килгән Ләйлә бу аждаһаларның эшләрен бетерер. Әнә ул прожектор нурларында талпына... Беликлар кайтып китте. Димәк, аларны озата барган утлар бирегә күчереләчәк... Үзең бит, Ләйлә җаным, янәшәгездә үк булырга тырышырмын дип, интервалны кыскарттырдың. Цельгә соңрак килгән булсагыз, бу җәһәннәмгә эләкмәс идегез. Юк, болай ташлап китәргә ярамый. Безгә хәзер хәрәкәт итү ансатрак. Шуңа күрә кирегә борылырга ашыкмыйм. Әйдә, атсыннар... Ләйләгә җиңелгәрәк туры килер.

Канатка тидерделәр. Самолетны чак-чак турылый алдым. Ялкын телләре дулап янган мич эчен хәтерләтә. Мич каршында да күпкә түзеп булмый, ә моңа? Безнең диңгез кичәсебез бар бит әле... Сүндерергә, сүндерергә канаттагы зәхмәтле ялкыннарны! Шунсыз кайтып житү турында сүз булуы да мөмкин түгел.

Штурман көтелмәгән бу хәлдән тәмам аптырап калган. Ул, шаккатып, утка карап бара. Күгәргән иреннәре һаман бер үк сүзләрне кабатлыйлар.

— Нишләргә? Хәзер нишләргә?

Штурман мондый очракта һичнәрсә эшли алмый. Чәбәләнмичә үз урынында утырып торса, шул җиткән.

Ә очучы кулында котылу чаралары бөтенләй үк юк түгел әле. Шуның берсе — машинаны кинәт чалышайтып утны сүндерү. Бу хакта хәзер үк штурманга әйтергә кирәк: каешларын ныгытып, кабинасында нык утырсын. Югыйсә, төшеп калуы ихтимал.

— Ныграк тотын, штурман! — дип кычкырдым да моторга тулы газ бирдем. Тизлек артты, көчле һава дулкыны уң канаттагы ялкын телләрен өзгәли башлады. Ләкин утның бирешергә исәбе юк иде әле. Артка таба чаткылар сибелә, кисәк-кисәк ялкын оча. Ярый әле, кар катыш яңгыр ява... Тагын чалышаям, тагын... Ниһаять, ут сүнә...

Икебез дә дәшмибез. Газны киметәм. Хәзер инде җайлап кына кайтырга кирәк. Аста — диңгез. Фашистлар, «төн пәриләренең» берсен чәнчелдердек дип уйлап булса кирәк, атмыйлар иде инде. Ә без үз аэродромыбызга, үз дусларыбыз янына кайтабыз. Ярга якынлашкан саен хәл яхшыра, рухыбыз нығый бара...

Вералар өс-башларын алмаштырырга да өлгергәннәрдер инде. Бүген икенче очышка җибәрмәячәкләр — Яңа ел якынлаша бит. Күтәренке, көр күңел белән каршылап булырмы инде аны, юкмы? Штабтагы сөйләшүләр исемә төшә. Менә тикшердек... Шикләнүләребез расланды: кызлар унсигезенче квадратның кырыен гына бомбага тоттылар. Өстеннән очып узып. Нәкъ теге вакыттагыча... Исәпләүдә ялгышу яки соңгару түгел бу, белеп, уйлап эшләнгән эш. Бомбаларны тиешле урынына ташлауда беренчелекне үзендә тоткан экипаж бер үк объектка икенче кат кагылмыйча узсын әле!.. Башың ничек чатнамасын моңа?!

Комиссар да шул хакта уйлап кайта икән. Әнә ул: «Ачыкларбыз», — дип, үзалдына әйтеп куйды. Димәк, очышка анализ ясый, күргәннәрен хәтерендә яңартып нәтиҗә чыгара...

— Яңа елны үткәргәннән соң инде...

— Әлбәттә, — диде комиссар, ни әйтергә теләвемне шундук аңлап.

Аэродромга төшү ташка үлчим булды. «Кәҗә» ясап, ярыйсы гына сикергәләп алгач, әнкәй әйтмешли, тәмам эчләрем кузгалды, оныты-лып торган чуаннарым үтереп сызлый башлады. Кабинадан чыгарлык та рәтем калмаган иде — күтәреп алдылар. Шулай мәж килгәндә, Рая Аронова самолеты чак-чак кына безгә бәрелмәде. Күктә ифрат күндәм машина җиргә төшкәч әллә нишләгән. Бизгәк тоткандай калтырап, һаман читкә каера икән. Мондый хәлгә очраганым булганга, сәбәбен пропеллердан эзләргә киңәш иттем. Карасалар — чыннан да пропеллер сынган. Ярый әле, җиргә төшкәч... Язмышка рәхмәтләр укып, бата-чу-ма торакка юнәлдек. Тиз-тиз генә өс-башны алмаштырдык та әйдә мәҗлескә! Унике тулып килә, радиода Михаил Иванович Калинин Яңа ел рече сөйли иде. Түргә төрле уенчыклар белән бизәлгән, очын-да кызыл йолдызы да янып торган купшы чыршы куелган. Түшәмгә почмактан-почмакка кызыл флагчыклар, энҗеле кар бөртекләре та-гылган җепләр сузылган, электр лампасының зурысы балкып яна. Ап-ак җәймәле өстәлләрдә мул ризык, хәтта Яңа ел бүләге итеп, ку-накчыл абхаз халкы җибәргән мандарин да күренә.

Менә, йөрәкләрне җилкендереп, Кремль курантлары чыңлый баш-лады, сәгать уникене сукты.

— Яңа ел белән, кадерле иптәшләр!

— Яңа җиңүләр белән!

Һәммәбез аяк өскә баскан идек, калай кружкаларны чәкештереп, шәрабларны эчтек. Кунаклар да бар икән: бер контр-адмирал, өч диң-гезче-офицер һәм битләре мәк чәчәге кебек алсуланып торган Катя Рябова янында безгә таныш Григорий Сивков...

Командующиебыз генерал Вершинин фронт Хәрби советының Яңа ел тәбрикләвен укыды:

— Кадерле иптәш, азатлык сугышчысы! Менә син Яңа ел бусага-сында торасың. Бер мизгелгә артка борылып, үткән елга күз сал. Ул — зур сынаулар, ныклык һәм батырлык елы булды. 1943 ел барлык фронтларда батырларча сугышты һәм җиңде. Артта — йөзләрчә кило-метрларга сузылган азат ителгән җирләр. Миллионнарча күзләр, азат-лык сугышчысы, рәхмәт хисләре белән, чиксез соклану белән сиңа те-кәлгән, миллионнарча йөрәкләр алга омтылуыңны хуплап тибә. Ватан-ана сиңа олуг рәхмәтләрен күндерә. Дан сиңа, дан, азатлык сугышчы-сы! Башыңны югарырак күтәр, алга кара — 1944 ел, дошманны үз өнендә кыйнау һәм зур җиңүләр елы башланды. Алга, фәкать алга! Ватан синең белән бергә атлый. Ул сиңа Яңа ел котлавын җибәрә, ул сиңа газиз әнкәң, сөеклең, нарасыең күзләре белән карый. Шушы тан-таналы сәгатьтә аның фатихасын кабул итеп ал һәм һөҗүмгә омтыл! Даны сүрелмәс җиңүләр белән 1944 ел сафта килә!..

Дулкынлануыбызның чиге-чамасы юк иде. Чиксез горур да, бәхет-ле дә идек без бу минутта. Туган илгә, партиягә, командованиегә, фронт Хәрби советына рәхмәт хисләребезне белдереп, аларның ыша-нычын аклар өчен, кирәксә, тормышыбызны бирергә дә әзер икәнле-гебезне әйтергә теләдек без. Полк командирына, комиссарга, партор-гыбызга рәхмәт яусын — алар безнең күңелләребездәгене тулы һәм җыйнак итеп, матур итеп әйтеп бирә белделәр.

1943 елда күбебез икешәр орден һәм медальләр белән бүләкләнде.

1943 елда безнең полкка, дивизиядә беренче булып, гвардияче исе-ме бирелде.

1943 елда без ундүрт батыр очучыбызны югалттык...

Янымда Ләйлә килде. Күзләремә әллә ничек моңлы карап, Дуся Носаль, Ира Каширина һәм Галя Докутовичларны искә төшерергә тәкъдим итте.

Төшенкелеккә бирелә язуыбызны күреп булса кирәк, генерал аяк өскә басты, дәртле итеп сөйләде. Ахырда:

— Дөньяда, кызлар, сездән дә гүзәлләр, сездән дә чибәрләр юк. Чөнки сез үз теләгегез белән туган илне азат итүдә катнашасыз, фашистларга каршы аяусыз сугышасыз. Соклангыч батырлык белән балкыган гүзәллек өчен тост күтәрергә тәкъдим итәм! — диде ул. Һәм бокалын беренче булып Ләйлә белән чәкештерде. Бу юлы аңардан көнләшүче булмады шикелле. Ситуациясе шундый: Ләйләне без полкта беравыздан чибәркәебез дип атыйбыз, батырлык мәсьәләсендә дә күршегә бурычка керә торганнардан түгел ул. Үз мәхәббәтенә турылыклы икәне күптән һәркемгә билгеле. Әйдә, кичәбездә генерал сандугач булып сайрасын, без риза. Ләйләгә таба иелә-иелә ниндидер кызык сөйләвен күрмәмешкә салыштык, музыка уйнап җибәргәч, генералның элек аны биергә чакырганга шулай ук ачуланмадык.

Яңа ел кичәсе гөр килә. Җыр, бию, шигырь, мәзәк сөйләү... Менә бер заман пәрдә артыннан мыеклы көяз авыл агае һәм аның уңган хатыны килеп чыкты.

Спекулянт булып киенгән, аркасындагы камыш сумкасыннан чирегә белән самогоны күренеп торган һәм куллаңында ялт-йолт кәрт уйнаткан, азрак «төшергән» кыяфәтле Хивазны күргәч, көлә-көлә эч катты. Менә ул, бармагын иреннәренә тидереп: «Ш-ш-валь килә!» — диде. Масайган кыяфәттә бөеренә таянды. (Бу — «мин Валя-шваль» дигән мәгънәдә килеп чыкты.) Хивазның багучы бакчасына таш атуы һәрберебезгә билгеле иде.

Моңарчы да мәҗлестә көлүләргә катнашмый утырган багучы, үзен танып, шыпырт кына чыгып китте.

## «Безнең гаскәрләр ил чигенә чыккан!»

Таня Макарова, ишекне киң ачып, Ленин бүлмәсендә политукуга әзерләнеп утырган Верага әнә шулай кычкырды. Кыз мышкылдап беткән, битләре кып-кызыл — Вераны дөнья бетереп эзләгән, күрәсең. Менә ул шлемын салып газеталар өстенә ыргытты, комбинезонының изүен чишеп җибәрде.

Без, бүлмәдәгеләр, һәммәбез Таняга текәлеп, аңардан бу яңа шатлыклы хәбәр турында тулырак мәгълүмат көтәбез. Ә ул безне бар дип тә белми, аерылгысыз штурманы Вераның муеныннан үбә, колагына нәрсәдер пышылдый. Таня өчен дөньяда Верадан да кадерле кеше юктыр. Ул аңардан башка ашарга бармый, аңардан башка очарга теләми.

— Ил чигенә чыкканнар дип кем әйтте? — дибез без тәкатьсезләнеп.

— Сүз иясе белән йөрми, — ди Макарова.

— Син, Макарова, мондый хәбәреңне тәгаенләп, тәфсилләп сөйлә. Сугыш сере түгел ич ул боргаланып торырга!

— Нәрсәсен тәфсилләп торасың инде аның? Кыскасы, Беренче Украина фронты гаскәрләре Бельцы районында Прут елгасына, ягъни илебезнең дәүләт чигенә, килеп чыкканнар. Сунның теге ягында — Румыния.

Без куанышып «Ур-ра!» кычкырдык.

— Болай булгач, Берлинга җитәргә дә күп калмый инде! — диде Вера.

Әйе, ул көн дә килеп җитәр. Безнең гаскәрләрнең беришләре ил чигенә чыккан икән, бүтәннәр дә кул кушырып утырмас. Сизеп торабыз: безнең тирәләргә җитәрлек гаскәр, техника тупланды. Илле беренче армия Сиваш ягыннан бәрә, без — моннан. Утлы киләшчәгә эләгәчәк фашист Кырым җирендә!

Пилипенконың ярдәмчесе искиткеч сабыр холыклы, җыйнак техник Ганна Барсунь стенада эленеп торган карта янына килде дә, күзләрен мөлдерәтеп, үрелеп-үрелеп Бельцы тирәсенә карый башлады.

— Таня... Танечка, димәк, анда немец юк инде, әйеме? — диде ул.

— Әлбәттә. Ә ник шулай кызыксынасың әле, Барсунь? Әллә берәр таныш егетең шунда идеме?

— Берәү генә түгел, икәү алар!

— Берүзенә... икәүме?

— Балаларым... ике балам шунда калды,— диде Ганна.

Без шаккатып Ганнага текәлдек.

— Соң син, җаным, үзең дә бала гына ич әле!..— дидем мин.

Ганна гаебе ачылып, шуннан нык оялган кешедәй башын аска иде.

— Нишләп син аларны ташлап фронтка киттең? Ул сабыйларыңны кем карый?

— Кайнанам әйбәт минем. Ул рөхсәт итте...

Бу якты дөньяның әнә нинди кешеләре бар! Гитлер — ахмак, әнә нинди хөр халык яшәгән илне тез чүктермәкче булган бит!.. Зур куанычыбызга Ганна сөенече кушылды. Аның сөенече — безнеке дә инде ул. Дөрес, бәләкәчләрнең исән-имин булулары билгеле түгел-түгелен. Әмма өметсез — шайтан диләр. Бәлки афәт җилләре аларны читләтеп узткәндер?

Ганнаны хат язарга утырттык. Үзебез аның балаларына посылка хәзерләргә керештек.

Күп тә үтмәде, хат язып утырган яшь ана өстәленә шикәр, сохари кебек ризыклар һәм аякчу өчен бирелеп янга калдырылган фланель кисәкләре өелде.

Валя һәммәбездән баерак икән: хушбуй, исле сабын, пудра кебек нәрсәләр китерде. Мондый нәрсәләр сабыйларга нигә кирәк инде дигәч, «багучы» булып йөргәндә кәрт ачып «дөресен алдан әйткән» өчен үзенә бүләк итеп биргән ислемайларны ияләренә кире өләшеп чыкты. Бер авыз сүз эндәшмәде. Уңайсызланып аска гына карап торды. Иреннәре кипшенеп ярылгалаган, битләре каушакланган, авыз кырыйларында җыерчыклар барлыкка килгән. Соңгы атна-ун көн эчендә кызыбыз кыраугa эләккән чәчкәдәй бөреште, куырылды. Ни хикмәт, нәрсә булган? Күнегү очышларын уңышсыз башкаруы гына сәбәпчеме моңа, әллә Ленинградта калган туганнары турында кайгылы хәбәр килдеме икән үзенә?

— Валя, ни хәлләрең бар? Туганнарыңнан хат юкмы әле? — дидем мин, аны үз итеп иңбашыннан сөеп.

— Юк,— диде ул сискәнеп китеп. Куркынгандай як-ягына карап алды.

Минем аңа: «Сөйкемсез үрдәк баласы кебек нигә син шулай шөкәтсез? Ни җитми сиңа? Сине эзгә бастыру өчен күпме иза чигәрмен тагын?» — дип әйтеп саласым килә, ләкин тыелам.

Валя эндәшми. Ә бит әлек «карталар алдамый, карталар дөресен сөйли!» дип өзлексез тәтелдәгән кыз иде ул! Үзгәрсә дә үзгәрә икән адәм баласы! Ярар, күмәк көч белән фаш итеп багучылыгын ташлаттык. Штурманлыкка өйрәтәбез, кулыннан җитәкләп дип әйтерлек йөртәбез. Ләкин барыбер тиешенчә игә китереп җиткерә алганыбыз юк әле...

Посылканы тегеп азапланганда полк штурманы Женя Руднева белән Ләйлә килеп керде. Ләйлә сабыйларга җибәрәсе күчтәнәчләр арасына һәммәбезгә дә яхшы таныш булган авыз гармунын тыкты. Рудне-

ва, кесәләрен капшап та бүләккә әйбере табылмагач, алюмин кашыгын алып бирде.

Хиваз белән Вера посылканы тегеп бетерделәр дә, иянне тиз генә тап дип, өстәлгә тәгәрәтеп җибәрделәр. Төенчекне Макарова әләктереп алды һәм, биләүле бала тоткандай итеп, Барсуньга тапшырды.

Кызлар посылкага адрес язган арада Ләйлә минем янга килде һәм акрын гына:

— Мәгубә апа, бер яңалык: безнең складтан ике банка аксыл эмаль юкка чыккан. Ларионовнаның тәрәзә рамнарын буяп калдырыйк дигән идегез, сез алдыгызмы әллә?— диде.

— Юк, Ләйлә, мин алмадым.

— Кызганыч... Бүтән андый шәп лак юк.

— Бәлки әле складка тагын кайтыр?

— Ул чакта без Кырымда булырбыз шул инде, — диде Ләйлә.

— Шулай дисеңме?

Ләйлә баш какты:

— Әйе.

Димәк, Кырымга һөҗүм башлана. Ләйлә әле кичә генә армия штабында булып кайткан иде, шунда ишеткәндер, мөгаен. Мин, Валяга эндәшергә теләп сулга борылсам, кыздан җилләр искән. Нишләп капыл гына юкка чыкты икән соң? Кинәт йөрәгемне чәнчеп исемә төште: Валя беләзегендә юылмыйча калган аксыл лак табы бар иде бит...

Тәмам гарык мин бу Валядан... Ләкин полк командиры алдында, комиссар алдында шул кызны дөрес юлга бастырам дип биргән вәгъдәм бар. Сүземне сүз итмәгәч, нигә яшим дөньяда?! Хәзер мин аны табып, почмакка терим... Нишләгән ул ике банка лак белән? Фильтрлап аерып спиртын эчкәнме әллә? Барыбер әйттерәм!

Елмаеп кояш чыкты. Кояш төсле көләч Руднева полк командирының боерыгын җиткерде:

— Күнегү очышларына әзерләнергә!

Аэродромга йөгердек. Миннән алда ашыгып Женя бара. Итекләре дөп-дөп итә. Кая ашыга ул шулай? Полк командирының бүгенге боерыгы безнең эскадрильяга гына карый бит.

— Валя ничек, Марта Хөсәеновна? Һаман бер дәрәҗәдәме? — дип сорады Руднева, самолетлар тора торган җиргә җитәрәк.

— Шулайрак шул. Программаны авыр үзләштерә.

— Бәлки күнегүләрдән бөтенләй азат итәргәдер аны? — диде Женя.

— Белмим шул...

— Аналитик исәпләү җитми Валяга. Реакциясе акрын. Бу хакта мин Евдокия Давыдовнага әйткән идем инде.

Полк штурманының бу сүзләре мине шөбһәгә калдырды. Димәк, Валя турында штабта сөйләшү булган икән инде. Аның безнең файдага түгеллеге күренеп тора. Мин хәзер ни эшләргә тиеш? Валяның житешсезлекләренә күз йомыйммы, әллә... Ни хикмәт, ни өчен ул ачылып бетми? Евдокия Давыдовна минем болай икеләнүләремне белсә, Валяны күнегү очышларыннан бүген үк азат итәчәк.

Женя самолетлар янында кайнашучы кызларны сәламләп уза. Мин аларга башымны гына иям. Мин үз уйларым белән мәшгуль. Әнә ул Руфина Гашевага эндәшә...

Әһә! Югалган лак турында сөйләшәләр ич:

— Табылды, — диде Гашева, — кемдер кызлар кабере өстендәге пирамидаларны буяган.

— Ә кем буяган? Ни өчен ул моны яшереп эшли?

— Белмибез...

Руднева, мәгънәле елмаеп, яныма килде. Без юлыбызны дәвам иттек. Һавада түбәннән генә очучы акчарлаклар кычкыра. Ун гына адымда диңгез чайкала. Ак күбекле дулкыннар ярга бәрә.

Буявы юылып бетмәгән беләзек күз алдыма килде дә үз-үземә: «Аңлашыла!» — дип куйганымны сизми дә калдым.

— Нәрсә аңлашыла, Марта Хөсәеновна? — Руднева, гаҗәпләнеп, күзләрен миңа текәде.

— Валяның синең белән миңа караганда тирәнрәк исәпли белүе аңлашыла, иптәш полк штурманы! Аналитик исәпли белә ул кыз, белә!

— Ә... сез һаман аның турында... Бүген дә шул сәер кыз белән очарсызмы?

— Ә үзегез, штурман? Сез үзегез дә авырлык белән килгән җиңүне ят итмисез бугай?!

Ул ризалашып баш какты һәм кабинасында үзен көтеп торган яшь очучы Клава Прокофьева янына ашыкты.

Тиздән аларның самолеты җилдереп күккә менеп китте.

Мин Рудневаны җирдә бүтән күрмәдем.

Валя минем унталарны һәм комбинезонымны алып килгән иде: тиз-тиз киендем. Очышлар җитәкчесе Марина Чечнева белән маршрутны аныклагач, стартка юл алдык. Без бүген төрле режимда сәгать ярым очарга тиеш. Валя курсны күзәтә, исәпләп төзәтүләр кертә. Әгәр калфак кигән килеш[1] адашмаса, күнегүләрне дәвам итәбез, адашса, аңа күк белән саубуллашырга туры киләчәк. Бу очышта кызның язмышы хәл ителәсе булганга, аның складтан лак чәлдереп, кабер өстендәге пирамидаларны буяп йөрүе хакында сүз кузгатмадым. Әйдә, дулкынланмасын... Тик ни өчен ул моны качып-посып эшләгән? Гаеп эш түгел бит. Киресенчә, һәрьяклап мактауга лаек, күркәм эш бу. Мин төшенеп җитмәгән нәрсәдер бар монда, бар... Шул серле табышмакка җавап тапмый торып, Валяга фатиха бирә алмам, ахры.

Сөйләшү аппаратында Валяның басынкы тавышы ишетелде:

— Мәгубә Хөсәеновна, курстан читләштек кебек тоела.

— Мәгубә Хөсәеновна түгел, ә иптәш командир, — дидем мин рәсми тонда.

— Егерме дүрт градус сулгарак, иптәш командир.

— Есть, егерме дүрт градус сулгарак.

Тагын бераз очкач, штурманнан хәзер кайда булуыбызны сорадым. Җавап булмагач, сабырлыгымны җуеп, сорауны кабатладым.

— Чушка борынына җитеп киләбез шикелле, — диде Валя һәм, үз исәпләүләренең раслыгына инанырга теләптер, ахры, кабинасын томалаган брезенттан башын тыгып, аска карарга кереште.

— Чушка сул якта, — дидем мин, канәгать төстә. — Хәзер, штурман, идарәне үзеңә ал. Иплән кенә борыл... Менә шулай... шулай. Кабаланма. Машинаны турайт. Биеклегең кими — ручканы җай гына үзеңә тарта төш. Әйбәт! Шәп борылдың, молодец!.. Инде «тау» ясап күрсәт. Булды... Эшләр болай барса, ике атнадан аттестация ишеген шакырбыз. Әйдә, Ахтанизовская өстеннән түбәнтен очыйк... Нәрсә булды, Валя? Бу нинди калтырану? Бизгәгең кузгалдымы әллә?! Җиргә кадалабыз бит!..

Самолет белән идарә итүне кичекмәстән үз кулыма алырга туры килде. Валя иелеп-иелеп аска карый. Йөзе агарынган, ярым ачык аскы ирене калтырый.

— Кайдадыр шунда булырга тиеш...

— Нәрсә җуйдың, штурман?

— Анечка белән Танечка егылып төшкән җир...

Валя планшетындагы картасына карап алды да:

---

[1] Кабинаны каплап сукыр килеш очуга шулай диләр.

— Зинһар өчен... Ходай хакы өчен... үтенәм. Урап әйләник, — диде. — Алар көн саен төшемә керәләр. Үпкәлиләр... Мин куркам... Мин... алар һәлак булган урынны күрергә телим!

Менә эш нәрсәдә икән... Берсүзсез борылдым. Газны киметеп акрын очабыз. Тирә-як әйбәт күренә. Узган елгы соры камышлар, яшәреп килгән куе куаклар, җәелеп яткан су.

— Тагын бер әйләник, зинһар, — диде Валя.

Әйдә, аныңча булсын, дим. Ниһаять, җае чыкты: бүген ул миңа һәммәсен сөйләячәк. Өркетмәскә генә кирәк.

— Мәгубә Хөсәеновна, мондый йомшак җиргә төшкәндә мотор нык зарарланмый бит? Шулай бит?..

— Әлбәттә, чәлпәрәмә килми. Аның каравы, тирәнгәрәк сеңә ул.

Әллә бу кыю кыз һәлакәткә очраган самолетның моторын эзләмәкчеме? Дөрес, шәп эшли иде, көчле иде ул мотор. Ләкин аны мондый шайтан чытырманлыгыннан ничек алып чыкмак кирәк? Самолет ватыклары арасыннан кызларыбызның үле гәүдәләрен аралап алганда Валя үзе дә бар иде бит. Шул чакта нәрсә карады икән соң?

Валяның кайгылы тавышы уйларымны бүлде:

— Командир, һәлакәт урыны уң як бортта...

Җиргә төшәргә хәзерләнгәндәгечә, газны нык киметтем. Самолет ватыклары таралып яткан аланлык гүя каршыга йөгерә. Менә без, һава дулкыны белән куакларны җиргә бөгеп, сугышчан иптәшләребезнең гомерләре өзелгән ачыклык өстеннән очып уздык.

— Тагын бер кат карыйсыңкиләме? — дидем мин Валяга.

— Юк, — диде ул еламсыраган тавыш белән.

Азрак тынычлансын, аннары сораштыра башлармын, дим үз-үземә. Әйбәт кенә кайтабыз. Канат астындагы җирләргә октябрь аеннан бирле үзебез хуҗа булганлыктан, күңел тыныч. Фашист козгыннары хәзер бирегә онытканда бер генә килеп чыккалый. Гайрәтләре шиңде. Генерал Енеке, Кырымга һөҗүм ясалачагын сизенеп, сугышчан машиналарны хәлиткеч бәрелеш өчен саклый, күрәсең.

— Мәгубә Хөсәеновна, әйтегезче зинһар,— диде Валя,— картердагы май анализыннан моторның ничек эшләгәнлеген белеп була бит? Әйеме?

— Әлбәттә...

— Ә безнекеләр кайчанга һөҗүмгә кузгалырлар, сезнеңчә?

— Мөгаен, шушы көннәрдә, Валя... Хәзер син әйт инде миңа, хөрмәтлем...

— Нәрсәне?...

— Фәкать дөресен. Күктә һичнәрсәне яшермичә сөйләргә кирәклеген беләсеңдер. Чын очучы булырга теләсәң, юхаланмассың...

— Сорагыз, — диде Валя, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән.

— Яхшы, — мин сферик көзгене штурманымның йөзе күренерлек итеп җайлап куйдым. — Анечка белән Танечка кабере өстендәге пирамидаларны ни өчен качып-посып буядың? Ни өчен бу изге эшеңне яшерәсең?

Валя күзләрен еш-еш йомгалады, иренен тешләде:

— Болай гына...

— Юк! Намусыңа көч китермә, Валя. Дөресен әйт.

Валя, бераз икеләнеп торгач:

— Мин дип уйламасыннар өчен... Болай да көн юк. Аннары... Куркам мин!.. — диде һәм кулларын белән битен томалады.

Кызны тынычландырырга ашыктым:

— Валечка, сөеклем, елама. Батыр ич син. Аннары без икәү бит. Икәү! Нәрсәдән куркасың? Әйт... Бәлки куркырлык бернәрсә юктыр...

Валя башын күтәрде, аскы кабакларына кан сава башлаган кур-

кынган күзләрендә өмет чаткысы кабынгандай булды, ләкин ул шунда ук сүнде.

— Тикшерүче чакырып сорау алды...— диде кыз, борынын еш-еш тартып.— Бригада ысулы белән эшләгән чакта моторны син карап җибәргәнсең, ди. Анечка белән Танечка хәзер көн саен төшемә кереп йөдәтә... Май фильтрының купкан сеткасын төзәтергә иренмәгән булсаң, без кабердә ятмас идек, диләр...

— Күп уйлануның нәтиҗәсе бу, Валя! Уйлама. Үлгәннәр барыбер терелми.

— Ничек уйламыйсың, Мәгубә Хөсәеновна! Авария делосы ябылмаган әле. Аварияга томан сәбәпчеме, заводтан килгән бракмы яки минме?.. Моны тәгаенләмичә туктау юк. Намусым мәңге газапланачак минем!.. Сезгә дә күңелле түгел бу хәл: самолетны якташларыгыз ясаган бит...— Кыз миңа дүрткә бөкләнгән бер кәгазь сузды. Анда балалар кулы белән:

«Кадерле очучы абый!

Бу «У-2» самолетын заводта без җыйдык. Безнең җыючылар бригадасы сигез кешедән тора. Барыбыз да комсомоллар. Безгә хәзер ундүрт яшь. Без һөнәр училищесында укыйбыз да. Әйбәт укыйбыз. Башкача ярамый.

Бу — без ясаган дүртенче самолет. Дүртенче булса да, аңа бишле куярлык! Шуңа гарантия бирәбез.

Күптән түгел генә Мусакин фамилияле бер очучы, үзенең иптәшләре белән, заводтан өр-яңа җиде самолет алып китте. Киткәндә хат язармын дигән иде, сүзендә торды[1]. Ул, без ясаган «У-2»дә төнлә очып, фашистлар өстенә егерме биш мең кило бомба ташлаган.

Сез дә шулай дөмбәсләгез фашистларны. Һәм сез дә безгә хат языгыз.

Безнең эшебез хак, җиңү безнең якта булыр!

Комсомолларча сәлам белән: Ирек Низамов, Федор Скороходов, Гадел Сабиров һ. б. Казан, Тукай урамы, 25».

— Кайда иде бу хат?

— Приборлар тактасына кыстырылган иде,— диде Валя.— Анечкага укыткан идем, егетләргә җавап язарлык эшебез юк бит әле, эш күрсәткәч язарбыз, дигән иде. Инде самолет та юк, экипаж да...

— Тикшерүче моны беләме?

— Хәзергә — юк.

— Белсә, сабыйларны тинтерәтәчәкләр...

— Тинтерәтми генә торсын әле! — Валя, хатны ерткалап, очырып җибәрде.

— И-и, җүләр кыз!.. Шулай ансат кына котылып булса! Бу вакыйганы кешеләр хәтереннән сызып ташлап булмый бит. Бәлки бүтән самолетларда да шундый ук хатлар бардыр?..

Мотор «төчкерә» башлады. Карасаң, ягулык үлчәгеч нульгә якынлаша. Әле кайчан гына бензин ярты бак иде. Ни генә булмасын, мәҗбүри төшү котылгысыз иде хәзер. Ярый әле, төн түгел... һәлакәткә очрасак та үз җиребездә... Табарлар... һәм... К черту төшенкелек! Ләйлә белән Руфина немецлар ягына егылып төшеп тә исән кайттылар!.. Көрәшергә! Соңгы чиккә кадәр көрәшергә... Аста җир чокырлы-чакырлы... Мотор сүнде. Канатларда җил моңлы көй суза... Әй безнең пирамидаларны кем акка буяр икән?..

— Штурман! Каешларыңны ныгытып бәйлә!..

Валя мәҗбүри төшкәндә кулланыла торган кызыл ракеталарны атты... Тәгәрмәч җиргә тиде. Ике рәт «кәҗә» ясап, исән-имин төшеп

[1] 1943 елда Казаннан «Татарстан пионеры» исемле авиа-эскадрилья фронтка җибәрелә. Бу эскадрильяның сугышчан батырлыгы «Кызыл Татарстан» газетасының 1943 ел, 28 октябрь санында басыла.

кунакладык. Самолетның койрыгы бөгелгән иде. Кабинадан җиргә сикердем дә койрыкка барып ябыштым. Буй җитми генә! Бәхеткә, кайдандыр көтүче малай йөгереп килеп җитте. Аның озын чыбыркысын элмәк ясап, икәүләп тарткач кына самолетның койрыгы турыланды.

Валя нык курыккан икән. Исән калуыбыз белән тәбрикләштек.

— Валечка, төшкәндә ни өчен кызыл ракета аттың? — дидем мин.

— Инструкция шулай куша ич, — диде Валя.

— Аэродромга төшкәндә — икенче мәсьәлә. Монда япан кыр. Ярдәмгә кем килсен?

— Килделәр ич: көтүче малайның озын чыбыркысы булмаса, самолетның койрыгын ничек рәтләр идек?

Шунда гына нәни булышучыбызны искә төшердек. Ләкин ул малай безнең яннан китеп барган иде инде.

Самолетны бер кат күзәтеп, әллә ни зур зыян килмәгәнен белгәч, моторны тикшерергә керештек. Карбюраторга тоташтырылган җиз көпшә чатнаган. Аэродромда булса, аны алмаштырып кую — ун минутлык эш. Ә биредә? Минем исәп буенча, моннан Пересыпька чаклы егерме биш чакрымнар чамасы. Җәяүле өчен бу биш-алты сәгатьлек юл. Димәк, полктан иртәгә генә килә алачаклар.

Мин — командир, миңа сугышчан машинаны ташлап китәргә ярамый. Валяга бортпаекларны суздым:

— Хәерле юл сиңа, кадерлем. Полкка исән-сау кайтып җит. Бензин һәм көпшә җибәрсеннәр...

Ул китеп барды. Кул болгап озатып калдым. Берәм-берәм йолдызлар калыкты. Тирә-юньгә колак салып, корулы пистолетымны кыса төшеп кабинада утырам. Ямансу. Кайдадыр ябалак кычкыра... Мин көндезге хәлләрне күз алдымнан үткәрәм. Уйланам. Йокымсырыйм. Эт өргән тавышлар ишетелә сыман. Көтүче малай биредә күзгә чалынган икән, ул яши торган авыл яки станица да әллә кайда еракта түгелдер дип өметләнәм.

Шул ук төндә, Митридаттан ерак түгел, яшь очучы Клава Прокофьева белән Женя Руднева һәлак булган иде. Бензин багына снаряд тиеп, самолет кипкән шырпы кебек кабынып киткәч, Руднева бер-бер артлы өч ракета аткан. Безгә соңгы сәламен җибәрүеме, әллә һөҗүмгә юл ачык, әйдә, тизрәк кузгалыгыз, диюе булдымы икән бу аның?..

Иртән Дүртенче Украина фронты гаскәрләре һөҗүмгә күчте. Анннары — безнекеләргә чират җитте.

## Ләйлә хат укый иде...

...Тәмләп әңгәмә корып утырганда ишек шакыдылар. Ләйлә авыз ачарга өлгермәде, бүлмәдә Себрованың дәртле тавышы яңгырады:

— Рөхсәтме, иптәш командир? Мин бер генә секундка... Ашыгыч эш чыкты. Һәм бик мөһим эш.

— Әйдә, сөйләгез, лейтенант, — диде Ләйлә елмаеп. — Тыңлыйм мин сезне, Ирина.

Себрова эскадрилья командирының ярым искәртүле баштагы сүзләреннән азрак уңайсызланып калды, йөзенә күләгә йөгерде. Ләкин үзенең исемен ишеткәч, балкып, җанланып китте.

— Гитлер 17 нче армиясенә Кырымны ничек кенә булса да саклап калырга приказ биргән,—диде ул, бер сулыштан.— Шуңа җавап итеп...

— Гитлерга? Аның приказына?..

Ирина сабырсызлыгым хур итте дигәндәй кул селтәде дә:

— Аның бу приказына тирәнтен нәфрәтләнеп һәм явыз дошманны изге җирләребездән тизрәк куып чыгарып...— дип, нотык башлаган иде, Ләйлә бүлдерде. Ул сәгатенә ымлап:

— Ой, Иринушка, зинһар сузма. Гади генә итеп әйт тә бир,— диде.

— Алайса, болай: «Энекәшләр» полкында заданиегә өчәр йөз килограмм бомба тагып оча башлаганнар. Без алардан кимме? Әйт менә, кимме?

Ләйлә Себровага текәлде:

— Ә сез нәрсә тәкъдим итәсез?

— Безме? — диде Себрова. — Без дә өч йөзне тагарга телибез. Тик башта аларга барып танышып кайтырга кирәк.

— Кемнәр бара?

— Рая Аронова, мин һәм Гашева.

— Тагын мотоцикл беләнме? — диде Ләйлә, хәйләле итеп.

— Так точно, иптәш командир! — диде Ирина.

...Вәкилләр «Энекәшләр» полкында озак тормадылар. Алар кайтуга аэродромда ук эскадрильяларның партия җыелышын үткәрдек. «Энекәшләр» үрнәгендә, һәр самолетның көч-куәтенә, очучыларның осталыгына, тәҗрибәсенә карап бомба йөген билгеләдек. Аннары Ялта портындагы дошман корабльләрен бомбага тоту өчен задание алдык. Хәтәрнең хәтәре иде бу. Ник дигәндә, ара ерак, диңгез һәм таулар өстеннән очарга кирәк. Дөрес, андый-мондый хәл туа калса, Иске Кырым тирәләрендә запас аэродром бар барын. Әмма төшәргә мәҗбүр булсаң, заданиене үтәвең икеле инде ул...

Энгер-меңгер куера башлауга һәммәбез аэродромга юнәлдек.

Менә Себрова экипажы стартка чыкты. Күп тә үтмәде, аларның самолеты күтәрелеп тә китте.

Хәзер безнең чират. Командир җилкәдән кагып читкә атлауга, газны өстәдем. Тизлек акрын арта. Идарә тоткасын тартырга иртә әле. Хәзер... хәзер... Вакыт!.. Бу ни? Әллә җиргә ябышканмы без? Күтәрелеп китми генә бит самолет. Ә бит күтәрелү полосасының читенә җитеп киләбез инде. Алда — аэродром бетә, анда — куаклар. Анда — һәлакәт... Эссе... Идарә тоткасын тарта төшәм. Гәүдәмне җиңеләйтмәкче булып, урынымнан күтәрелеп куям. Уф! Ниһаять, самолет көпчәкләренең дыңгырдавы бетте — күтәрелдек.

— Котлаем, командир! — диде Хиваз, телгә килеп.

— Кайтып төшкәч котларсың, штурман. Давай, җаным, осталыгыңны күрсәт: маршруттан бер сантиметр да читкә чыкмыйк. Килештекме?..

— Килештек, командир.

Феодосияне сулдарак, Иске Кырымны уңдарак калдырып үттек. Бу калаларны безнең фронт гаскәрләре кичә генә азат итте. Дүртенче Украина фронты гаскәрләре Симферопольны алды. Фашистларны Ялтадан үкчә ялтыраттырсак, Кырымда тик Севастопольне генә азат итәсе кала...

Хәзер без Карловка тирәләрендә. Тоташ таулар өстеннән очабыз. 1527 метр биеклектәге Чатыр тауны уңдарак калдырдык. Мотор хәзергечә әйбәт тартса, тагын егерме минуттан Ай-Петри ягыннан үтеп, портка керәчәкбез. Болай әйләнеп килүебезнең сәбәбе шул: һөҗүм көтелмәгәндә булырга тиеш. Дошман чигенүче гаскәрләрен, техникасын һәм Кырымнан талап җыелган халык байлыгын бүген төнлә бирелән Севастопольгә озатырга чамалый икән. Әгәр без моңа комачаулый алсак, иртән штурмовиклар корабльләрне ачык диңгездә дөмбәсләячәк. Шуны аңлаганга, дошман төн караңгылыгын файдаланырга тели дә. Тамань ерак, «төн пәриләре» бирегә чаклы очып килмәячәкләр дип уйлыйлардыр.

— Командир, хәзер туры сызык буенча Ялтага дүрт минут, — диде Доспанова.
— Ә Ай-Петрига?
— Ай-Петри Алупка белән Ялта арасында. Аңа чаклы тагын җиде минут.
— Маршрутны төгәл сакларга! — дидем мин.
Билгеле, Хивазның «Ялтага туры сызык белән» дип сүз башлавы тикмәгә түгел. Ул тәҗрибәле штурман, мотор бар көченә эшләсә дә, биеклекнең һаман кими баруын күреп тора. Димәк, без җиргә юнәлгән мәкерле һава агымына туры килгәнбез. Аның тырнагыннан ычкыну, ай-һай, авыр. Тагылган йөкнең нормадан артыклыгын искә төшерсәң, бөтенләй өмет өзелә. Ниләр генә дип шундый ерак маршрутка өч йөз кило йөк белән чыгып киттек икән соң?! Өйрәнелгән маршрут, булса бер хәл иде...
Һаман түбәнәябез... Болай ярамый. Ни дә булса эшләргә кирәк.
— Хиваз...
Штурман сүземне әйтеп бетерергә ирек бирмәде, эндәшүемнә үзенчә аңлап: «Тагын илле биш секунд!» — диде.
— Ай-Петриның... төгәл биеклеге күпме? Картадан күрмим...
— Мең ике йөз утыз өч метр.
Биеклекне үлчәү приборы 1150 метр күрсәтә иде.
Тәвәккәлләп уңга борылдым. Башка чара юк. Хәзер урап әйләнү хисабына биеккәрәк күтәрелергә тырышырга кирәк. Диңгезгә таба искән һава агымына каршы очу ярады. Мең дүрт йөз метрга күтәрелә алдык. Арырак очсаң, биеклекне арттыра төшәргә дә мөмкин булыр иде, тик бензин аз кала шул...
Ай калыкты. Күктә эреле-ваклы бихисап йолдызлар җемелди. Аста — күгелҗем ефәк тышлы кәләш юрганыдай таулар сузылып ята. Юрганга бик охшасалар да, җылы юк, йомшаклык юк аларда.
Ә биеклек үлчәгечнең угы, тетрәнә-тетрәнә, төшүен дәвам итә...
— Ай-Петрига күпме?
— Минут чирек...
Тагын борылып китәргә туры килер микәнни? Киеренкелекне йомшартырга, куркыныч турында уйламаска тырышып:
— Хиваз, синең Алупкада булганың бар идеме? — дидем.
— Юк, Мәгубә апа...
— Монда Воронцов дигән берәү «Мең дә бер кичә» әкиятләрендәгечә иттереп гаҗәеп шәп таш сарай салдырган булган. Ә сарай эчендәге затлы әйбер, алтын-көмеш кырык дөягә төясәң дә бетәрлек түгел, ди.
— Немец аны дөяләргә түгел, корабларга төяр шул инде, Мәгубә апа-җан...
— Төяр-төяр... Ә без синең белән ни өчен? Тыныч кына төятер өченме? — Телем сөйли, ә күзләр һаман тетрәнеп түбәнәя барган теге кызыл укта... Әнә ул 1290 ны күрсәтә. Менә 1270 кә калды. 1250... 1240... 1235... Кабат борылырга телим... Минут чирек үтте бит инде...
Хиваз шул чак:
— Унбиш градус сулга! — дип, катгый итеп әмер бирде. Мин аның тавышында: «Әгәр шулай борылмасак — беттек!» — дигән мәгънәне ишеткәндәй булдым.
Самолетны ул кушканча бордым. Уңда, бездән кырык-илле генә метрда шайтан бармагыдай каралып, Ай-Петри утырып калды...
Икебез дә җиңел сулап куйдык. Мотор, авыр имтихан тапшырып чыккандай, дәртләнеп эшли. Хәзер мин аңа ял бирәм: Ялта портына без тавышсыз гына очып килергә тиеш. Мәшһүр Ливадия өстеннән үтәбез. Зиннәтле ак сарайларны күргәндәй булам. Монда элек җәйге айларда патша һәм аның хатыны, бала-чагасы, иярченнәре яшәгән. Севастопольны алгач, немецлар монда зур тантана ясаганнар. Шушында,

Гитлер боерыгы буенча, генерал-полковник Эрих фон Манштейнга иң югары чин — генерал-фельдмаршал чины бирелгән.

«Ореанда» тирәсендә диңгез култыкланып шәһәр эченәрәк кереп тора. Хиваз, рәхмәт төшкере, беренче САБны шул тирәдә ташлады. Аның яктысында яр буйларын шактый ачык шәйләргә мөмкин иде. Әнә, бер-бер артлы тезелеп, причалга таба автомашиналар колоннасы бара... Кырык дөя күтәрерлек кенә байлык төялмәгән аларга! Ә суда әнә үз йөрешле баржалар аларны көтеп тора. Алар күп — унбишләп. Берикесен зарарласаң да унөче исән калачак. Димәк, баржаларны түгел, бәлки причалны бомбага тоту мәслихәтрәк: причал җимерелсә — аларга йөк төяп булмаячак!

Прожекторлар кабынды. Зениткалар телгә килде. Беренче ике бомбаны причалның диңгезгә чыга торган ягына ташладык. Нәтиҗәсе без көткәннән дә яхшырак булды—бомбабызның берсе фашистларның баржаларын ягулык белән тәэмин итү урынына туры килгән иде. Андагы ягулык шартлап, койрыгыбызны өтеп ала язды. Бөтен тирә-юньгә ут җәелде. Причал койрыгы яна, диңгез өсте яна! Ут үзләренә дә кучмәгәе дип шүрләп булса кирәк, буш баржалар ачык диңгезгә чыгып шылу ягын карый башлады. Безгә шул кирәк тә.

— Хиваз, причалның икенче башына барам! Әйбәтләп төзә!..

— Җаксы! Җаксы, командир! — диде штурманым.

Ләкин зениткалар әйбәтләп төзәргә ирек бирмәде безгә. Ут давылы эчендә калдык. Шундый чакта берәрсе ярдәмгә килсә икән!.. Юк, кайда соң башкалар? Бомбаларны причалга җитәрәк ташларга мәҗбүр булдык. Өчесе бушка китте, дүртенчесе яр кырыена кагылган рәт-рәт субайларны кубарып диңгезгә атты. Эх, чак кына сабыр итеп, менә бирегә, причалның үзенә тидергән булсаң, Хиваз! Нишләмәк кирәк, каплкан саен калҗа эләкми ди бит әнә казакъ баласы. Дөрес әйтә. Моторны кабызып, диңгезгә тайдык. Маякта дөрләгән ут Гурзуфка җитәрәк тә күренә иде әле...



## Шатлана беләсезме?

Безнең гаскәрләр, дошманны кысрыклап, көн-төн алга бара. Кояшлы Кырым җиренең күп өлеше азат ителде инде. Фашистлар, ике яклап Севастопольгә чигенеп, рәт-рәт ныгытмалар артына кереп ышыкланды.

Гитлер, Кырымны кулдан ычкындыра барган өчен 17 нче немец армиясенең командующие генерал Енекены постыннан алып, аның урынына генерал-полковник Альмендингерны билгеләгән. Ләкин командалык итәргә фюрер үзе килсә дә, бу якларда көннәре санаулы инде аларның.

Без Карловкага күчтек. Кара көннәрдә дә оккупантлар хакимлегенә буйсынмаган зур гына авыл ул. Монда да, Ассиновская станицасындагыча, халык безне ипи-тоз, якты йөз белән каршылады. Хәтта бәйрәм ризыклары да пешергәннәр иде.

— Туйганчы ашагыз, кызлар! Мондый нәрсәләрне сагынгансыздыр инде, — диләр.

Авыл хатыннары, яшьле күзләрен сөртә-сөртә, безне котлыйлар, безгә иминлек, бәхет телиләр. Кулларына ак күмәч һәм кабартма тоткан сабыйлар, әлегәчә күрелмәгән бу хәлләргә тәмам хәйран калып, борын астын сөртергә дә онытып торалар. Кыюраклары бәйрәм алып килгән очучы апаларының итәгенә үрмәли, орден, медальләрен капшап карый.

Механик Ганна Барсунь үз нарасыйларын күргәндәй шатланган.

Мисыр кугәрчене кук гөрләп, балаларны күкрәгенә кыса, туймастай булып үбә.

— Ой, нинди рәхәт, ой, нинди рәхәт!.. Ике күз нурымны имезүләрем исемә төште! — ди ул, Пилипенкога кайнар пышылдап. — Наныйларыма посылкабыз барып җиткән. Җиткән! Хәзер инде алар ачка үлмәячәк. Үлмәячәк!..

Пилипенко, Ганнаны тынычландырырга теләп, кое янында салкын су белән юынырга чакырды. Кое чыгырының шыгырдап әйләнүе, чиләктән чайпалып түгелгән суның түбәндә чәпелдәве иргә чыгып, тыныч тормышта яшәүнең тәмен татып караган яшь ханымны рәхәт үткәннәргә алып китте, күрәсең. Ул үтә күренмәле су тамчылары эленеп торган каш-керфекләрен, алсу шома битен сөлге белән сөртә-сөртә, урамда вальс әйләнә башлады. Бернәрсә ишетми, бернәрсә күрми. Колак төбендә хәләл иренең ягымлы тавышы, сөекле балаларының чыркылдашып көлүе...

Без, бер төркем командирлар, күләгәдә яңа задание белән танышып утыра идек. Һәммәбездә Севастополь карталары. Шәһәргә бару юлларында чәнечкеле тимер чыбык киртәле траншеялар, окоплар, пулемет оялары, дотлар, батареялар, тагы әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр... Болары разведка билгеләгән мәгълүматлар, ә билгеле булмаганнары ничаклыдыр?!

Көтмәгәндә, кояш артыннан ыргылып чыккан кебек, өстебездә ике «Миссершмитт» пәйда булды. Берсе авыл читендә торган самолетларыбызга ташланды, икенчесе урамга кургаш яңгыры сибеп узды. Шунда ук ике самолетыбыз яна да башлады.

Бершанская, сикереп торып, штаб начальнигына:

— Күктә Чечнева, дивизия белән элемтәгә керсен. Истребительләр җибәрсеннәр! Башкалар — минем арттан! — дип боерды.

Янгынга ташландык. Бер төркемне Евдокия Давыдовна, икенчесен Ләйлә ияртте.

Бершанская кулына күн перчаткасын кия-кия:

— Иң әүвәл яна торган машиналарны читкә этәргә! — дип кычкырды. — Тик сак булыгыз...

Самолет чытырдый-чытырдый яна. Канатлардан утлы тамчылар тама. Безнең чәчләр, каш-керфек өтелә, гимнастеркалар көйри. Түзеп булмаслык кызу...

Ачы чинап, янгын сүндерү машинасы килеп җитте. Шлангтан су бөркелде. Бер самолетны сүндердек, ә икенче самолет дөрләп яна бирде. Менә ут бензин багына үрләде.

— Ложись!..

Колакларны тондырып һавага ут чүмәләсе бөркелде. Ул шундук чәчрәп җиргә төште һәм әйләнә-тирәдә алтын телле уннарча учаклар хасил булды.

Шул арада тәнне чымырдатып, йөрәккә салкын йөгертеп, артта зәһәр «та-та-та-та!» яңгырады: кара тәреле тилгәннәр тагын әйләнеп килгән иде.

Тагын бер самолетка ут капты.

— Болай алар безнең барлык машинаны яндырып бетерә! Кайда, кайда истребительләр? — дип өзгәләнде полк командиры.

Килделәр безнекеләр, килделәр, җанкисәкләрем.

Һава сугышы башланды. Һәм күп тә үтмәде, муеннарына кара шарф тагылган тилгәннәр икесе дә җиргә мәтәлде.

Янгын сүнделәлде. Ике экипаж атсыз җайдак хәленә калды.

Авыл халкы урамда ятып калган Ганнаны алмагач төбенә күләгәгә төзәтеп салган иде инде. Кулларын күкрәгенә кушырганнар. Күзләре йомылган. Кипшенергә дә өлгермәгән чигүле сөлге шома ак маңгайга басып куелган, аңа кан тибеп чыккан.

Әле кайчан гына солдат апаларының тезендә утырып, аның тәти орден, медальләрен тотып-тотып караган сабыйлар, авызга бармак кабып, тынып калганнар иде.

Бакчадагы алмагачлар җиргә чәчәкләрен коя, гүя алар да яшь түгә иде.

Карловкада бүген шушы ярты сәгать эчендә җиде кешенең гомере өзелгән иде.

Башымны аска иеп штабка юнәлдем.

— Авыл халкыннан ни өчен болай үч алулары аңлашыла-а-а, — диде сузып кына бер таныш тавыш. — Таулардан төшкән егетләр шушы авылда Севастопольгә барырга тиешле немец обозын элэктергәннәр иде.

— Кем соң бу? Кайда күргәнем бар бу кешене? — дип уйладым мин, таякка таянып җәһәт-җәһәт атлаган биштәрле, сәләмә киемле агайга карап.

— Танымыйсызмы? — диде ул елмаеп. — Танымассыз шул. Кызлар хәтере кыска була бит ул!

— Тимершәех агай!!

— Әкренрәк, якташ...

— Авылда дошман юк ич! — дидем мин.

— Дошман бар дип әйтмим. Әмма сакланганны ходай саклармын дигән. — Ул тавышын акрынайта төшеп өстәп куйды. — Бүген мин Тимершәех түгел, ә Вәли Әхмәтов, мөсафир, ягъни мәсәлән. Азык-төлек җыеп, кызларым янына кайтып барам. Белбектә хатыным туганнарында булдым... Сөалың бармы? Булмаса, миндә бар, командирыгыз кайсы йортта тора?

Мин хәйләле елмаеп:

— Белбектән аңа да күчтәнәчләр биреп җибәрделәрмени? — дидем.

— Җибәрделәр шул. Әманәтне тизрәк тапшыру яхшы. Ихтимал, аның да сез кызлар аша җибәрергә хәстәрләгән күчтәнәчләре бардыр, ә?..

— Булмыйча... Һәр әрҗәдә илле кило да йөз кило!

Мин «мөсафир агай»ны Бершанская янына алып кердем. Бершанская, мине чыгарып торып, карт белән икәүдән-икәү генә калып сөйләште дә, соңыннан дәшеп кертеп:

— Бу иптәшне бик тиз Симферопольгә илтеп куярга кирәк. Башындагы бер бөртек чәченә дә зыян килмәскә тиеш! — диде. Аннары командир, аңлаешлы булсын диптер, ахры, өстәп куйды: — Мин бүгенге налетны күздә тотып әйтәм, Мәгүбә Хөсәеновна. Сак була күрегез. Иптәш кыйммәтле мәгълүматлар китергән...

Мин өстәлгә җәеп салынган картага күз төшереп алдым. Севастополь тирәләре кызыл һәм зәңгәр билгеләр белән шактый гына чуарланган иде....

Җиңел машина безне самолет янына ук илтеп куйды. Очтык. Юлда барганда мин сәер мөсафирның Саба районы егете Гайнанов икәнлеген белдем [1]. Ул Кавказны һәм Кырымны берничә тапкыр җәяү йөреп чыккан.

Теге чакта без аның белән Иске Кырымда очрашканнан ары Гайнанов «хатыны туганнарында кунакта» йөргән: төрле кыяфәтләргә кереп, немецларның Севастополь оборонасы турында бөртекләп мәгълүмат җыйган, шушы хәтәр эшкә бүтән патриотларны да тарткан.

Безгә каршы торган 17 нче армия биш немец, өч румын дивизиясеннән гыйбарәт икән. Анда 72 мең солдат һәм офицер, 1500 туп һәм ми-

---

[1] Якташыбыз Т. Гайнанов ике елдан артык дошман тылында йөри, партизаннарның кыю разведчигы була. Элемтә урнаштыра, бик күп хәтәр операцияләрдә катнаша. Сугыштан соң Т. Гайнанов Казан аэропортында эшләде, 1968 елда вафат булды. (Автор.)

номет, йөздән артык самолет, шактый гына танклар һәм танкка каршы ата торган орудиеләр бар икән.

Яңа командующий Альмендингер үз приказының ахырында: «Рус — лар Севастопольны сигез ай үз кулларында тоттылар, без исә сигез ел тотачакбыз!» — дигән.

Генерал тикмәгә генә лаф ора торганнардан түгел. Ул бу сүзләрне хәрби белгеч-инженер буларак әйткән. Севастополь өч рәттән торган көчле оборона корылмалары белән уратылган. Балаклавадан Белбеккәчә беренче рәт, Любимовкадан Круглая култыгынача икенче рәт, шәһәр читләре — өченче рәт. Болар өстенә беренче, икенче рәтләр арасында Мекензи таулары, Сахарная Головка һәм Сапун-тау биеклекләре тимер-бетоннан коелган ДОТлар, траншеялар, җир асты корылмалары, көчле ут нокталары белән нығытылган. Чикләнмәгән күләмдә сугыш кирәк-яраклары туплаган бу үлем базларын ваттырмасаң, шәһәргә кош та үтеп керә алмаячак...

Гайнанов сөйләде дә сөйләде. Мин аның хәтеренә сокланып бетә алмадым. Шул чаклы мәгълүматны ничек истә тотмак кирәк?! Кайда нинди часть урнашуын, командирының кем икәнлеген, корал төрен, барысын-барысын белә иде ул.

...Кич Белбек тирәсендәге нығытмаларны бомбага тотарга очтык. Бередән Икенче гвардия армиясенең 13 нче һәм 55 нче укчы корпуслары Мекензи таулары юнәлешенә таба һөҗүмгә күчәргә тиешләр. Бу һөҗүмнең уңышлы чыгуы күбесенчә артиллерия һәм авиациягә бәйле. Икенче гвардия армиясе дошман оборонасын өзеп керергә тиешле участокның һәр чакрымына уртача 180 орудие куелган. (Кайбер участокларда 250 гә чаклы.) Димәк, командованиенең авиациягә өмет баглавы ап-ачык.

Без 27 нче апрельдән алып 8 нче һава армиясе составында сугыша идек инде. Имеш-мимеш хәбәрләргә караганда, элеккеге командующиебез К. А. Вершинин, үз штабы белән, 2 нче Белоруссия фронты карамагына җибәрелгән, ди. Кызганыч, аңа тәмам ияләшеп беткән идек инде.

Яңа начальство безгә ничек карар? Көндезге «ЧП» — немец истребительләренең ике самолетны сафтан чыгарып китүе ышанычны какшатмасмы?..

Штурманым Валя:

— Цельгә якынлашабыз! — дип уйларымны бүлде. Гадәттәгечә, моторны сүндереп килсәк тә, сизделәр. Прожекторлар, көткән кунакларын капка төбенә чыгып каршылаган хуҗалар кебек, нығытмаларга житкәнче үк күкне яктырттылар. Зенитчылар каршыбызга бәйләм-бәйләм ут букетлары чөяргә керештеләр. Илледән артык очыш ясап, калын тиреләгә әверелгән Валя бүген сокланмыйча кала алмады.

— Әнекәем, нинди матур!..

— Курергә күркәм, тотарга куркам, диләр бездә. Давай, Валя, күзеңне ача төш!..

Самолетны әле уңга, әле сулга бора-бора юлны дәвам итәм. Якйакта, күзләрне чагылдырып, шартлаулар хасил була тора. Әйтерсең төнге күл өстенә шулай төнбоеклар калка һәм мин, аларга бәрелмәс өчен, көймәмне боргалап барам. Идарә токкасын кыскан кулым тирләп чыкты. Эчке күлмәгем аркага ябышты. Канат астына өч йөз кило йөк тагылган килеш төрле маневрлар ясап очуы кыен шул...

Шулай да бомбаларны барыбер тиешле урынга ташладык: аста ярыйсы гына шартлаулар барлыкка килде...

Бу төндә без унберәр очыш ясадык.

Полкка бомба ташып өлгертә алмыйлар. Бершанская канәгать, парторг Рунт канәгать. Хәзер алар яңа начальство белән аяк терәп сөйләшә алачак.

Иртән сәгать 10 да армия артиллериясе тоташ ике сәгать буена дошманның оборонасын талкыды. Җир сәлкенде, җир калтырап торды. Җир риза, азатлык хакына барысына түзәргә риза...

Артиллерия уты басылуга 8 нче һава армиясенең штурмовиклары очты. Аларның бер төркемен икенчесе алмаштырды... Тәүлек эчендә 1332 очыш ясалды. Белбек тирәсендәге ныгытмаларның шактые урынында таш кисәкләре һәм тәкә мөгезедәй кәкрәйгән корыч өрлекләре тырпаеп, пыскып яткан тирән чокырлар гына калган иде.

Көндезге 12 дә безнең гаскәрләр һөҗүмгә күтәрелде. Тоташ биш сәгать дәвам итте бу кан койгыч сугыш. Артиллерия уты һәм бомба тимәгән бетон корылмалардан яуган кайнар кургаш күп яшь гомерләрне кисте. Ләкин һөҗүм тукталмады. Гвардиячеләр, штык сугышын дәвам итеп, икенче һәм өченче рәт траншеяларга бәреп керделәр.

Караңгы төшәр-төшмәс үк без дә дошман позицияләренә очтык. Кичәге утлы букетлар, бүгенге белән чагыштырганда, пүчтәк кенә булган икән ул. Бүген күктә — тоташ ут! Снаряд бензин багына тимәсен дә, бомбаларга тимәсен. Бөтен теләк шул.

Валя, давыллы диңгездә мәрҗән утраулары арасыннан корабльне алып барган капитан сыман, үз-үзен белешмичә, тамагы карлыкканчы кычкыра. Кайсы якка борылырга кирәклеген үзем дә күреп торам, ләкин штурманга ачуланмыйм: вакыт юк. Менә уң як канатта баш сыярлык тишек барлыкка килде. Расчалканың бер ябе юкка чыкты. Самолетны идарә итү коточкыч кыенлашты. Прожекторларның берсеннән ычкынабыз, икенчесенә эләгәбез. Ут, төтен, дары исе...

Ниһаять, Валя:

— Цель! — дип кычкыра.

Бомбаларны түбәнгә очырабыз.

Җәһәннәм утына Чечнева килә. Аның артында Ләйлә. Аннары — Макарыч. Бу ике экипаж, цельгә Чечневаны җибәреп, үзләре ни өчендер кырыйгарак борылды. Тизлек азая төшкәнгә, мин хәзергә һәммәсен күреп кайтам. Ни өчен кырыйгарак борылдылар икән соң? Аңлашылды: дошманның зенит батареясен дөмектерергә чамалыйлар. Әйбәт! Бик дөрес карар бу!

Көч-хәл белән исән-имин кайтып төштек.

Пилипенко, учын-учка бәреп, яраткан «мамочка моя»сын әйтте дә үз бригадасын без алып кайткан тишек-тошыкны ямарга куйды.

Яныбызга ашыгып килеп җиткән Бершанская:

— Я, ничек, Сыртланова, бик кызумы анда? — дип сорады.

— Урак өстендәгедән дә кызурак, иптәш командир, — дидем мин, честь биреп. — Фашистлар бу юнәлешкә өстәмә көчләрен китергәннәр булса кирәк. Макарыч белән Санфирова экипажы зенит батареясен бомбага тотарга ниятләп калды. Шунсыз ярамый хәзер...

— Ремонтлаган арада сезнең самолет белән очып кайтыймчы, — дип, Бершанскаяга мөрәҗәгать итәргә авыз ачкан идем, полк командиры өлкән инженер-техникка:

— Озеркова! Минем самолетны очышка әзерләгез: биш минуттан үзем очам дип, ашыгып КПга китеп барды.

Полк командирының сугышчан заданиегә очуын дивизия командованиесе беркайчан да хупламый иде. Аны һаман кисәтәләр, ә бу оча бирә. Теге яки бу участокта килеп туган кискен хәлне үз күзләре белән күрергә омтыла ул.

Бүген резервта штурман юк икән ләбаса. Очышлар буенча үз урынбасары Амосованы заданиегә алып китәр микәнни? Бу бит бернинди

инструкциягә сыймый. Бәхетсезлеккә очрасалар, полк җитәкчесез калачак... Мин, төн куенында аэродром ыгы-зыгысын тыңлап, әнә шулай уйлап утырам. Утлар сирәк-сирәк кенә кабынып ала. Немец авиациясе Кырымда өстенлекне җуйса да, саклану чараларын тиешенчә үтибез. Командир нишләр? Әнә аның самолетын әзерләп бетерделәр...

Евдокия Давыдовна аптырап калмады, минем Валяны алып китте.

Чечнева кайтты. Аның самолетын да иләк ясап җибәргәннәр. Ул, канатлардагы тишекләрне тиз-тиз яматкач, фюзеляжны иртәгә көндез карарсыз дип, командир булмаудан файдаланып, җәһәт кенә стартка борылды.

Ах, Марина! Син бит, җаным, элегәчә беркайчан тәртип бозмадың. Ни дип бүген тәкатьсезләнәсең? Механигыбыз Ганка Барсунь үлеме өчен тиешенчә үч алырга теләү шулай ашкындырамы үзеңне?! Әллә йөгереп барып үгетләп карыйммы? Тыңламастыр, ахры. Әле күптән түгел генә этисенең үлем хәбәре килде, аннары сөйгән егетенең госпитальдә «Марина», «Марина» дип саташып җан бирүен әйттеләр. Һәм — Ганка. Орчык хәтле генә кызчыкка бу хәсрәтләр күбрәк түгелме икән соң?! Кайдан көч таба ул, ничек түзә? Ничек өлгерә? Командир булarak та бик тырыша. «Давай, парторг, уйлашыйк әле» дип, миннән киңәш сорый, төпченә, һәр вакыт гадел була белә. Иң чуалчык мәсьәләләрне дә, әллә ничек шунда дөрес сизенеп, гел тиешенчә хәл кыла. Ничек яратмаска ди шундый командирны?

Бершанская самолетын да ремонтка куйдылар.

— Хакны әйткәнсез, Марта Хөсәеновна, — диде Евдокия Давыдовна. — Немец безнең Икенче гвардия армиясенә каршы 51 нче һәм Приморье армиясе полосасындагы гаскәрләрен, шул исәптән шактый гына зенит артиллериясен дә, күчергән булырга тиеш. Сапун-таудан бирегә таба хәрәкәт һаман дәвам итә. Моны дивизия штабына кичекмәстән белдерергә кирәк.

Валя кызлардан чәй сорап алды. Полк командиры белән очудан канәгать икәнлеге аның йөзенә чыккан иде.

— Димәк, Валюша, көтмәгәндә-уйламаганда тагын бер имтиханны тапшырып кайттык, ә? — дидем мин.

Валя, кичерешләреннән һаман әле арынып бетә алмыйча, башын селкеде. Кайчандыр туктаусыз бытылдаган кызның сүзсез калуы өчен эчтән генә шатланып куйдым: кеше башкарган хезмәтеннән чын шатлык табып ләззәтләнә, кеше шәхес булып формалаша...

— Я, штурман, сусавың басылдымы?

Валя кабат башын селкеде.

Яктырганчы сигез очыш ясадык. Пилипенко бригадасына тагын әллә ничаклы эш алып кайттык. Агач борысларны котырган эт кимергән диярсең. Галина бу юлы учын-учка бәреп «мамочкасын» да әйтә алмады хәтта, хәйран калып, башын гына чайкады. Күзләрендә моң, сагыш иде. Аның болай чиктән тыш боегуының сәбәбе бар икән: командирыбыз Марина Чечнева очыштан кайтмаган... Экипажны күрүче дә булмаган. Эх, Марина, Марина... Яктыргач төзәттерден менә фюзеляжны...

Кырым җире таулы-ташлы булганга күрәдер, ахры, туп тавышларыннан биниһая кыңгыраудай нык гүләп, яңгырап тора. Әледән-әле тәрәзәләр зыңгылдый, өебез калтырап куя.

Мин, авыр көрсенеп, әйләнеп-тулганып ятам. Баш тубал кебек, аякулларның салам селкетерлек тә җегәре юк. Ял итәргә, хәл җыярга кирәк. Ә күз алдында шул нәләт төшкән утлы бозралар, албасты койрыклы ут шарлары, прожекторлар...

## Кырым тулысынча азат!

Соңгы көннәрдә көнен дә, төнен дә очтык без. Азрак кына черем итеп алуга — күккә. Нәкъ урак өсте инде менә. Әлегә чаклы бу кадәр еш очканыбыз юк иде.

Фашист, Севастопольны бирмәс өчен, барлык көчен безгә каршы куйды. Җирдә, күктә, диңгездә аяусыз сугышлар соңгы өч көндә аеруча коточкыч булды. Безнең 8 нче һава армиясе, дошманга бер минут тынгылык бирмичә, Севастополь әйләнәсендәге ныгытмаларны бомбалады. Шул ук вакытта Северный, Камышлы, Казачий һәм Стрелецкий култыкларындагы корабльләрне, баржаларны бомбалау да дәвам иттерелде.

9 нчы майда көндезге сәгать өчләрдә 1 нче гвардия корпусы һәм 2 нче гвардия армиясе сугышчылары Корабельная бистәсенә бәреп керделәр. 63 нче һәм 10 нчы укчы корпуслар, коньяк-көнбатыш юнәлештә урам арты урамны алып, үзәккә якынлашты. Урам дигәч тә хәзерге матур ак йортларны күз алдына китермәгез тагы. Ул чакта ике яклап таш, кирпеч өемнәре генә пыскып ята иде Севастопольдә. Россия мәмләкәтенең хәрби данын гәүдәләндергән, һәр ташы үлемсез каһарманнарның, мәшһүр полководецларның каны белән сугарылган тарихи каладан дошман ансат кына чыгып китәргә уйламый иде. Китә икән, ул барысын юк итә, хәрабәләр генә калдыра.

Малахов курганындагы Корнилов һәйкәлен дә шартлатып киттеләр ул бәдбәхетләр. Алар өчен нәрсә ул һәйкәл! Туганнар зиратына кагылмасалар икән, ичмаса. Батырлар күмелгән каберләр астына тирәнгә казып кереп блиндажлар, күзәтү, команда пунктлары ясаганнар, складлар корганнар иде хәтта.

Бүген, төнге сәгать өчләргәчә очып, Херсонестагы рәт-рәт чәнечкеле тимер чыбык киртәләрдән, тимер-бетон ут нокталарыннан һәм төрле бүтән җир асты корылмаларыннан торган дошман ныгытмаларын биш тапкыр бомбага тотып кайттык. Бу тирәләр «авария рубежы» дип атала икән. Дошманның 17 нче армиясе моннан диңгез буйлап Румыниягә чигенергә ниятләве көн кебек ачык иде безгә. Чөнки бүтән барыр урын юк. Кырым тулысынча азат ителде диярлек. Бары тик шушы уч төбе чаклы җир калды. Һәм бирегә, елганың тар урынына бөялгән язгы ташкынны хәтерләтеп, качып баручы гаскәр калдыклары тупланды. Әле калган техниканың да исәбе-чуты юк. Дошман рубежында көчле янгыннар чыгарып кайтып төшкәч, Бершанская «авария рубежы»н бомбага тотуны туктатырга боерды.

— Анда хәзер берьюлы мең орудие ата башлаячак. Самолетка үзебезнең снарядлар тиюе мөмкин, — диде ул, сәгатенә карап.

Без тик утырырга тиешменни? Төне менә дигән, дошманнан үч алу өчен моннан да шәбрәк урын тагын булырмы әле. Очасы килә... Безгә төзәп аткан, безнең чәчне вакытсыз агартырга сәбәпче булган дошман артиллериячеләре, прожекторчылары, корыга чыгарып ташланган балык кебек, һәммәсе шул Херсонес борынында котылу өмет итеп ята бит. Фронт командующиебыз генерал Толбухин боерыгында әйтелгәнчә, аларны исән-сау ычкындырырга һич ярамый.

Без, бер төркем очучылар, КП алдында торабыз. Төн җылы, аяз. Ара-тирә генә еракта атышлар ишетелгәләп куя. Менә сәгать өч тулуга төнге күк йөзендә яшеннәр яшьни башлады, көчле гөрелте яңгырады, ул көчәйгәннән-көчәя барды.

— Мең орудие диләр аны!..
— Әйдә, тәмам изсен изсен фашистның!
— Ә без спектакльдәге тамашачы кебек карап кына утырыйкмы?!

Шулай үзара гәп куерткәндә, Евдокия Давыдовна яныбызга чыкты. Без аны артиллерия башлаган эшне карый дип торабыз. Ә ул:

— Гвардейцы, по машинам! — дип кычкырмасынмы.

Биш минут үтмәгәндер, без кабинада идек инде. Мотор салмак кына эшли. Бершанская маршрутны бәйнә-бәйнә аңлатты. Ул бүген аеруча гайрәтле иде.

— Дошманга корабларына төялергә ирек бирмәскә! Корабларын батырырга! Батыра алмаган очракта, аларны буш килеш диңгезгә китәргә мәҗбүр итәргә! — дип боерды полк командиры.

Без, Түбән Чоргун, Федюхин биеклекләре өстеннән очып, Севастопольнең көньяк читенә чыктык. Батырлык, ныклык үрнәге булган каланың данлы үткәне белән яхшы хәбәрдар булган Вера сугышчан заданиегә баруын бөтенләй онытты, ахры, уң як бортка иелеп карыйкарый:

— Аста — Коммунарлар каберлеге, — диде. — Анда 1905 елның ноябренда патшага каршы баш күтәргән 14 хәрби кораб диңгезчеләре күмелгән. Восстаниенең җитәкчесе лейтенант Петр Шмидт та шунда... Беләсезме, Марта Хөсәеновна, ул нинди васыять калдырган?

— Экскурсовод сөйләгән иде сөйләвен...

— Ул болай дигән: «Мине җәзалап үтергәч, күмү өчен, гәүдәм Севастополь эшчеләренә бирелсен иде. Алар мине кабергә озатуда хуҗа булсыннар. Чөнки мин — аларның депутаты, һәм алар гына миңа зур бәхет бирде.

Каберем Севастополь зиратына, төрмә янында 19 октябрьга каршы төндә атып үтерелгән корбаннарның туганнар кабере белән янәшә казылсын. Шушы туганнар кабере янында халкыма турылыклы булырга ант иттем, аңа турылыклы булып калдым. Шуңа күрәдә минем бирегә ятасым килә...»

— Биредә тагын нинди истәлекле урыннар бар, иптәш экскурсовод? — дидем мин шаяртып.

— Сулда — 4 нче бастион. Анда поручик Лев Николаевич Толстой сугышкан. Атышлар тынып торган арада ул шунда «Севастополь декабрьда» дигән беренче хикәясен язган. Ә хәзер, иптәш экскурсант, Стрелецлар култыгына сакланыбрак барырга киңәш итәм: атып каршыларлар.

— Шундый данлы җирдә нигә кунакчыл түгелләр? Җалоба кенәгәсен китерегез!..

— Иртәгә чаклы сабыр итегез инде, иптәш экскурсант. Башта фашистны диңгезгә тибеп төшерик. Әнә ул, ләгыйнь, ничек каршылый...

Култыкның ике ягында прожекторлар кабынды.

Күксел нурлар яр читендә торган корабларның төз мачталарын яктыртып уздылар да күкне айкарга керештеләр. Вера беренче САБны ыргытуга мин самолетны бу урыннан читкәрәк алып китәргә ашыктым. Уннарча зениткалар хәзер бирегә төбәләчәк. Әнә туктаусыз ата да башладылар. Ярдан да аталар, кораблардан да.

Бездән соң очкан Себрова цельгә кергәч, утларның бер өлеше аңа күчерелде. Мин, шуннан файдаланып, култыкка узарга тырыштым. Туры барам. Безнең тирәдә шартлаудан хасил булган ут бөҗрасы кысылганнан-кысыла. Ләкин штурман курсны үзгәртү турында уйламый да. Мин, снаряд самолетка гына тимәсә иде, дип теләп барам.

Кинәт алдыбыздан гына, күзгә күренеп, бер зур снаряд узып китте.

— «Дора»дан аталар! — диде Вера.

— Нинди дура? Үзебез дура булып калмыйк! — дидем мин.

— Фашистларның Севастополь ныгытмалары өчен махсус койдырган туплары бу. Көпшәсенең озынлыгы утыз метр. Лафетының биеклеге биш катлы йортныкы чаклы.

— Кайдан белдең боларны?

— Газетага язганнар иде, — диде Вера. — Давай, иптәш командир, менә шушы үзйөрешле баржаны... Әнә борылырга маташа. Сай җирдә дә йөзә торган яссы төпле баржа ул.

Мин, тешләрне кысып, самолетны баржага юнәлттем.

— Так держать! — диде штурман.

Баржадагылар безгә каршы ут ачтылар. Эре калибрлы пулеметларның бер-бер артлы тезелешеп килгән сары төрткеләре төн пәрдәсенә әллә нинди бизәкләр ясый сыман. Снарядлар ярылып, тирә-юньгә утлы көлтәләр сибелә. Куркыныч... Ләкин Вера курсны үзгәртми. Алай-болай була калса, самолетны менә шушы баржага юнәлтергә исәп тотам..

Кабина алдына куелган махсус пыяла чәлпәрәмә килеп аска коелды. Сискәнеп, иелергә мәҗбүр булдым. Тән калтырый. Тирләп чыктым.

Ниһаять, Вера бомбаларны ычкындырды. Аста су фонтаннары күтәрелде. Димәк, өч бомба әрәмгә китте. Ә дүртенчесе баржаның койрыгына эләкте. Ләкин ул һаман ачык диңгезгә шылу ягын карый... Кызлардан кайсы да булса эшеңне бетерер әле!..

Без кайтып киттек. Дошманның алгы сызыктагы ныгытмаларын артиллерия һаман дөмбәсли иде әле. Аста ут бии, ялкын котыра.

Херсонес борынына без тагын дүрт тапкыр килдек. Чигенүче 17 нче немец армиясенең калдыкларының судноларга төяләргә маташуын тәки өздек. Судноларның беришләре батырылды, беришләре йөк төйи алмыйча шыларга мәҗбүр булды.

Иртәнге тугызларда безнең гаскәрләр һөҗүмгә күтәрелде. Башта танклар кузгалды, аннары — пехота. Җимерттерелгән ныгытмаларда исән калган фашист солдатлары төркем-төркем булып әсир төшүне кулай күрде. Каршылык күрсәтүчеләр өстенә дистәләрчә бомба яудырдык. Менә, ниһаять, атаклы Херсонес маягында Кызыл байрак җилферди башлады. Кырым тулысынча азат! Биредә хәзер безгә каршылык күрсәтүче бер генә дошман солдаты да юк.

Немец-фашист илбасарлар 1941 елның октябренда Кырымга бәреп кергәннәр иде. Алар, тукталып тормастан, Севастопольны алырга ниятләделәр. Әмма максатларына ирешә алмадылар.

1942 елның язында, Англия һәм АКШның Европада икенче фронтны һаман ачмауларыннан файдаланып, гитлерчылар Севастопольга яңа зур һөҗүм башладылар. Бирегә 230 меңнән артык солдат, 450 танк һәм меңнән артык самолет тупланды. Меңнәрчә орудиеләр һәм минометлар, самолетлар шәһәрне биш көн буена тоташкан утка тоттылар. Ваттырылмаган бер генә бина да калмады анда. Ләкин дошман барыбер үтә алмады. Севастопольны саклау 250 көнгә сузылды. Верховный Башкомандующий боерыгы буенча, совет гаскәрләре 1942 елның 3 июлендә генә шәһәрне калдырып киттеләр.

Хәтерегездәдер: 17 нче армиянең яңа командующие генерал Альмендингер, руслар Севастопольны сигез ай сакладылар, ә без сигез ел сакларбыз, дип, үз гаскәрләрен рухландырган иде. Бүтәннәре кебек үк бу да бушка шапырынучы булып чыкты. Безнең гаскәрләр дошманның ныклы Севастополь оборонасын өзүне өч атнада тәгәлләделәр. Ә Севастополь үзе өч көндә алынды. Фашистлар Кырым өчен барган сугышларда 300 меңнән артык солдат һәм офицерларын, 400 гә якын танкларын, шул чаклы ук самолетларын югалттылар.

Верховный Башкомандующий кояшлы Кырымны азат итүдә катнашкан гаскәрләргә рәхмәт белдерде. Моның өстенә безнең төнге җиңел бомбардировщиклар хатын-кызлар гвардия авиация полкы Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнде. Утызга якын очучы төрле орденнар һәм медальләр алды. Ә штурман Женя Руднева Советлар Союзы Герое исеменә лаек булды.

## Гамил Афзал

### Борылам да карыйм...

●

Кәгазьдәй ап-ак кар, ап-ак кар,
Күзләрең күреме җиткәнче —
Үтелгән гомерне язып бар
Күңелнең карасы беткәнче,
Күзләрнең яшьләре кипкәнче...

●

Малай чакта дөнья ямьле иде,
Кесә дә буш иде, күңел дә.
Ә үскәндә кырыс заман килде,
Без һөҗүмгә бардык, үлемгә.
Картайганда кыен көннәр килде,
Авыр безгә иртән-кичен дә:
Заман безгә җаваплылык өйде
Бүгенгесе, киләчәге өчен,
Әллә кайчан үткән өчен дә...

●

Биеклеккә менәсе бар микән,
Төшәсеме упкын эченә —
Сыртларына уйчан үлән үскән
Биек таулар керә төшемә.
Биеклеккә менәсе бар микән...

●

Каерылып кайнады заманнар,
Ярларга чайпалды дулкыны.
Күңелгә моң булып утырды
Ачысы,
        төтене,
                юшкыны.

Тырмашып ябыштык тормышка,
Өметләр сыгылды, кителде.
Ялкынлы, ярсулы сулышта —
Юшкыны,
ачысы,
төтене.

Тимерләр бәгырьгә бәрелде,
Кулларны кабартты катысы.
Барсы да йөрәккә кадерле:
Төтене,
юшкыны,
ачысы.

●

Сулар ага, кайда Сувар, Болгар...
Сирәгәеп калган урманлык.
Биек булмаса да тауларым бар,
Итәгенә ятып еларлык.

●

Һәр яфрагы тере кебек,
Табигатьнең сере кебек
яшел эңгер.
Ак каеннар арасыннан
Яшькелт нурлар коя кемдер,
җилбер-җилбер...

●

Мин барын да күрдем.
Күрсәтмичә йөрдем
кайнар яшьләремне.
Тарадым да үрдем,
Тарадым да үрдем
кара чәчләремне.

●

Мин сайламый идем,
Мин аңламый идем.
Син санламый идең,
Син аңламый идең.

Мин бик юаш идем,
Син бик чая идең.
Мин башымны идем,
Син елмая идең.

Елмайдың да киттең
Гөлләр арасына.
Бик ямансу иттең
Адәм баласына.

Чәчәкләрен чөеп
Матур җәйләр узды.
Сары күзләр килеп,
Тузганаклар тузды...

Сәлам җибәр диеп
Үтенәсең хәзер.
Их, мин юләр диеп
Үкенәсең хәзер...

●

Урманда бер җан елады,
Бер гөнаһсыз җан.
Офыклар авыр сулады,
Көрсенде урман:
— Мин усал булмам!
— Мин усал булмам!

●

Борылам да карыйм
Бормалы юлларга,
Барлыгым офыклар иркендә.
Күңелләр тулганда
Бер сагынып еларга
Ак яулык болгамый беркем дә...

●

Бакчада йөргәндә,
Тауларга менгәндә,
Дусларың көлгәндә боекма;
Гөлләрең шиңгәндә,
Кайгылар килгәндә,
Дөньяда мин барын онытма!

●

Идел буе ил булса да,
Тар буласын сизендек.
Чәчелдек тә сибелдек без,
Чәчелдек тә сибелдек.

Себер ягы, Урал ягы —
Урманлык та тигезлек.
Чәчелдек тә сибелдек без,
Чәчелдек тә сибелдек.

Үзбәк ягы, казакъ ягы —
Җылы як дип сөендек.
Чәчелдек тә сибелдек без,
Чәчелдек тә сибелдек.

Ил булып та, яу булып та,
Еракларда күмелдек.
Дан булып та, моң булып та,
Чәчелдек тә сибелдек.

## Алтын Бөртек

Казан зиратында 1297 нче елда куелган таш бар, ул ташта Алтын Бөртек исемле хатын-кызның вафаты турында язылган.

Бурап-бурап карлар ява.
Кар астыннан борын төртеп,
Борынгы таш сагыш сала:
«Монда ята Алтын Бөртек...»

Язлар килә, дөнья гөжли,
Яфрак яра бөре бүртеп.
Борынгы таш серен сөйли:
«Монда ята Алтын Бөртек...»

Гүзәл-гашыйк җисемең булган,
Ташка язар исемең булган...
Тагын ни дип фикер йөртик,
Алтын Бөртек, Алтын Бөртек!

Яңгыр булып төшмәдең син,
Сәмум булып исмәдең син,
Җиде гасыр онытылмаслык
Нинди эшләр эшләдең син?

Кылыч тотып дан алдыңмы,
Илне саклап, гаскәр йөртеп,
Дошманнардан камалдыңмы,
Алтын Бөртек, Алтын Бөртек?

Шаһзадәләр сокланырлык
Ак кулыңда яулык селкеп,
Әйлән-бәйлән уйнадыңмы,
Алтын Бөртек, Алтын Бөртек?!

Беләзектәй билләреңне
Бөгеп кенә, сыгып кына,
Каш астыннан карадыңмы
Чыбылдыктан чыгып кына?

Очлы күзләр, кыяк телләр
Кемгә агу эчермиләр,
Җан кыялар, мал җыялар,
Кыз гөнаһын кичермиләр.

Харап эшләр, хәтәр хәлләр —
Бер карасаң күзең сирпеп,
Телдә ширбәт, кында хәнҗәр,
Алтын Бөртек, Алтын Бөртек.

Моң булырлык, җыр булырлык
Хәлләреңнән хәбәр көттек,
Ташларга уеп язарлык
Ниләр кылдың, Алтын Бөртек?

Яңа буын тормыш кора,
Машинасын бора иртүк.
Борынгы таш санап тора:
Алтын Бөртек,
Алтын Бөртек...

●

Бәгырьне өткән суыклар сынды.
Яз ямьнәренә җаннар ымсынды.
Яшәрде тугай, җилпенде тургай,
Ярга сыймаган ташулар тынды.

Кояшлы көннәр — озын җыр кебек,
Җылы җил исә — моң-хисле.
Җылы яшь түгә болытлар килеп,
Мең чәчәк үсә — мең төсле.

●

Даннары дулап тарихта,
Шагыйрьләр килгән-киткән;
Бер җырың калсын халыкта,
Бер җырың калсын икән.

Гасырлар аша җемелдәп
Йолдызың янсын икән.
Йөзек кашына куярлык
Бер җырың калсын икән!..

●

Яшьле күзләре кипмәгән,
Яулык болгады бакчадан,
Бу юлдан кемнәр китмәгән,
Бу юлдан кемнәр кайтмаган!

Яшьле күзләре мөлдерәп,
Җилфердәп чыкты капкадан.
Бәхет тәяп, өмет тәяп
Бу юлдан кемнәр кайтмаган!

●

*Габдрәхим Утыз Имәнигә*

Монда фикер туып җырга күчкән,
Шагыйрь килгән шушы төбәктән.
Җилдә шаулап утыз имән үскән,
Айлы кичләр аһәң тирбәткән.

Елап, җырлап күпме еллар үткән,
Сандугачлар сайрый һаман да.
Офыкларга карап нидер көткән
Утыз имән шаулый аланда.

●

Дан кирәкми, мал кирәкми,
ял кирәкми, — эш кирәк.
Җан яңарсын, аң агарсын,
кул кабарсын —эш кирәк!

Чын кирәк дип, мул кирәк дип,
моң кирәк дип, иплерәк
тип, йөрәк!

●

Офыклар артында дөньялар тынгысыз,
Гомергә сагаеп тор икән.
Ә бездә утыз ел хәвефсез, сугышсыз —
Әллә бу иң матур чор микән?!

●

Кызыл болыт болгап шәфәкъ батты —
Үткән заманнарның моңы кебек.
Ак Идел өстенә ай нуры ятты —
Килер заманнарның юлы кебек.

●

Мине, ахры, чиргә сабыштырды
Кояшсыз, чәчәксез соры көз.
Болганчык су кебек ялыктырды
Илһамсыз, рухсыз коры сүз.

Газиз Кашапов

# СӘМУМ ҖИЛЕ

*Бәйгеләрдә җиңеп килгән кебек,*
*Ялларына ятып атымның,*
*Аяз көндә олы юлга чыктым,*
*Еллар кочагына атылдым.*

*Бу шигъри юллар Газиз Кашаповның үз биографиясеннән. Олы юл аны әтисе әзеннән алып килә, офицер итә, кырыслыкка, «дөнья малларына алданмаска» өйрәтә. Изгедән-изге бурыч — илне саклау.*

*Кинәт җайдакның аты сөрлегә: фаҗигале авария. Хәрби госпиталь койкасы. Айлар, еллар буе үлем белән тартышу.*

*Газиз Кашапов исеме поэзия сөючеләргә гражданлык тойгысына бай, якты фонлы, омтылышлы лирик шигырьләре белән таныш. «Сәмум җиле» повесте — авторның проза мәйданына беренче җитди адымы. «Ахыры ни белән бетәр?» — әсәрне укыганда шул сорау сине буеннан-буена дулкынландырып, борчып тора. Геройлары тормышка, кешегә, көрәшләренә битараф түгелләр. Чөнки хәрби семьяда битарафларга урын юк.*

*Үлем белән көрәшүче Рамиз Җәләев, аның тормыш иптәше Фагыйлә, медицина фәннәре докторы, полковник Ирина Андреевна, үзе үлгәндә дә Рамизда яшәү өчен өмет чаткысы уятып киткән көчле рухлы коммунист, генерал-лейтенант Орлов — болар һәммәсе саф күңелле, кеше язмышын ил язмышы белән бәйли белүче кешеләр, хәтердә калырдай образлар.*

*Укучыга алдан ук барлык «карта»ларны да ачып салмыйк. Газиз Кашаповның күләмле беренче проза әсәренә карата ул үз хөкемен чыгарыр. Авторга киләчәктә хәерле юл — авариясез юл телик!*

**ӘДИП МАЛИКОВ.**

Әниемнең якты истәлегенә багышлыйм.
Автор.

ПОВЕСТЬ

## 1



ивизияне сугышчан тревога белән күтәрделәр. Санаулы минутлар эчендә сугышчан әзерлек хәленә килеп гарнизоннан чыккан батальоннар җыелу районына тупланды. Озак та үтмәде, киртләч биек тау итәгендәге КП [1] да рота командирына сугышчан бурыч тапшырылды. Рамиз ротасы авангардта барырга тиеш. Бернинчә минуттан рота алдагы машиналарны әйләнеп узды да олы юлга чыкты. Җир өстен төнге куе караңгылык каплаган иде. Кичтән явып узган яңгыр болай да салкынча көзге һаваны тагын да салкынайткан. Озакламый рота дәүләт чигенә килеп җитте һәм, бу изге сызыкка аяк басарга кыймыйча, туктап калдылар. Наушникларда дивизия командирының боерыгы ишетелде: «Кадерле иптәшләр,— диде ул.— сезгә мәгълүм булганча, дөнья капиталистлары безнең күршебез, социализм төзүче Венгриядә, кайбер вакытлы авырлыклардан файдаланып, аны эчтән җимерү юлына басканнар иде. Бүген төнлә Венгриядә контрреволюцион фетнә купкан. Аның җитәкчеләре халык хөкүмәтен бәреп төшерү бурычын куя. Венгрия коммунистлары һәм эшчеләренең соравы буенча, безнең илебез социализм төзүче дәүләткә ярдәм кулын сузарга булды. Алга — Будапештка!»

Корыч машиналар, барлык куәтләренә үкереп, алга ыргылды. Рамиз машинасы контроль полоса алдында бер мизгелгә генә тукталган кебек булды да чикне беренче булып үтте. Аның артыннан, тигез ара калдырып, башка машиналар да алга омтылды... Алда, инде тарала башлаган караңгылык эчендә, дус илнең беренче шәһәре калкып күренде. Рамиз радиодан батальон командирына шул турыда хәбәр иткәч, машина йөртүчегә:

— Алга, алга, тизлекне әкренәйтмәскә! — диде. Шәһәр уртасындагы борылышны узганда, Рамиз машинасы астында чүмәлә чаклы ут хасил булды. Машина, бәйгедә килгән ат йомшак туфракка батып җиргә ауган сыман, сөрлегеп куйды. Аннары шартлау дулкыны белән күтәрелде дә чалкан әйләнеп төште. Рамизлар артыннан килә торган машина юл читендәге канауга борылып, янтаеп туктады. Солдатлар яшен тизлеге белән җиргә сикерделәр. Якындагы йорт тирәләрендә дә, бакчаларда да кеше күренмәде. Бары тик шартлау тавышы гына

[1] КП — команда пункты.

таулар артыннан кайтаваз булып килде дә тагын каядыр китеп югалды.

... Рамиз унҗиде тәүлектән соң гына аңына килде. Башта аның колагына ниндидер аңлаешсыз авазлар ишетелде. Ул тавышлар, төпсез коедан килгәндәй, тоның иде. Ул уң кулын күтәрергә тырышып карады, ләкин кул буйсынмады. Өстенә тегермән ташы төшеп утырган диярсең... Сул кулы да шулай ук җансыз... Егет теге аңлаешсыз авазларга колак салып тагын бераз ятты да, тәмам уянып китүенә ышангач, башын күтәрә башлады. Сизелер-сизелмәс кымшанудан да арка сөяге буйлап миллион энәләр аяк табанына тикле чәнчеп узды һәм, кире муенга таба күтәрелеп, түзә алмаслык авырту кузгаттылар. Рамиз ишетелер-ишетелмәс кенә:

— Әә-әә-ни, — дип пышылдады.

Җавап кайтарган кеше булмады. Рамиз ялварып дәшкән ана моннан якын да, ерак та иде... Егет бик авырлык белән генә күзләрен ачып җибәрде. Дөньяны сокланырлык матур, зәңгәрсу томан каплаган иде... «Күрәсең, болында төнге күкне күрәмдер, — дип уйлады егет. — Алай булса, нигә соң йолдызлар юк? Нигә куллар күтәрелми?.. Төш күрәм микән соң әллә?..» Ләкин егетнең күз алдындагы зәңгәрсу томан һаман таралмады. Шулай үз-үзе белән сөйләшеп байтак яткач, ул тирә-юньдәгеләргә эндәшеп карарга булды. Ләкин аның бу тырышуы да бушка иде. Рамизда әле кеше ишетерлек итеп дәшәрлек көч юк иде. Аның бөтен гәүдәсе марля белән уралган. Тәне утка салгандай яна. Маңгаена бәреп чыккан бөрчек-бөрчек салкын тир бөртекләре марля тасмаларын чылаткан.

Рамиз үзенең кайда һәм нинди хәлдә икәнлеген һаман төшенә алмады. Әлеге бихисап күп һәм үткен энәләр янә башыннан аягына тикле чәнчеп үткәннән соң ул тагын һуштан язды, аннары йокыга китте...

Рамиз, имеш, Төмчә елгасы буендагы зәңгәр чәчәкле киң болында ята. Биектә-биектә, әллә кайда, күк гөмбәзе күренә. Ара-тирә генә таркау аксыл болытлар агыла. Тыныч болынны гаҗәеп аһәң белән тутырып, күктә тургайлар чутылдый. Бөтен тирә-якка чәчәк исе таралган. Печән өсте. Аргы яктан чалгы кайраган тавыш ишетелә. Йомшак үлән өстенә чалкан яткан Рамизның битен җылы җәйге кояш нурлары иркәли. Алар тәнгә сихәт, йөрәккә куәт бирәләр кебек... Рамиз тургайлар сайравын тыңлап торды-торды да, терсәкләренә таянып, көч-хәл белән башын күтәрде. Авыл ягына таба борылып карады. Авыл читендәге бакча сукмагыннан, көянтә-чиләк күтәреп, өстенә кызыл чәчәкле күлмәк кигән, зәңгәр косынкалы кыз чишмә суына төшеп килә. Кызның көянтәсенә эленгән чиләкләр көе шулай уяттымы икән әллә Рамизны? Шулайдыр... Авылдагы чиләк баулары чыгарган көйләрне Рамиз яхшы белә. Ә бу көйне, менә хәзерге минутта, сукмак буйлап килгән кызның чиләк баулары көен ул шартлап ярылган туп гөрелтесе арасыннан да таныр иде. Бу көй авылда бер генә көй. Рамиздан башка аны беркем дә белми. Хәтта һәр көн саен шушы көйне уйнатып суга баручы кыз үзе дә моңа игътибар итми торгандыр... Рамиз башын йомшак үләннәр өстенә куйды да, һавага карап, әлеге көйне тыңлап ятты. Беравыктан кабат күтәрелде. Кыз, тыкрыкны үтеп, чишмә ягына таба китеп бара иде. Чәчәкле кызыл күлмәк ераклашканнан-ераклашып, елга ярына барып җиткәч, бөтенләй үк күренми башлады. Рамиз, көрсенеп, башын яңадан җиргә куйды. Бу юлы аңа нәрсәдер комачаулый иде. Башын икенче урынга күчерде, ләкин монда да аңа нәрсәдер комачаулады. Ниндидер көч аны әйләндереп, йөзтүбән ят-кырды. Шул вакыт ялангач биленә якында гына выжылдап йөргән бал

корты килеп кунды. Ул кояшта янып каралган арканың чәчкә түгеллеген белгәндер... Ялгыштынмы әллә, бал корты? Рамиз кымшанмады. Бал корты үзенең кечкенә һәм үткер угын бил тиресенә батыра башлады. «Эх, туган, — дип уйлады Рамиз, — мин бит сиңа усаллык эшләмәдем, нигә, угыңны миңа кадап, үз гомереңне үзең кистең? Юк!— диде ул бераздан, — юк! Бал корты бер дә юкка кешене чакмас, мөгаен, мин аның кунарга әзерләнеп йөргән чәчкәсен изгәнмен. Шулайдыр... Аю! — дип үртәде ул үзен, — аю, шул кирәк сиңа! Измә гөнаһсыз чәчәкләрне, измә!» Бал корты чаккан урын аз гына сулкылдап торды да берни сизмәс булды. «Шешеп чыгармы икән? — дип уйлады Рамиз. — Юк, бил юка тиреле түгел ич минем!» — дип җавап бирде егет үзенең соравына. Искәртмәстән чыккан өермә баганасы авызга әрекмән яфрагы китереп япты. Аннан күңел болгаткыч авыр ис килә иде.

Икенче мизгелдә, ят, салкын әйбернең бал корты чаккан урыннан умыртка сөягенә керә башлавы тоелды. Нәрсә бу? Әллә тагын корт чагамы? Менә теге каты әйбер умыртка сөяге арасындагы кимерчәкләргә килеп тирәнде һәм ныграк авырттыра башлады. Аның салкынлыгы тәнне чиркандыра. Тупас әрнү умыртка сөяге буйлап өскә күтәрелә. Рамизның уң аягы электр тогы суккан шикелле тартышып куйды. Умыртка баганасы эченә кызган тимер тыгып, аны муенга таба күтәрәләр шикелле тоелды. Рамиз, авыртуга түзә алмыйча ыңгырашып, тирән чокырга егылып төшә башлады. Билгесезлеккә очканда сайрауларыннан тукталып калган тургайларны узып китте. Таркау аксыл болытлар бер читтә күренеп калды. Кеше башлы бал корты, иләмсез авызын ерып, үткер угын күрсәтте. Зәңгәр чәчәкләр иелеп-иелеп нәрсәдер пышылдадылар... Борынны ярып, нашатырь исе килеп керде. Рамиз күзләрен ачып җибәрде. Баягы зәңгәрсу томан азрак тарала төшкән. Каршыда ак кәгазь сыман пәрдә тора. Пәрдәме соң? Юк. Кеше. Хәзер ул кешенең битен каплаган марля да күренә башлады. Ә аннан да өстәрәк, кара кашлар астындагы озын керфекләр арасыннан күзләр, зәпзәңгәр, ягымлы күзләр карап тора. «Могҗиза! — дип уйлады Рамиз, — могҗиза! Әле генә мин чокырга егылып төштем ич. Бу күзләр кайдан килеп чыкты соң?» Менә күзләр елмаеп куйдылар. Борынны ярып кергән нашатырь исе азаеп, бөтенләй сизелми башлады диярлек. Тик күңел генә болгана. Һәм умыртка баганасындагы тупас авырту һаман башына менә бара. Менә инде ул баш сөяген эчтән кыса. Баш сөяге чыдый алмыйча чатный, менә-менә ярылып китәр сыман тоела. Рамиз, тагын ыңгырашып, баягы чокырга ава, борынга янә нашатырь исе тула. Авыр күз кабаклары күтәрелми. Улының хәле кыен булуын белеп булса кирәк, таркау аксыл болытлар арасында кул-канатларын сузып ярдәмгә килүче Ана сурәте пәйда була. Бер мизгелгә генә аң кайта, ләкин үзәк өзгеч авырту егетне кабат упкын төбенә ташлый...

## 2

Өлкән лейтенант Рамиз Җәләев яткан госпиталь башкаланың үзәгендә диярлек, Яуза елгасы буена урнашкан. Госпитальнең моннан ике ярым гасыр элек кызыл кирпечтән салынган күп санлы корпуслары бөтен яктан да койма белән уратып алынган.

Рамиз шул корпусларның берсендә, икенче катта, егерме беренче палатада ята. Янында берөзлексез шәфкать туташы утыра. Бүлмәдә, ашыгыч рәвештә кирәк булырдай дарулардан башка, стена буйлап сузылып киләгән кислород көпшәсе күренеп тора. Тәрәзәгә якты үткәрми торган пәрдә корылган. Егетнең баш очында гына өч плафонлы өстәл лампасы. Аларның өчесенә өч төрле төстәге лампочкалар куелган.

Шәфкать туташы йомшак креслога утырган да укый торган китабын тезенә куеп уйга чумган. Әллә нигә бер, кайдадыр биектә очып бара торган самолет тавышыннан башка бер генә аваз да ишетелми. Тынлык...

Бүген көн болытлы, ара-тирә генә яңгыр сибәләп тора, ләкин шактый җылы. Госпиталь йортында да ашыга-ашыга эшкә килүче хезмәткәрләрдән башка кеше күренми.

...Медицина полковнигы Геева госпиталь капкасыннан керде дә, көндәгечә, вахтер белән исәнләшеп узды. Һәр вакыт ягымлы бу докторны госпитальдә белмәгән бер генә кеше дә юк. Госпиталь территориясендә генә түгел, шәһәрдә, метрода, трамвайда да бик күпләр аның белән исәнләшеп үтә.

Полковник Геева беренче кат ишегеннән кергәч тә алгы бүлмәдә өс киемнәрен чишенде. Киемнәр элеп торучы апа аңа ап-ак халат сузды. Доктор рәхмәт әйтеп алды да, өстенә кия-кия, икенче катка күтәрелде. Дежур шәфкать туташы аңа үткән төн бүлеккә яңа авыру китерүләрен, аның хәле бик тә, бик тә начар икәнлеген әйтеп бирде. Туташның йөзе борчулы, күзләре, йокысызлыктан булса кирәк, сизелерлек кызарган иде. Ул кулындагы шприцка күз төшереп алды да, «гафу итегез» дип, коридорга җәелгән келәм өстеннән җиңел атлап ары башка китеп барды. Доктор Геева ординаторлар бүлмәсенә юнәлде. Коридорда әле тонык кына төнге лампалар яна, авырулар палаталардан чыкмаган иде.

Ординаторлар бүлмәсендә нәрсәдер язып утыручы дежур врач Геева белән исәнләште дә, сораганны көтеп тормыйча:

— Менә, иптәш полковник, монда бер яралы егетне китерделәр. Төнлә самолеттан барып алдык. Хәле бик начар. Аңына килгәне юк, авыр контузия алган. Кыр госпиталендә, операция ясап, умыртка сөягенә кереп терәлгән һәм баш сөяген яралаган ике мина кыйпылчыгын алганнар. Кан басымы түбән, йөрәк тибеше сизелер-сизелмәс кенә. Миенә кан да бәргән булырга тиеш, — диде дә докторга авыру тарихын сузды. Полковник папканың беренче битен ачып авыруның фамилиясенә күз төшерде.

«Җәләев Рамиз Сәлимович, өлкән лейтенант» диелгән иде анда. Доктор күнегелгән тәртип буенча автобиографик мәгълүматларга күз йөгертеп укый башлады. Авыруның туган елына да әллә ни әһәмият бирмәде. Туган урынын шулай ук игътибарсыз диярлек карап үтте. Инде авыру тарихының икенче битен әйләндереп, өлкән лейтенантның нинди шартларда яралануы турында укый башлагач исә, урыныннан торып, янә беренче биткә карады. «Җәләев, Җәләев...» дип торды ул. «Сәлимович, Сәлимович...» Аннары, аякларында хәлсезлек тоеп, урынына утырды. Йөзе төссезләнеп, агарынып китте. Моны күреп торган дежур врач:

— Иптәш полковник, сезгә нәрсә булды? — дип, ярдәм итмәкче булып, өстәл артыннан кузгалды.

Ләкин доктор Геева инде үзен кулга алып өлгергән иде. Томанлы сиземләүнең беренче дулкыны азрак уза башлады. «Моның очраклы хәл булуы мөмкин» дип уйлады полковник һәм:

— Юк, юк. Борчылмагыз! Безнең яшьтәге кешеләр белән шулай булгалый ул, — диде. — Мин авыру тарихы белән кыскача гына танышып чыгам да аннан соң үзе янына барырмын. Сез борчылмагыз, — дип өстәде.

Дежур врач өстәл өстендә яткан «чүкеч»ен алды да полковникка сәерсенеп карап чыгып китте. Доктор Геева кулына авыру тарихын алып, өлкән лейтенантның туган җире язылган юлга карады.

— Әйе, — диде ул, — әйе. Туган җире Татарстан, Күксубай районы, Яңа Кизү авылы. Ата-аналары турында мәгълүматлар юк. Авыру тарихында аларны язар өчен аерым юллар да юк. Аннан соң ул мәгълүматлар бу очракта әллә ни әһәмиятле дә түгел...

Полковник инде тулысынча тынычланган иде. Ул тагын бер-ике рәт күз йөгертеп, авыру тарихының кирәкле урыннарын карап чыкты да егерме беренче палатага, яралы өлкән лейтенант янына юнәлде...



## 3

Фагыйлә бүген рәтләп йоклый алмады. Октябрь ае булуга карамастан, һава эссе һәм бөркү тора иде. Бүлмә тәрәзәләре тулысынча ачык булса да, бөркү. Монда узган ике ел вакыт эчендә Фагыйлә хәзергедәй бөркүлекне генә түгел, урамга чыгып тәнеңне күрсәтсәң куырып ала торган кайнар көньяк кояшын да күрде. Шулай да...

Рамиз киткәнгә дә инде дүрт ай да егерме көн вакыт узды. Соңгы хатында, көзге өйрәнүләр узгач та кайтып алырмын, әзерләнебрәк тор, дип язган иде. Нәрсә әзерләсен соң Фагыйлә? КЭЧ[1]тан алган ике солдат койкасын, әллә кайчан модадан чыккан, ишеккә сыймагач, солдатлар казарма тәрәзәседәй киң тәрәзәне алып бүлмәгә керткән кием шкафын, конторапарда гына була торган дүрт урындык һәм ике өстәлне санамаганда, аларның бу фатирда монда килгәч үзләре алган радиоалгыч һәм «Саратов-1» суыткычы, икесенә өч чемодан кием-салымнан башка әйберләре дә юк бит. Ә аларны җыяр өчен ярты сәгать вакыт җитә. Суыткычны күрше Нинага калдырып китәргә сөйләште Фагыйлә. Радиоалгычны шулай ук күтәреп йөртеп булмаячак, калдырырга туры килер...

...Рамиз хәрби училищеның икенче курсында укыганда кыш көне ялга кайтты. Алар, Фагыйлә белән Рамиз, җиденче класста укыганда ук инде бер-берсенә хатлар бирешкәннәр иде. Аннан соң урта мәктәптә, күрше авылга бергә йөреп укыдылар. Ул вакытта алар, дөрес, алай бер-беренә әйтешеп, атап йөрешмәделәр, әмма Фагыйлә Рамизның карашын сизә, күрә иде. Рамизга инде шул вакытта ук хәрбилек җене кагылганны да белә иде Фагыйлә.

...Ул ялга кайтканда Фагыйлә колхоз идарәсендә хисапчы булып эшли иде. Өлкән хисапчы чулак Зиннур абый әйтмешли, урамга яхшы кешенең эте дә чыкмаслык бер көнне, счет төймәләрен чалт-чолт тартып утырган Фагыйләне сискәндереп, идарәдәге телефон шалтырарга тотынды. Фагыйлә тизрәк барып трубканы алды. Колакка, тышта да, трубкада да улаган буран аша, әллә кайдагы тавыш ишетелде.

— Кем бу, кем? — дип сорады теге әллә кайдагы тавыш.

— Фагыйлә Мөэминова,— диде кыз. Трубкадагы тавыш бераз югалып торды да аннан соң, кинәт, бүлмәдәгеләргә дә ишетелерлек янгырап:

— Фагыйлә... классташ, зинһар, тыңлый күр. Мин район үзәгеннән шалтыратам. Бары тик уң көнгә генә ялга кайтып киләм. Монда күз ачмаслык буран. Минем туган тиешле абыйга барып әйт әле. Ат белән Моратка таба чыга алмасмы? Авылны күреп китәсе килә бит! — диде. Аннары акрынрак, Фагыйләгә генә ишетелерлек итеп: — Сине дә,— дип өстәде.

---

[1] КЭЧ — квартирно-эксплуатационная часть.

Фагыйлә инде тавыш иясенең кем икәнлеген таныган иде. Аның бит алмалары алсуланып, йөрәге каушап тибә башлады, ул сүзсез калды. Аны бу хәлдән колхоз председателе Галәви абыйсы коткарды. Килеп трубканы алды да:

— Кем әле бу? Ни йомыш? — дип кычкырды. Рамиз үзенең кем икәнлеген әйткәч, Галәви абый аңа: — Бу буранда юлга чыга күрмә, энем, азрак басыла төшсә, абзаң Галләметдинне айгыр белән җибәрермен, — диде.

Буран туктардан купмаган булып чыкты. Ул көнне һәм тагы төне буена котырынды да котырынды...

Шул чак, Фагыйләнең уйларын бүлеп, капка төбенә автомашина килеп туктады. Бераздан капка ачылып ябылды да йөзем агачлары артында сөйләшкән тавыш ишетелде.

Ике офицер — Рамиз хезмәт иткән часть командирлары сөйләшә-сөйләшә өйгә кереп килә иде. Фагыйлә тиз генә халатын киеп, ишекне ачты. Күрәсең, Рамиз яңа җирдән чакыру кәгазе җибәргәндер, мине озатуларын үтенгәндер, дип уйлап алды ул.

Олы гәүдәле, ләкин шактый җиңел хәрәкәтле командир бүлмәгә кергәч, тәкъдим ителгән утыргычка утырырга ашыкмады. Түр стенага эленгән рамкалардагы фоторәсемнәрне карап чыкты. Фагыйләнең сәламәтлеге, кәефе белән кызыксынды. Сирәк чәчләрен артка сыпыргалады. Аннан соң гына өстәл янындагы урындыкка утырды. Фагыйлә кофе ясап китерде. Часть командиры кофега кагылмыйча, урыныннан торып, тәрәзә каршына килде, өй турындагы йөзем агачларына күз салды. Ниһаять, тирән уйлардан арынган кеше шикелле башын чайкап куйды да:

— Әйдәгез, комиссар, — диде.

Ул башта кулындагы кыр сумкасын ачты, аннан нәрсәдер эзләгәндәй булды. Ахырдан тамагын кыргалап:

— Фагыйлә ханым! — диде. Тагын кыр сумкасына тыгылды. Янә: — Фагыйлә ханым, — дип кабатлады. — Бүген үк, Фагыйлә ханым, сез Мәскәүгә очарга тиешсез. Мин... мин билетлар кайгырттым. Гомумән, сезгә кайгыртырга туры килмәс. Без сезне озатып, утыртып җибәрербез. Миңа бу телеграмма Рамиз хакында. Безнең хезмәттә, Фагыйлә ханым, сез беләсез инде, төрле хәлләр була. Кыскасы,— диде ул, тагын бер кабатлап,— «Җәләев авыр яраланды» дип әйтелгән монда...

Фагыйлә офицерның соңгы сүзләрен ишетмәде. Калтыранган кулдан телеграмманы тартып алды да андагы хәрефләргә текәлде. Ул хәрефләр берсен-бәрсе узып сикерешәләр, телеграмма бланкасына ябыштырылган тасмадан чыгып югалу җаен карыйлар сыман иде...

## 4

Рамиз бая егылып төшкән упкын төбендә күпме яткандыр, ачык төшенә алмады. Аның күзләренә көчле яктылык килеп бәрелде. Баш утка салгандай кайнар иде. Өлкән лейтенантның хәтере моннан берничә ел элек булган вакыйгаларны кино кадрларындагы кебек әйләндерә башлады.

...Ком чүле. Кояш. Кайнар кояш. Аның нурларыннан баш яшерерлек ышык урын да юк. Пешерә. Әйтерсең лә дөнья шушы утлы нурлардан һәм ком бөртекләреннән генә тора. Ком. Иксез-чиксез киңлекләргә сузылып киткән кайнар ком өемнәре.

Рамиз, моннан бер ел элек хәрби училище тәмамлап, гарнизонга килеп төште. Аны укчы взвод командиры итеп билгеләделәр. Яшь лейтенант җиң сызганып, үзенең солдатлары белән бергә, таш-тау кыяларында «һөҗүм итәргә» һәм «һөҗүм итүчеләрдән» сакланырга өйрәнә башлады. Бүген Рамиз полкы округ өйрәнүләрендә катнаша.

Моннан берничә сәгать элек, полк командиры, полковник Гусар Рамизны чакыртып алды да, Курган янындагы иске коеларны тикшереп, разведка ясап кайту бурычын куйды. Ул су чыганаклары картага «Әллә кайчаннан бирле хәрәкәтсез» дип төшерелгән. Командир алар белән кызыксына иде.

Озакламый Рамиз взводы 130 километрлы юлга чыкты. Башта взвод чәнечкеле дөя үләннәре, кәкре-бөкре саксаул агачлары үсеп утырган җирдән барды. Төш вакытында, кояшның иң кайнар нурлары астында, бер-бер артлы тезелешеп, барханнар арасына кереп китте. Тагын 25—30 километр чамасы юл калгач, дулкын сыман киртләч-киртләч бархан аралары тәмам тараеп, алга баруны бик нык кыенлаштырды. Солдатлар әледән-әле туктала башладылар. Аякларны ком агымыннан тартып алу торган саен авырайды.

Тагын ярты сәгатьтән дөнья танымаслык булып үзгәрде. Искәрмәстән кузгалып киткән көчле җил ком океаны дулкыннарын хәрәкәткә китерде. Әле генә эссе кояш нурлары астында утлы күмер кебек кызып яткан ком бөртекләре дөньяны каплап алды. Бу тирәдәге халыкка элек-электән бу җил күп бәла-каза китергән. Менә хәзер дә ул тау арасында посып яткан, корбанын күргәч тә аңа ташлана торган юлбарыс сыман кинәт килеп чыкты. Өч-дүрт метр арада да берни күреп булмый башлагач, Рамиз машиналарны туктатырга мәҗбүр булды. Ул үзләре тукталган урынны полк командирына әйтергә дип радиостанцияне кабызды. Ләкин наушникларда аяусыз җил улавыннан башка бернәрсә дә ишетелми иде. «Димәк,— дип уйлады Рамиз,— радиостанция эшләми». Һавада очкан ком бөртекләре радио дулкыннарын тоткарлый, шунлыктан әллә ни көчле булмаган бу радиостанция аша полк радиостанциясе белән бәйләнешкә керү мөмкин түгел иде. Рамиз планшетын алып люктан тышка күтәрелде. Авызга, колак-борынга ком бөртекләре килеп тулды. Компас шулай ук эшләми. Аның уклары, читлеккә эленгән кош сыман, әле анда, әле монда бәргәләнә иде. Рамиз тиз генә аска, броня ышыгына чумды да, блокнотын чыгарып, чама белән үзләре тукталган урынның координатларын билгеләде. Аннары «17 сәгать 12 минутта көчле җил котырына башлады» дип язып та куйды.

Мондый хәлдә калуы беренче тапкыр гына булса да, лейтенант артык аһ ормады. Үзенең монда төп җаваплы кеше икәнлеген исенә төшерде. «Тиз генә туктала торган җил түгел,— дип уйлады ул.— Димәк, солдатларга каушавымны сиздермәскә кирәк». Ул аны бик саклап кына тотарга карар итте. Беренче отделение командирына солдатлардан сулы фляжкаларны җыеп алырга кушты. Үз рөхсәтеннән башка беркемгә бер тамчы су да бирмәскә боерык бирде. Элемтә дә, компас та булмагач, юлны дәвам итәргә тырышудан файда юк иде. Аннары ягулыкны да бетермәскә кирәк. Лейтенантның боерыгы буенча машиналарны бер рәткә тезеп куйдылар.

...Давыллы җил егерме сәгать буена котырынды-котырынды да, кинәт башланган кебек үк, кинәт юкка да чыкты. Күк йөзе теләр-теләмәс кенә ком болытларыннан чистарына башлады. Аннары, нәкъ кичәгечә, кояш кыздырырга тотынды.

Рамиз күпме тырышса да полк радиостанциясе белән элемтәгә керә алмады. Караңгы төшкәч, йолдызларга карап юнәлешне билгеләрбез, дип уйлады ул. Ә кояш һаман чамасыз нык кыздыра иде. Болай да соң

чиккә җитеп арыган, талчыккан солдатлар, Рамиз командаларына буйсынып, ком әсирлегеннән котылырга азапланалар. Ләкин алып ташланган бер көрәк ком урынына, агымсу сыман, тагын ком коела тора. Караңгы төшкәнче әзер булырга тиеш! Үч иткән кебек, кояш һаман түбәдә тора. Сусау артканнан-арта бара. Кибеп ярылган иреннәрне чылатып булса да аласы килә. Анда да, монда да:

— Иптәш лейтенант, берәр генә йотым рөхсәт итегезче? — дигән ялварулы тавыш ишетелә.

Рамиз барысын да ишетә. Ләкин взводның бу әсирлектән кайчан котыласын кем белә? Ә чүлдә бөтенләй сусыз калу... Арктика бозлары өстендә утсыз калудан да хәтәррәк.

Түземсезлек белән көтелгән кич килеп җитте. Күк йөзендә җемелдәп йолдызлар кабына башлады. Лейтенант люк өстенә утырып яклар-ны билгеләде.

Машина моторлары үкереп эшли башлады. Һәр люктан күзәтүче солдат күренде. Алдан эз салып баручы Рамиз машинасы ун-унбиш адым да уза алмады, көпчәкләре йомшак ком эченә кереп чумды.

Таң атты. Янә кояш... Аяусыз, кайнар кояш, моторлар төн буе файдасызга эшләп ягулыксыз калды. Фляжкалар да акрынлап бушап бетте. Тик берсенең төбендә генә азрак су бар. Рамиз иреннәрен ялап чылаткандай итә. Теле кайрак кебек кытыршы, авыр... Лейтенант, алпан-тилпән атлап, арттагы машина янына килә. Солдатларга чишенергә боера. Тегеләр аңламыйча аңа гаҗәпләнеп карыйлар. Рамиз боерыкны кабатлый. Аз гына булса да дым сакланган комга күмелергә кирәк, дип аңлатырга аның көче җитми...

Шул вакыт икенче отделение ягыннан:

— Юк, юк, егетләр! Мине тереләй җиргә күмә алмассыз! — дигән куркулы тавыш ишетелә.

Лейтенант шул якка таба атлый. Аның каршысына икенче отделение командиры, кече сержант Бутаков килеп баса. Ул, кызарган күзләрен ачулы әйләндереп:

— Мине җиргә күмә алмассың, литер[1]. Су бир, су! Хәзер үк барлык суны чыгарт. Син үзең суга тук. Син безне алдыйсың! — ди.

Рамиз кече сержантны бүлдермичә тыңлап тора. Алар тирәсенә солдатлар җыела. Берәүләр гимнастеркадан, икенчеләре ярым шәрә. Лейтенант, уртада баскан килеш, күзләре белән солдатларны барлап чыга. Фляжкалар янына куелган беренче отделение командирыннан башкалар барысы да монда. Йөзләр ямьсезләнеп, сузылып калган, талчыкканнар... Бәлки, чынлап та, Бутаков хаклыдыр? Калган суны хәзер үк бүлеп эчертергә кирәктер?..

Лейтенант шулай уйлап өлгермәде, кече сержант Бутаков, үзенә таяныч эзләп:

— Егетләр! Лейтенант безне бернәрсә дә эшләтә алмый. Барыбыз да бетәчәкбез. Әйдәгез суны алабыз, — диде.

Рамиз, барлык куәтен җыеп, училищеда старшина өйрәткәнчә:

— Взвод, смирно! — дип боерды.

Солдатлар баскан җирдә үрә катты. Лейтенант, алар алдыннан ава-түнә үтеп, кече сержант каршына килде. Алар, армиядә инде бишенче ел хезмәт итүче, солдат хезмәтенең түмен инде шактый татыган лейтенант һәм яшь кече сержант күзгә-күз карашып тындылар. Сержант бераздан командирның шелтәле авыр карашы астында сыгыла

---

[1] Лейтенантны бозып әйтү.

башлады. Үзенең гаебен, түбән җанлылык күрсәткәнлеген Бутаков белә, аңлый иде. Командирның сусаудан кара көйгән иреннәренә кабат күз төшереп алды да башын түбән иде...

Рамиз отделение командирына кешеләрне комга күмеп яткырырга дип кабатлый. Үзе дә аларга булыша. Кече сержант Бутаковны чокырга үзе яткыра, аның тирәсенә астарак яткан (дымны күбрәк саклаган) ком өяргә тырыша... Аннары алдагы машина янына бармакчы була. Ә ул нинди ерак. Рамиз анда барып житәргә тиеш... Юк, булмый. Баш әйләнә. Күз аллары караңгылана. Рамиз берничә адым атлый да чайкалып китә. Ул, аяк өстендә кала алмыйча, машина янына килеп ава. Соңгы көчен җыйнап, ниһаять, тора да читкә китә башлый... Кире борыла. Гимнастерка якасыннан икенче һәм өченче төймәләрен ычкындыра. Яртылаш комга күмелеп ятучы кече сержант Бутаков саташа. Аның күзләре йомык... Лейтенант беренче машинадан соңгы фляжканы алып килә. Савыттагы су Төмчә буендагы салкын чишмә суы кебек чылтырый. Лейтенант иреннәрен чылатмакчы була. Юк! Әнә кече сержант Бутаков тагын да авыррак хәлдә ич. Лейтенант сержант янына тезләнеп, фляжканы аның иреннәренә китерә. Сержант башта иреннәрен селкетеп кенә су тәмен татып карый. Аннан соң кысылган тешләрен ачып авызына коелган ике йотым суны голт иттереп каба да күзләрен ача. Лейтенант фляжканы селкетеп карый, әмма анда бер тамчы да су юк. «Ә башкалар? — дип уйлый Рамиз,— ә башка солдатлар...» Су бетте. Бөтенләй бетте. Юк, бетмәде. Әнә ич! Томан. Зәңгәрсу томан. Томан артында канал. Андагы су эчәргә генә түгел, коенырга да житә. Әле бит Рамиз взводы йөзү нормаларын да тапшырырга тиеш. Лейтенант фляжканы иелеп ала да канал ягына таба атлый. Аның колагына гөрелте ишетелә. Юк, гөрелте түгел, җил улый торгандыр. Шул каһәр җил көпчәкләр арасында сызгыра, гөрелди. Канал да ерак түгел инде... Менә яр... Гөрелте якыная. Җилме соң бу? Әллә мотор тавышымы? Лейтенант башын күтәреп, күзләрен күккә төби. Аның баш очында яшелгә буялган вертолет чайкала. Рамиз үзеннән егерме-утыз адымда гына җиргә төшеп утырган вертолетны да, аннан бер-бер артлы чыккан солдатларны да, полк командирын да күрми. Үзенең дә, солдатларның да чүл әсирлегеннән котылуларын аңлый алмый иде әле.

5

Бүген ял көне. Медицина полковнигы Ирина Андреевна Геева йокысыннан кәефе кырылып уянды. Соңгы ике айда Ирина Андреевна нервлары какшый башлаганны тоеп яши. Билгеле, егерме алты еллык хәрби хезмәт эзсез генә үтмәгән. Моңа чаклы Ирина Андреевна үз-үзен кулда нык тота, хезмәт һәм көндәлек тормыш мәшәкатьләренә болай ук бирешми иде.

Урта буйлы, төз һәм матур гәүдәле, түгәрәк йөзле, тыгыз тәнле хатын ул. Өстенә кигән шинеле, башка хатын-кызлар иңендәге кебек, «мин ир-ат киеме» дип кычкырып тормый, ятышлы калку күкрәкләре исә хәрби кием кигән гәүдәне тагын да матурайта төшә. Ирина Андреевна күзгә алдында күренергә яратмый. Кайчандыр шомырт кара чәчләргә инде «кар яуган». Аларны, билгеле, каралтып та булыр иде. Ләкин Ирина Андреевна андый бизәнүләрне электән үк артык өнәмәде. Хәзер исә аның аксылланган чәчләре йөзенә мөлаемлык, ягымлылык кына өсти. Сугыштан соң унбер ел үтүгә карамастан, әле һаман хәрби формасын саклаган Ирина Андреевнаны хезмәттәшләре һәм аның уңган кулларыннан саулык алып чыгучы башка бик күп офицер-

лар, генераллар бик нык ихтирам итәләр иде. Иң каты авырудан сызланып, өметсезлеккә төшеп баручы кеше дә, Ирина Андреевна дәваларга тотынса, савыгасына ышана башлый. Һәм, гадәттә, шул ышанычы аклана да.

Ирина Андреевна йокысыннан тәмам айныгач та әле шактый вакыт урыныннан тормады. Ул үзенең соңгы айларда еш кына юк кына сәбәпләр аркасында кәефе китеп, эче поша башлавының серенә төшенергә тырыша иде... Моннан ике ай ярым элек, яраланган өлкән лейтенант Җәләевне китергән көнне Ирина Андреевнага «Нигә каушап калдыгыз, шприц урынына скальпель сорадыгыз» дисәләр, ул моңа бик үк ышанып та житмәс иде... Ләкин бу хәл дөрес — нәкъ шулай булган иде. Егерме алты еллык эш дәверендә беренче тапкыр шулай каушап калган иде ул.

Ирина Андреевнаның уйларын бүлдереп, бәләкәй өстәлдәге телефон шалтырый башлады. Урыныннан тормыйча гына үрелеп, доктор трубканы алды. Госпитальдән шалтыраталар иде. Дежур торучы шәфкать туташы өлкән лейтенант Җәләевнең аңына килүен әйтте. Бу хәбәр Ирина Андреевнаның кәефен шактый күтәреп җибәрде. Чөнки Җәләевкә операция ясар алдыннан врачлар арасында барган бәхәсләрдә полковник Геева «операция өлкән лейтенант өчен күңелсез бетәчәк» дип әйтүчеләр ягында түгел, «уңышлы булырга тиеш» диючеләр ягында булды. Тегеләр операция ясаучы нейрохирургка ассистентлык итүгә дә риза булмадылар. Шунлыктан Ирина Андреевна хирургка ярдәм итәргә үзе алынды... Өлкән лейтенантның баш миендәге кыышчыклар арасына кереп утырган ясмык бөртегедәй корыч кыйпылчык әле һаман Ирина Андреевнаның өстәл тартмасында ята... Өлкән лейтенант Җәләев! Менә кем полковникның уйларында. Якын дусларының һәм меңләгән хәрбиләрнең яралардан сызлануларына тешләрен кысып, иреннәрен тешләп түзгән, ничәмә-ничә үлемнәрне җиңгән тәҗрибәле врач, доктор Ирина Андреевна Геева егетне беренче күрүдә ук калтыранып китте. Моның сәбәбе дә бар иде, әлбәттә. Ул сәбәпнең беренче билгеләре өлкән лейтенантның йөзендә язылган. Аның маңгае, чәчләре, күз кабаклары, битендәге мәхәббәт чокыры, иреннәре, колаклары һәм, ниһаять, уң як кашы өстендәге миңе күп нәрсә турында сөйли иде. Ирина Андреевнага бик-бик таныш билгеләр иде болар. Алар аның белән кай якларда гына йөрмәделәр. Ирина Андреевна аларны һәрчак күңелендә йөртә һәм төшләрендә күрә торган иде...

Утызынчы елның язында Ирина медицина институтын тәмамлады. Мәскәү клиникаларында эшкә калу мөмкинлеге дә бар иде. Ләкин ул чор вакыйгалары яшь врачны үз эченә тартып алды. Ирина башта Оборона министрлыгы карамагына җибәрелде. Министрлыкта аны Ерак Көнчыгыш хәрби округының медицина бүлегенә тәгаенләделәр.

Гражданнар сугышы елларында башта әтисен, соңрак Атлы Армиядә шәфкать туташы булган әнисен дә югалтып, унөч яшеннән балалар колониясендә үскән Ирина унбиш яшендә иң актив комсомолка иде инде. Колониядәге тәртипләр белән килешә алмаган усал малайларга да бирешмәслек нык һәм житез Ирина революция дошманнарына һәм Совет властен буарга жыенучы элементларга ачы һәм килешмәс нәфрәт хисләре татып үсте. Шуңа күрә дә яшь доктор бары тик алгы сызыкка омтылды. Әле институтта укыганда ук аның дус кызлары күрше институт студентларына — инженер булырга җыенучы егетләргә кияүгә чыгып беттеләр. Ә Ирина үзе артыннан йөрүче егетләргә әйләнеп та карамады. Башта балалар колониясендә, аннары институт тулай торагында үткән озын төннәрдә Ирина әтисен һәм әнисен һәлак иткән революция дошманнарыннан үч алырга кат-кат сүз биргән иде.

Хәрби округның кадрлар бүлеге инспекторы белән берничә көн тартышканнан соң, теге чакта Иринаны ил чигеннән ерак түгел бер гарнизонга хәрби врач итеп билгеләделәр. Шунда эшләгәндә салкын тидереп госпитальгә кергән застава начальнигы — кара чәчле, конгырт күзле татар егете Иринаны үзенә каратты да инде. Иринаның гарнизонга килүенә бер ел тулганда алар бергә тора башладылар. Туй мәҗлесен көз көне — Октябрь бәйрәмендә ясадылар. Әмма туй әллә ни гөрләп узмады. Табында иң якын хезмәттәш дусларыннан башка берсенең дә туган-тумачалары юк иде. Җитмәсә, табынның иң кызган җирендә заставадан шалтыратып, күрше дәүләт җирендә мотор тавышлары ишетелүен, ул тавышларның ил чигенә таба якынаюын әйттеләр. Шул минуттан соң инде яшьләрнең дә, кунакларның да уе чик буенда йөрде. Тагын сәгать ярым вакыт уздымы-юкмы, баштанаяк пычракка чумган застава начальнигының ординарецы атылып керде. Кулындагы камчысы белән балтырына суккалап, ул бер тын белән егермеләп кешенең чикне үтеп чыгуы турында хәбәр итте.

Туй мәҗлесе таралды. Ирина ирләр чыгып югалу белән өс киемнәрен алыштырды да, шинелен җилкәсенә элеп, госпитальгә йөгерде. Ул килеп җиткәндә госпитальдәге икенче врач һәм шәфкать туташлары да, авыру кызылармеецлар да, тирә-яктагы тынлыкны бозарга кыймаган сыман, нәрсәдер көтеп, тынып калганнар иде. Ләкин бу куркыныч тынлык озакка бармады. Госпитальгә санитарлар килеп керде һәм ыгы-зыгы башланды. Ирина, кайнар маңгаен салкын тәрәзә пыяласына тидереп, караңгылыкка караган җиреннән борылып:

— Операция бүлмәсе әзерме? — дип сорады. Җавап көтеп тормастан:— Мин перевязочныйда булырмын,— дип өстәде дә ашыгып ишегалдына чыкты...

Сизә, диләр, хатын-кыз йөрәге киләчәк кайгыларны, сизә, диләр... Ирина ул мизгелләрдә иренең шулай тиз арада кабат кайтасын уйламаган да булгандыр бәлки. Шулай да әллә нинди генә эчке бер тойгы аны арбада яткан яралы янына килергә мәҗбүр итте. Санитарлар яралыны арбадан носилкага күчерә башлаганнар иде. Шунда яралының өстенә ябылган шинеле шуып җиргә төште. Ирина госпиталь тәрәзәсеннән төшкән сүрән яктылыкта иренең киң маңгаен күреп алды да хәрәкәтсез калды. Носилканы перевязочныйга алып киттеләр. Инде ишек тә ябылды, ә Ирина әле һаман тавыш-тынсыз басып торды. Аның күзләре төн караңгылыгына текәлгән иде. Ирина кисәк кенә борылып, бинага таба бер-ике адым атлады да:

— Ой! — диде. Үзе дә сизмәстән уң кулын күкрәк астына куйды. Анда кулга бәрелеп тагын бер йөрәк тибә иде. Тамырларындагы канны әле генә җан кергән шул икенче йөрәк куа башлаган шикелле тойды. Ирина ашыгып перевязочныйга кереп китте... Бәхеткә каршы, иренең ярасы җиңел иде. Сул аякның балтыр итенә кереп утырган кургашын һәм кулбашындагы хәнҗәр эзе ике атна ярымнан төзәлде дә диярлек. Ул бераз аксабрак булса да үз вазифасын үти башлады. Тагын өч айдан ире аны ил чигеннән еракта, Татарстандагы Төмчә елгасының бормаланып-бормаланып ага торган җиренә урнашкан Яңа Кизү авылына әнисе янына озатып җибәрде.

Ирина ике атналык юлдан кайтып авылда атна-ун көн яшәмәде, һич көтмәгәндә, тулгак тота башлады. Күрәсең, юлда поезддан поездга күчеп йөрүләр йончыткандыр. Бала табарга әле тагын айдан артык вакыты булырга тиеш булса да, февраль аеның урталарында, таң беленә башлаганда, Ирина дөньяга малай китерде. Иренең дә кендек әбисе булган туксан яшьлек күрше карчыгы, кипкән, кытыршы куллары белән тотып, ул малайны Иринага күрсәтте. Яшь ана хәлсез кулы белән

үрелеп баланы тотып карады да, куанычыннан күз яшьләрен тыя алмыйча, йомшак түшәк өстенә ауды. Ә малай, ашыгып тууына артык исе китмичә, яңа кеше дөньяга килүен белдереп, беренче тапкыр чәрелдәп аваз салды.

## 6

Иртәнге обходтан соң башланган операция көндезге сәгать өчкә чаклы дәвам итте. Ниһаять, Рамизны операциядән чыккан авырулар ята торган палатага алып киттеләр. Коридордагы кешеләр, юл биреп, стенага сыендылар. Бүлекнең урта өлешендәге залда шахмат уйнап утыручы ветераннар, катгый боерыкка буйсынган шикелле, бердәм торып бастылар. Рамизны салган арба йомшак келәм өстеннән тавышсыз гына тәгәрәде.

Рамиз операциядән соң өч тәүлек узгач кына аңына килде. Палатада кеше юк иде. Авыр күз кабаклары теләр-теләмәс кенә ачылды. Рамиз күз алдында торган зәңгәрсу томан таралган. Бернинди тавыштын ишетелми. Егет кымшанып куйды. Умыртка сөякләре инде чәнчешми, баш авыртуы да алай түзә алмаслык түгел, шактый кимегән иде. Ниһаять, Рамиз үзенең госпиталь палатасында ятканлыгын төшенде.

Палата ишеге ачылып, бүлмәгә Фагыйлә килеп керде. Өстендә ак халат, башында шундый ук ак косынка иде. Рамиз бер генә секундка күзләрен йомды да кабат ачты. «Саташам» дигән уй яшен тизлеге белән миен телеп үтте. Фагыйләнең йомшак бармаклары Рамизның күз кабакларына тияр-тимәс кенә уздылар да маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен сөртеп алдылар. Фагыйләнең кайнар сулышы биткә бәрелде. Бүлмәгә таныш ис таралды. Рамиз белгән бер генә кеше чәчләрендә була торган ис иде бу. «Саташмыйм! — дип уйлады Рамиз.— Бу — Фагыйлә! Әйе, әйе!» һәм ул ничә көннәр буена бер сүз әйтмәгән иреннәрен авырлык белән генә кыймылдатып:

— Фагыйлә! — диде.

Фагыйлә аның марля астыннан әйтелгән тавышын ишетмәде. Рамиз җавап көтте һәм хуш ис таратучы чәчләрне күзәтте. Фагыйлә нидер сизенгәндәй Рамизга таба борылды. Шул мизгелдә аларның күзләре очрашты. Икесенең дә күзләреннән соңгы айларда күрешми торганнан соң туган сагыш катнаш шатлык очкыннары сибелә иде.

Рамизның инде ничә көннәр буена чамасыз киеренкелек белән эшләп алҗыган йөрәге, күкрәк куышлыгына сыя алмыйча, сикерергә-бәргәләнергә тотынды. Фагыйләнең бүгенгә хәтле сер бирмәгән аяклары кинәт хәлсезләнде, ничә көннәр һәм төннәр буена җыелып килгән кайгы төере тамагына утырды, керфекләре чыланды.

Палатага ике шәфкать туташы кереп хәл белешкәннән соң, Рамизны күтәреп алдылар да ишек төбенә үк китереп куйган арбага салдылар. Аннары икенче бер палатага алып керделәр. Анда, ул палатада тагын бер авыру ята иде. Рамизга:

— Хәзер доктор кереп кислород белән дәвалау үткәрер, — дип, шәфкать туташлары чыгып киттеләр.

Рамиз арбасы койкадан биегрәк иде. Шуннан файдаланып, ул теге авыру кешене күзәтеп ятты. Чал чәчле, озынча битле, искиткеч ябык иде ул кеше. Күзләре эчкә батып ямьсезләнеп калган... Доктор һаман кермәде. Рамиз әлеге авыруның тирән коедан килгән кебек, тонык кына булып ишетелгән:

— Исемегез ничек? — дигән тавышына сискәнеп китте.

— Минем? Рамиз. Өлкән лейтенант Җәләев!

— Бик рәсми икәнсез. Алайса, таныш булыйк: генерал-лейтенант Орлов. Иван Тимофеевич. Менә үз аякларым белән килдем... Тиз генә китеп булмый...

Рамиз һаман генералны күзәтте. «Моның да хәлләр бик үк шәптән түгел икән шул», дип уйлап куйды. Генерал өстендәге одеалны төзәтим дип талпынган иде — одеал, хәлсез кулларны тыңламыйча, шуып идәнгә төште. «Генералның хәле дөрестән дә шәп түгел. Тегенең тышкы «нужа» белән йөреп азапланасы юк икән: койка читенә «үрдәк» куелган. Шулай яшәп була микәнни?»

— Ә син, — диде генерал, — син, өлкән лейтенант, нинди җилләр белән монда килеп эләктең? Нинди хәерсез җилләр бу йортка китереп ташлады сине?

— Мин, иптәш генерал, үзем дә белмим...

— Ярый, синең хакта мин бераз ишеткән идем. Венгриядәнме?

— Әйе...

Бүлмәгә шәфкать туташы белән Ирина Андреевна килеп керде. Өстендә, көндәгечә, килешле ап-ак халат. Күкрәк кесәсенең капкачына «И. А. Г.» хәрефләре чигелгән. Уң як кесәсеннән ике башына да резина киертелгән «чүкеч» күренеп тора. Доктор, ишектән керә-керә үк, генералга мөрәҗәгать итеп:

— Исәнмесез, Иван Тимофеевич, хәлегез ничек? — диде.

— Сезнең хәер-догада, Ирина Андреевна, — диде генерал шаяртып.

— Ә син, герой? Ни эш бетереп ятасың? Ну, ну... Син хәзер молодец. Так держать!

Иван Тимофеевич кабат шаяртып:

— Ул да сезнең хәер-догада инде, Ирина Андреевна,— дип өстәде.

Рамиз дәшмәде. «Әйбәт кешеләр монда, — дип уйлады ул. Доктор да әйбәт кеше булса кирәк. Мин саташып аңсыз яткан көннәрдә дә гел минем янымда булган. Фагыйлә белән беррәттән борчылган, кайгырган. Юкса, доктор кирәкле даруларны язгач, карагач, төннәрен шалтыратып авыруның хәле белән кызыксынмаса да ярый лабаса. Ә ул кызыксынган... Шунысы бар, минем аны кайдадыр, кайчандыр күргәнем бар шикелле. Әллә инде аңсыз яткан чаклардан алып аның бу таныш, мөлаем сурәте күңелгә сеңеп, якынаеп калдымы икән? Юк. Мин аны күптән беләм төсле. Кайда, ләкин кайда гына күрдем мин бу докторның күзләрен?..»

Ул арада шәфкать туташы Рамизның одеалын ачты. Рамизның тәненә Ирина Андреевнаның җылы, йомшак кулы килеп орынды.

— Тоясыңмы, Рамиз?

— Тоям шикелле.

— Кайсы төштә минем кул?

— Тездә... Юк! Түбәнрәк... юк...

Рамизның ялангач бот итенә тупас башлы юан энә кадалды. Шәфкать туташы кислород юлын ачты. Басым астында килгән кислород, бот итләре арасына үтеп, аякларны авырттыра башлады.

Ирина Андреевна, арбада яткан авыру лейтенантка карап торгач, бер генә минутка күзләрен йомды. Докторның күз алдына (инде ничәнче кат!) моннан күп еллар элек Татарстанның Яңа Кизү авылында үткәргән көннәре килеп басты.

... Бала туганнан соң Ирина авылда тагын дүрт ай да егерме көн яшәде. Ул арада иренең әнисе белән дә якыннан дуслашып өлгерде. Татарчага да аз-маз өйрәнде. Китәргә җыенып йөргән көннәренең берсендә аны авыл Советына чакырдылар. Иринаны авыл Советының ишегалдында хәрби кеше каршы алды. Ул район хәрби комиссариаты вәкиле иде.

— Иптәш хәрби врач, — диде вәкил. — Мин сезгә шактый күңелсез хәбәр китердем. Сез хезмәт иткән гарнизон начальнигының язуына

караганда, соңгы вакытта ул якта шактый борчулы вакыйгалар булгалый икән. Сез андагы шартларны, билгеле, миннән яхшырак аңлыйсыздыр. Шуңа күрә сезнең гарнизон начальнигы, тиешле ялыгыз беткәч тә, мөмкин булса, балагызны вакытлыча авылда калдырып торуыгызны да үтенгән.

— Туктагыз әле, иптәш, — дип бүлдерде аны Ирина. — Нигә бу турыда миңа гарнизон начальнигы яза, җитмәсә тагын, сезнең учреждение аша. Анда минем ирем бар ич?

— Гафу итегез, иптәш хәрби врач. Мин Сезгә барысын да аңлата алмадым. Эш шунда ки, Сезнең ирегез, застава начальнигы, илебез, чиген бозып керүчеләр белән бәрелештә авыр яраланган... Аннары... аннары... кичерегез...

Ирина башын ике куллап тотып, бер минут чамасы өнсез торгач, өй түрендәге бүрәнә өстенә утырды. Аның ике күзеннән мөлдерәп яшь ага иде.

Икенче көнне, баланы вакытлыча кайнанасына калдырып, Ирина ерак юлга кузгалды. Иринаны станциягә илтеп куярга тиешле ат та килгән, чемодан һәм башка төргәкләр дә күптән арбага чыгарып куелган инде. Ә Ирина әле һаман төрле сәбәпләр табып бала тирәсендә әйләнде. Инде чыгам диеп ишек тоткасына кулын сузгач, ул күкрәкләренә шаулап сөт төшкәнне тойды. Борчылып, сиртмәле бишек янына килде. Чыбылдыкны ачып баланы алды. Бала, йокы аралаш булса да, сулыгып-сулыгып имә башлады. Аның түгәрәк битләренә әнисенең кайнар күз яшьләре тама иде. Ләкин бала да, ана да моны тоймадылар.

Капка төбенә озатучылар — иренең туган-тумачалары, тирә-күршеләр һәм бала-чагалар җыелган иде. Кайнана, үз гомерендә тугыз бала тәрбияләп үстергән ана, Иринаны ашыктырмыйча, нәрсәдер әйтергә теләп йөрде. Имеп туйгач, баласын яхшылап төреп бишеккә салды да Ирина кайнанага таба борылды. Кайнана, гомере буена шушы авылдан чыкмавына, үз балаларын калдырып бер генә көнгә дә читкә китмәвенә карамастан, баладан аерылып китүнең авырлыгын аңлый иде. Ләкин ни эшләсен? Аның да килене белән улын үз янында гына тотасы килә дә бит... Улы, нәселдә булмаганны, хәрбилеккә бирелеп, әллә кая — җир читенә китеп барды... Киленен юаткан булып җылы сүзләр әйтсә дә, тегесе аның ярты сүзен дә аңламады. Тел белмәү дә кыен...

Әмма бу очракта барлык милләт аналары да бер-берсен тылмачсыз аңлыйлар. Ирина кайнана каршына килде. Мәһабәт гәүдәле карчык кечерәеп калган, ап-ак чәчләре тагын да агарганрак төсле күренә иде.

— Эни, — диде Ирина һәм, күз яшьләрен тыя алмыйча, кайнана иңенә сыенды. Карчык, килененең аркасыннан сөеп, йомшак тавыш белән:

— Яхшы, кызым, балам, яхшы. Борчылма. Тиз кайтыгыз. Бала исән-сау, сәламәт булыр, — дип сөйли-сөйли озата барды. Тыштан:

— Иринә, пайыхыли, бриме, — дип кычкырдылар.

Ирина бала яткан бишеккә тагын бер тапкыр карап алды да артка таба атлап бусагадан чыкты. Ишегалдындагылар барысы берьюлы нәрсәдер әйтергә теләп сөйләнә башладылар. Ләкин күп кеше берьюлы сөйләгәнгә, Ирина бернәрсә дә аңламады. Бары тик:

— Рэхмэт, рэхмэт. Сав булигиз,— дип кенә кабатлады. Аннары печән тулы арбага утырды. Шуны гына көтеп торган ат кузгалып та китте...

...Басым белән килгән кислород, бот итләре арасына үтеп, аякларны авырайта башлады. Ирина Андреевна шәфкать туташына таба борылмыйча гына:

— Җитәр, — диде.

Кислород килүе тукталды. Шәфкать туташы энә һәм шприцларны җыештырып чыгып китте. Доктор почмактагы кранга барып кулларын юды да Рамиз янәшәсенә килеп утырды.

— Син, лачыным, бер-ике сәгать монда ятып тор инде, аннары кабат үз палатыңа күчербез, яме?

— Ярый, доктор.

Иван Тимофеевич каш астыннан гына башта докторга, аннары Рамизга карады. Кинәт генерал искиткеч ачыш ясады. Арба өстендә яткан егет доктор Ирина Андреевнага шундый охшаган, шундый охшаган... Икесенең дә күзләре бер үк төстә. Әгәр кирәк булса, өлкән лейтенантның борынын Ирина ханымныкы белән алмаштырып булыр һәм моны берәү дә сизмәс иде. Ә Ирина ханымның кашларын, күзләренең бераз кысыбрак каравын, битендәге мәхәббәт чокырын, шулай ук тыштан берни дә сизелмәслек итеп, Рамизга күчереп куярга мөмкин булыр иде. Хәтта икесенең дә уң як кашлары өстендәге миңнәре дә нәкъ бер төсле иде аларның.

Генерал мондый ачышка гаҗәпләнеп яткан арада, доктор, Рамизның одеалын төзәткәләп:

— Өлкән лейтенат, гафу итегез. Документларыгыздан карарга онытканмын, әтиегезнең исеме ничек әле? — дип сорады.

— Сәлим... Сәлимович...

— Ул хәзер кайда соң? Туган авылыгыздамы?

— Юк. Мин аны бөтенләй белмим...

— Гафу ит, Рамиз. Сиңа тыныч булырга кирәк. Борчылма... матурым.

— Бик борчылмаска иде дә бит, доктор, минем «җырлыйсы җыр инде җырланган» түгелме соң?

Генерал тамак кырып куйды, бер сүз дә әйтмәде. Әмма Рамиз ягына усал караш ташлап алды.

Ирина Андреевна тагын бер тапкыр Рамизга күңелен төшермәскә кушып чыгып китте. Аның артыннан ишек ябылгач та генерал:

— Синең, өлкән лейтенант, нинди «җырың инде җырланган?» Мин әллә аңламыйча калдым, әллә ялгыш ишеттемме?

— Соң бит, иптәш генерал...

— Иван Тимофеевич.

— Соң бит, Иван Тимофеевич, күпме түзәргә мөмкин? Тереләсе кеше алты ай гомер койкадан тормыйча ятамы соң? Башка берәр җир булса да ярар иде, баш бит, баш!

— Анысы шулай, браток. Баш бөтен нәрсәгә дә баш инде ул. Әмма ул баш нәрсә турында уйлый бит — шунысы әһәмиятле. Хәлеңнең начаррак булуы бик мөмкин иде. Болай булгач әле син врачларга һәм үзеңнең яшьлегеңә рәхмәт диген.

— Эх, Иван Тимофеевич, рәхмәт әйт... дисез. Әгәр дә иптәшләрем белән бергә «китеп», бу газаплардан котылган булсам... рәхмәт әйтеп булыр иде. Хәзер инде бетте, барысы да бетте. Белеп торам ич мин, — диде Рамиз карлыккан тавыш белән.

Аның күзләре түшәмгә текәлгән, ә иреннәре калтырый иде.

— Ялгышасың, туганым. Син кем? Совет Армиясе офицерымы, әллә... бер чүпрәк кисәгеме? — дип кычкырды кинәт моңа чаклы тын

гына сөйләшеп яткан генерал. — Син кем? — дип кабатлады ул. — Мондый газаплар белән, өлкән лейтенант, бер син генә ятасыңмы? Әнә, безнең бүлектә генә дә ничә кеше сугыштан калган яралардан җәфа чигеп ята. Аларга унар еллар дәвамында госпитальләрдә йөрү әллә җиңел эш дип уйлыйсыңмы? Әллә син дә үзеңне озак ятучылар рәтенә кертергә уйлыйсыңмы? Юк, кадерлем! Менә мин — генерал абзаң — инде өч ел, аңлыйсыңмы, өч ел! — урында ятам. Сугыштагы ямауларны санамыйм әле мин... Менә бит, үз аягым белән атлап килдем госпитальгә. Сукыр эчәктән ниндидер яман шеш тапканнар иде. Кисеп алырбыз да шуның белән вәссалам диделәр. Бар да бик яхшы гына башланып китте. Операциягә әзерләп, өстәлгә кертеп яткырдылар. Кистеләр... кистеләр... — генерал шактый вакыт сүзсез торды. Бер генә минутка йомшарып китте, тешләрен шыгырдатып куйды, тамагындагы төерне үткәреп җибәрә алмыйча азапланды. Маңгаена бәреп чыккан тир тамчыларының тәгәрәп мендәргә төшүенә дә игътибар итмичә, янә сөйләргә тотынды. — Нәкъ менә шул яман шешне кисәбез дип торган вакытта гына, минем тәндә кан йөреше кискен бозылып куя, сул якны паралич суга. Инсульт. Операцияне җиренә җиткерү мөмкин булмый. Ашыгыч рәвештә туктаталар, мине менә шушы шланг белән караватчитендәге әнә теге «үрдәк»кә тоташтырып куялар... Яңадан кеше рәтенә кергәнче шактый гына вакыт узды. Коры сөяккә генә калган идем. Барыбер кул һәм аяк хәрәкәтләнә башладылар. Авызның да чалышаюы бетте. Операциягезнең эшен бетерегез дә мин китим инде дип ялварам докторларга. Алар, алай да болай, һаман тикшерәләр дә әйләндерәләр. Әле рентген, әле тагы әллә нәрсәләр. Ниһаять, мине бер атаклы профессорга күрсәттеләр. Ул карагач кына операцияне яңартып, эшен бетерергә булдылар. Шулай итеп, икенче мәртәбә пычак астына яттым... Ләкин бу юлы да мине һәлакәт саклап кына торган, кабахәт... Мине, өлкән лейтенант, икенче тапкыр да җыештырып тегеп куя алмадылар. Ике яклы паралич... Икенче дәрәҗә инсульт... Менә инде өченче операция ясарга җыеналар. Кул-аяклар ярыйсы гына кыймылдый башлады. Нәрсә? Әле, брат, кайсы да булса округ маневрларында бергәләшеп атакага барырбыз...

Рамиз берөзлексез генералны күзәтеп ятты. Үзенең бая кече җанлылык күрсәткән мизгелен ул инде кызгана иде. Ничек инде ул ышанычын югалту турында әйтеп салды. Дөрес, чүпрәк син, өлкән лейтенант, чүпрәк. Әнә кара, пенсиягә яше җиткән, күпме сугышлар күргән генерал «атака»га бару хакында хыяллана. Ә син, өлкән лейтенант? Син соң әле барлык энергияңне, көчеңне көрәшкә, тормыш өчен көрәшкә бирдеңме? Әлегә чаклы, туганым, син көрәшмәдең, синең өчен башкалар көрәште. Син әлегә чаклы пассив идең. Син түгелме соң Корчагин батырлыгына сокланучы? Юк, болай ярамый, иптәш өлкән лейтенант. Түзәргә, көрәшергә, кабат түзәргә кирәк. Врачлар да хәлләреннән килгәннең барысын да эшләячәкләр. Бергәләп көрәшергә, һәлак булган солдатлар өчен дә көрәшергә!...

Ишек ачылып, палатага ике шәфкать туташы килеп керде. Рамизны үз урынына күчерәләр иде.

## 7

...Ирина үзе хезмәт иткән гарнизонга уналтынчы көндә кайтып житте. Юл буенча диярлек күкрәкләре әрнеде. Башта алар таш кебек катып, киерелеп киттеләр. Ирина ни эшләргә дә белмәде. Авылдан чыкканның өченче көнендә, Уфа вокзалында поезд көтеп утырганда, күкрәкләре авыруга түзә алмыйча, яшь балалы хатын янынарак утыр-

ды. Баланың чәбәләнә башлавын көтте. Киез эскәмиядә йоклаган бала уянуга, теге хатын белән исәнләште дә күкрәкләренә күрсәтеп:

— Авырталар бит... имезергә рөхсәт итсәгезче? — дип үтенде.

Теге хатынның күкрәкләре сизелер-сизелмәс кенә иде. Аның сөте алай муллан түгел булса кирәк. Шуңадырмы, хатын шатланып риза булды. Ирина кесәсеннән ап-ак кулъяулык чыгарды да имчәкләрен сөртте. Шуннан соң баланы кулларына алып күкрәгенә китерде. Бала имчәкне табып бераз чупылдатып торды да кире тартылды. Ирина әрнүләренең тизрәк бетәчәген өмет итеп җиңел сулыш алган иде инде... Әмма... бала имчәкне тагын кире чыгарды. Ирина, аптырап, яшьле күзләре белән бала анасына карады. Тегесе барысын да аңлады бугай:

— Ниңә көн имезмәдегез? — диде.

— Дүртенче китте...

— Җаныем, сезнең сөтегез инде тәмен югалткан. Гади генә итеп әйткәндә, әчегән. Аны бала иммәячәк.

— Ничек?

— Шулай, җаныем, шулай...

— Соң минем дә балам бар ич...

— И юләр, — диде теге ана. — Юләркәй. Соң мин балаң юк дидемме әллә. Бардыр... Булмаса күкрәкләрең шундый булмас иде... Түзәргә кирәк, матурым. Әгәр дә аларны хәзер бушатсаң, кабат сөт төшәр. Гел, гел савып тора алмассың... Түз, җаныем. Тагын берничә көннән авыртуларың кимер...

Ул арада бала анасының янына кара сакаллы баһадир килеп басты да, Иринага кырын карап, хатынына:

— Җыен, — дип гөрелдәде. — Безнең поезд менә-менә килергә тиеш. Ә сезгә, мадам, нәрсә кирәк?

Аның тавышы усал иде.

Хәрби врач Геева, ил чигендәге хәлнең киеренкелеген яхшы аңлаганга күрә, хәрби хезмәттән азат итүләрен сорамаска булды. Әлегә бала кайнана янында торып торыр. Киләсе елга ял вакытында кайтып килермен дип уйлады.

Ирина округның медицина бүлегенә кереп, үзенең ялдан килүе турында рапорт биргәннән соң тизрәк гарнизонга кайтырга ашыкты. Гарнизонга кайтканның икенче көнендә, иртүк, застава начальнигының урынбасары белән ире Сәлим яраланган урынга китте. Бу урында ил чиге урман алдындагы ачыклыктан ага торган исемсез бер елга буйлап үтә. Дошманнар аңгырлы, күзгә төртсәң күренмәслек төндә чикне үтеп чыккан. Сәлим «секрет»ларны тикшереп йөргәндә, нибары ике сугышчы белән теге дошманнарның юлына аркылы төшкән. Тигезсез бәрелеш озак бармаган. Яраланып якындагы чокырга егылган сугышчы болай дип сөйләде: «Без дошманнарны иң соңгы мизгелдә генә күрдек. Застава начальнигы сигнал ракетасын атты. Без өчебез дә җиргә ятып ут ачтык. Чокырда озак ятмаганмын, күрәсең. Мин атыш тавышын ишетеп көч-хәл белән өскә күтәрелдем дә капшанып винтовкамны эзли башладым. Шул чагында застава начальнигының «аһ, кабахәтләр» дип сүгенгәнен ишетеп, шул якка карадым. Кинәт тирә-якны яктыртып ракета кабынды. Мин застава начальнигының күкрәген тотып бөгелеп төшкәнен күрдем».

Ирина барлык вакытын госпитальдә уздыра торган булды.

Яңа Кизү авылыннан килгән сирәк хатлар улының сәламәт үсүен ишеттереп тордылар. Ирина түзәргә өйрәнә башлады. Дөрес, эштән бушаган араларда ана йөрәге тавыш-тынсыз сыкрана, елый иде.

Ил өстендә йөзгән кара болытлар һаман саен куера, карала барды. Икенче елны Иринага тиешле ялны бирмәделәр.

Бер очрашуда Ирина үзенә тиешле ял хакында исенә төшергәч тә, медицина бүлеге начальнигы.

— Ирина Андреевна, кадерлем, зинһар өчен тагын биш-алты гына айга түзегез. Сезсез без ни эшләрбез? Безгә берничә яшь врач җибәрергә вәгъдә итәләр. Шулар килгәч хәл итәрбез мәсьәләне,— дип үтенде. Ләкин яшь врачлар һаман килмәделәр. Округ госпиталендәге хәлне яхшы белгән Ирина икенче тапкыр бу турыда сүз кузгата алмады.

Шулай итеп, хәрби врач Геева улы янына бер елдан да, ике елдан да кайтмады...

Дөньяның бер җирендә дәһшәтле вакыйгалар бераз тынычланган арада, икенче җирдә тагын давылларга тотынды. Менә инде ничә ел буена ерак Испаниядән бер-бер артлы шомлы хәбәрләр килеп тора иде. Анда Гитлер һәм Муссолини башкисәрләрнең аяусыз легионнары республиканы канга батырырга җыеналар иде. Испания республикасын яклар өчен төрле илләрдән җыйналган ирекчеләрдән интернациональ бригадалар оештырылды.

Беркөнне госпитальгә округ командирлары килеп керде. Авырулар ята торган бүлмәләрне карап йөрделәр. Кызылармеецлар белән озак-озак сөйләшеп утырдылар, врачлар һәм медицина хезмәткәрләре белән дә әңгәмә уздырдылар. Сүз ил чикләренең тынычсызлыгы, сизгерлек, уяулык турында барды. Соңыннан, әлегә чаклы беркем белән дә сөйләшмичә, тыйнак кына тыңлап йөргән батальон комиссары хәрби врач Гееваны чакырып алды да врачлар бүлмәсендә аның белән озак кына сөйләшеп утырды. Хәрби врач Геева моннан бер ай ярым элек округ политидарәсенә интернациональ бригада составында Испания революциясен якларга җибәрүләрен сорап гариза язган иде. Сүз асылда шул хакта барды.

— Иптәш батальон комиссары, мин округ политидарәсенә язган гаризамдагы сүзләремдә нык торам,— диде Ирина Андреевна.— Әмма... бер үтенеч: балам янына кайтып килергә рөхсәт итегез?

Батальон комиссары тиз генә Ирина Андреевнага күз төшереп алды да карашын тәрәзәгә күчерде. Уң кул бармакларының өстәл өстендә уйнавы, каш араларының җыерылуы аның авыр уйлар белән көрәшкәнлеген күрсәтә иде. Балалы ананы интернациональ бригадага җибәрергә хакыбыз бармы соң дип уйлый иде ул. Ләкин бит анда да белемле, тәҗрибәле врачлар кирәк булачак иде.

## 8

Яңа Кизү авылында Ирина ун көн яшәде. Башта улы аны танымады гына түгел, янына да килмәде. Чөнки ул бу хәрби киемле «апа»ның телен бөтенләй аңламый иде. Дөрес, соңга табарак бераз ияләште. Әмма ике яшь ярымлык бала барыбер йокларга әбисе янына килеп ята торган булды. Ирина үзе алып кайткан киемнәрнең беришесен улына таманлап текте, беришесен үсә төшкәч кияр дип шул көенчә калдырды. Ике көн вакыт район үзәгендә үтте. Ирина документларны тиешле орган вәкиленә тапшырып, улына пенсия юллады. Икенче көнне район үзәгендәге бердәнбер фотографны эзләп табып, улы белән фоторәсемгә төште. Дөрес, ул фоторәсем бераз сәеррәк чыкты чыгуын. Ирина, «хәрби киемле хатын-кызга игътибар күбрәк булыр» дип, ул көнне хәрби формасын авылда калдырган иде. Ә мондый көндәлек кием Иринага бөтенләй үк ятышлы түгел икән...

Иртәгә китәргә дигән көнне Иринага әллә нәрсә булды. Башта ул моның сәбәбенә төшенә алмыйча йөрде. Ахырдан аңлады. Искиткеч ачыш: Ириналың йөрәге беренче тапкыр баласын калдырып киткәндәге кебек үк сыкранмый иде. Ни әйтсән дә, баланы тудыру әле ана булуның яртысы гына. Аның, баланың, барлык мәшәкатьләрен дә үз өстеннән уздырырга кирәк. Аның авыру минутларын, төнге елауларын да татырга кирәк. Ә Ирина бу мәшәкатьләрне күрмәде. Баланы үз куллары белән иркәләп үстермәде... Күрәсең, язмышның көтелмәгән сынаулары кичергән чорда ана хисләре дә кырыслана булса кирәк.

Мәскәүдә врач Гееваны көтәләр иде инде. Аңа батальон комиссары белән дә очрашырга туры килмәде. Ул бирен калдырган телефон номерын җыеп шалтыраткач та, башта бик төпчәнеп кем сорый дип аптыраттылар. Ирина исем-фамилиясен әйткәч:

— Иптәш хәрби врач, батальон комиссары сез шалтыратсагыз гафу үтенергә кушты. Ул хәзер Мәскәүдә юк, — диделәр.

Ирина Андреевна үзе чакырылган идарәгә ашыкты. Анда аларга тиешле документлар, киемнәр бирделәр. Һәм тагын берничә көннән Испания республикачыларына ярдәмгә озаттылар.

...Ирина Эбро елгасы янында барган сугышларда яраланды. Бәхеткә каршы, яра артык зыянлы түгел иде. Ирина Андреевна кеше күрмәгән арада ярасын бәйләде дә авыррак яралы сугышчыларга ярдәм итәргә кереште.

Бригада сугышчылары иртәгә Октябрь революциясенең егерме бер еллыгын билгеләп үтәргә хезерләнәләр иде. Әмма кичке караңгы төшә башлагач та фашистлар һөҗүмгә күчте. Яңа гына ярдәмгә килгән батальон да ут эченә ташланды. Сугышчылар чигенергә юл юклыкны беләләр. Өченче көн Сарагос[1] җиңелде. Һавада бер-бер артлы фашист самолетлары улый. Тирә-як кара төтен белән күмелгән. Интернациональ бригада сугышчыларының барысын бергә тупласаң, бер батальон җыелырмы, юкмы? Менә шундый чакта ярдәмгә килгән — аз санлы булса да — батальон зур көч иде. Ул сугышчыларның рухын күтәреп җибәрде. Әле анда, әле монда төрле телдә әйтелгән шаяртулар ишетелгәли башлады. Фашистларның соңгы һөҗүме аеруча аяусыз һәм кискен булды. Бомбалар шартлавы тынып бетмәс борын, төтен арасыннан аклы-каралы танклар күренде... Алар траншеяларны, тузан һәм кургаш белән коендырып, таптап үттеләр. Бригада корыч дәһшәтне туктата алмады. Сул флангка таба чигенергә боерык булды. Сәламәт сугышчылар яралыларны җитәкләп, җилкәләренә күтәреп, куып килгән фашистлар белән атыша-атыша чигенә башладылар. Ирина барлык яралыларны озатып бетергәч тә арьергард сугышчылары белән генә чигенергә булды. Эбро елгасының уң ягында бер кызыл һәм яшел ракета һава ярып күтәрелде. Бу — без елганы хәвеф-хәтәрсез кичтек. Кичү эшли. Чигенегез! — дигән сүз иде. Бригада командиры аларны онытмаган икән. Сугышчылар төне буена төньяк-көнчыгышка — Пиреней тау итәкләренә таба бардылар. Интернациональ бригада кешеләре, таулар аша үтеп, Франциягә чыгарга тиеш иде...

## 9

Рамиз яткан караватны тәгәрәтеп тәрәзә каршысына китерделәр. Шул ук бүлмәдә тагың бер караваг бар. Ул Фагыйлә өчен куелган. Аңа палатада яшәргә рөхсәт бирелгән иде. Айлар буена хәрәкәтсез яткан,

[1] Республикачылар сафында сугышкан интернациональ бригадаларның иң соңгы терәк пунктларыннан берсе.

талчыккан ябык гәүдәгә кояш «яшибезме?» дигән сыман елмаеп карады. Шактый вакыт кояшны күзәтеп ятканнан соң, Рамиз урамга күз салды. Анда башкала урамнары. Яуза елгасы салмак кына агып ята. Аргы яр читеннән бер-берсенә сыенышып утырган кызыл кирпеч өйләр, ерактарак алтынга манчылган манаралар күренә. Киртләч калай түбәләрдә — күгәрченнәр... Бер җирдә дә кар әсәре күренми. Елга уртасыннан кечкенә пароходлар сыман боз кисәкләре агып уза... Сул якта елга аша салынган күпернең яртысы күренә. Аннан дөбердәшеп трамвайлар чаба... Әй, гомерләр! Әле бит кайчан гына Рамиз да Төмчә бозларын кораб итеп йөзеп уйный иде. Һәр язда ташкын вакытында суга төшмичә калмый иде ул. Кар сулары төшкәч, елга ярларыннан ташып ага башлый. Ләкин нинди дә булса бер борылышта бозлар терәлеп, туктап кала. Аларның иң алдагысын, иң куркынычын, кыш көне ук хәзерләп куйган өрәңге колга белән мышный-мышный кузгатып, каерып җибәрәсең, аның артыннан башка бозлар да теләр-теләмәс кенә кузгалалар да Иделдәге саллар кебек тоташ ага башлыйлар. Төмчә өсте — эскалатор төсле. Малай-шалайлар һәм егетләр кичләрен боз өстендә учаклар яга. Ул учаклар авылны үтеп киткәнче дөрләп янып, тирәякны яктыртып баралар. Аннан соң, елга борылышы артына кереп китеп, бөтенләй күздән югалалар...

Бер тапкыр Рамиз елганың теге ягында бүленеп калды. Бу як ярда кичке уенга чыккан авыл яшьләре «Беләзек» уйнарга тотындылар. Кыз белән егет кул тотышып басалар да алгы рәткә җиткәч, икесе ике якка йөгерәләр. Алда, урта бер җирдә, «көтүче» тора. Ул кыз булса — егетне, ә егет булса — кызны тотып алырга тиеш. Рамиз бу як югары ярдан Фагыйләнең бер егет белән тотынышып алгы рәткә килеп җиткәнен дә, тегеләрнең болын буйлап әллә кая чаклы йөгерешеп китүләрен дә күреп торды. «Көтүче егет», кыр казы кебек кыелып-кыелып чапкан кызны тота алмагач, кул изәде дә икенче парны куарга әзерләнде. Ә Фагыйлә белән теге егет болынның аргы башыннан килергә ашыкмый кебек тоелды. Рамиз текә ярдан йөгерә-атлый төшү уңаена бер бакча киртәсен суырып алды һәм бер-берсен куышып агып барган бозларның берсенә сикерде. Боз янтаеп китте, әмма капланмады. Ул арада Рамиз икенче зуррак бозга сикерде, аннан өченчесенә, дүртенчесенә... Моны күреп алган яшьләр, уеннарын бүлеп, Рамизның «тилелеген» битәрли башладылар. Яр читенә Фагыйлә дә килеп басты. Рамиз аның алсуланган йөзен, тузгып торган кара чәчләрен күрде дә, тәвәккәлләп, баядан бирле сикерә алмый торган бозга бар куәте белән сикерде. Тик ул сикергән җирдә боз түгел, кайдадыр каралмыйча яткан җепшек кар өеме икән... Рамиз һаман якындагы бозга менә алмыйча азаплана, бозлар арасында ага. Киемнәр торган саен авырая. Инде Рамиз берике кабым су да йотты. Су искиткеч салкын иде. Шул чак яр читендәге төркемнән аерылып Фагыйләнең каядыр чапканын шәйләп калды ул... Ниһаять, аның янына озын колга шапылдап килеп төште. Шуңа тотынгач, ул ярдәмчесенә күтәрелеп карады. Рамиз менәргә азапланган боз өстендә яулыгы җилкәсенә төшкән, чәчләре тузган Фагыйлә елмаеп тора иде. Алар елганың калган өлешен бергә кичтеләр. Иң соңгы боздан ярга сикергәч тә Рамиз Фагыйләнең чәчләренә кагылды. Алардан печән исләре белән аралаш таныш хуш ис аңкый иде...

## 10

Фагыйлә госпиталь тәртипләренә тәмам иятәшеп, кешеләр белән дуслашып бетте. Сестралар ике-өч атнадан ук аны үз иптәшләре итеп саный башлады. Чөнки аның хезмәт сөючән куллары бер эшне дә ярты

юлда калдырмый иде. Бер Рамизны гына карамады Фагыйлә. Барлык авыруларның да гозерләрен үтәргә тырышты ул. Госпитальдә ике атна чамасы Рамиз янында торгач та доктор Ирина Андреевна Фагыйләне няня урынына эшкә алу турында сөйләште. Бүлек начальнигы моңа бик шатланып риза булды. Операциядән соңгы кыен вакытлар, йокысыз төннәр инде үтеп бара шикелле. Тиздән Рамиз торып утыра башлар. Аннары инде йөреп китәргә дә озак калмый диде бит доктор. Әле бүген дә Ирина Андреевна үз бүлмәсенә керергә кушкан иде. Бәлки... бәлки, минем палатада яшәвем кирәкмидер? Юк. Әлегә Рамиз үзе йөри башламас борын, моннан китеп булмый. Алай-болай монда торуның инде кирәге юк дип сүз кузгатса, тагын берәзга гына булса да калдырып торуын үтенергә кирәк булыр. Ә инде риза булмаса, гостиницага чыгып булса да яшәп, килеп-китеп йөрермен. Бәлки әле монда да калдырырлар.

Шул уйлар белән Фагыйлә ординаторлар бүлмәсенә килеп җитте, ак халатын төзәтеп куйды һәм ишек шакыды. Бүлмәдән:

— Керегез, керегез, — дигән тавыш ишетелде.

Ирина Андреевна ялгызы гына авырулар тарихын тутырып утыра иде. Фагыйлә косынка астыннан чыккан чәчләрен тиз-тиз генә яшерде дә Ирина Андреевна тәкъдим иткән креслога барып утырды. Доктор алдында яткан кәгазьләрне таныды Фагыйлә: Рамизның авыру тарихы. Рамизның кайда, ничек яралануы, шуннан соң нинди дарулар белән дәвалаганнары, нинди операцияләр ясалганы — барысы да шул тарихта язылган иде. Андагы күп кенә төрле анализ кәгазьләрен Фагыйлә үз кулы белән теркәп барган иде бит. «Нигә чакырды икән? Әллә Рамизга яңадан берәр төрле операция ясарга җыеналар микән? Югыйсә, Ирина Андреевна юкка гына чакырмас иде». Фагыйлә башын күтәрде дә кара керфекләре аша Ирина Андреевнага карады. Ниһаять, доктор сүз башлап җибәрде:

— Фагыйлә ханым, — диде ул. — Беләсем килгән нәрсәм шул иде: әйтегезче, сез кайда тудыгыз? Татарстандамы?

— Әйе, Ирина Андреевна.

— Сез Җәләев белән бергә үстегезме?

— Әйе, Ирина Андреевна. Дөрес, Рамиз Җәләев миннән ике яшь чамасы олырак... Алтынчы класска чаклы ул миннән бер класска алда укыды. Ә алтынчы класста... ул үзенең ике иптәше белән «бәхет эзләргә» чыгып китте. Мин көтү куып кайтканда күреп калдым.

— Ничек инде ул, Фагыйлә? Нинди «бәхет эзләргә»?

— Бездә, Ирина Андреевна, шундый гадәт бар иде. Сугыштан соң ата-анасыз ятимнәр һәм шук малайлар тимер юл станциясенә барып, товар вагоннарына утырып китеп баралар иде. Шушы «сәяхәтләрен» алар «бәхет эзләү» дип атыйлар иде.

— Шуннан, Фагыйлә? Сезнең Җәләев «бәхетен» тапканмы соң?

— Каян тапсын! Тавыш кубарып йөрүләре генә булды. Өч атна дигәндә үзләрен милиция белән авылга кайтарып куйдылар. Шуннан соң инде гел бергә укыдык.

— Сезнең туганнарыгыз, әти-әниләрегез исән-саулармы соң?

— Минем әнкәй исән-сау, шул авылда яши. Абыем, апам бар. Ә Рамизның... аның хәзер беркеме дә юк.

— Ничек алай?

— Аның әтисе белән әнисе Кызыл Армиядә хезмәт иткәннәр. Рамиз авылда туган. Әнисе ялга кайткан чак булган. Рамиз туып өч-дүрт ай үтмәгән, әтисе ил чигендә үлеп калган. Әнисе, сезнең кебек, хәрби врач булган. 1936 елны авылга кайтып күреп киткән Рамизны. Аннары, имеш, аны чит илгә озак вакытлы командировкага җибәргәннәр.

Шуннан бирле хаты да, хәбәре дә килмәгән. Рамиз алар турында сөйләшкәнне бер дә яратмый. Исенә төшерсәң, кашларын җыера башлый. Мин әйтәм, бәлки әниеңне Испаниягә җибәргән булганнардыр. Вакыт шундый булган ич. Шулай булуы бик мөмкин бит әйеме, Ирина Андреевна?

— Мөмкиндер, бәлки... Әйе, мөмкин... Ә Җәләевнең ата-анасы турында шуннан башка бернәрсә дә билгеле түгелме?

— Юк. Әтисе шулай хәбәрсез югалган. Әнисеннән дә бүтән хәбәрхәтәр булмаган...

— Ә соң Рамиз үзе эзләтеп карамаганмы?

— Исән булса, бер кайтыр иде, ди, әнисе турында. Бәлки башка семьясы, башка малайлары бардыр, минем кирәгем дә юктыр, ди... Рамизның әнисе рус кызы булган, Ирина Андреевна. Авылдашлар «ул авыл җиренә кайтып яшәргә теләмәгәндер» дип тә сөйләнделәр. Аңа Рамиз ышанмый. Әле Рамизның әбисе сөйләгән сүзләр һаман хәтердә: «Бигрәк тә үз итә иде безне, авылда торган арада гына да әллә нихәтле сүз өйрәнгән иде», дип сөйли иде ул.

— Ул әби кайда соң хәзер, авылдамы?

— Үлде шул, Ирина апа. Рамиз унынчыда укыганда үлде...

Әлегә чаклы тыныч булырга тырышып утырган Ирина Андреевна, иреннәрен тешләп, чигәләрен куллары белән тотты. Аның дулкынланганы әллә кайдан күренеп тора иде. Шулай да күп еллар буена хәрби тәртипләргә, көтелмәгән хәлләргә күнеккән бу хатын кирәк вакытта үзен кулга ала иде. Аннары... моны көтелмәгән борылыш дип тә булмый бит әле... Ирина Андреевна, урыныннан торып, өстәл артыннан чыкты да паркет идәнгә җәелгән келәм өстеннән арлы-бирле йөри башлады. Аның иң соңгы икеләнүләре дә челпәрәмә килгән иде. Ул хәзер теге вакытта авыл Советыннан килгән хатка ышануына үкенә, аптырый иде. Ул сизелер-сизелмәс калтыранган бармаклары белән өстәл тартмасыннан сигарет алып кабызды. Тагын берничә тапкыр арлы-бирле йөренеп алды. Шул вакыт ишек төбендәге тумбочкада телефон шалтырады. Ирина Андреевна сигарет көлен көл савытына төшерде дә телефон трубкасын күтәрде.

## 11

Палатага Совет Армиясенең баш хирургы — академик Вишневский, Рамиз дәваланган бүлек җитәкчесе — Совет Армиясенең баш невропатологы, Рамизга катлаулы соңгы операцияне ясаган нейрохирург һәм Ирина Андреевна килеп керде. Аларны озатып йөрүче врачларның палатага сыя алмаганнары ачык ишек төбендә калды. Ләкин академик Вишневский ишекне ябарга боерды. Ирина Андреевна, генерал янынарак барып, Рамиз Җәләевнең авыру тарихын сөйли башлаган иде, академик аны бүлдереп:

— Мин бу егетнең тарихы белән таныш инде. Күрәм, операция уңышлы үткән, — диде.

— Әйе.

Академик, инде шактый олы яшьтә булуына карамастан, ярыйсы гына хәрәкәтчән кеше икән. Өстендә ятышлы тегелгән генерал мундиры. Күкрәгенең сул ягында биш рәт булып тезелгән орден һәм медаль тасмалары күренеп тора. Халат төймәләре төймәләнмәгән. Маңгай чәчләре инде күптән сирәгәйгән, чигәсенә чал суккан. «Иптәш академик, үз гомереңдә күпме кешене үлем кочагыннан тартып алып, сафка бастыр-

дың! Мине ни эшләтерсең икән?» дип уйлады Рамиз. Аннары генералның:

— Ә син, өлкән лейтенант, ничек уйлыйсың: операция уңышлы үттеме? — дигән соравына:

— Мин, иптәш генерал, тизрәк бу «санаторий»дан котылып, хезмәтемә кайтасы иде дип уйлыйм. Ләкин бәла шунда — һаман урыннан күтәрелеп булмый, — дип җавап бирде.

— Э-э-э, брат. Синең кәефләр шәптән түгел икән. Ә бит мондый «сикерешләрдән» соң, дускаем, организмыңның ныклыгына, яшьлегеңә, менә бу «ак халат»ларга һәм аеруча Ирина Андреевнага күп итеп рәхмәт әйтергә кирәк.

Рамиз дәшмәде. Академик аның авыру тарихындагы анализ кәгазьләрен бик зур игътибар белән карады, йөрәк тибешен тыңлады. Ирина Андреевнадан «чүкеч» алып, егетне «чүкечнең» әле бер башына, әле икенче башына каратты. Каш тирәләренә бармаклары белән басты. Аннан соң Рамизны йөзтүбән әйләндереп салдылар. Академик егетнең ябык аркасына, муенына энә белән чәнчеп чыкты. Сизү-сизмәвен сорашты, аяк табаннарына чаклы энә белән кадап карады. Рамизга мондый «процедураларны» көн саен бернечә врач кабатлап тора иде. Әмма аның табаннары берни дә тоймый торган иде. Ә менә бүген Рамиз табаннарына энә чәнчелгәнне тойган кебек булды. Башта бу хәлгә ышанмыйчарак торса да, икенче, өченче тапкыр чәнечкәндә, Ирина Андреевнага карап, гаепле кеше сыман кыяр-кыймас кына:

— Сизәм,— диде. Аның табанына тагын чәнчеп карадылар. Шуннан соң Рамиз бөтен бүлмәне яңгыратып: — Сизәм! — дип кычкырды.

— Син нәрсә, өлкән лейтенант, акырасың? — диде генерал һәм докторларга латинча нәрсәдер әйтте. Академикны баш невропотолог алмаштырып, «процедураны» янә бер кат кабатлады. Аннары академик кичәге рентген рәсемнәрен сорап алды. Ул тырышып-тырышып рәсемнәрдән нәрсәдер эзләде. Кесәсеннән икенче күзлек чыгарып киде дә тәрәзә яктысына килеп тагын карады. Янә килеп Рамизга чәнечкәләде. Рамизның кулларын күтәреп-төшереп «физзарядка» ясатты. Рамиз кулларын авыртусыз диярлек күтәрә дә, төшерә дә ала иде.

— Шәп бу, бик шәп, дускай, бик шәп! — дип сөйләнде Вишневский. Аннары Рамизның аягын тездән бөгәргә тырышып карады. Ләкин Рамизның умыртка сөягенә меңләгән энәләр чәнечте. Егет ыңгырашып куйды.

— Нәрсә, авырттымы? — дип килеп кушылды нейрохирург. Ул, латинчалап академикка нәрсәдер әйтте дә, Рамизның аякларына учлары белән сугып: — Ничего, пехота, бу аякларның элекке взвод командиры аяклары икәнен әле дә белеп була. Озакламый кросста йөгерергә мөмкин булачак синә! — диде.

— Ишеттеңме? — диде Вишневский, тегенең сүзен куәтләп. — Ә син... Һәр нәрсәнең, дускай, үз вакыты бар. Так што, борыныңны салындырма. Сау бул. Терел! — дип урыныннан кузгалды да уң кулы белән ишеккә ишарә ясады. Барысы да аңа юл бирделәр...

Докторлар кереп тулганда Фагыйлә бер почмакта басып калган иде. Ул барысын да ишетеп торды. Дөрес, ул элек тә Рамизның тереләүенә өметен өзмәгән иде. Ә хәзер, докторларның шундый сүзләреннән соң, аның ышанычы чыңга ашты. Ул, Рамиз янына килеп, койка читенә утырды. Йомшак куллары белән иренең әле күптән түгел генә марлялардан арынган, озак вакытлар бәйләүле булудан марля төсле агарган маңгаена кагылды, битләреннән сыйпады.

— Рамиз, — диде ул. — Рамиз, кадерлем! Ишеттеңме, җаным? Әйттем ич мин сиңа, әйттем ич, терелерсең дип!..

Фагыйлә — ничәмә-ничә төннәр буена күз йоммыйча Рамиз янында утырып чыккан, шул төннәр эчендә күз төпләренә, маңгаена әллә нихәтле сырлар салган Фагыйлә — Рамизның күкрәгенә башын куеп, сулкылдый башлады. Аның күзләреннән әле генә җир катламын тишеп өскә чыккан чишмә суыдай саф, кайнар яшь тамчылары тама иде. Рамиз дулкынланудан, бөтен күңелен биләп алган, әлегә аңлашылып бетмәгән шатлыктан аптырап калды. Авыр сулыш ала-ала Фагыйләне юатырга тырышты. Әлегәчә әйтелмәгән ниндидер тылсымлы сүзләр эзләп карады. Аның баш мие — яраланган, ләкин һәр минут, һәр секундта, секундның һәр мизгелендә яшәү өчен көрәшүдән тукталмаган җисем — бу юлы көчсез иде. Андый назлы, мәхәббәтле, бар теләгәнен бер талпынуда әйтеп бирердәй сүзләрне эзләп таба аласыңмы соң? Ул сүзләр әллә кая китеп югалган иде. Рамиз бары тик:

— Фагыйлә!.. Фагыйлә!.. Фагыйлә!.. — дип кенә кабатлады.

Икенче көнне иртүк Ирина Андреевна өлкән лейтенант Җәләев палатасына кереп чыкты. Фагыйлә Рамизны юындыру белән мәшгуль иде. Ул гаҗәпләнеп докторга карады. Гадәттә, бу вакытта бүлек врачлары әле җыела гына башлыйлар. Шуңа күрә дә ул докторның сәламенә җавап бирү белән:

— Иртәләгәнсез бүген, Ирина апа, — диде.

Фагыйләнең инде шулай дип эндәшүенә күнеккән доктор:

— Юк, Фагыйлә, иртәләмәдем. Менә Рамизны куандырыйм дигән идем. — Ул Рамиз янына килде. — Беләсеңме, өлкән лейтенант, синең авыру тарихыңа якташың нәрсә язды?..

— Кем ул, Ирина Андреевна? Нинди якташ?

— Академик Вишневский! Ул Казанда, Татарстанның башкаласында туган, Казан университетының медицина факультетын тәмамлаган ич! Белергә кирәк, кадерлем, андый якташларны...

Фагыйлә Рамизның битләрен сөлге белән сөртеп алды да, докторга борылып:

— Ирина апа, нәрсә эшләргә дип язган соң безгә академик? — дип сорады.

— Бик җиңел нәрсә түгел. Ләкин түзәргә кирәк булачак. Пневмоэнцефалография дип атала ул операция. Без Рамизга аны бер ясаган идек! Ул вакытта егетебез, һушсыз булганга, аның шифасын сизмичә калды. Академик ул операцияне хәзер, операция яралары инде төзәлеп килгәндә, тагы да бер кат ясарга куша, — диде дә, тәрәзә каршысына килеп, урамга карады.

Инде көз якынлашып килә иде. Башкала өстендә вак яңгыр сибәли. Аның тамчылары салкын җил белән тәрәзә пыяласына килеп сылана. Ирина Андреевна салмак кына борылды да:

— Син, Рамиз, әзерләнебрәк тор, — диде. — Әгәр дә инструментларны әзерләп бетерсәләр, сәгать уннан да калмабыз.

Фагыйлә: «Теге көндәге сөйләшүдән соң доктор бөтенләй үзгәрде бит, нигә шундый сораулар бирде икән ул», дип уйлап калды.

Нәкъ сәгать унда Рамизны рентген кабинетына алып килделәр. Рентген өстәленең бер башы югары күтәреп куелган иде. Егетнең башын шул якка салдылар... Бераздан аның бил турысында умыртка сөяген нәрсәдер чеметеп куйды. Рамизның хәтеренә теге вакытта, саташып болында ятканда, умарта корты тешләгән вакыйга килеп төште...

## 12

Совет дипломатларына интернациональ бригада составында сугышкан совет граждannарын илгә кайтару өчен шактый көч куярга туры килде. Чөнки аларны илдән илгә, лагерьдан лагерьга күчереп йөртәләр иде. Әмма совет кешеләре һәм аларның күп санлы дуслары сугышчыларны кабат-кабат эзләп таптылар. Ниһаять, бу эшкә Совет хөкүмәте җитәкчесе, Верховный Башкомандующий да кушылды.

Хәрби врач Геева һәм интернациональ бригаданың тагын дүрт сугышчысы туган илебезгә Бөек Ватан сугышы башлангач, Франция, Канада, АКШтагы авыр, берничә елга сузылган мәшәкатьләрдән соң Иран аша кайттылар. Ватан үзенең кыю улларын һәм кызын даулап алды.

Алар Ашхабад кунакханәләренең берсенә урнаштылар да, өс-башларын да тәртипкә кертеп тормастан, соңгы айлардагы газеталарга ябыштылар. Инде шактый вакыт илдән аерылып торган кешеләр өчен Ватан җирендә барган канлы сугыш вакыйгалары беренче чиратта торсалар да, илебез халыкларының соңгы еллардагы сулышы шулай ук олы әһәмияткә ия иде.

Тагын бер атнадан интернациональ бригада сугышчылары самолет белән башкалага очтылар. Мәскәү урамнары элеккечә шау-шулы, ыгы-зыгылы түгел, һәркайда сугыш билгеләре сизелеп тора иде.

Ирина Андреевна иптәшләре белән бергә үзләре чакырылган идарәгә килде. Аларны идарә ишегалдындагы тулай торак бүлмәләренә урнаштырдылар...

Ирина Андреевна коеп яуган көзге яңгыр тавышын озак тыңлап ятты. Ул үзенең яңадан илебез башкаласында икәнлегенә куанып бетә алмады. «Менә ул — туган ил! Менә ул, кайчандыр мин — ятим кызны үз кочагына алып, югары уку йортында белем биргән башкала!..»

Ирина Андреевнаның уйлары яңгыр тамчылары шыбырдаган тавышка кушылып еракка китте. Мондагы идарәдә эшләр беткәч тә Ирина Андреевна ял алачак. Татарстанда аның улы бар бит. Ул инде хәзер дәү малай булгандыр. Быел икенче класста укырга тиеш. Әнисен, билгеле инде, танымас, танымас... Ләкин ул барыбер аны сагына торгандыр. Испания окопларында ятканда да, төрле күчерү лагерьларында да, теләсә генә нинди ил күге астында да ана үзенең баласын оныта алмый. Ул аның күз алдына иң хәтәр, иң мөһим һәм хәлиткеч минутларда килеп баса. Ирина Андреевна үзенең улын алпан-тилпән тәпи йөри башлаган түм-түгәрәк малай итеп исенә төшерә иде... «Әле мондагы эшләр бер-ике атнага сузылыр, иртәгә үк кайнанам белән улыма хат язарга кирәк булыр», дип күңеленә беркетеп куйды Ирина Андреевна. Яңгыр шыбырдавы аша кайдадыр бер читтәрәк еш-еш тукылдап, зенит туплары аткан тавыш ишетелде. Ирина Андреевнаның аңына илдә дәһшәтле сугыш барганлыгы бөтен тирәнлеге белән барып җитте. Күпме дусларын Испания тауларында калдырган врач йөрәге сыкранып куйды. Җир шарында тагын кан коеш бара. Фашизмның эшәкелекләрен үз күзе белән күргән Ирина Андреевна ил өстенә килгән дәһшәтне бөтен барлыгы белән аңлый иде. «Тизрәк, тизрәк, мондагы эшләрне тәмамлап, улымны кайтып күрергә дә фронтка ашыгырга кирәк!» Пиреней тау итәкләрендә ятып калган дуслары өчен, совет кешеләренең тыныч йортына вәхшиләрчә бәреп кергән өчен, Ирина Андреевнаның фашизмнан үч алу чарасы бер генә иде: ул яраланып сафтан чыккан бөркетләрне мөмкин кадәр тизрәк яңадан сафка бастырырга тиеш. Моның өчен ул бөтен белемен, бөтен көчен һәм тәҗрибәсен биреп тырышачак.

Инде башка йоклый алмаячагын аңлап, Ирина Андреевна урыныннан торды да, тәрәзә пәрдәләрен тагын бер кат яхшылап томалап, өстәл янына барып утырды. Озак кына уйланып, кәгазь өстенә карап

утыргач та Ирина Андреевна улына язасы хатны ничек башларга белмичә аптырап калды. Теге вакытта язган хатларын ул, аңа атап язса да, олыларга адреслый. Ә хәзер?.. Ана булып яшәүне кырыс хәрби хезмәткә алыштырган Ирина Андреевнага семья тормышы бөтенләй диярлек ят иде. Еллар һәм берсеннән-берсе кырыс вакыйгалар үз эшен эшләгән. Хәзергә әле Ирина Андреевнаның иң нечкә, иң саф хисләре әллә кайда, йөрәкнең иң тирән түренә яшеренгән иде... «Башта баланың сау-сәламәт икәнлеген, кайда һәм ничек яшәвен белергә кирәк», дип, Ирина Андреевна хатын авыл Советы председателе исеменә язарга булды.

Идарәдәге эшләр озакка китте...

Бер көнне идарә ишегалдында һава сулап утыручы Ирина Андреевна янына җиңел машина килеп туктады. Аннан дүрт кеше чыкты. Аларның берсе Ирина Андреевнага таныш иде.

— Иптәш батальон комиссары!

Машинадан чыгучылар барысы берьюлы беседкага таба борылдылар. Ирина Андреевна тагын бер кат, аларның бөтенесе дә ишетелерлек итеп:

— Иптәш батальон комиссары! — диде.

Батальон комиссары хәрби врачны таныды.

— Хәрби врач Геева! — диде ул һәм ашыгып килеп күреште.

— Сез, сез ничек монда?

Ирина Андреевна эндәшмәде...

Тагын ике атнадан интернациональ бригада сугышчыларының бишесен дә Кремльгә чакырдылар. Башкала урамнарында инде күптән салкын кыш иде. Аларны зур, якты бүлмәгә алып керделәр. Бүлмәнең аргы башында төрле кәгазьләр һәм папкалар белән тулы эш өстәле. Өстәл артындагы стенада «Правда» газетасын укып утыручы Ленин портреты. Бүлмәгә кергәч тә уң якта тагын бер — утырышлар өчен махсус өстәл. Интернациональ бригада сугышчылары утырышлар өстәле тирәсенә утырдылар.

Ниһаять, каршы яктагы ишек ачылды. Бүлмәдәгеләр торып басты. Алар алдында Верховный Башкомандующий үзе иде. Ул барысы белән дә берьюлы баш кагып исәнләште дә өстәл янына килде. Аннары өстәл өстендәге кызыл тартмаларның берсен алды һәм өстәл тирәсендә басып торучыларны барлап карагач:

— Хәрби врач Геева Сугышчан Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә, — диде.

— Советлар Союзына хезмәт итәм!..

Ул төнне Ирина Андреевна күз йоммады: уттай янган яңагы астына йодрыгын куеп уйланып ятты. «Иртәгә!.. — дип уйлады ул. — Иртәгә поездга билет алам да ике-өч көннән улым янында булам. Дөрес, хәзергә кадәр мин аңа дус та, иптәш тә, кыерсытканда яклаучы да түгел идем. Мин аны яңадан тудырган сыман булырга тиешмен. Мин аның белән әнисе буларак яңа гына танышачакмын... Чөнки мин бит аны бөтенләй белмим. Мин аны иркәләп бишек җырлары җырламадым. Ләкин мин аны беркайчан да онытмадым. Ул Ерак Көнчыгышта да, Пиреней тау итәкләрендә дә, чит дәүләт «кунакханә»ләрендә дә минем белән иде. Кайткач та аның белән һәр сүзне уйлап сөйләшергә кирәк булыр. Аны уңайсыз хәлгә куймыйча, барысын да акрынлап кына ачыклый барырга кирәк булыр...

Ирина Андреевна торып тәрәзә янына килде.

Пәрдә читен ачып, кышкы урамга карап озак басып торды. Туңа башлавын тоеп, бүлмәгә узды. Тәрәзә янындагы өстәлдә хат ята иде. «Кич кайткач та, ут алып тормыйча урынга егылган идем. Дежур апа хат кертеп куйган лабаса», дип, Ирина Андреевна өстәл лампасын кабызды.

Галләметдин Җәләев Ватан сугышына бөтенләй бармады. Кырыгынчы елда фин сугышында яраланып, сул кулын имгәтеп кайткан иде. Ватан сугышы башланып, кулына корал алырлык ир-атлар фронтка китеп баргач та аны авыл Советы председателе итеп куйдылар. Ул кеше — Рамиз этисе Сәлимнең бертуган абыйсы иде.

Ноябрь ахырларында авыл Советына Мәскәүдән бер хат килеп төште. Ул хатны Рамизның әнисе язган булып чыкты. «Күр әле, югалган килен сау-сәламәт килеш Мәскәүдә яшәп ята икән лабаса!» Председатель бу хатны кат-кат укыды. Ләкин беркемгә дә күрсәтмәде. «Ярый әле, — дип уйлады ул, — почта үземнең кулыма килеп эләкте, болай булгач, шөкер, үзебез генә белеп торырбыз».

Галләметдин Җәләевнең энесе Сәлимнең чик буенда үлеп калуына әнә сигез елдан артып китте. Хатыны да «командировкага китәм, энкәй, баланы үстерегез инде» дип әйтергә атна-ун көнгә авылга кайтты да шуннан китеп юкка чыкты. Ләкин бит җиде еллык командировка буламыни соң? «Авыл халкын томана дигәч тә... Юк, без дә төшеп калганнардан түгел. Безне алай гына кәкре каен терәтүчеләр дип санамагыз әле!» Галләметдин абзый Рамизның әнисе турында үз каланчасыннан торып фикер йөртте. — Рамиз инде үсмер булып килә. Икенче класста укый. Аны үстереп җиткергәндә генә кемгәдер биреп җибәрергәме? Юк инде, туган, шабаш! Галләметдин абзагызның әнә алты кызы бар. Алар белән ни эш майтарасың, ди? Берсе артыннан берсе китеп тә барырлар, күр дә тор. Ә Рамиз исә гел кул астында булачак. Бу председательлек эше озакка бармас. Герман немечләрен тиз дөмектерерләр, сугыш беткәч тә яшьләр кайтыр, авылга алар хуҗа булыр. Кыскасы, — дип уйлады Галләметдин абзый, — форсаттан файдаланып калырга кирәк. Рамизны караучысы юк дип, үземә уллыкка яздырып алырмын. Ә бу хатка җавап бирергә кирәк. Яхшылап, башка хат язмаслык итеп җавап бирергә кирәк. Бер ходай үзе аклар әле. Әллә нинди җинаять эшләмим, ятим бала турында кайгыртам бит. Рамиз үз ата-анасының хәрби кешеләр булганын белә. Аңа, әнә, әбисе белән икесенә, 470 тәңкә пенсия чыгып тора. Инде хәзер егет үзе дә эти-әни дип борчылмый кебек. Үзеннән ике-өч яшькә олырак малайларга да бирешми: чаялыгы бар, чәчрәп тора. Бер көн әнә түбән оч Әхмәди малае Гаптеринә авызын канга буяп кыйнаган. Тегесе: «Синең анаң маржа», — дигән, бәрәкәтсез. Атасын чакыртып әйтергә кирәк булыр, телен тыйсын»...

Берничә көн шушы уйлар белән йөргән Галләметдин абзый, ниһаять, төннең-төн буена авыл Советында утырып, тирләп-пешеп хат язды. Кәҗә тиресеннән тегелгән камзулын салып, йорт кенәгәләре сандыгы өстенә ташлаган иде. Бөтен булган гыйлемен җыеп, әйләнә тирәсенә русча-татарча газеталар җыйнап эшкә утырды:

«Уважаймая Иринә Әндриевнә!
Ваша писма получила Сельсовет персидәтеле. Нижепоследущим сопшаю следуши. Ваша сын Ремез Җәләев типир диривня не живет. Он за диривня могила закопали ишшо 1938 году. Весной речной вода упал. Танул. Бабушка его 1940 гаду умирла. Подомовой книга точно написал секлитар. Прашу изминит такуй сопшени. Твой горе наш горе.

Персидәтел Галләметдин
28 ноябр 1941 гуд».

Дөрес, Галләметдин абзыйның әлегә исән-сау әнисен һәм уллыкка алырга йөргән туганы Рамизның үләме турында язганда кулы тынламый торды торуын. Ләкин, ходайның ярдәменә ышанып, Галләметдин абзый аларын да язып куйды. Үзенең әллә ни биек булмаган каланчасыннан фикер йөртсә дә, председатель ике нәрсәне бик нык истә то-

тып язды. Беренчесе — Рамизның үзгәртелгән исеме булса, икенчесе председатель подписына кагылышлы иде. Галләметдин абзый үзенең фамилиясен ачык язмыйча, гарәпчә «Галләметдин» дип куйды.

Ә икенче көнне Галләметдин абзый, районга махсус барып, хатны район элемтә бүлеге почта ящигына үз кулы белән салып кайтты.

...Ирина Андреевна кулында хәзер әнә шул хат иде. Ирина Андреевна дулкынланудан каушаган хәлдә конвертның бер читен ертып, сул як почмагына Яңа Кизү авыл Советы штампы һәм текст астына герблы печать сугылган кәгазь битенә карады. Тагын бераздан басып торган җирендә идәнгә чүгәләде. Якындагы караватка барып җитәрлек хәле калмаган иде. Бүлмәдә дә, башкала урамнарында да тынлык. Көн саен берничә тапкыр ямьсез тавыш белән улый торган сиреналар бүген бөтенләй ишетелмәде. Ирина Андреевна еламады. Аның күкрәген, ниндидер авыр таш баскан сыман, кайгы кыса иде...

Иртәгесен Ирина Андреевна идарә начальнигы янына кереп, ял алырга теләмәвен әйтте һәм үзен хәрәкәттәге армиягә җибәрүләрен үтенде. Идарә начальнигы аның олы кайгысын уртаклашып, кулыннан килгәнне эшләргә вәгъдә итте. Ул сүзендә торды. Шул ук көнне кич хәрби врач Геева башкаланы оборонлап тора торган бер дивизия госпиталенә баш врач итеп билгеләнде.

## 14

Рамиз пневмоэнцефалография дип аталган операцияне бик авыр кичерде. Берничә мәртәбә һуштан язды. Ләкин борынын ярып кергән нашатырь исе аны кабат-кабат аңына китерә торды. Сызлануларга һәм авыртуларга, төрле-төрле хирургия инструментларына инде ияләшә башлаган Рамиз доктор кисәткән операция шифасын хәзер чын-чынлап тойды. Арка мие юлыннан баш куышлыгына җибәрелгән кислород искиткеч авырлык белән баш миен кыса. Баш сөяген җимереп чыгар шикелле тоела. Яралардан зарарланган нервларның ябышкан җирләре, кислород басымына каршы торалмыйча, өзелеп, яңа авыртулар кузгата. Ләкин әле эш баш куышлыгына кислород җибәрү белән генә бетми. Рамизны әйләндереп-әйләндереп рентген аша рәсемгә төшерәләр. Кислород баш миендәге, хәзергә башка ысуллар белән күреп булмый торган, нервларны «яктыртып» күрсәтә икән. Авырулар бу операцияне авыр кичерәләр, ләкин үзәк нерв системасын тикшерүдә һәм дәвалауда иң яңа, иң ышанычлы ысул шул.

Аз гына кыймылдау да бетмәс-төкәнмәс авыртуга әверелә. Баш куышлыгына кереп тулган кислород «йөри» башлый Моңа бер генә чара бар: ничек кенә булса да селкенмичә, авырту дулкыннары үтеп киткәнне көтеп, түзеп торырга кирәк. Берничә минуттан, әрнүле авырту югалып, кислород басымы тудырган тупас авырту гына кала.

Рентгеннан алынган рәсемнәр яхшы сыйфатлы булып чыккан иде. Төшке аштан соң аларны Ирина Андреевнага кертеп бирделәр. Рентгенологның аңлатмасы да шунда иде. Анда да Рамизга ясалган операциянең уңышлы булырга тиешлеге әйтелгән. Ирина Андреевна, әлеге рәсемнәрне тагын бер тапкыр бик җентекләп карагач һәм үзенең күзәтү нәтиҗәләреннән чыгып, «Рамизның аяклары хәрәкәтләнә башларга тиеш» дигән нәтиҗәгә килде. Башка эшләрен тәмамлагач, ул тагын бер кат Рамиз палатасына керде. Өлкән лейтенант йоклый иде. Доктор Фагыйлә белән сөйләшеп утырды. Аның уйлары һаман саен үткәнгә кайта иде.

Ирина Андреевна инде өлкән лейтенантның үз улы, туган улы, бердәнбере икәнлегенә ышана. Ләкин моны Рамизга ничек әйтергә соң?

Ничек аңлатырга? Моңа чаклы Ирина Андреевнага аңлашылып бетмәгән бер нәрсә булса да, хәзер ул да ачыкланды. Бу бик гади иде. Татарлар өчен аңлаешсыз РЕМЕЗның РАМИЗга әйләнүе бик табигый икән. Әйе, Ирина Андреевнаның өлкән лейтенантны әле беренче тапкыр күрүгә үк йөрәге сискәнеп куйды. Чөнки авыр яралы егет янына барып, марляларны чишеп карый башлауга докторның күзләре егетнең каш өстендәге миңенә төште. Бу «тамга»ны Ирина Андреевна оныта ала идеме соң? Аның үзендә дә тумыштан килгән шундый ук миң бар ич. Ләкин бу охшашлыкның очраклы хәл булуы да мөмкин иде.

Ирина Андреевна үз гомерендә бер генә ялган сүзне дә кәгазь битенә язмады гына түгел, сөйләмәде дә. Һәр эшне намус белән, җиренә җиткереп башкарырга өйрәнгән иде ул. Һәм рәсми урыннарда Совет власте ышанып тапшырган эшне барысы да шулай, үзе кебек намус белән башкара дип уйлый иде. Ләкин әле безнең басуларда, сирәк булса да, чүп үләннәре үсә икән...

...Полковник Геева сугыштан соң һәр ел саен Яңа Кизүгә кайтып, улының каберен күреп килергә җыенды. Әмма һаман да вакыт тимәде. Сугыштан соңгы берничә ел Ленинградта Хәрби медицина академиясенең ординатурасында үтте. Аннары кандидатлык һәм докторлык диссертацияләре дә күп вакыт таләп итте. Шулай итеп, улының каберен кайтып күрү һаман соңга калды...

Пневмоэнцефалография операциясеннән соң икенче көнне Рамиз йокысыннан, башы әле авыртса да, тәнендә җиңеллек тоеп уянды. Урында җайлабрак яту теләге туды. Рамиз инде бер ел буена хәрәкәтсез яткан уң аягын караватарка сына китереп терәде дә гәүдәсен өскә таба этәрде. Моны күзәтеп торган Фагыйлә, ни әйтергә белмичә, аптырап сүзсез калды. Аннары:

— Рамиз, Рамиз, сул аягыңны да кыймылдатып карале,— диде.

Рамиз, әлегә үзе дә төшенеп бетмәгән автоматик хәрәкәт белән, сул аягын да урын өстеннән бераз күтәреп караватчитенәрәк күчерде. Ләкин баш куышлыгындагы азрак селкенүне генә көтеп торган кислород Рамизны сыкранырга мәҗбүр итте.

Ә Фагыйлә исә, күз ачып йомганчы палатадан чыгып, ординаторлар бүлмәсенә барып керде:

— И-ии-рина... Ан...

Докторның миен Рамизга бер-бер хәл булгандыр дигән уй ярып узды, тамагына тыгыз төер килеп тыгылды.

— Ни булды, Фагыйлә?

Һәм ул, Фагыйләнең җавабын көтеп тә тормастан, Рамиз палатасына ашыкты. Рамиз авызын колагына хәтле ерган да аякларын тездән бөгеп һәм турайтып карау белән мәшгуль иде. Бу хәлне күргәч, Ирина Андреевна тәмам хәлсезләнеп ишек яңагына сөялде. Аның күзләреннән шатлык яшьләре бәреп чыккан иде. Докторның елап торуын күргәч, Рамиз шөгыленнән туктады. Кинәт аның күз аллары караңгыланды. Ишек яңагына сөялеп торучы доктор баскан урынында әйләнә башлаган шикелле тоелды. Өлкән лейтенант, күзләрен зур ачып, кабат ишек төбендәге докторга карады. Аның иреннәре ирексездән «әни» дип пышылдады. Рамиз, үзе дә сизмичә, сул кулын маңгаендагы миң өстенә куйды. Миң үз урынында иде. «Кара, ничек охшаган бу доктор минем фотокарточкадагы әниемә,— дип уйлады Рамиз.— Дөрес, мин аны бер тапкыр да күрмәдем. Аның образын, бала чактан сакланган бердәнбер рәсемдәгечә, гомер буена күңелемдә сакласам да, Галләметдин абый «әниең чик буенда хәбәрсез югалды» дип әйткәч, мин аны көтмәдем дә, эзләмәдем дә. Исән булса, кирәк булсам, кайтыр иде дип исем китмәгәнгә салыштым. Ләкин алай түгел бит. Менә әнкәй, минем хыялымда һәр вакыт сау-сәламәт яшәгән әнкәй мине саташтыра...» Ләкин бу инде саташу түгел иде.

Бу Рамиз Җәләевнең яңадан тууы, тормышка кайта башлавының башы иде.

## 15

Рамизны азаплаган баш авыртулары шактый кимеде. Шуның өстенә моңарчы һаман караватта ятарга мәҗбүр итеп, әсирлектә тотучы аяклар да ярыйсы ук хәрәкәтләнә башладылар. Егетнең йөзенә алсулык йөгерде. Аппетиты күзгә күренеп әйбәтләнде. Инде берничә көн рәттән өлкән лейтенант махсус врач ярдәмендә гимнастика күнегүләре белән шөгыльләнә. Баштарак бер-ике селкенү белән шыбыр тиргә бата торган Рамиз хәзер күнегүләрне врач киткәч тә кабатлап ята. Соңгы көннәрдә ул: «Озакламый терелеп частька кайтып китәрмен», дип тә хыяллана башлады.

Бүген дә, һәр вакыттагыча, иртәнге унда палатага Ирина Андреевна килеп керде. Аның артыннан ук физиотерапевт та күренде. Ул Рамиз белән исәнләшкәч тә докторга:

— Бүген, Ирина Андреевна, сезнең белән бергәләп, өлкән лейтенантны тәпиләренә бастырып карыйбызмы әллә? — диде.

— Бик әйбәт булыр иде ул. Мин дә шул фикердә. Тик тагын бер тикшереп карыйк әле.

Ирина Андреевна Рамизның кулын беләзек турыннан тотып йөрәк тибешен санады. Аннары ике беләгеннән дә кан басымын үлчәде. «Чүкеч»ен чыгарып Рамизның беләкләренә, тезләренә суккалап тикшереп карады. Чүкеч сабына урнаштырылган энәне суырып алды да егетнең күкрәкләренә, калак сөякләренә сызгалады, чәнечкәләп карады. Рамизның башын акрын гына бер уңга, бер сулга, артка һәм алга таба боргалады. Ярты сәгатьләп тикшергәннән соң гына:

— Ну, эшләр начар түгел. Болай булгач тәпиләренә бастырмыйча да булмас... — диде.

Дежур шәфкать туташларын да чакырдылар, дүртәүләп Рамизны тәпиләренә бастырып карарга керештеләр.

Бер елга якын гел урын өстендә генә яткан Рамизны беренче тапкыр аягына бастыра башлагач, аның күз аллары караңгыланып китте, башы әйләнергә тотынды. Күңеле болгана башлады. Шулай да берничә көн урында утырып тору һәм гимнастика күнегүләре ясауның файдасы тиде бугай. Ул тешләрен кысып озаграк басып торырга тырышты. Ике пар кулның аны тотып торганын да, тагын ике кешенең һәр мизгелдә ярдәмгә килергә әзер икәнлеген дә онытты ул. Күз алдындагы караңгылык сизелер-сизелмәс кенә кими барып, зәңгәрсулана башлады. «Мәнә ул мин күргән зәңгәрлек» дип уйлады Рамиз. «Күр әле син! Үз аякларыңа басып дөньяга карау рәхәт икән».

Аяк өстендә тору Рамизга бик озак кебек тоелса да, ул бары тик минут ярым чамасы гына басып торды. Ләкин шул арада коридорга чыгып үзенең фотоаппаратын алып кергән шәфкать туташы аны фоторәсемгә төшереп алырга өлгергән иде инде.

Шәфкать туташы:

— Тарих өчен, Ирина Андреевна. Сезнең рөхсәттән башка гына булды инде, гафу итегез, зинһар, — диде.

Аның искиткеч фотоһәвәскәр икәнлеген яхшы белгән доктор елмаеп:

— Бик яхшы иттең, молодец! — дип, аның аркасыннан кагып куйды...

Элек игез балалар кебек бер-берсенә охшаган һәм ялыктыргыч госпиталь көннәре хәзер кызыклырак сыман тоела башлады. Рамизның күңеле күтәренке иде. Хәзер инде ул кеше ярдәменнән башка коридорга, дежур шәфкать туташы янындагы креслога чыгып утыра, хәтта Фагыйләгә тотынып коридор буйлап йөреп тә килгәли иде.

Беркөнне Ирина Андреевна иртәнге обходка кермәде. Рамиз инде аңа шул чаклы ияләшкән иде ки, ул аны юксынып дежур шәфкать туташы янына чыгып утырды. Чынлап та хәзер Рамиз докторның үзенә ничектер аеруча якынлыгын тоя иде. Рамизны үлем тырнагыннан тартып алу өчен тырышучылар бу госпитальдә бик күп булды. Һәм алар Рамизга барысы да үз туганнарыдай якын тоела. Ләкин шулар арасында Ирина Андреевна аңа аеруча якын, аеруча кадерле. Шул ук вакытта Ирина Андреевна үзе дә Рамизны бүтән авырулардан якынрак күрә иде. Әле бит тагын теге фоторәсемдәге охшашлык та бар... Рамиз бу турыда Фагыйлә белән сөйләшергә ничә тапкыр омтылып караса да, нигәдер, һаман тәвәккәлли алмады. Ә бит Рамизның әнисе дә хәрби врач булган. Әгәр дә... әгәр дә доктор Ирина Андреевна Рамизның әнисе булып чыкса? Мондый нәтиҗәдән Рамизның хәтта тыны кысылды. Ул бит алмаларының, колакларының ут кебек януын, әле чыныгып җитмәгән организмның хәлсезләнүен тойды.

Шуңа да карамастан, өлкән лейтенантның аңы инде яңадан-яңа уй катламнарын ача бара иде.

Әгәр дә ул Рамизның әнисе булып чыкса? Ул чакта Совет Армиясе офицеры, хәрби врач, медицина фәннәре докторы Ирина Андреевнаның бердәнбер улын бөтенләй онытып шушылай тыныч кына яшәп ятуын ничек аңларга соң? Моны ничек аңлатырга?.. Ләкин икенче мизгелдәге уйлар егетнең бу уйларына каршы үз дәлилләрен китерә башладылар. Ярар. Доктор синең әнием дә булсын, ди. Син соң әле аның улын онытканлыгын кайдан беләсең? Ул сиңа бу турыда сөйләдеме? Бәлки аның синең кебек уллары, кызлары бардыр? Әле бит сиңа, тәти егет, Ирина Андреевнаның тормыш юлы, язмышы, аның эшләре турында бер генә нәрсә дә билгеле түгел... Әгәр дә ул синең әниең икән, ул чагында...

— Нәрсә монда моңаеп утырасың, Рамиз? — дигән тавышка ул сискәнеп китте. Башын күтәреп караса, аның алдында шундый таныш, шундый ягымлы, мәрхәмәтле доктор Ирина Андреевна тора иде.

Рамизга доктор аның әле яңа гына уйлап утырган уйларын белә сыман тоелды... Тагын тыны кысыла башлады...

— Менә нәрсә, Рамиз, — диде Ирина Андреевна. — Әйдә, палатага керик әле. Сөйләшәсе сүз бар.

Рамиз дәшми-тынмый гына докторга тотынып, урыныннан торды. Алар җитәкләшеп палатага керделәр. Ул арада шәһәргә чыккан Фагыйлә дә кайтып җитте. Аның күзләрендә дә әлегә Рамизга билгеле булмаган куанычлы сер бар шикелле иде.

— Менә нәрсә, Рамиз, — диде доктор, инде шактый талчыгырга өлгергән Рамизга караватына ятарга булышкач. — Мине ике атнага командировкага җибәрәләр. Кая диген әле? Казанга. Медицина институтында лекцияләр укырга. Фагыйлә дә минем белән кайтмакчы була. Авылыгызга кайтып килергә тели. Әгәр дә вакыт булса, бәлки мин дә авылыгызны күреп килермен. Без Фагыйлә белән шулай сөйләшкән идек. Ә сине... син инде хәзер Фагыйләсез дә молодец. Сине госпитальнең терелеп килүче авырулары ята торган санаториясенә — Красногорскига илтеп куярбыз. Мин сине анда күчерү мәсьәләсен хәл иттем. Озакламый машина килер.

Рамиз, әле һаман да баягы ачышлар һәм уйлар әсирлегендәге Рамиз, Фагыйләнең болай яшертен эш йөртүенә хәтере калса да, дәшмәде. Ә тегесе Рамизның баш очында утырган килеш, сүзсез генә елмая иде.

Красногорскида көннәр тагын да тизрәк үтә башлады. Ике атна узганны Рамиз сизмичә дә калды. Ул инде хәзер көннәрнең күбрәк өлешен санаторий бакчасында, агачлар арасында уздыра иде. Баш авыртулары кимеде, аяклар да нытый төште. Шулай итеп, Рамизның госпитальгә элэгүенә дә елдан артып китте. Әгәр дә элек кем дә булса шаяртып аңа госпитальдә шулай озак ятарга туры киләчәк сиңа дип әйтсә, Рамиз, әлбәттә, ышанмаган булыр иде. Менә бүген аны госпитальгә алып кайттылар. Комиссиягә. Рамиз мондый комиссияләр булырын башына да китермәгән иде. Кара син, әнә нинди имтиханнар үтәсе бар икән. Ичмаеам, Ирина Андреевна да кайтмады. Аның янында Рамиз болай ук каушамаган булыр иде. Дөрес, элегрәк ул бер тапкыр бу хакта сүз чыгарган иде. Комиссиянең теләсә генә нинди карарына да әзер булырга хәзерлән, дип тә әйтте бугай әле. Димәк, хезмәткә яраксыз дип табулары да мөмкин... Юк. Рамизның карары бары тик бер генә булачак: ул үзен армия хезмәтендә калдыруларын үтенәчәк. Шунсыз бу дөньяда яшәүнең Рамиз өчен нинди мәгънәсе кала соң? Уксигез яшеннән хәрби училищеда, аңа чаклы Бөек Ватан сугышы каһарманнары рухында тәрбияләнгән Рамиз өчен тормышның бар мәгънәсе — өстендәге соры шинельдә. Дөрес, ул башка эштә дә эшли алыр иде. Рамиз хезмәт сөючән егет. Ике кулына бер эш кайда да табылыр. Ул бит ун яшеннән колхозда, зурлар белән беррәттән эшләде. Көтүен дә көтте, атлы эшенә дә йөрде. Туган авыл кырларында ул белмәгән түмгәк, ул егылмаган чокыр, ул атланып яки җигеп эшкә бармаган ат юк иде. Рамиз тире таммаган бер генә карыш та юктыр кебек ул кырларда. Дәһшәтле сугыш җилләре алар авылына кагылмый узмады бит... Ләкин, ничек кенә булмасын, ул хәрби хезмәттә калырга тели, шуннан башка тормышны күз алдына да китерә алмый...

Уйларын бүлдереп, Рамизны ординаторлар бүлмәсенә чакырдылар. Аның йөрәге күкрәк капкачын җимереп чыгардай булып сикерергә, бәргәләнергә тотынды. Ул, дежур шәфкать туташы янында тукталып, валериан сорап эчте. Маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен халат җиңе белән сыдырып төшерде. Ишек төбенә барып җиткәч, борылып коридорга карады. Коридор буйлап өсте ак простыня белән капланган арбаны ике шәфкать туташы ишек ягына таба алып килә. Арбада кеше ята иде. Йомшак келәм өстеннән тәгәрәп килә торган арба Рамиз турына җиткәч, аның халатына ышкылып арбадагы кеше өстенә ябылган простыня ачылып китте. Арабада эчкә баткан күзләре йомык иськиткеч ябык Иван Тимофеевич... генерал Орлов гәүдәсе иде... Генерал соңгы юлына чыгып бара... Рамиз колакларында тирән коедан килгән кебек тонык тавыш яңгырады: «Ялгышасың, туганым. Син кем? Совет Армиясе солдатымы? Сугыштагы ямауларны санамыйм әле мин... Нәрсә? Әле, туганым, кайсы да булса округ маневрларында бергә атакага барырбыз! Очрашырбыз әле»... «Очраштык, — дип үз-үзенә пышылдады Рамиз. — Очраштык, иптәш генерал. Ләкин кайда? Сез бит шундый өметле рух белән... Хушыгыз, иптәш генерал. Хушыгыз, Иван Тимофеевич».

Рамиз, иреннәрен тешләп, ординаторлар бүлмәсенә керде. Аның түше киткән йөзен күреп, комиссия членнары аптырашып калды. Аннары арадан берсе:

— Сезгә нәрсә булды, иптәш? — диде.

Рамиз әле яңа гына булган хәлне аңлатып бирерлек сүз таба алмыйча:

— Анда... монда... иптәш... — дип тотлыгып калды. Шул вакыт аның колагында Ирина Андреевнаның, аңа гына ишетелерлек итеп: —

Каушама... каушама... улым, — дигән сүзләре яңгыраган сыман тоелды. Рамиз, әллә ул да мондамы икән дип, бүлмәне янә бер кат күздән кичерде. Ләкин доктор Геева монда юк иде. Рамиз, ниһаять, башы белән ишеккә ымлап:

— Тегендә... генерал Орловны... алып киттеләр, ич, — диде.

Комиссия әгъзалары җавап кайтармады. Бераздан күзлекле доктор:

— Берни дә эшләп булмый, иптәш. Врачлар да кайчак көчсез була, — диде.

Ирина Андреевна урынына калган врач Рамизның авыру тарихын алып, комиссия әгъзаларына укый башлады. Тегеләр зур дикъкать белән тыңладылар. Бернichә тапкыр бүлдереп, кабат-кабат укыттылар, рентген рәсемнәрен алып, әле бер якка, әле икенче якка боргалап, әйләндергәләп карадылар. Авыру тарихы әле берсенә, әле икенчесенә күчте. Кемгәдер телефоннан шалтыратып сөйләштеләр. Озакламый бүлмәгә диңгезчеләр формасы кигән доктор, икенче ранг капитаны, зур кәгазь төргәге күтәреп керде. Бу «моряк» Рамизны электроэнцефалограмма бүлмәсенә әллә ничә мәртәбә китертеп җәфалап бетергән иде. Утны бер кабызып, бер сүндереп, тагын әллә нинди гудоклар кычкыртып, баш тирәсенә дистәләгән үткәргечләр тоташтырып кайнашкан иде. Хәзер дә ул килеп керүгә кулындагы төргәген түрдән ишеккә чаклы палас сыман сузып таратты да ярым латинча, ярым русча аңлатырга тотынды. Рамиз докторларның теге кәгазь-палас өстендә чүгәләп йөрүләрен карап утырды. Ниһаять, комиссия әгъзалары идәннән торып, өстәл артына утырдылар.

Күзлекле доктор тагын бер мәртәбә Рамизның авыру тарихын актарып чыккач:

— Минем уемча, өлкән лейтенантны хәзергә хәрби хезмәттә калдырып торырга кирәк. Ул, һичшиксез, сафка басачак, — диде.

Башкалар моңа дәррәү каршы төшеп, үз фикерләрен куәтли торган дәлилләр китерә башладылар...

## 18

Рамиз палатага кереп караватка ничек ауганын хәтерләми. Совет Армиясе Үзәк медицина комиссиясенең карары, күзлекле докторның карышуына карамастан, бер булды: «Фәлән приказның фәлән статьясы нигезендә Рамиз Җәләевнең сәламәтлеген хәрби хезмәткә яраксыз дип табарга. Аны хезмәттән азат итәргә». Рамизның күңелендә давыл иде. «Менә ничек! — дип уйлады ул, бөтен дөньяга ачуланып.— Мә, сиңа! Азат итәргә, имеш!..» Хәзергә Рамиз өчен бер генә хакыйкать, бер генә иман бар иде. Ул да булса хәрби хезмәттә калу. Юк. Хәрби хезмәт Рамиз өчен иңендәге погоннар ялтыравында түгел иде. Өлкән лейтенант өстендәге шинелен, солдатларын, күченеп йөрүләрне, тревогалы төннәрне, кырыс дисциплинаны бөтен җаны-тәне белән ярата иде. Аның өчен хәрби хезмәттән дә кирәклерәк, мөһимрәк хезмәт илдә юк һәм булачак та түгел иде кебек...

Дежур шәфкать туташы инде бернichә тапкыр Рамизны кичке ашка чакырды. Янәшәсенә килеп юатып карады. Ләкин ул Рамизга берничек тә ярдәм итә алмый иде шул. Рамиз исә, яралары сызлавыннан сыкрап, һушсыз яткан чакларындагы төсле, дөньядан читләшеп, тирән бушлык эчендә ята бирде. Ул ике көн буена кеше белән сөйләшмәде. Түшәмгә карап ятты да ятты.

Ә вакыт уза торды. Рамиз үз хәленә күнегә, иләшә башлады. Күпне күргән олы яшьтәге командирлар да:

— Комиссия карарын хәрби боерык дип санарга кирәк. Ә безнең боерыкка каршы килергә хакыбыз юк, энекәш, — дип юаталар иде.
Бер атнадан Оборона министрлыгына җибәрелгән документлар да кайтты. Анда да комиссия карары көчендә калдырылган иде.

## 19

... Алар госпиталь ишегалдында очраштылар. Полковник Ирина Андреевна Геева, Фагыйлә һәм... Галләметдин абзый бергә киләләр иде. Рамиз Җәләев аларны күргәч башка авырулар белән атлап барган җиреннән шып туктады.
Ул аны-моны әйтеп өлгергәнче, Галләметдин абзый Рамиз каршына килеп басты. Ул сизелерлек картайган иде. Өстәвенә элек үзе дә бик хупламаган сакал үстереп җибәргән. «Галләметдин абзыйны картлык чынлап та баскан икән», дип уйлады Рамиз.
Шунда, һич көтмәгәндә, Галләметдин абзый Рамиз каршына тезләнеп:
— Рамиз, улым,— диде.— Рамиз, улым, синең алда чиксез гаеплемен. Соңгы вакытта мин үзем дә синең кайтуыңны көтеп яшәдем. Хат яздырырга да җыендым. Ләкин... Син, улым Рамиз, мин карт мәхлукны, булдыра алсаң, кичер. Мин синең алдыңда мәңге гаеплемен, — дип тезеп китте.
Аның кыяфәте кызганыч иде.
Рамиз дулкынлануыннан көчкә тын алып, тотлыга-тотлыга:
— Тор, Галләметдин абзый. Ниткән гаеп ул? — дип, карт алдына чүгәләде.
— Рамиз, улым. Менә синең яныңда, хатының белән бергә, синең әниең, туган әниең, үз әниең басып тора. Мин аңа, ул озак командировкадан кайткач, сине... суга батып үлде дип язган идем.
Рамиз кемгә мөрәҗәгать итәргә дә белмичә аптырап:
— Әни!.. Доктор Ирина Андреевна?.. Суга батып?.. Кем?..
Рамизның хәлиткеч сынауларны үткән йөрәге инде мондый киеренкелекне дә җиңә ала иде. Ул янында торган полковникка таба атлады. Икесенең дә күзләренә мөлдерәп тулган яшь тамчылары, сүз әйтергә ирек бирмичә, яңаклары буйлап тәгәри иде.
Урамдагы ябалак кар бөртекләре дә шул көмеш тамчыларга кушылып ялтырый башладылар... Алар да җирдәге тормышның дәвам итүенә шатлана иде бугай...

## 20

Төшке аштан соң Рамиз йокларга ятмады. Палатага Ирина Андреевна, бүлек начльнигы, врачлар һәм шәфкать туташлары кереп тулды. Бергәләшеп Рамизга өр-яңа штатский киемнәр кидерделәр. Аннары:
— Менә, ичмасам, егет! — дип, Рамизның яңа киемнәрен мактадылар.
Докторларны һәм шәфкать туташларын этеп-төртеп, Рамиз янына гражданнар сугыш ветераны, легендар командарм Блюхерның сугышчан дусты, отставкадагы генерал килеп басты. Аның кулында тере кашкарый чәчәге иде.
Өлкән лейтенант белән саубуллашырга дип башка бүлек авырулары һәм шәфкать туташлары да керде. Бөтенесе дә өлкән лейтенантка күңелен төшермәскә, Совет Армиясе командиры рухына турылыклы булырга киңәш бирделәр. Госпитальнең политотдел начальнигы Рамизны үз улы кебек кочып үпте дә:

— Кирәк булган чакта ярдәм итәрбез. Турыдан-туры үземә шалтырат, — диде.

Әйтеләсе сүзләр әйтелде. Саубуллашучылар Ирина Андреевнаны һәм Рамиз белән Фагыйләне госпиталь капкасы төбенә чаклы озата чыктылар.

Каршыдагы Архангельский паркы ак җәймә белән капланган иде. Йөз еллар яшәгән агач ботакларындагы әле коелып бетмәгән яфракларны йомшак җил тибрәтә. Паркның икенче башыннан дөбердәп трамвай узып китте. Кызыл хач төшерелгән җиңел машина госпитальнең йолдызлы тимер капкасына кереп югалды.

Рамиз, еллар буена күнегелгән гадәт буенча, портупея каешын төзәтергә дип биленә үрелде. Куллары каешка тимәгәч, аптырап, өстендәге киемнәргә күз төшерде...

Озакламый Ирина Андреевна, Рамиз һәм Фагыйлә, ундүрт катлы йорт ишегалдына кереп, машинадан чыктылар. Лифт аларны җиденче катка күтәрде. Ирина Андреевна, шинель кесәсеннән ачкыч чыгарып, квартира ишеген ачты. Рамиз белән Фагыйлә бүлмәгә уздылар.

Рамиз, күзләрен зур ачып, стенага эленгән фоторәсемгә карады. Портрет итеп зурайтылган рәсемдә... Ирина Андреевнага сыенып, өстәл өстенә куелган кечкенә эскәмиягә баскан, башына «күз тиюдән саклый торган» чепчик кигән, түм-түгәрәк битле, ике-өч яшьлек малай — Рамиз басып тора иде.

Рамиз, Ирина Андреевна янына килеп, аңа нәкъ әнә шул рәсемдәгечә иркәләнеп сыенды да ничәмә-ничә еллар кешегә ишеттермәскә тырышып кабатлап йөргән иң кадерле, иң матур һәм иң изге сүзне авыз тутырып кычкырып әйтте:

— Әни!!!

1974—1975.

## Зиннур Насыйбуллин

### Кыюлар кимеми

Яхшылык җиңәчәк.
Күрсәтер киләчәк!..
Тик әле кешелек
Корбаннар бирәчәк.

Кыюлар кимеми —
Дәлилләр булачак:
Альенде туачак,
Неруда туачак!

Кыюлар барында
Җан кыю булачак.
Шунлыктан кысага
Сыюлар булачак.

Һәм йөгерек фикергә
Гер тагу булачак.
Шунлыктан авызга
Су кабу булачак.

Бугазга кургашын
Коюлар булачак.
Түбәнне үрнәккә
Куюлар булачак.

Ак төсне каралтыр
Буяулар булачак.
... Тик аны күрердәй
Уяулар туачак.

### Сораулар

Дөнья кебек зурмы җаның,
Әллә гүр кебек тармы?
Гомереңне бирер булып
Табынган нәрсәң бармы?

Табынганың нәрсә синең —
Бу хакта уйладыңмы:
Халкыңмы, илең-телеңме?
Сәяси иманыңмы?

Ни калыр узган юлыңда:
Якты эз, сөрем-күмер?
Гомерең бирер нәрсәң юкта
Нәрсәгә соң ул гомер?

## Тыйнакка һәйкәл куйсак

Тартынмады, тайчанмады эштән,
Аермады акка, карага.
Тик тартынды җыелышларда чыгып
«Эшләдем!» — дип күкрәк кагарга.

«Балда-майда йөзим!..» димәде ул,
Ә яшәде майга буялып.
Һәйкәл куйсак аңа — мәйданда да
Торыр сыман һаман оялып.

## Хатирәләр йөри

Борынгы Ай, моңсу нурдан тукып,
Чирәмнәргә серле челтәр япкан.
Тупылларның сыек күләгәсе
Чирәмнәргә чалкан төшеп яткан.

Яфракларга кунып чыклар йоклый,
Таҗга йомылып гөлнең төсе йоклый.
Кемнәрнеңдер хәтере-хисе йоклый —
Ваемсызга заман гаме йокмый.

Тәрәзәләр кара күзлек кигән...
Алҗыган җир сабыр... оеп ята.
Ләкин катламнарда тамырларның
Кыймылдавын хәтта тоеп ята.

Катламнарда еллар, чорлар йоклый,
Көпә-көндез килгән төннәр йоклый,
Йорт-курадан калган көлләр йоклый,
Меңнәр йоклый.

Күпне күргән акыл ияседәй
Иягенә таянып төн уйлана.
Борчуларын төнгә сөйләр өчен
Йокылары качып кем уяна?

Учакларда эссе көл астында
Сүнмәс хәтер кебек күмер көйри.
Өй тирәли җилләр белән бергә
Кыштыр-кыштыр хатирәләр йөри.

## Үзеңчә һәм кешечә

Ир затына дәрт һәм дәрман кирәк,
Ә фәрманнар... булыр фәрманнар.
Йөгәнләнгән килеш, фәрман үтәп,
Эзсез уза күпме кәрваннар!

«Үзеңчәлек» белән «кешечәлек»
«Шәхес» дигән төштә кисешә.
Син үзеңчә яшәмисең икән —
Яшәмисең, димәк, кешечә.

●

Заман һәркемне сыный.
Сыгылмалылар сынмый.
Кыллар — скрипка җаны —
Өзелгәндә дә чыңлый.

## Гамьнәр иләндә

Сәяхәтләр кылып хозурлану,
Илләр гизү насыйп булмады;
Җаным гына һаман юлда булды,
Эзләнүдән аңым тынмады.

Бу тормышны күпме яратсам да,
Бернине дә җиңел бирмәде.
Тапмый калмый ләкин ир-егетнең
«Табам!» диеп җилкән киргәне.

Шатлыкларым булса, һәр бөртеген
Табып кайттым кайгы иленнән.
Нәкышләре шуңа сагышлырак,
Моңнар белән шуңа чигелгән.

Сөюем бар: югалтулар дигән
Упкын аша кирәк үтәргә.
Йөрәгендә сөю булган кеше
Юл газабын җиңел күтәрә.

Уңышларым булса менеп алдым
Эзләнүләр, Еллар тавыннан.
Ышанычым минем шул юллардан
Җәяү килгән чакта табылган.

Тынгысызлык һаман алга дәшә,
Ил хәстәрен салып иңемә.
Ваемсызлык иленә тукталмыйча,
Килеп кердем Гамьнәр иленә.

# ОЧЕРКЛАР

# КамАЗ ЕЛЪЯЗМАСЫ

**ИЮЛЬ, 1975 ЕЛ**

Чаллыда КПСС Үзәк Комитеты каршындагы Югары партия мәктәбе тыңлаучылары — Кубаның бер төркем партия работниклары булды. Кунаклар КамАЗ төзүчеләрнең эшләре, ремонт һәм инструментлар заводында хезмәтне оештыруның куелышы белән кызыксындылар, шәһәр белән таныштылар, «Чебурашка» балалар бакчасында булдылар.

**«Социалистическая индустрия» на строительстве Камского автозавода».**

КамАЗның удар пульсы һәркемне дулкынландыра. Редакциягә килгән күп санлы хатлар әнә шул хакта сөйлиләр. Безгә мәктәпне яңа тәмамлаган егетләр һәм кызлар, халык хуҗалыгының төрле тармакларында эшләүче белгечләр язалар. Алар КамАЗда эш, уку, ял итү өчен нинди шартлар булуы турында белергә тели.

Илебезнең барлык почмакларыннан килгән ул хатлардагы сорауларга җавап бирүен үтенеп, безнең хәбәрчебез «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенең эшче кадрлар бүлеге начальнигы Гончарукка мөрәҗәгать итте.

— Берләшмәдә төзүчеләрне якты чырай, ачык йөз белән каршылау матур гадәт булып урнашты, — диде ул. — Үз теләкләре белән эшкә килүчеләрне каршы алу өчен елга портына, аэропортка, «Круглое поле» тимер юл станциясенә һәм Бөгелмәгә махсус автобуслар җибәрелә. Яңа килүчеләрне төзелеш белән таныштыру, тулай торакка урнаштыру, күңелләренә хуш килгән эшне сайлап алу өчен, кагыйдә буларак, бер көннән артык вакыт узмый.

«Камгэсэнергострой» подразделениеләре 2—5 кешелек бүлмәләрдән торган иркен һәм уңайлы тулай тораклар белән тәэмин ителгән. Аларның һәркайсында кызыл почмак һәм кайнар ашы да булган буфет бар. Шәһәр үсә һәм анда яшәүчеләрнең ялын оештыру буенча күп кенә эшләр эшләнә. Биредә инде дүрт кинотеатр, район культура йорты, «Энергетик» культура сарае төзелде.

КамАЗ төзелеше тарихының чагыштырмача кыска гына чоры эчендә шәһәрдә берничә уку йорты — Кама автомеханика техникумы, Нижнекамск энергетика техникумы филиалы, СССР Минэнерго техник урта уку йортларының уку-консультация пункты эшли башлады. Казан инженерлар төзелеше институты филиалы үзенә һәр ел саен йөзләрчә эшчеләрне кабул итә. Шәһәрдә эшче яшьләрнең җиде кичке урта мәктәбе эшли... Югарыда саналып үтелгәннәр, әлбәттә, Чаллы шәһәрен төзү буенча Генеральный планда каралган эшләрнең әле кечкенә бер өлеше генә. Якындагы киләчәктә монда фән һәм техниканың соңгы казанышлары нигезендә төзелгән тамаша заллары, социаль һәм культура-көнкүреш, спорт объектлары, уку үзәкләре челтәре тагын да киңрәк колач җәячәк.

Гүзәл Кама буена, күлләр һәм урманнар арасына урнашкан ял базалары

КамАЗ төзүчеләрнең, спорт һәм туризм белән шөгыльләнүчеләрнең иң яраткан урыннарына әверелде.

Төзүче һөнәренә ия булмаган (ә андыйлар безгә йөзәрләп киләләр) кешеләр өчен берләшмәдә уку-укытуның берничә төрле формасы булдырылды. Производстводан аерылып яки аерылмыйча тракторчы, шофер, электр белән эретеп ябыштыручы, стена буяучы-бизәкләүче, ташчы һәм башка шундый белгечлекләргә берләшмәнең үзәк уку пунктында өйрәнергә мөмкин. Уку пунктлары «Камгэсэнергострой» подразделениеләрендә дә бар. Төзелештә бригада ысылу белән эшләргә өйрәтү дә киң кулланыла.

Партия, профсоюз, комсомол оешмалары автогигант төзүчеләренең профессиональ үсеше, аларны коммунистик рухта тәрбияләү проблемаларына зур игътибар бирә. Безнең төзелеш илгә үзенең темплары һәм зур масштаблылыгы белән генә түгел, кыска гына вакыт эчендә биредә һәртөрле авырлыкларны җиңеп чыгарга сәләтле, күп милләтле вәкилләрнең меңнәрен берләштергән бердәм коллектив туюы белән дә билгеле.

Шәхеснең формалашуы өчен бездә тудырылган барлык уңай шартлар өстенә ул шәхеснең үз-үзен һәрьяклап үстерергә теләве дә кирәк. КамАЗ төзелешенә моннан биш ел элек беренче тапкыр аяк баскан яшьләр безгә нәкъ әнә шундый теләк белән килделәр. Бүгенге көндә Ватаныбызның уннарча һәм йөзләрчә патриотлары илгә КамАЗ төзелешенә керткән хезмәтләре белән танылдылар. «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсе дип аталган күп меңле дус коллектив әнә шундый кешеләрдән тора һәм ул үзенең язмышын илебездәге зур удар төзелеш — КамАЗ белән чын-чынлап бәйләргә теләгән һәр кешене үз сафларына ике куллап кабул итә.

«Советская Татария», Казан.

Бөтенсоюз студентлар отряды быел «Җиңүнең 30 еллыгы» дигән горур исем йөртә. Җиңү көнен хезмәттә яңа уңышлар белән билгеләп үтү буенча, Мәскәүнең яшь эшчеләре башлангычына кушылып, меңнәрчә отрядлар үзләренең исемлекләренә сугыш һәм хезмәт батырларын керттеләр. Алар исәбенә эшләнгән хезмәт хакы һәйкәлләр, обелисклар төзүгә һәм реконструкцияләүгә, музейлар оештыруга тотылачак.

Егетләр һәм кызлар отрядның хезмәт биографиясенә һәр ел саен матур сәхифәләр өстиләр. Алар «Бишьелыкка — студентлардан биш миллиард» дигән авыр имтиханны «отлично»га бирәчәкләренә һәм шуның белән Ленин комсомолының партиянең XXV съездына Рапортына кул кую хокукын яулап алачакларына ышаналар.

«Комсомольская правда», Мәскәү.

«XXV съездга — 25 удар үнкөнлек!» дигән сугышчан лозунг Александр Степанец җитәкчелегендәге комсомол-яшьләрдән торган шоферлар коллективы тарафыннан күтәреп алынды. КамАЗ яшь транспортчыларының удар хезмәт көннәре башланды. Бу ел — алар өчен искиткеч киеренке ел. Егетләр Мәскәү комсомолларының «Үзем өчен һәм шул егет өчен» эшләргә дигән башлангычына КамАЗда беренчеләрдән булып кушылдылар һәм ун атналык удар хезмәт вахтасында берничә тапкыр җиңүче булып чыктылар. Алар, шәһәр һәм заводның төзелеш мәйданнарына планнан тыш биш мең тонна йөк ташып, беренче ярты еллыкка алган социалистик йөкләмәләрен срогыннан бер ай элек үтәүләре турында рапорт бирделәр.

Яшь шоферларның күбесе КамАЗга Совет Армиясе сафларында хезмәт итеп кайтканнан соң комсомол путевкасы белән килделәр һәм илнең зур төзелешендә үз урыннарын таптылар.

«Комсомолец Татарии», Казан.

**Мидхәт Миншин**

# КАНӘФЕР ЧӘЧӘГЕ

Ә бит башың иелмәсә,
Һавалар нинди биек.

**Мостай КӘРИМ.**



Асия йокысыннан елмаеп уянды. Гаҗәеп матур төш күргән иде ул. Үзебезнең шушы Казан шәһәре, имеш. Кайсы урам икәнен генә тәгаен абайлап бетерә алмыйча калды. Нәкъ урта бер җирдән зәп-зәңгәр юл киткән, ә як-якта бихисап күп чәчәкләр. Шушы зәңгәр юлдан Асия каядыр ашыга. Урам чатына җитәм дигәндә генә... уянып китте.

«Шагыйрь яки рәссам булсам әле бер хәл иде, — дип гаҗәпләнде ул. — Миңа инде зәңгәр юллар турында хыялланыргамы. Унҗиде яшьлек чагым түгел. Әнә кызым үзем хәтле булып килә...» Аннан сәгатькә күз төшерде. Бишенче ярты. Күргән төшен хәтерләп, елмаеп ятарга вакыт калмаган икән. Торырга, эшкә җыенырга кирәк.

Кызы Әлфияне уятмас өчен, аяк очларына гына басып кухня ягына узды. Чәй куеп җибәрде. Тәрәзә пәрдәсенең бер читен күтәреп, урамга күз салды. Көн бик салкын булырга охшый. Быелгы кыш үтә «характерлы» булып чыкты. Җылырак киенмичә ярамас.

Төш онытылды. Зәңгәр юллар да күз алдыннан югалды. Каршыда чын тормыш үзе. Бөтен мәшәкатьләре, вак-төякләре белән. Тиз генә ашап-эчәргә дә троллейбус тукталышына йөгерергә кирәк.

Асия Исмәгыйлова — өс киемнәре тегү берләшмәсенең өченче фабрикасы эшчесе. Балалар пальтосы тегә.

Фабрика турысында аны шәкерте Нажия Нуретдинова куып җитте.

— Артыгыздан чаба-чаба тыным кысылды, — диде ул исәнләшкәч. — Бигрәк тә кызу йөрисез инде.

— Салкыннан куркып ашыга төшкәнмендер, сеңелем.

— Кайберәүләрне салкын да кузгата алмый. Аякларына гер таккан диярсең. Сез үзегез шулай җиңел сөякле инде.

— Үзеңә генә әйтим, моның кечкенә бер сере бар. Бүген мин бик матур төш күрдем, юра әле шуны.

— Яле, сөйләп карагыз.

— Казанның бер урамы, имеш. Уртадан зәп-зәңгәр юл сузылган. Ике якта чәчәкләр. Шул чәчәкләргә карый-карый, мин каядыр барам...

Асияне йотылып тыңлаган Наҗиянең күзләре очкынланып китте.

— Абау, менә, ичмасам, төш дисәң дә төш. Китапта язылган кебек! Шатлык инде бу, Асия апа, зур шатлык көтә сезне. Сөенчегә ни бирергә икәнен хәзердән үк кайгыртыгыз.

— Анысы миннән калмас, җаным!

Смена башланды. Конвейер хәрәкәткә килде. Цех тулы хатын-кызның һәркайсы үз урынында. Асиянең хезмәте башкаларныкыннан үзгәрәк. Ул аерым бер урынга беркетелмәгән. Конвейерның кайсы буынында тоткарлык туса — аны шунда куялар. Моның үзенә күрә бер хикмәте бар. Балалар пальтосы теккәндә 35 төрле аерым-аерым кисәк әзерләргә кирәк. Асия аларның һәркайсын башкара ала. Осталык һәм тизлек буенча цехта аның тиңдәше юк. Кайда нинди өзеклек килеп чыкса да, аны күз ачып йомганчы төзәтеп җибәрә, конвейерның ритмы бозылмый кала. Моннан барлык тегүчеләр ота, хезмәт җитештерүчәнлеге күтәрелә, сыйфат яхшыра.

Әле менә кичә генә бер кызны эшкә алганнар иде. Асия әледән-әле аның ягына күз төшерә. Өйрәнчекнең йөзендәге үзгәрешләр остазга һәммәсен җиткереп тора. Чү, әнә ул аптырашта калган түгелме?

Асия башлаган җөен тәмамлады да кыз янына ашыкты.

— Нәрсә булды, сеңелем?

— Менә җебем чуалды. Рәтләп җибәрә алмыйм гына бит.

— Башта андый хәлләр булгалый инде ул. Кая әле, бир үземә.

Ул, кыз белеп калырлык итеп, җай гына эшли. «Менә болайрак кирәк», — дип куя. «Аңладыңмы?» — дип сорый. «Инде хәзер үзең тегеп кара», — ди.

Өйрәнчек кыз капылт кына педальгә басты, энә ике сантиметр да бармады, җеп тагын чуалды. Кыз, гаеп өстендә тотылган кешедәй, әллә нишләп китте. Комачтай булып кызарды, Асия апасына күтәрелеп карарга да оялды.

— Зарар юк, зарар юк. Берәү дә бөтенесен белеп тумый. Син бит әле конвейерда түгел. Педальгә син катырак басасың икән, эшне алай бик югары тизлектә башларга ярамый. Һәр нәрсәнең үз көе бар.

Асия кабат эшләп күрсәтә, аны өйрәнчеге алыштыра.

— Хәзер әйбәт, әйбәт.

Кызның йөзендә елмаю билгеләре уйнаклый.

— Ярый, мин киттем. Ашыкма, үз җаең белән генә. Бер өйрәнгәч, тыеп та туктатып булмас әле үзеңне. Ул-бу килеп чыкса, ишарә яса, уңайсызланма.

— Алай бик борчыйсым килми иде шул. Сезнең дә эшегез кала бит.

— Анысы өчен кайгырма, бер яхшы тегүче тәрбияләсәм дә, мең бәхетле булам шикелле бит мин. Ә яшьләрне без өйрәтми кем өйрәтсен. Тегүче һөнәренең кадере елдан-ел арта. Хәзер кешеләр өс-башлары бөтен булганга гына риза түгел, һәркем матур киенергә омтыла. Матур киемне кем тегә? Иң яхшы осталар! Менә шуны беркайчан да исеңнән чыгарма.

Асия җәһәт-җәһәт атлап үзенең эш урынына китте. Килү белән пальтоларга якалар куя башлады. Берне, икене, өчне...

Сменаның яртысы да узмаган иде әле, ул көнлек планын тутырды. Барлык эш беренче күрсәтүдә үк «бик яхшы» билгесенә тапшырылды.

Төш җиткәндә цех буйлап шатлыклы хәбәр таралды. Фабком председателе Анна Федотовна Ибраһимова Асия Исмәгыйловага Промышленность министрлыгыннан килгән чакыру билетын тапшырды. «Сезне тугызынчы бишьеллыкта ике бишьеллык план үтәүчеләрнең Бөтенсоюз слетына — Иваново шәһәренә чакырабыз» диелгән иде анда.

Нажия Нуретдинова остазын кочаклап тезеп китте:

— Әйттем бит, Асия апа, әйттем бит. Ул шатлык менә килеп тә җитте. Бу безнең өчен дә шатлык, бөтен фабрикага да мәртәбә.

Әле берсе, әле икенчесе килеп, Асияне тәбрикли башлады. Моңарчы санаганы юк иде, күр, шәкертләре дә дистәләп икән.

...Мондый вакыйгалар кемне дә дулкынландырмый калмый. Асия дә уйлана, башында күп төрле сораулар туа. Шуларга җавап эзлиэзли, үзенең гомер юлына борылып карый.

Ә бит язмышның ачысын-төчесен ул бер генә тапкыр татымады. Беренчесе аның, үзәкне өзсә дә, ил белән бергә иде. Әтисе Габдулла сугышка китте дә әйләнеп кайтмады. Брянск урманнарында һәлак булды, дүрт бала ятим калды. Әле ярый, әниләре кул эшенә оста иде. Кызларын да энә-җеп тотарга өйрәтте. Күлмәген дә, пальтосын да үзләре тегеп киделәр. Юрганын да үзләре сырды, уч төбе кадәр чүпрәкне дә исраф итмәделәр.

Аларның арзанлы күлмәкләре дә килешле була иде. Асия тегүчигүне апасына, сеңелесенә караганда да ярата төште. 1953 елны ул шушы фабрикага эшкә дә урнашты.

Бөтенесе дә көйләнгән иде, яраткан егетенә кияүгә чыкты, кызы туды. Өч килендәш бергәләп кайната йортында яшәделәр, сүзләре килешмәгән чак булмады. Йортларын сүтеп, һәркайсы аерым квартира алгач кына... моны әйтергә дә авыр, дуска түгел, дошманыңа да теләмә... Асиянең ире үлде.

Ул көннәрне күз яшьләре дә түгелгәндер, язмышка үпкә сүзләре дә әйтелгәндер. Әнисенең ачыргаланып әйткән сүзләре һаман әле колак төбендә яңгырый сыман.

— Бер бәхетең булмаса, чәчең белән җир себерсәң дә, табып булмый икән аны, — диде ул. — Ирем сугышта башын салды, сыңар канат белән дүрт бала үстердем, әле кызыма да өлеш калганмыни...

Күпне кичергән ана шул ук вакытта киңәш тә бирә белде:

— Берүк башыңны ия күрмә, кызым, башы иелгән кеше тере мәет ул, — диде.

Хезмәттәш дуслары да ана сүзләрен кабатлады, фаҗигане алар да күтәреште. Шул иптәшләреннән башка тормышын күз алдына да китерә алмый Асия. Гомеренең яртысыннан күбрәген алар белән уздырган өчен генә түгел, алар белән бергә ул яшәүнең чын мәгънәсен аңлады, яңа бәхетен тапты. Хезмәт уңышлары турында әнә Мәскәүдә, министрлыкта беләләр, ил күләмендәге слетка дәшәләр.

...Асия Исмәгыйлова фабком члены, балалар арасында эшләү комиссиясен җитәкли. Сменадан соң нәниләр комбинатына барырга планлаштырган иде. Хезмәттәше Ирина Кулагина белән бергәләп шунда киттеләр.

Бу юл аларга күптәннән таныш. Аккош күле буендагы «Балалар патшалыгына» эзләре суынып тормый. Сокланып туймаслык матур урыннар. Килгән саен әйләнә-тирәнең яме тагын да артып киткән кебек.

— Гүзәллекнең нәкъ уртасында яшиләр, — диде Ирина, табигатьнең бу хозурлыкларын беренче тапкыр күргән шикелле. — Һавасы сулап туйгысыз. Комбинатны монда салып бик яхшы иттеләр.

— Киңәшле эшнең ахыры һәр вакыт күңелле була, — дип, аның сүзен җөпләде Асия. — Бергәләп хәл кылдык бит...

Урман юлыннан атлыйлар. Бер каен каршында икесе дә кинәт тукталып калды. Бер сүз дә дәшмичә шактый гына карап тордылар.

— Әгәр дә рәссам булсам, мин моны сурәт итеп сызар идем... аз гына да үзгәртмичә, — диде Ирина.

Балалар комбинатында тәрбиячеләрнең үз кешеләре алар. Өсләрен чишенүгә, һәммәсе хакында уртага салып киңәшә башладылар.

— Фабкомнан сезгә нинди ярдәм кирәк? — дип, кат-кат сорады Асия.

Тәрбиячеләр вак-төяк үтенечләр белән чикләнде.

— Эшлим дигән кешегә монда шартлар җитәрлек, — диделәр.— Борчылуыгыз, кайгыртуыгыз өчен рәхмәт.

Асия белән Ирина барлык бүлмәләрне, санитария-гигиена кагыйдәләренең үтәлешен, балаларның нинди яңа җырлар, шигырьләр, уеннар өйрәнүләрен — барысын да җентекләп тикшерделәр. Монда нәниләр атна буе яши, әти-әниләре янына ял көннәрендә генә кайталар. Шуңа күрә тәрбиячеләргә таләп аеруча зур.

Комбинатның эше белән даими кызыксынып торгач, кирәк чагында ярдәм иткәч, бөтенесе тәртиптә — балалар рәхәтләнеп яши, әти-әниләренең дә күңеле тыныч...

Асия белән Ирина кайтканда да комбинатта күргәннәрен, ишеткәннәрен әледән-әле исләренә төшерделәр.

— Нинди күңелле яшиләр, — диде Ирина. — Балалар рәхәттә икән, ата-ана да кайгы-хәсрәтсез.

— Әйе, бик күп нәрсә күз алдында яхшыра. Әле без бала үстергәндә дә нинди кыен иде.

— Кызыгызны байтактан күргәнем юк, зур үскәндер инде, — диде Ирина.

— Көн саен диярлек үлчәшәбез, мине куып җитә инде, үзен комсомолга алдылар. Куанып кайткан, — диде Асия. — Аларның классларын белсәң иде син! Кырык укучының утыз сигезе отличниклар, ударниклар.

— Кайсы мәктәптә?

— Җитмеш беренчедә. Җиденче «Б» классында. Класс җитәкчесе гаҗәеп тырыш аларның.

— Үзегез дә булышасыздыр, югыйсә, аның гына көче җитмәс.

— Ничек дип әйтергә инде. Балаң укыган мәктәп тә үзең эшләгән коллектив шикелле үк якын була ул. Шунда гел барасы килеп тора. Чакырганнарын да көткән юк.

— Әнисе дә ударник, кызы да... — диде көлемсерәп Ирина. — Бәхетле син, Асия! Өлгермәгән җирең, булдырмаган эшең юк. Карале, сорарга онытып торам икән, слетка кайчан китәсең?

— Киләсе атнада. Иртәгәдән җыена башласаң да, таманга туры килер.

— Күңелем сизенә: слетка килүчеләр арасында яңа бишьеллыкта да ике план үтәргә йөкләмә алучылар булачак. Сер булмаса, әйт әле, син ничегрәк уйлыйсың?

Мондый сорауга тиз генә җавап табуы авыр иде. Асия ни диярг дә белмәде, сорауга каршы үзе сорау бирде:

— Минем урында син нишләр идең?

— Синең урыныңда мин булсаммы? — Ирина, һәр сүзенә басым ясап, өздереп-өздереп кенә әйтте: — Минме... һич тә шикләнмичә... ике бишьеллык план үтим дип йөкләмә алыр идем.

— Син бик тә җиңел хәл иттең бит әле, дустым. Минем менә йөрәгем җитми. Бу чакыру билеты килгәнче үк инде әллә кайчаннан бирле баш ватам. Кай көннәрне батыраеп та куям, сүземне әйтәм дип эшкә килəм, тагын шүрләп калам. Ике бишьеллык план ич ул...

— Анысы шулай инде. Уен түгел. Әмма син булдырасың аны. Без бит инде кемнең кемлеген беләбез.

— Ярый ла, бөтенесе дә уйлаганча гына килеп чыкса.

— Син бит инде егерме өченче ел фабрикада, күреп торасың: эш шартлары елдан-ел яхшыра. Көтелмәгән тоткарлыклар тумас, сыйфатны күтәрү турында бөтенебез кайгыртабыз.

— Бик яхшы агитатор икәнсең син, Ирина, — дип шаяртты Асия. — Ышандыра беләсең.

Дуслар трамвай тукталышында аерылыштылар. Ирина әйткәннәрдән Асия шуны аңлады: аның сүзен коллективта көтәләр икән инде.

Икенче көнне Асия эшкә гадәттәгедән иртәрәк килде. Смена башланганчы цех начальнигы Любовь Дмитриевна Маликова белән сөйләшеп алырга уйлады.

Любовь Дмитриевна да егерме елдан артык шушы коллективта. Тегүче булып килгән иде, эшли-эшли читтән торып институт тәмамлады. Ихтирам казанган булдыклы җитәкче. Аның белән киңәшсәң, беркайчан да ялгышмассың. Асияне ул бүлдермичә, дикъкать белән тыңлады.

Шул чак бүлмәгә фабком председателе Анна Федотовна Ибраһимова килеп керде.

— Әллә күңелегез сизенгән инде, — диде цех начальнигы. — Үзем сезгә шалтыратырга җыенган идем. Бик тә җитди мәсьәлә турында сөйләшәбез.

— Я, тыңлыйм, — диде фабком председателе.

— Асия яңа башлангыч белән чыгарга уйлый. Бу бишьеллыкта да ике план тутырырга теләге зур. Булдырып булыр микән, ди, киңәш сорый.

Анна Федотовнаның йөзе балкып китте. Әмма ул җавап бирергә ашыкмады. Бераз уйланып торгач:

— Асиянең шундый тәвәккәллеген хуплыйм, — диде. — Тик бөтенесен дә алдан ачыклыйк әле. Әйдәгез, эштән соң партбюрога керик, үзебезнең тәкъдимнәрне әйтик. Шәхси йөкләмә булса да, бу шәхси эш кенә түгел.

Барысын да энә күзе аша үткәрделәр.

Асиянең эш көне фотографиягә алынды. Нормировщиклар секундына кадәр исәпләделәр. Контролерлар һәр җөйне кат-кат карады. Нинди генә саннар, нинди генә мәгълүматлар теркәлмәде! Күпме тикшермәсеннәр — нәтиҗәләр бер: ике бишьеллык план үтәргә Асиянең дәрте дә, дәрманы да җитәрлек.

— Асиянең эшен тикшерә-тикшерә үзебез өчен әллә нихәтле яңалык ачтык, — диде фабриканың партбюро секретаре Раиса Александровна Токарева. — Турысын гына әйткәндә, ул безгә сабак бирде, аның минуты да әрәм булмый, ә башкаларның сәгатьләре дә югала икән. Вакыттан дөрес файдаланмасаң, хезмәт җитештерүчәнлеген ничек күтәрәсең. Асия 35 процессның һәммәсен дә «бик яхшы» билгесенә башкарды, ә кайберәүләр исә бер-ике үрнәк эшләүдән бүтәнне белми. Дөнья булгач, төрле хәл очрый, кемдер авырып китә, яисә башка мәшәкать чыга, эшкә килә алмый. Шундый чакларда Асия кебекләр алар өлешен дә башкарырга өлгерә. План да өзелми, җитәкчеләр дә ут йотып йөрми. Фикерем ачык, — дип басым ясады секретарь, — Асия Исмәгыйлевага уңышлар телик, аягы төкле булсын. Ә без аның үрнәген бөтен фабрикага таратырга тиешбез.

...Бөтенсоюз слетына Татарстаннан алар җидәү китте. Гомерләрендә беренче тапкыр очраштылар, ләкин әйтерсең лә тумыштан бергә үскәннәр, бергә эшләгәннәр — сүзләр бер, теләкләр уртак, омты-

лышлар бер төсле. Хөсәен Ямашев исемендәге Татарстан мех берләшмәсеннән Луиза Хәерова да, Владимир Ильич Ленин исемендәге күн берләшмәсеннән Клара Герасимова, Алевтина Роначыва да, беренче тегү фабрикасыннан Нина Аксенова да, нәкъ Асия кебек үк, аз чыгымнар тотып, продукцияне күбрәк җитештерү, аның сыйфатын яхшырту турында кайгырта.

Поезд Казаннан ераклаша барган саен алар бер-берсенә якынайдылар. Сүзләр үзләренең предприятиеләреннән читкә дә китте. КамАЗ баһадир да, икенче миллиард тонна нефть чыгаручы нефтьчеләребез дә, үзенең 800 еллык юбилеена килүче Казан да, Габдулла Тукай, Муса Җәлил шигырьләре дә, Салих Сәйдәшев музыкасы да алар белән бергә иде.

Мәскәүдән махсус поезд Ивановога юл тотты. Вагоннарда илнең төрле ягыннан җыелган ударниклар.

Аларның һәркайсына канәфер чәчәкләре бүләк иттеләр. Бәйләмдә ун чәчәк... Биш елда ун еллык юл узган батырларга илдәшләр чәчәк китерә.

«Сезнең фидакарь хезмәтегез, үз эшегезгә рухландыргыч мөнәсәбәтегез билгесе... Алдынгыларның бай тәҗрибәсе — һәр эшченең казанышы булырга тиеш». КПСС Үзәк Комитетының Генеральный секретаре Леонид Ильич Брежнев слетта катнашучыларга әнә шундый котлау телеграммасы җибәрде.

Уңышлар зур, уртаклашырлык сөенечләр бар, әмма уйлар гел киләчәктә. Трибунага кем генә күтәрелмәсен, унынчы бишьеллык проблемасын ачыклый. «Сыйфат бишьеллыгына — эшче гарантиясе». «Бишьеллыкта — ике бишьеллык» — һәркемнең тел төбе шул.

Үзләре кабул иткән мөрәҗәгатьнең һәр сүзе Асиянең йөрәгенә уеп язылды.

«Без ирешелгән темпларны киметмичә эшләргә сүз бирәбез. Социалистик ярышның девизы: «Бишьеллыкта — ике бишьеллык». Без һәр эшчегә мөрәҗәгать итәбез: хезмәттә югары күрсәткечләр өчен көрәшегез, аларны ныгытыгыз, үзегезнең көндәлек нормагызга әйләндерегез. Яныгызда бер генә артта калучы да булмасын...»

Слетта катнашучыларга сувенир да тапшырдылар. Ул — тукып, чәчәкләп-бизәкләп ясалган календарь, 1976 нчы ел календаре. Иваново тукучылары үзләренең изге теләкләрен дә, осталыкларын да чагылдырган анда.

«Бер көндә ике көнлек эш эшләргә!» — бер авыз сүздә бөтенесе әйтелгән.

Ударниклар җыеныннан кайткач, Асия Исмәгыйлова берләшмәнең партия-хуҗалык активында чыгыш ясады. Тегүченең сүзләрен һәркем йотлыгып тыңлады. Гади генә итеп сөйләде үзе, ә күпме уйлар кузгатты, күңелдә әле бөреләнеп кенә килгән фикерләрне үстереп, канатландырып җибәрде.

Стенада бүләк календарь — тукыма календарь. Анда көннәрнең үз агышы. Хезмәт календарен исә Асия үзе эшли: балаларга матур пальтолар тегә, бер урынына — икене. Яңа бишьеллыкның алты аенда ук 1976 нчы ел белән хушлашып, 1977 нчегә кул бирде ул. Еллар аңа тагын канәфер чәчәкләре бүләк итәр.

## Вадим Луценко

# ЯКТАШЫБЫЗ «МИШКА-ТАТАРИН»

### I



Партизаннар төнге рейдтан соң ялга талганнар, дошман тылына ясалачак чираттагы поход алдыннан хәл җыялар.

Бер урында япа-ялгыз басып торудан ялыга башлаган сакчы, өстендәге киеме теткәләнеп беткән кызыларамеецның давыл аударган агач өстенә килеп утыруын күргәч, кинәт җанланып киткәндәй булды. Бу сугышчы, сазлык-куаклыклар арасында ике атна буена иза чигеп йөргәннән соң, әле кичә генә отрядка килеп кушылган иде.

— Тартасыңмы, туган? — диде ул сакчыга, ялтырап торган трофей портсигарын ачып.

— Оһо, сигарет! — диде аңа таба якынайган сакчы. — Күрәм, монда килешли вакытыңны бушка уздырмагансың.

— Әйе, тар сукмакта бер фриц белән очрашырга туры килде...

— Бер-берегезгә юл бирергә теләмәгәнсез, алайса? — Сакчы сизелер-сизелмәс кенә елмаеп куйды. Аннан трофей зажигалкасын кабызып, күршесенә сузды.

— Шулайрак туры килде шул, — диде кызыларамеец һәм иреннәренә ябышкан тәмәке вагын кул аркасы белән сыпырды. — Ләкин мундштугын «бүләк итмәде», каһәр. Югалткан булгандыр, ахрысы.

— Мундштуксыз уңайсызрак, әлбәттә. Ярый, болай да зарарсыз.

Алар, тәмәке суыра-суыра, минут чамасы тын тордылар.

— Отрядта күптәннәнме? — дип сорады аннары кызыларамеец, әңгәмәне дәвам итәргә теләп.

— Оешкан көненнән башлап дияргә була. Кырык икенең язынан бирле.

— Командирыгыз бик тәвәккәл кеше күренә.

— Ә, Мишканы әйтәсеңме? — Сакчы тәмәкесен сүндереп җиргә ташлады. — Андый командирны бөтен әйләнә-тирәне бетереп эзләсәң дә таба алмыйсың. Безнең «Мишка-татарин»ны Замойщинада белмәгән кеше юк. Ышанмасаң, әнә җирле халыктан, кирәк икән, фрицларның әнә үзләреннән сора.

— Фрицларның кирәген биргән, димәк.

— Ничек кенә әле! Әйе, мактанып әйтүем булмасын, иманнарын укыттык без аларның. Командирыбыз менә дигән безнең. Ә үзе бит бернинди дә академия-мазар бетермәгән. Чины буенча нибары кече лейтенант. Батырлыкка дисәң, аның кебекләрне очратканым юк әле минем.

— Аз гына арттырасың да бугай...

— Минме арттырам? Син белмисең әле аның кемлеген. Без аның белән һәр төн саен диярлек гитлерчыларның я такта яру, я аракы куа торган заводларын көл-талкан китерәбез. Ә андый операцияләрне хәзерләү өчен башыңны эшләтә белергә кирәк.

— Әлбәттә, шулай. Ә үзе ул әсирлектән качкан кеше, имеш.

— Әйе, Ченстохов янындагы лагерьдан. «Тәүлек буе кача-поса, әллә нинди ташландык сукмаклар буйлап уздым», дип сөйләде ул безгә. Аннан ниндидер бер авылга килеп чыккан. Авыл читендәге өйнең тәрәзәсеннән үрелеп караса, күрә: түрдә япа-ялгыз бер карчык утыра... Иске киемнәрне аңа шул табып бирә, партизаннар отрядына юлны шул күрсәтә. Тәре сурәте төшерелгән медальон-бүләк тә аныкы: «Шуны тагып йөрсәң, исән калырсың!»

— Һәм ул аны тагып йөриме?

— Ник йөрмәсен... Әйбәт күңелле кешенең истәлеге ул, ди. Поляклар әйтәләр: шул медальон аркасында исән калган ул, диләр. Чыннан да искиткеч тәвәккәл кеше ул, теләсә нинди кыенлыкны җиңел ерып чыга. Бервакыт шулай җиңел арбага утырып урман аша узарга туры килә аңа. Күрше отрядка баруы буламы шунда, башка җиргәме... Көтмәгәндә засадага тап була. Немецлар ут ачалар, ә ул арбага аягүрә баса да атларны бар көченә каулый башлый. Һәм исән-имин котыла бит шул уттан. Пулялар бричканы гына челтәрләптишкәләп бетерә.

Сакчы тәмәке төпчеген сүндерә, итек үкчәсе белән угалап, аны җиргә батыра.

— Бәхетле күлмәк киеп туган ул! — дип өстәгәч, кинәт башын күтәрде һәм колакларын сагайтты.

— Кемдер ат юырттырып килә. Ялгызы гына, ахры.

Ул автоматын җайлап тотты да үзе сөялеп торган агач яныннан читкәрәк китте. Хәзер инде тояк тавышлары аның әңгәмәдәшенә дә ап-ачык ишетелә иде.

— Борута бу, — диде сакчы. — Корсар отрядыннан.

Юлчы ап-ак күбеккә баткан атын агачка бәйләп куйды да аңа мөрәҗәгать итте:

— Командир кайда?

— Командир биредә, — диде искәрмәстән таш өеме артыннан күтәрелгән киң җилкәле бер егет. Аның артка тарап куелган кара чәчләре чуар бизәкле яулык белән кысып бәйләнгән, яулык очлары як-якка асылынып төшкән иде.

Тумышы белән Татарстаннан булганы өчендерме, отрядта аңа «Мишка-татарин» дигән кушамат тагыла. Бу якларга ул 1942 елның яз башларында килеп чыкты. Ул чакта җирле халык арасында Сольская Пуща тирәләрендә яшерен хәрәкәт итүче ниндидер диверсион группалар турында имеш-мимеш сүзләр йөри иде. Дөрестән дә, гитлерчыларның үлем лагерьларыннан качкан совет хәрби әсирләре, өчәр-дүртәр кешелек группаларга оешып, тирә-якта актив хәрәкәт итә башладылар, үзләренә азык-төлек һәм кием-салым булдырдылар. Әнә шул вак-вак группаларның кайберләрен «Мишка-татарин» Григорий Котовский исемендәге аерым бер отрядка туплады. Аның беренче ярдәмчеләре поляклар, элек-электән Польша коммунистлар партиясенә теләктәшлек күрсәткән кешеләр булды. Лукова тирәсен-

дәге җирләрдә Польша эшчеләр партиясе ячейкалары төзелә башлады. Җирле халык Михаил җитәкчелегендәге партизан отрядын азык-төлек белән тәэмин итте, аларга карабиннар һәм патроннар табып бирде.

Котовский отряды кулына март ахырларында алпавыт Фудаковскийның Краснобродтагы утарында шактый мул азык-төлек эләкте. Әмма кайтып килешли алар лейтенант Форстер командалыгындагы бер төркем жандармнарга юлыктылар. Ике арада атышлар башланып китте. Котовскийчыларның җир астында озак ятып дымланган патроннарының кайберләре атылмаганы беленде. Көчләрнең тигез түгеллеге күренеп торгач, Михаил отрядны урманга чигендермичә нишләсен.

Апрель аенда отрядка әсирлектән качкан күп кенә солдат һәм офицерлар, үлем лагерьларына җибәрелүдән яшеренеп калган поляклар һәм еврейлар килеп кушыла. Крестьяннар яшереп куйган җирдән тагын берничә карабин табылды һәм отряд үзенең эшен тагын да киңрәк җәелдереп җибәрде. Егерменче майда котовскийчылар Тарнавкадагы такта яру заводына һөҗүм иттеләр. Биредә Сольская Пуща урманнарында киселгән агачның шактый күп өлеше эшкәртелә торган була һәм аны уналты полицай, алты жандарм саклый икән. Полицайлар, беренче атыш тавышларын ишетү белән, объектны саклауны жандармнарга калдырып, табан ялтыраттылар. Шул чакны партизаннар, жандармнарны юк итеп, такта яру заводын һәм йөк төялгән дүрт машинаны яндырды. Берничә автомат һәм пулемет кулга төште.

Уңышлы уздырылган бу операция Томашева тирәләрендә вакытлыча төпләнгән оккупантларны куркуга салды. «Томашева жандармнары Замостьеда төн уздыралар», — дип язды 1942 елның 1 маенда Людова Гвардия командованиесе органы «Гвардеец» газетасы. Ә Замостьеда вермахтның зур көчләре урнашкан иде.

Озак та үтмәде, отряд «тәртип урнаштыру» өчен Юзефувка җибәрелгән Люблин «дистрикте» полициясе һәм СС начальнигы бригаденфюрер Одило Глобоцник үзе җитәкчелек иткән камап алу операциясе планын челпәрәмә китерде. Авиациядән ярдәм алуына да карамастан, ике мең солдат һәм полицейскийлар Юзефув белән Александров арасындагы урман сукмакларын өзә алмады. Партизаннар, дошман белән бәрелешкә кермичә генә, камалыштан чыктылар.

Ләкин оккупантлар үзләренә искиткеч күп борчулар тудырган отрядны юк итү ниятеннән кире кайтмады. Алар оештырган иң зур операцияләрнең берсе октябрь аенда Зелена авылы янында уздырылды. Атлы өч йөз жандарм Михаил отрядын чолганышка алды һәм партизаннарны кысрыклый башлады. Бу бәрелеш, кул сугышларына күчә-күчә, көн буе дәвам итте. Ниһаять, командир отрядны хәлиткеч контратакага күтәрде. Партизаннар, бердәм кыю күтәрелеп, жандармнар тезмәсен өзде, алар арасында чуалыш тудырды һәм урман эченә кереп яшеренде. Бу бәрелештә егермегә якын жандарм үтерелде һәм яраланды.

Башкисәрләрдән торган подразделениеләргә тирә-якны партизаннардан «чистарту», җирле халыкны Германиягә куып алып китәр алдыннан Сольская Пущада тынычлык урнаштыру бурычы йөкләнгән була. Әмма октябрьда уздырган бу операцияләре дә, май аендагы шикелле үк, гитлерчыларга бернинди уңыш китермәде.

Людова Гвардия командованиесе сводкаларында партизаннарның иң популяр командирларыннан берсе булган «Мишка-татарин» җитәкчелек иткән Котовский исемендәге отряд бик еш телгә алына: 1 апрельдә ул оккупантларның күп санлы көчләренә каршы ике сәгать буе дәвам иткән сугышта дошманны зур югалтуларга дучар ит-

те... 2 апрельдә җәзачы-башкисәр сигез гитлерчыны дөмектерде... Әч көн узгач, карабиннардан һәм автоматлардан атып, фашистлар самолетын зарарлады. Немец очучысы самолетын отрядка якын тирәдә утыртырга мәҗбүр булды... 29 апрельдә ике мең ярымга якын гитлерчы Сопот һәм Танев елгалары арасындагы урманда Котовский исемендәге отрядны камап ала. Урынның сазлыклы, үтү өчен ифрат авыр булуыннан файдаланып, инде 75 кешелек отряд командиры, оста маневрлар оештыра һәм дошманны юлдан яздырып, отрядны куркынычсыз җиргә алып чыга... 1 майда такта яру заводына яңадан һөҗүм. Сакчылар коралларын ташлап качты, комендант үтерелде. Дүрт власовчы — партизаннар әсире. Такта яру заводының көле күккә очты... 16 майда Краснобрад һәм Длугой Конт такта яру заводларындагы гарнизоннар тар-мар ителде... Отряд командирының шундый батырлыгы турындагы хәбәрләр инде телдән-телгә күчеп йөри башлый.

Басып алынган Польша җирләрендә бер-берсенә капма-каршы төрле политик карашлардагы группалар була. Лондонда эмиграциядәге хөкүмәтнең хәрби оешмасы Крайово Армия белән мөнәсәбәтләр аеруча катлаулы булып, бу оешма үз кешеләрен совет партизаннары белән нинди дә булса бәйләнешкә керүдән тыя, поляк халкының бәйсезлеге өчен көрәшүче совет сугышчыларын илбасарлар белән бер рәткә куеп, «игез дошманнар» теориясен пропагандалый.

Ләкин Крайово Армия отрядлары командирлары арасында Лондон политикларының карашын хупламаучылар да аз булмый. Фашист илбасарларын юк итүне алар үзләренең төп максатлары итәләр.

Менә бер мисал. Партизаннар базасы урнашкан Старая Гута авылына 1943 елның 6 январенда фашист-башкисәрләр бәреп керә. Бу турыдагы хәбәр тизлек белән отрядка барып ирешә. Авыл халкына ярдәмгә беренчеләрдән булып Крайово Армия подпоручигы Конрад Бартошевский җитәкчелегендәге отряд һәм «Мишка-татарин» сугышчылары ашыга. Ләкин Конрад Бартошевскийның бу тәвәккәллеге Крайово Армия башлыклары арасында, аеруча майор Эдвард Маркевичта, зур курку тудыра. Ул Бартошевскийга отрядны кичекмәстән Сольская Пущага алып китәргә әмер бирә. Бу әмер үтәлгәннән соң Бартошевский икенче көнне шул ук Маркевичтан: «Сугышчыларның бер өлешен таратырга, калганнарын урман эченә алып кереп китәргә», — дигән яңа приказ ала. Приказга буйсынырга тиеш булса да, Бартошевский аны ахырынача үти алмый: солдатлар кораллы килеш отрядта калуны артыграк саныйлар.

8 январь иртәсендә гитлерчылар, төрле яктан һөҗүм итеп, Сольская Пуща урманы эченә үк керә башлый. Ләкин аерым подразделениеләре арасында өзеклек туа: аларны бер-берләреннән куе үләнле сазлыклар аера. Засадалардан ут яудырып, дошман сафларын кыру өчен партизаннарга әйтерсең язмыш үзе зур мөмкинлек ача. Ләкин, шулай эшлисе урынга, Конрад Бартошевскийга майор Маркевичның дошман белән бәрелешкә кермәскә, отрядларны таратырга дигән приказын үтәргә туры килә. Хәлнең шундый борылыш алуын тиз аңлап алган «Мишка-татарин», Бартошевскийдан аерылып, үз отрядын Сусецк урманнарына алып китә... Крайово Армия командованиесе аны берничә тапкыр әнә шундый кыен хәлдә калдыра. Ләкин оккупантларга каршы көрәштә ул уртак операцияләрдә катнашудан беркайчан да баш тартмый.

Поляк партизаннары белән дуслык урнаштыру өчен җан-тән бе-лән тырышкан шат күңелле, олы җанлы, мәзәкчән һәм җыр ратучан «Котовский» командиры күрше отрядларда һәр вакыт көтеп

алына торган кадерле кунак санала. Поляк отрядлары сугышчылары мәкерле дошманга каршы авыр көрәштә чиксез батырлыклар күрсәткән совет партизаннарына һәр вакыт таянырга мөмкин икәнлеген яхшы аңлыйлар...

— Командир мин булам! — диде «Мишка-татарин», куе агачлык арасыннан чыгып.— Сөйлә, дус кеше, нинди хәбәрләр алып килдең?

— Юзефувта немецлар! Иртәнге якта самолетлары бомба да ташлап, пулеметлардан тырылдатып үткән иде... Төштән соң солдатлар төялгән поезд килде... Шәһәрне камап алдылар. Безнекеләр дошманны Юзефувтан бәреп чыгарырга тиеш. Корсар сездән ярдәм көтә. Мөмкин кадәр ашыгырга тырышыгыз.

— Димәк, Юзефувка да чират җитте, — дип куйды Мишка. «Вервольф» азау тешләрен күрсәтә башлады, алайса. Аларның кайберен булса да бәреп сындырырга кирәк. Анысы да бер файда булыр...

«Вервольф» — безнеңчә әйтсәк «Убыр» — 1943 елның җәендә Замойщинада «тәртип урнаштыру» өчен хәзерләнгән зур хәрби чараны гитлерчылар шулай дип атадылар. Оккупантлар бер удар белән ике куянның койрыгын тотарга — җирле халыкны юк итеп, партизаннарны таянычсыз калдырырга һәм, «рейх»тан күчеп килүчеләрне бушап калган шәһәр-авылларга урнаштырып, «Көнчыгыш-эсэсчыларныкы булырга тиеш» дигән лозунгны тормышка ашырырга ниятләде. 18 майда Шараювка авылын яндыру шуның кереше булды. Гитлерчылар авыл халкын әвеннәргә куып кертеп, капкаларны тышкы яктан кадаклап куйдылар һәм ут төрттеләр. Җәзадан бәрәңге бакчаларына качып өлгергән 200 кешенең бары тик берничәве исән кала... Юзефувны да шундый ук язмыш көткәнлегенә шик юк иде. Бу шәһәр гитлерчылар өчен күптән инде күзгә төшкән ак булып исәпләнә. Округта партизаннар хәрәкәте шундый киң колач җәйде ки, Красноброд, Юзефув, Билгорная тирәләрендә оккупантлар власте чынлыкта бетерелгән иде инде. Алар администрациясе үз эшчәнлеген туктатты, немецлар бирегә бары тик көндез, анда да ике-өч взводтан ким булмаган солдат белән генә киләләр иде. Җирле халык бу округны «Юзефув республикасы» дип йөртә башлады: барлык эшләр белән идарә итү биредә нигездә партизаннар кулына күчте.

— Анысы да бер файда булыр,— дип кабатлады «Мишка-татарин» һәм атчабарга сорау бирде: — Бу хакта тагын кемгә дә булса хәбәр иттегезме?

— Якындагыларның барысына да, — дип җавап бирде Борута.— Антонга әйтелде. Врон отрядына да кеше җибәрделәр.

— Вронның коралы да юк диярлек түгелме соң аның? — дип куйды Мишка.

— Корсар аңа запас коралларны бирергә кушты.

— Анысы ярый. Димәк, Корсар отрядында йөзләп кеше, Антонда да шул чама җыелачак. Вронда илле, бездә илледән артык. Җәмгысен бергә кушсак, өч йөзләп штык дигән сүз. Аз түгел бит, ә?

— Түгел кебек. Сан ягыннан өстенлек хәтта безнең якта түгел микән әле.

— Әгәр шулай икән, бу бөтенләй әйбәт,—дип елмайды Мишка.— Һәр чакта да фрицларга гына өстен булырга димәгән. Бурыч ачык. Корсарга әйт: кичекмәстән барып җитәчәкбез. Юзефувта көрешкәнгә кадәр хуш!

Борута агачка бәйләп куелган атының тезгенен чиште дә ияргә сикереп менде һәм чабып китеп барды. Мишка сакчыга таба борылды:

— Тревога белдер!
Берничә минуттан бөтен отряд сафка тезелде.

— Менә нәрсә, туганнар, — диде командир, партизаннарга мөрәҗәгать итеп, — безнең алда зур эш тора. Монда исә һәркайсыбыз аеруча зур тәвәккәллек һәм осталык күрсәтергә тиеш. Беркемгә дә яшерен-батырын түгел, мондый сугышларда безнең тәҗрибәбез бик аз. Һөҗүмгә дә ачыктан-ачык барганыбыз юк диярлек. Ләкин без бүген булачак сугышка катнашмый кала алмыйбыз. Фашистлар бер гөнаһсыз сабыйларны, хатын-кызларны атканда бер читтә тыныч кына калырга безнең хакыбыз юк. Юзефувта безнең власть урнашырга һәм ул безнең база булып калырга тиеш. Дөрес әйтәмме, туганнар?

— Дөрес, — дип, аның сүзен җөпләде беренче рәттә басып торган өлкән яшьтәге сугышчы. — Фашистларга бер тапкыр ирек куйсаң, аннары алар оятларын бөтенләй югалтачаклар.

— Хак сүз, — диде Мишка көлемсерәп. — Ирек куярга ярамый. Барыгызга да патроннарны, гранаталарны кирәгенчә әзерләп куярга, мылтыкларны тагын бер тапкыр җентекләп тикшерергә! Бөтенесенә өч минут вакыт бирелә...

Поездга төялеп килгән гитлерчылар Юзефувны чолгап алдылар һәм урамнарга бәреп керделәр.

Кайчандыр халык белән мыжгып торган шәһәр тынып калган. Анда яшәүчеләрнең кулына корал тота алырдайлары партизанлыкка киткәннәр. Фашистлар, ишекләрне мылтык түтәләре белән ватып, йортлардан картларны, хатын-кызларны, бала-чагаларны урамга сөйрәп чыгара башладылар, ишегалларын, яшелчә бакчаларын, печән өемнәрен актарырга тотындылар. Алар уенча, шәһәрдәге бер генә кеше дә җәзасыз калырга тиеш түгел иде: йөздән артык кешене зират коймасы кырына алып килеп тезделәр һәм тезләнергә мәҗбүр иттеләр. Каршы якка пулеметлар куелды, җәзалауга хәзерлек башланды. Бу «эш»тән азат фашистлар йортларны, кибет һәм складларны талау белән мәшгуль булды...

Зират буенда өзек-өзек командалар яңгырады, пулеметлар койма кырында тезләнеп торучыларга төбәлде. Менә фашист офицеры, яңа команда бирергә әзерләнеп, кулын өскә күтәрде һәм авызын ачарачмас кинәт тынсыз-өнсез калды: шәһәр читендә пулеметлардан, автоматлардан аткан тавышлар ишетелде. Башкисәрләр арасында чуалыш китте, күз ачып йомганчы зират буенда аларның берсе дә калмады. Үлемгә хөкем ителгән кешеләр, үзләренең исән калуларына ышанырга да, ышанмаска да белмичә, төрлесе төрле якка сибелде.

Котовский исемендәге отряд билгеләнгән урынга, гадәттәгечә, бу юлы да алданрак килеп җитте. Башка отрядлар да озак көттермәде. Мишка отрядыннан сулда Антон һәм Врон партизаннары позицияләргә урнашты. Тагын да сулдарак Корсар сугышчылары күренде.

— Нәрсә, пан Куделка... — диде Мишка, поляк связноена мөрәҗәгать итеп. — Бөтенесе дә тәртиптә шикелле. Башласак та ярыйдыр.

— Алга! — Бу сүз партизаннарны яшен тизлеге белән җирдән күтәрде. Алар кул пулеметыннан ата-ата йөгергән командир артыннан алга ыргылдылар. Шәһәр читендәге йортларга җитәргә дүрт йөз метрлар чамасы гына калды. Калын, таш стеналар артында бу һөҗүмне һич тә көтмәгән фашистлар яшеренгән иде. Беренче һөҗүм кире кайтарылды.

Нәкъ шушы минутта сул флангта станковый пулеметлар тырылдавы ишетелде. Димәк, Корсарның сугышчан сафлары «эшкә» кереште. Пулеметларга автоматлар кушылды. Алгарак узып киткән автоматчылар ышанычлырак урынга — кирпеч йортлар, каберлек стеналары, төзелеп бетми калган мәктәп бинасы артына ышыкландылар. Ату тавышлары берәм-сәрәм генә ишетелгәләп торган тынлык урнашты. Партизаннар кечкенәрәк кенә бер иңкүлеккә җыелып, алга таба ничек хәрәкәт итү турында киңәштеләр. Бөтенесе дә бары тик кинәт ясалган һөҗүм генә уңыш китерәчәк дигән фикерне якладылар.

Капрал Радыкол җитәкчелегендәге утыз юзефувчы Осуховск тракты ягына юнәлде. Тагын унбиш минут үтүгә, командирлар партизаннарны һөҗүмгә күтәрделәр. «Ура!», «Алга!» сүзләре, атыш тавышларын күмеп, әле рус телендә, әле поляк телендә яңгырады.

«Мишка-татарин» үзенең аерылгысыз дусты булган кул пулеметы белән тагын отряд алдында. Аның белән янәшә командир урынбасары Василий Полынев белән Куделка атлый. Мишка кинәт тукталып калды һәм кабалана-кабалана уң як кесәсеннән нәрсәдер эзләргә кереште. Аның сул кулы яраланган иде.

— Яраң бик авырмы? — дип сорады Куделка, Мишкага якынлашып.

— Зарланырлык түгел, — диде Мишка һәм кесәсеннән кульяулыгын чыгарды. — Мә, бәйлә тизрәк!

— Алга!

Тагын бер сикереш ясауда партизаннар билгеләнгән сызыкка аяк бастылар. Сул як флангтагы сугышчылар, яшеренер өчен уңайлырак урын эзләп, җиргә елыштылар. Корсар да, авыр сулап, алар янына ауды һәм шунда ук башын калкытты. Чү, нәрсә бу? Совет партизаннары командирларының ашкынулы адымыннан калышмыйча һаман алга ыргыйлар түгелме? Алар кысрыклавына каршы тора алмыйча, дошман чигенә башлады. Артык көтеп торырлык ара юк. Корсар сикереп торды һәм «Мишка-татарин»ның командасын кабатлады:

— Алга!

Шул чак шәһәрнең төньяк-көнбатыш читендә атышлар көчәйде: үзенең ирекләләре белән Радыкол эшкә кереште. Немецлар, станциядә торган эшелонга кадәр ничек кенә булса да исән-сау барып җитәргә тырышып, табаннарын ялтыраталар иде. Аларны куып барган Мишка шәһәр читендәге урамга килеп керде. Менә ул качып баручылар өстенә пулеметыннан ут яудырырга тотынды. Ләкин көтмәгәндә аның дискасы бушап калды. Мишка аны берьяк читкә тотып атты да сумкасыннан икенчесен алды... Һәм кинәт кулыннан пулеметын төшереп җибәрде. Ул каты яраланган иде. Янына килеп җиткән Куделка аның, хәрәкәтсез күзләрен күккә төбәп, тын гына ятканын күрде. Мишканың ике күз арасыннан куе кан саркый иде.

...Ярсып алга ыргылган партизаннарны хәзер инде бернинди көч тә туктата алырлык түгел иде. Сугыш шәһәр урамнарына күчте. Исән калган фрицлар станциядән менә-менә кузгалырга торган поездга үрмәли башладылар... Партизаннарның бер өлеше үзләренең даими яши торган урыннарына кайтты, ә бер өлеше шәһәрдә калды: коткарылган халыкка ярдәм күрсәтергә, ашлык һәм башка төрле азык-төлекне немец складларыннан чыгарырга, һәлак булган сугышчыларны җирләргә кирәк иде. Соңгы төркем партизаннар шәһәрдән караңгы төшкәч кенә китте. Алар белән бергә җирле халыкның да байтагы юлга чыкты: фашистларның яңадан бирегә кайтып, бүгенге җиңелүләре өчен үч алырга тырышулары көн кебек ачык иде.

...Герман Иванов әсирлеккә авыр яраланып, һушын югалткан хәлдә төште. Бераз савыга башлау белән ул Новоград-Волынский янындагы лагерьда совет әсирләре оештырган яшерен группага керде. Һәрбер саксыз адымың тормышың бәрабәренә торган, түзә алмаслык чиксез авыр шартларда группа членнары листовкалар басуга һәм «Кызыл партизан» дигән газета чыгаруга ирештеләр. Газетаның редакторы итеп Николай Николаев, аның урынбасары итеп Герман Иванов билгеләнде. Әмма бер сатлык җанның хыянәте аркасында Николай кулга алынды һәм гестапочылар тарафыннан җәзалап үтерелде. Ә Герман Ивановка яралары көн-төн тынгылык бирмәде, аның сәламәтлеге начарланганнан-начарланды. Ләкин кыю партизан кул кушырып эшсез утырмады. Тиз арада шәһәрдә совет газеталарын таратучы яшьләр группасы төзелде. Связнойлар партизан отрядларыннан «Правда», «Красная звезда», «Комсомольская правда» һәм партизаннар өчен чыгарыла торган «Червоне Полися» газеталарын китертеп тордылар.

Эзләнә торгач, оккупантлар яшерен группаның эзенә төшеп, култык таякларына таянып көч-хәл белән йөргән Герман Ивановны кулга алуга ирештеләр. Бәхеткә каршы, 1944 елның 1 январенда Новоград-Волынскига бәреп кергән совет гаскәрләре кулга алынганнарның барысын да коткарды. Алар арасында Герман Иванов та бар иде.

...Инде егерме елдан артык урын өстендә ятуына карамастан, Герман Иванович Иванов әле хәзер дә сафтан китәргә җыенмый. Күзләре аның кояш яктылыгын күрүдән мәхрүм. Шәһәрдәге тугызынчы номерлы урта мәктәпнең өлкән класс укучылары — Герман Ивановичның иң якын дуслары. Ул аларга үзенең башыннан кичкәннәрне әйтеп яздыра. Аның беренче очеркы «Партизаннар редакторы» дип атала. Исеменнән үк күренгәнчә, очерк партизаннар өчен чыгарылган газета редакторына, атап әйткәндә, Николай Николаевка багышланган. Аннан соң Советлар Союзы Герое Вячеслав Антонович Квитинский турындагы очеркы басылып чыга.

1969 елда «Рабоче-крестьянский корреспондент» журналы аның турында түбәндәгеләрне яза: «Иванов квартирасы партизан язмалары штабына әверелгән. Бирегә элекке партизаннар, журналистлар, яшь эзтабарлар, музей архивлары хезмәткәрләре бертуктаусыз агылып тора... Ивановның барлык очеркларын да санап торуның кирәге юк. Аларның саны илледән артып китә, һәркайсы төгәл документларга нигезләнеп язылган. Шулай да аның ике эзләнүе турында аерым тукталып үтәсе килә. Аның эзләнүләре һәм истәлек язмалары чуваш журналистларына «Чуваш» кушаматы белән йөргән кешенең Польшадагы Люблин воеводствосында партизаннар көрәшен оештыручыларның берсе булган совет разведчигы Яков Николаев икәнлеген ачыкларга ярдәм итте. Люблин журналистлары аңа «Чуваш» белән иңгә-иң торып көрәшкән икенче бер совет разведчигының «Мишка-татарин» кушаматын йөрткәнлеге турында сөйләделәр. Ивановтан алар бу геройның чын исемен ачыклауны үтенделәр. Шуннан соң ике арада хәбәрләшү башланып китте. Мишка турында «Советская Татария» газетасында мәкалә басылып чыга. Һәм менә яшерен оешмада эш алып барган герой табыла. Ул — Михаил Сергеевич Атаманов булып чыга...»

Хәзерге көндә Казанда яшәүче Анна Антоновна Атаманова, газета битләреннән куркусыз партизан турында укыгач, «Мишка-татарин» кушаматы белән йөргән кешенең үз ире Михаил икәнлегенә ышанып җитә алмый. Ул эзләнүләрен һаман дәвам иттерүче Герман Ивановка хат язып сала һәм криминалистларга мөрәҗәгать итә.

Киев фәнни-тикшеренү институты экспертизына ике рәсем: Билгорая шәһәре музееннан килгән тонык, бик үк танылып җитмәгән һәм Атамановларның гаилә архивында сакланган рәсемнәрне җибәрә. Бу рәсемнәрнең беренчесендә Котовский исемендәге партизаннар отряды командиры, икенчесендә хатыны белән Михаил Сергеевич Атаманов төшерелгән була. Һәм менә криминалистика белгечләре ясаган нәтиҗә: «Экспертизага җибәрелгән һәр ике фоторәсемдә дә бер үк кеше сурәтләнгән».

Хәзер инде легендар партизанның кем икәнлеге тулысынча ачыкланды дип санарга мөмкин. Ул Алабуга шәһәрендә туа. Гаиләгә ифрат авыр шартларда яшәргә туры килә. Михаил, алтынчы классны тәмамлагач, җиләк-җимеш питомнигында кара эшче булып эшли башлый. Аннан соң ФЗӨ мәктәбенә укырга керә, тимерче һөнәрен үзләштерә һәм башта Ижевск заводларының берсендә, соңыннан Алабуга артелендә эшли. Бераздан киномеханиклар хәзерли торган кечке курсларны тәмамлый һәм кинотеатрга эшкә күчә. 1935 елда хәрби хезмәттән кайта һәм күчмә кино белән район буйлап йөри. Шул ук елны тормыш корып җибәрә. 1938 елны Осовиахим курсларын тәмамлап, 1 нче номерлы шәһәр мәктәбенә военрук булып килә. Бер үк вакытта физкультура һәм рәсемнән дәресләр бирә. Михаил бала чагыннан ук карандаштан аерылмый һәм Алабуга тирәсе пейзажларын бик яратып сыза торган була.

Тормышта ул үз урынын укытучылык эшендә таба. Моңа аның кешеләр белән якыннан һәм тиз аралаша алуы, көр күңеллелеге, укучыларны кызыксындырырлык төрле нәрсәләр уйлап чыгарырга сәләтле булуы ярдәм итә. Шугалак ясау дисеңме, мәктәпне бәйрәмчә итеп бизәү, чаңгы походлары оештырумы — боларның бөтенесен дә Михаил Атаманов башлап йөри.

Запастагы кече лейтенант Михаил Атаманов һәр ел саен хәрби сборларга чакырыла. Чираттагы повестка аңа 1941 елның маенда килә. Ә 23 июньдә, сугышның икенче көнендә, ул лагерьдан туп-туры фронтка чыгып китә. Алабугага Михаилның юлдан, Оршадан язган бер генә хаты килә. «Бөтенесе яхшы булыр! Без фашистларны тармар итәрбез һәм яңадан өйләребезгә кайтырбыз!»

Аның турындагы икенче язуны Анна Антоновна Атаманова сугыштан соң, 1948 елда ала: «Сезнең ирегез, 1912 елда туган лейтенант Атаманов Михаил Сергеевич, Бөек Ватан сугышында 1941 елның сентябрендә хәбәрсез югалган...» диелә ул хәбәрдә.

Михаил Атамановның язмышы турында без 1966 елда белдек. Партизаннарның, Люблин тирәләрендә яшәүче җирле халыкның сөйләве, поляк каршылык хәрәкәте турында язган һәм иң сугышчан отрядларның берсенә командалык иткән Михаилның батырлыгына аерым бүлекләр багышлаган Войцех Сулевский, Тадеуш Шиманский, Збигнев Якубик, Тадеуш Новак, Юзеф Гарас китаплары буенча Польшада аның исеме киң таралган булган. Шуңа күрә, легендар «Мишка-татарин»ның тормыш иптәше Казанда яшәгәнлеген белгәч, поляк дусларның аны кунакка, ире сугышкан җирләрне күреп китәргә чакырулары бер дә гаҗәп түгел. Һәм Анна Антоновна кызы белән Польшада булып кайта. Котовскийчыларның куркусыз командиры башта күмелгән урман аланлыгындагы калку урынга чәчәкләр куялар. Михаил Атамановның мәете соңыннан туганнар каберлегенә күчерелә.

Ә кайда соң ул каберлек?

«Корсарга Мишкадан соң озак яшәргә насыйп булмый. Ул Александровск территориясенә «Вервольф» акциясе килгәч, август аенда Дембовцы янында һәлак була. Совет партизаннары үзләренең командирларын башта күмелгән җирләреннән алып Гамерня авылында

сугышка чаклы һәйкәлләр басып торган урынга бергә күмәргә дигән карарга киләләр. Табут артыннан ике отрядның да сугышчылары баш киемнәрен салып атладылар...»

«Бүрекләрне кыңгыр салып» дип аталган китабында Збигнев Якубик әнә шулай яза. Тадеуш Новакның командирларны җирләү турындагы «Тапшырылмаган хат» хикәясе дә шушы ук язмалар белән аваздаш. Дөрес, ул Мишканың Корсар белән бергә күмелгәнлеген телгә алмый. Әмма ул да күмелү урынының Гамерня авылында икәнлеген әйтә.

Анна Антоновна кызы белән Юзефувта да була. Алар Михаил Атаманов һәлак булган урам буйлап узалар һәм «Мишка-татарин урамы» дигән табличка кадакланган йорт янында рәсемгә төшәләр.

Икенче тапкыр Анна Антоновнаны Польшага иренә һәйкәл ачылу тантанасына чакыралар. Бәйрәмчә киенгән юзефувлылар, ветераннар колонналары оркестрлар һәм байраклар белән шәһәр читенә җыела. Гимн авазлары яңгырый һәм һәйкәлгә бөркәлгән япма төшерелә. Искиткеч зур таш сын күп санлы пуля эзләре белән тишкәләнгән. Анда: «1943 елның 1 июнендә гитлерчы оккупантларга каршы көрәштә поляк һәм совет партизаннары группасы белән бергә һәлак булган, «Мишка-татарин» кушаматлы партизан отряд командиры М. Атаманов истәлегенә», — дигән сүзләр уелган. Һәйкәлнең икенче ягына шушы ук сүзләр поляк телендә язылган...

Бу баруында Анна Антоновна совет офицеры Михаил Сергеевич Атаманов үзе үлгәннән соң бүләкләнгән III нче класслы Грюнвальд орденын алып кайта. Бу зур бүләктә юзефувлыларның — иң хәтәр сәгатьтә партизаннар коткарган кешеләрнең — балалары һәм оныкларының йөрәк җылысы, иксез-чиксез рәхмәте чагыла. Әйе, алар батырларны зурлап искә алалар. Ул батырлар арасында Алабугада туып-үскән, шунда яшәгән безнең кыю якташыбыз да бар. Һәлак булган сугышчылар истәлегенә кабынган мәңгелек утның шәүләсе кичләрен ул туган йортның да тәрәзәләрендә уйный.

*Рәшит Гәрәй тәрҗемәсе.*

**Виктор Попов,**
биология фәннәре докторы, Казан дәүләт университетының табигатьне саклау кафедрасы мөдире, Татарстан табигатьне саклау җәмгыяте советы президиумы члены.

# БИОСФЕРА ҺӘМ АНЫ САКЛАУ ЧАРАЛАРЫ

Хәзерге заманда, фән-техника революциясе, атомны буйсындыру, космосны үзләштерү, күп кенә производство процессларын машинага көйләү һәм автоматлаштыру һәм шәһәр халкының тизлек белән үсү чорында кешенең табигать белән мөнәсәбәте торган саен кискенләшә бара. Табигатьнең гармоник бөтенлеген бозу нәтиҗәсендә, табигать белән кеше арасындагы әлеге мөнәсәбәт еш кына конфликтлы ситуацияләр тудыруга китерә, ә кайбер очракларда табигать моның өчен кешедән аяусыз үч тә ала.

Мең еллар буе көч түгеп эшкәртелгән җирнең уңдырышлы өске катлавын бернична сәгать эчендә очыртып алып китә торган тузан бураннары әледән-әле булып тора. Сөрү җирләрен, авылларны, шәһәрләрне басып киткән һәм халыкка зур бәхетсезлекләр тудырган һәлакәтле су басулар да еш кабатлана, игеннәрне, терлекләрне, кыргый хайваннарны һәлак итә. Корылыклар чәчәк атып утырган җирләрне коры чүлгә әйләндерә, «онытылган авырулар» уяна, яңалары килеп чыга, бик күп кешеләр аллергия авырулары белән җәфалана, теге яки бу зәгыйфьлекләр белән туган балаларның саны арта бара.

Сәбәп нәрсәдә? Атаклы геохимик, биосфера турындагы бик күп хезмәтләр авторы академик Владимир Иванович Вернадский сүзләре белән әйткәндә, кеше үзенең аңын үз-үзен юк итәр өчен кулланырга сәләтле микәнни? XX гасырда яшәгән кешенең, Карл Маркс әйткәнчә, «Табигатьнең бөек законнары белән хисаплашмый төзелгән проектлар бәхетсезлек кенә китерәләр» дигән сүзләрен аңларга һәм файдаланырга көченнән килми микәнни?

Бөтен прогрессив кешелек дөньясын борчыган бу сорауга берьяклап кына җавап бирү практик яктан мөмкин түгел. Дөньяны хәзер өч лагерьга бүленгән диярга була: шуларның беренчесе үзара дуслыклары һаман үсә барган социалистик илләр, икенчесе капиталистик лагерь, өченчесе әлегә үзләренең киләчәктәге үсеш юлларын анык кына билгели алмаган үсә баручы илләр. Моннан илле еллар элек табигатьне саклау проблемасы биологик яктан чыгып кына каралса, хәзер исә ул экономик, социаль һәм политик проблемага әйләнде. Шуңа күрә, табигатьне саклау мәсьәләсенә кешенең мөнәсәбәте дә барыннан да элек аның кайсы социаль формациядән, политик һәм культура үсеше дәрәҗәсенең нинди булуына карап билгеләнә. Фридрих Энгельсның табигатьтә һәрнәрсә үзара бәйләнештә һәм үзара шартлылыкта дигән күренекле фикерен белү генә аз, ә бу төп теоретик фикерне практикада тормышка ашырырга

мөмкинлек тудырырга кирәк. Әмма җиргә, суларга, урманнарга һәм җирнең эчке байлыкларына хосусый милекчелек дәүләт строеның котылгысыз нигезе булган капиталистик илләрдә табигатьне саклау мәсьәләләре зур каршылыкларга очрый. Чөнки анда табигать ресурсларыннан файдалану шәхси байлык туплауның иң җиңел юлы булып хезмәт итә, кайвакыт хәтта кешелек тарафыннан кабул ителгән мораль рамкалары белән сыешмый торган бизнес та дәүләт тарафыннан яклау таба. АКШтагы 25 мең квадрат километр мәйданлы Эри күленең язмышын искә алу да бик гыйбрәтле. Күл буена урнашкан предприятиеләрнең ташландык суларын күпләп агызулары нәтиҗәсендә күлдә барлык тереклек иясе үлеп беткән дип әйтерлек. Җирне арендага бирү системасы да җир ресурсларына зур зарар китерә, йөзләгән гектар уңдырышлы җирләрне һәлак итә. Финнарның бик матур шундый мәкале бар: «Кыяны гомерлек файдалануга алган кеше аннан бакча ясый, бакчаны арендага алган кеше, аренда срогы беткәндә, аны ташландык хәлгә китерә». Капиталистик илләрнең Лондон, Лос-Анжелос, Токио, Чикаго һәм башка күп кенә эре шәһәрләрендәге кебек күп меңләгән кешеләрне һәлак иткән зарарлы пычрак һаваны гына искә төшерегез, бөтен дөньядагы вакытлы матбугатта басылган рәсемнәрне, фотографияләрне күз алдына китерегез. Аның берсендә Лос-Анжелос шәһәрендә кичке прогулкага противогаз киеп чыккан ана белән бала рәсеме төшерелгән, газеталарда противогазлы балалар колясқасы чыгарылуы турында рекламалар басыла.

Америка Кушма Штатлары президенты Никсонның 1973 елның 23 маенда Мәскәүдәге визиты вакытында табигатьне саклау эшләре буенча халыкара килешүне хәзерләгәндә «табигатьне саклау» дигән терминга каршы килүе очраклы түгел. Алар «әйләнә-тирәне саклау» дигән терминны тәкъдим иттеләр, чөнки хосусый милекчелекнең хөкем сөрүе нәтиҗәсендә АКШ хөкүмәтенең табигатьне саклау буенча киң эш җәелдерергә хокукы да, мөмкинлеге дә юк.

Табигать комплексларының гармоник бөтенлеге бозылуы һәм аның фаҗигале нәтиҗәләрен аңласа да, капиталистик җәмгыять кешесе берни дә эшли алмый. Бу хәл көчәл төшенкелеге тенденцияләренә, табигатьнең һәлакәте һәм, моның нәтиҗәсе буларак, кешенең дә юкка чыгуы котылгысыз булуын сурәтләгән байтак кына китаплар бастырып чыгаруга китерә. «Африка үлеп бара торган җир», «Табигатьне һәлакәткә дучар булганга кадәр карарга кирәк», «Экологик һәлакәт» һ. б. «Җир вакытлары» исемле экологик журнал редакторы турыдан-туры болай дип яза: «Әгәр егерме елдан соң алар да һәм без дә эчә торган су җитмәүдән һәлак булачакбыз икән, хәзер барлык акчаларыбызны «Кара пантера»ларга корбан итү ахмаклык булыр иде».

Социалистик дуслык илләрендә табигатьне саклау дәүләтләрнең иң мөһим бурычларыннан берсе булып тора һәм бу юнәлештә үткәрелгән эшләр ел саен киң колач ала бара.

Дөньяда беренче социалистик дәүләт урнашуның авыр елларында бөек юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленин табигатьне саклауны яхшырту һәм табигать ресурсларыннан дөрес файдалануга юнәлдерелгән 94 тән артык төрдәге документларны эшкәртүгә катнашты. Бу документларда Владимир Ильичның Октябрь революциясенә кадәр үк әйтелгән: «Менә дәүләтне үз кулыбызга алгач та табигать дошманнарына һөҗүм башлаячакбыз», — дигән сүзләре гәүдәләнә кебек.

Табигать ресурсларын саклау һәм алардан файдалану өлкәсендә табигатькә ленинчыл мөнәсәбәт безнең партиябезнең һәм хөкүмәтебезнең политикасы булып тора.

Советлар Союзы Коммунистлар партиясенең генеральный секретаре Леонид Ильич Брежнев: «Җир, урман, елгалар һәм саф һава, үсемлекләр һәм хайваннар дөньясы турында кайгырту — бу безнең төп, коммунистик эшебез», — диде.

СССР Верховный Советының сигезенче чакырылыш IV сессиясе 1972 елның 20 сентябрендә «Киләчәктә табигатьне саклауны һәм табигать ресурсларыннан рациональ файдалануны яхшырту чаралары» турында карар кабул итте. Анда: «Табигатьне саклауны даими рәвештә кайгыртып тору дәүләтнең иң мөһим бурычларыннан берсе», — диелә. 1972 елның 29 декабрендә КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы табигатьне саклауны көчәйтү һәм табигать ресурсларыннан файдалануны яхшырту турында 898 нче номерлы махсус карар чыгарды. Бу карарда табигатьне саклау эше дәүләткә хезмәт итү дип карала, һәм ул төрле союздаш министр-

лыкларның һәм ведомстволарның, СССР Фәннәр академиясенең һәм СССР Министрлар Советы каршындагы кайбер комитетларның табигый ресурсларны эченә алган аерым компонентларны саклау һәм файдалану, табигатьне саклауның фәнни нигезен эшкәртү һәм табигатьтә булып торган үзгәрешләр өстеннән контроль алып бару җаваплылыгын билгеләде.

Социалистик илләрнең Үзара Ярдәмләшү Экономик Советында табигатьне саклау мәсьәләсенә зур игътибар бирелә һәм махсус эшләнгән кординацион план нигезендә күп төрле зур проблем мәсьәләләрне һәм аерым фәнни темаларны бергәләп эшкәртү күз алдында тотыла.

Социалистик илләрнең техник прогрессын табигать комплексларындагы мөмкинлекләр белән яраштырылганда гына прогресс дип атарга мөмкин. «Фән-техника прогрессын тизләтү буенча чаралар күрелгәндә, — диде Л. И. Брежнев, — ул табигать ресурсларына хуҗаларча мөнәсәбәт белән үрелеп барсын өчен, аның һаваны һәм суны хәвефле пычрату, җирне ярлыландыру чыганагы сыйфатында хезмәт итүен булдырмау өчен барысын да эшләргә кирәк».

Шулай итеп, безнең дәүләтебезнең табигатьне саклау өлкәсендәге политикасы совет кешесе өчен гаять ачык һәм аңлаешлы. Табигатьне саклау эше ул бөтен халык эше, ул безнең партиябез эше, ул безнең изге эшебез һәм дәүләтебезнең иң мөһим бурычы. Табигать ресурсларын файдалану белән бәйләнгән барлык министрлыклар һәм ведомстволар әнә шул мәсьәләне искә алып эш итәргә тиешләр.

Табигый байлыкларны саклау һәм аны арттыру өчен кешенең бөтен җаваплылыгын һәм бу эшләрнең гаять катлаулылыгын аңлаган совет кешеләре киләчәккә тыныч һәм ышаныч белән карыйлар. Чөнки хуҗалык итүдә социалистик форма булу, табигый ресурсларны баету һәм файдалану, бердәм һәм дәүләткүләм планлаштыру ысулы биосфераны саклау юлында торган бөтен авырлыкларны җиңеп чыгарга ярдәм итәчәген алар аңлыйлар.

Социалистик илләрнең табигатьне саклау өлкәсендәге уңышлары, бөтен кешелек дөньясын борчыган проблемалар халыкара масштабта бик җентекләп өйрәнеләчәк һәм ул, һичшиксез, табигатьне саклау проблемаларын хәл итүне глобаль масштабта куярга ярдәм итәчәк. Шуның өчен, Л. И. Брежнев әйткәнчә, «Табигатьне саклау һәм аның ресурсларын рациональ файдалану буенча коллектив халыкара чараларда катнашырга без әзербез».

1974 елда Американың төньяк-көнбатышындагы кечерәк кенә Спокан шәһәрендә, безнең планетабызда беренче буларак, әйләнә-тирә табигать мохитен саклау мәсьәләсенә багышланган Бөтендөнья «Ехро-74» күргәзмәсе үткәрелде. Анда тирән уйланылган экспозицияләр урнаштырылды һәм зур павильоннарның берсе СССР павильоны булды. Бу павильонда табигатьне саклау проблемасының бөтендөнья масштабында булуы, дөнья халыкларының тормыш иминлеге өчен аның гаять зур әһәмияте һәм табигатьне саклау буенча СССРда алып барылган эшләр күрсәтелде. Күргәзмә директоры П. Коли әйтүенчә, совет павильоны күргәзмәгә уңыш китерде, аны көн саен 36 меңгә кадәр кеше карады.

1974 елның 23 октябрендә СССР дәүләт делегациясе «Әйләнә-тирә табигать мохитен саклау өлкәсендә Советлар Союзы политикасы» турында документ игълан итте. Анда безнең илебездә алып барылган табигатьне саклау өлкәсендәге принципиаль положениеләр яктыртылды.

1956 елда М. И. Будько, атмосфера температурасына кеше бернинди йогынты ясамый, соңгы 100 ел эчендә ул үзгәрешсез торды, дип язды. Әмма 1974 елда шул ук галим, хәзерге вакытта атмосфераның температурасы күтәрелү тенденциясе алды, елга ул 0,2 градуска күтәрелә, дип белдерде. Шуның өстенә Будько йөз елдан соң атмосфераның күпмегә җылыначагын һәм нәтиҗәдә Антарктида һәм Арктика бозлары эреп, дөнья океаны 40 метрга һәм аннан да артыгракка күтәреләчәген фараз итте. Моның төп сәбәбе органик ягулык яндыруда, диде ул. Чыннан да хәзер ел саен 2 миллиард тоннадан артык нефть һәм 3 миллиард тоннадан артык күмер, шулай ук гаять зур күләмдә газ яндырыла. Шуның нәтиҗәсендә атмосфераның физик җылынуы барлыкка килә.

Академик А. П. Виноградов (1973) атмосфера температурасы күтәрелүдә өч фактор: һава составындагы үзгәрешләр, атмосфераның тузанлануы һәм җирнең азонлы экранының җимерелүе төп роль уйный дип саный. Безнең гасырның урталарында атмосферадагы углекислый газның күләме 0,031 процент иде. Хәзер инде ул 0,0324 процентка кадәр күтәрелде. А. П. Виноградов кеше эшчәнлеге нәтиҗәсендә атмосферадагы углекислый газ 0,2 процентка арта дип яза. «Углекислый газ кояш яктысын интенсив рәвештә йота (инфракызыл спекторында), — ди ул. — Шуның өчен ул атмосферада оранжереядагы пыяла ролен уйный — кояш радиациясен үткәрә, ә инфракызыл (җылылык) нурларын кире чыгармый һәм шуның белән теплица эффекты тудыра». Углекислый газның шундый темпта үсүе нәтиҗәсендә 2000 нче елга атмосферада ул 0,0374 процентка җитәчәк, бу исә җир температурасының глобаль күтәрелүенә китерәчәк.

Атмосфераның тузанлануы да климатка катлаулы, шулай ук глобаль йогынты ясый. Бу — кешенең урманнарны кыруы, туфрак эрозиясенең прогрессивлашуы, индустриаль предприятиеләрнең тузан бүлеп чыгарулары, самолетлардан ашламалар сиптерү, туфракны эшкәртүне интенсивлаштыру, тирән һәм еш сөрү һәм шуның нәтиҗәсендә күп кенә очракларда структураның җимерелү күренешләре белән бәйләнгән. Бу турыда А. П. Виноградов болай дип яза: «Күп санлы күзәтүләр соңгы елларда атмосфераның тузанлануы шактый гына шәһәрләрдә XX йөз башындагыга караганда уннарча тапкыр артуын күрсәтә. Һавага күтәрелә торган тузан массасы күп миллион тонналарга якынлаша. Боларның барысы да атмосферага йогынты ясамый калмый. Шулай да монда галимнәрнең фикере кискен рәвештә аерыла. Берәүләр һавадагы тузаннар җиргә кояш нурлары үтеп керүгә тоткарлык ясап, планетабыз температурасын бозлык чоры башланып китү ихтималына кадәр суытыр дип саныйлар, икенчеләре исә, фараз итүгә генә таянмыйча, кояш нурларының гаять зур энергиясен дә исәпкә алып, атмосферадагы тузаннар кояш энергиясенең җиргә килүенә тоткарлык ясый алмаячаклар, дип белдерәләр. Шулай да җирдән кире кайтарылган һәм көчсезләнгән нур, үз юлында тузаннарга тап булып, космоска китми, ә кире җиргә юнәлә һәм шуның белән аның температурасын күтәрә.

Зур биеклектә очкан самолетлар азотның кислород белән кушылмасын (окисел) чыгара. Шуның нәтиҗәсендә планетабызның азонлы экраны җимерелү турында берничә сүз әйтеп китик. Азот окиселе азонны таркатырга сәләтле, бу исә ультрашәмәхә радиацияне арттыра. Болар барысы да атмосфера температурасының үзгәрүенә йогынты ясый. Бу проблема өлкәсендә фараз итүләр, фикерләр бик күп, ә фактлар аз булганлыктан, гаять җитди эзләнүләр, тикшерүләр сорала: поляр бозының эрү куркыныч бармы яисә, киресенчә, салкынаюны көтәргәме?

Бүгенге көндә дөнья чүленең киңәюен раслаучы күп сандагы фактлар тупланган. Аларның мәйданы хәзер 20 миллион квадрат километрга якын җир биләп тора. Бу 36 Франция кадәр диярлек һәм СССР территориясенең өчтән береннән бераз гына кимрәк дигән сүз. Без дөньяда чүл барлыкка килүнең өч үзәге — төньяк, үзәк һәм көньяк турында сүз йөртә алабыз. Дөньяда чүлләр үсүнең сәбәбе нәрсәдә? Озак вакытлар Сахарада эш алып барган француз галимнәре чүлләрнең үсүен кешеләрнең элекке сахара тирәсендәге комны каплап торган юка гына туфраклы җирләрне уйламыйча сөрү белән бәйлиләр.

Элекке Сахара тирәсендә урнашкан кешеләр туфрак белән ныгытылган комны ачканнар, ком хәрәкәткә килгән һәм уңдырышлы җирләргә һөҗүм итә башлаган. Хәзер Сахара комы, экваториаль Африкага таба хәрәкәт итә, һәр ел саен өч мең километрга диярлек сузылган фронтта 1—3 метр тирәнлектәге яхшы туфраклы җирне ком белән каплый. Тарихи чор эчендә Сахара мәйданы икеләтә арткан. Хәзер тоташ ком булган җирләрдә ком күмеп киткән елга эзләре, йөзеп баручы кешеләр, балыклар һәм су кошлары сурәтләре табыла. Атаклы сәяхәтче Н. М. Пржевальскийның шәкерте һәм аның эшен дәвам иттерүче П. К. Козловның «Монголия, Андо һәм үле шәһәр Хоро-хоть» исемле китабын исегезгә төшерегез. П. К. Козлов XIV йөздә таланган һәм ком белән капланган Хоро-хоть шәһәрен таба. Америкада чыга торган вакытлы матбугат битләрендә ком каплаган фермалар фотографияләре торган саен ешрак очрый. Австралиядә чүлләрнең киңәюе бик интенсив бара. Анда сарыкларны күп асрау нәтиҗәсендә үсемлекләр бетә бара һәм комлыклар хәрәкәткә килә. Бары

тик безнең илдә генә чүлгә планлы һөҗүм итү һәм авыл хуҗалыгы өчен яңа җир яулап алу эше үткәрелә. Бер Караком каналы гына да уннарча мең гектар җирне үзләштерергә, анда мамык, җиләк-җимеш, виноградниклар һәм башка авыл хуҗалыгы культуралары үстерергә мөмкинлек бирде. Ләкин шулай да чүл мәйданнарының глобаль үсү процессы барганда безнең уңышлар башка илләрнең югалтуларын каплый алмый.

Планетабызның чүлгә әверелә бару процессыннан тыш үсемлекләрнең ксерофитациясе[1] процессы, шулай ук үсемлекләрнең һәм хайваннарның шул төрләре яши торган ареалларның киңәюе шактый зур темплар белән бара. Бернича мисал китерик: СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы биология институтының экология лабораториясе инде егерме еллап Куйбышев сусаклагычы яр буен тикшерү эшләре алып бара. Тикшерүләр күрсәткәнчә, ике метр биеклеккә җитә торган дулкыннар бәрүе нәтиҗәсендә һәм комлы калкулыкларны туздырып, комны уннарча метрларга күчерүче җилләр тәэсирендә сусаклагычның яр буйлары урыны-урыны белән 50 метрга һәм аннан да күбрәккә җимерелгән.

Аерым участокларда туфрак 2—5 сантиметр калынлыгындагы ком белән капланган. Бу исә, табигый рәвештә, кайбер үсемлекләрнең юкка чыгуына, аларның гомуми массалары кимүгә, шулай ук бу урыннар өчен гадәти булган үсемлекләрнең күк үлән, дөя чәнечкесе, солыча, башаклы яушан һ. б. кебек ксерофитлы үсемлекләр белән алышуына китерә. Шулар артыннан хайваннарның да төр составлары үзгәрә. Актив ксерофитлашу процессы бара һәм сусаклагычка якын урыннарда чүлгә әверелгән участоклар барлыкка килә.

Россия империясендә җирләрне беренче генераль межалау XVIII йөзнең ахырында, урманнар һәм кырлар мәйданы азмы-күпме төгәлрәк билгеләнгәч үткәрелә. Казан губернасында ул вакытта урманлы җирләр 60 процентка җиткән була, ләкин ул чакта Мари республикасының бөтен территориясе диярлек һәм Чувашстан республикасының бер өлеше Казан губернасына кергән була. Аларны санамаганда урманлы җирләр 50 проценттан артык тәшкил иткән. Ә хәзер урманнар 15 процент чамасы гына. Болар, билгеле, барысы да хайваннар дөньясы составына һәм элек бары көньякта гына яшәгән кайбер хайван төрләренең төньякка күчүенә китергән. Соры көртлек һәм үр куяны моңа бик яхшы мисал булып тора. XVIII йөзнең ахырында Русь җирен өйрәнү буенча шактый мөһим эш алып барган һәм Симбирскида (Ульяновскида) кышлаган П. С. Паллас бу урыннарга гадәти булмаган куян килеп чыгуын күрсәтә. Ул аңа үр куяны (русак) дип исем бирә. Соңгарак Э. А. Эверсман (1850) үр куянының төньякка, Казанга кадәр таралуы, ләкин әле анда сирәк булуы турында яза. М. П. Богданов (1871) үр куянын күп булмаган санда Вятка губернасының көньяк өязләрендә дә очратулары турында белдерә. Хәзер үр куяны Идел — Кама краеның бөтен территориясендә дә бар (Попов, 1960). Соры көртлек һәм җирән йомран белән дә шул ук хәл килеп чыкты. Алар хәзер инде Мари АССР һәм Киров өлкәсе басуларында күренәләр. Болар барысы да туфракның комга әйләнү, урманнар кимү, һәм, билгеле, гомуми биомассаның кимү нәтиҗәләре булып тора.

Хәзер инде биосфераның кеше эшчәнлеге тәэсирендә пычрануының биш төп каналы бик ачык билгеле булды.

1. Производство ташландыклары белән пычрану;
2. Тормыш-көнкүрештә булган ташландыклар белән пычрану;
3. Транспорт газлары белән пычрану;
4. Биосфераның химик пычрануы;
5. Биосфераның радиация фоны күтәрелү.

Канада белән АКШ чигенә якын урнашкан Эри күле — табигый комлыкларга промышленность ясаган кире тәэсирнең ачык мисалы булып тора. 25 мең квадрат километр, ягъни безнең Куйбышев сусаклагычы кадәр биш өлеш мәйданны алып тор-

[1] Грекча ксерофитация сүзеннән. Ксерофитлар — корылыклы өлкәләрдәге үсемлек яки даими рәвештә суга сусаучан туфрак.

ган бу күл тирәсендә 350 эре промышленность предприятиесе һәм Детройт агломерациясе урнашкан. Промышленность калдыклары күп еллар буе шушы күлгә ташлана барган һәм хәзер ул үле күлгә әйләнгән. Аны элекке хәленә китерү өчен миллиардлаган сум акча таләп ителә. Рур промышленность районында (ГФР) күмер яндыру һәм башка ташландыкларның атмосферага таралуы нәтиҗәсендә ел саен җиргә 210 миллион килограмм корым һәм башка катнашмалар төшә. Болар анда яшәүче һәр кешегә 12 кг туры килә. Бездә мондый хәлләрнең булуы мөмкин түгел, ләкин промышленность калдыкларын елгаларга ташлау очраклары булгалый әле. Берничә ел элек Зөядә урнашкан шикәр һәм чүпрә заводларындагы казаннарны һәм башка җиһазларны чистартканнан соң, ул калдыкларны елгага ташлыйлар һәм бик күп балыкны һәлак итәләр. Хәзер безнең илдә чистарту корылмалары булмаган яңа заводларны эшкә җибәрү тыелды һәм табигатькә таралган промышленность ташландыкларының күләме елдан-ел кими бара. Бу урында Социалистик Хезмәт Герое, танылган химик, академик И. В. Петряков (1972) сүзләрен искә төшереп китәсе килә: «Мин «ташландык» дигән төшенчәнең үзен кире кагам. Бүгенге көнне торбаларга һәм канауларга ташланган калдыклар — алар кеше хезмәтенең җимеше. Аны ташламаска, ә файдаланырга кирәк. Әгәр дә кайсы да булса заводның һавага чыгара яки суга ташлый торган продуктлары була икән, ул вакытта галимнәр һәм инженерлар бу продуктларның халык хуҗалыгына кирәксез икәнен, аны яңа продукция эшләп чыгару өчен чимал формасында файдаланырга мөмкин түгеллеген расласыннар... Бары тик шуннан соң гына чистарту корылмалары төзү турында сүз булуы мөмкин. Шулай итеп, киләчәктә без ташландыклар калдырмый торган предприятиеләр төзергә тиешбез. Ул вакытта гаять зур суммалар таләп итүче чистарту корылмалары төзүнең дә кирәге булмас. Ә бит аларны төзүгә предприятиенең үзен төзүгә тотылган акчаның өчтән бере китә...»

АКШның Спокан шәһәрендә үткәрелгән беренче Бөтендөнья «Expo-74» күргәзмәсендәге АКШ павильонында 8—9 метр биеклектә өелгән чүп-чар тавы калкып тора. Болар — полиэтилен, банкалар, пластиклар, иске суыткычлар, кер юу машиналары, пыяла һәм кешелек эшчәнлегенең башка тормыш-көнкүреш ташландыклары. АКШта ел саен 130 миллион тонна тормыш-көнкүреш калдыклары ташлана икән. Аларны җиргә күмү проблемасы бүгенге көнгә кадәр хәл ителмәгән. Нью-Йорк шәһәрендә ел саен 6 миллион тоннага якын җыела торган ташландыкларны пресслап Атлантик океаны иңкүлегенә төшерергә булдылар. Ләкин бу хәл бик зур күңелсезлекләр китереп чыгарды. Океан төбендә яткан чүп-чар метан газы чыгара башлады һәм судагы барлык җан иясен агулады. Нәтиҗәдә Нью-Йорк янында тагын бер «үле диңгез» барлыкка килде.

Спокан күргәзмәсендә америкалыларны әлеге тормыш-көнкүреш ташландыкларын файдаланырга чакырган плакатлар алардан файдалы әйберләр эшләп бик зур суммалар тупларга мөмкин булуы турында белдерәләр. Ләкин бу чүп-чарны сортларга аерырга теләүче, күрәсең, һаман саен үсә барган эшсезлек шартларында да бик аз табыла.

Кер юу средстволары да табигатьне бик нык пычрата. Кояшлы май көннәренең берсендә мин Париж янындагы Сена елгасын күзәттем. Елгада тау-тау булып сабын күбекләре ага, алар үтеп баручы көймәләргә «менәләр» һәм бөтенләй аңлашылмый торган картина тудыралар. Юу средстволарын биологик юл белән чистарту кыен, алар үсемлек һәм хайваннар дөньясын һәлак итәләр һәм суны хәтта бакча түтәлләренә сибәргә дә яраксыз хәлгә китерәләр. Юу средстволарын куллануны чикләргә кирәк, ә химиклар аларны хәзерләү технологиясен үзгәртергә һәм микробиологик таркалуга бирешүчән итеп эшләүгә ирешергә тиешләр.

...Дөнья юллары буйлап 250 миллион машина йөри, аларның 110 миллионы АКШта. Ләкин бөтен планетага таралган һәм шактый уңай транспорт төре булып саналган машина биосфераны бик нык пычрата икән.

Этилләштерелгән бензин янган вакытта ис газы азот, кургаш һәм углеводород окисе чыгара. Кургашын, кагыйдә буларак, кеше организмында җыела бара, нәтиҗәдә аның организмны хәлсезләндерүе, «онытылган» авыруларны яңадан китереп чыгаруы мөмкин. Күптән түгел Америкада автомобиль барлыкка килгәнчегә кадәр яшәгән кешенең һәм күптән түгел генә Чикагода үлгән кешенең сөякләрендәге кургаш микъдарын тикшергәннәр. Беренчесенең сөягендә кургаш 2 миллиграмм, ә икенчесендә 200 миллиграммга якын була. Хәзер кайбер милли парклар территорияләрендә еш кына «Автомобиль белән керү тыела» дигән язу күрәсең. Автомобиль фирмалары моторларны кеше өчен зарарлы булган ташландыкларны кимрәк чыгарырлык итеп ясау өстендә эшлиләр. Германиянең кайбер шәһәрләрендә этилләштерелгән бензинны куллану тыела. Бүгенге көндә инде электромобильләр ясау буенча шактый зур эшләр алып барыла. Әгәр киләчәктә шуларга күчелсә, алар шәһәр һавасын сафландырырга нык ярдәм итәрләр иде. Безнең илдә инде аккумуляторын бер корганда 150 километр юл үтәргә сәләтле булган электромобиль үрнәкләре бар. Әгәр дә бер коруда 300 километр юл үтәргә мөмкинлек бирүче аккумуляторлар уйлап табылса, ул вакытта шәһәр транспорты проблемасы тулысынча хәл ителәчәк. Ә хәзер без игътибарыбызны моторларның сыйфатын яхшырту, зур шәһәрләрдә этилләштерелгән бензин куллану өстеннән контроль урнаштыру һәм шәһәрләрне әйләнеп үтә торган юллар салу турында кайгыртуга юнәлтергә тиешбез.

... Бу очракта галимнәрне генә түгел, бәлки киң җәмәгатьчелекне дә тирән борчуга төшергән мәсьәләләрнең бер ишесенә генә игътибар итик. Бу — авыл хуҗалыгында зарарлы бөҗәкләр һәм үсемлекләр белән көрәштә химик чаралар, аерым алганда пестицид куллану мәсьәләсе [1].

Пестицидны уйлап табу һәм аны киң куллану авыл хуҗалыгы үсеше өчен һичшиксез файдалы булды һәм товарлыклы продукцияне шактый арттыруга китерде. Пестицид белән эшкәртелгән участоклардан башкаларына караганда ике тапкыр артык уңыш алуны күрсәткән фактлар шактый. Агулы химикатлар чыгаручы химия промышленностеның кискен үсеше әнә шуның белән аңлатыла. Әгәр дә дөньяда үсемлекләрне зарарлы бөҗәкләрдән саклау өчен 1,5 миллион тонна химик средстволар җитештерелүен һәм авыл хуҗалыгында эшкәртелә торган җирләр мәйданының 4 миллиард гектар булуын исәпкә алсак, ул вакытта һәр гектарга 400 әр грамм пестицид туры килә. Кайбер илләрдә бу сан шактый югары исәпләнә. Мәсәлән, Франциядә, бер гектарга 2,7 килограмм (1970 ел мәгълүматлары буенча) туры килә. Безнең илдә 1967 елда 93 миллион гектар, ягъни авыл хуҗалыгы өчен файдаланырга яраклы җирләрнең 15 проценты пестицидлар белән эшкәртелде. Пестицидларны киң куллану һәм еш кына аның белән контрольсез эш итү шактый тискәре нәтиҗәләргә китерде. АКШның 44 елгасыннан һәм күленнән тоткан балыкларны тикшергәннән соң, аларның 99 процентында гадәттәгегә караганда 9 тапкыр артык ДДТ булганлыгы беленде. Черкиләрне һәм башка хәшәрәтләрне бетерү өчен сулыкларны гектарына 0,2 килограмм күләмендәге ДДТ белән эшкәрткәндә, 80 проценттан артык балык һәлак була, ә су төбендә 3,3, үсемлекләрдә 75, балыкларда 250 миллиграмм ДДТ туплана. Агуланган балыклар белән тукланган акчарлакларда аның тагын да күбрәк микъдарда туплануы беленде. Соңгы еллардагы тикшеренүләр күрсәткәнчә, кошлар организмына кергән пестицидлар калий алмашуын бозалар һәм шуның нәтиҗәсендә кош йомыркасының кабыгы бик юка булып чыга, ә даими әйләндереп торганда алар ватылалар. Хәзерге вакытта дөньядагы ерткыч кошлар санының кимүе әнә шуның белән аңлатыла. Пестицид сөттә, майда, тәмәкедә, җиләк-җимештә, яшелчәләрдә һәм башка продуктларда да табыла.

Украина галимнәре (А. П. Федоренко, Л. С. Шевченко) үткәргән тикшеренүләр пестицидларның җенес органнарына тәэсир ясавын расладылар. Деллодринның хәтта аз гына дозасы да куяннарның спермотозоидларын үтерә. Пестицид тәэсирендә

[1] Pestis — латин сүзе — чума coedo — үтерәм.

ата женесендәгеләр күбрәк үлә. Ә аналарның, күрәсең, бала тудырганда пестицидларның бер өлеше кан белән бергә чыга. Зур шәһәрләрдә бала булдыруга сәләтсез ирләрнең күбәюе, мөгаен, шуның белән бәйледер. Бу бигрәк тә Парижда бик ачык сизелә. Аны пестицидлар булган яшел азыкны термик эшкәртелмәгән салат, шпинат, кәбестә һ. б. шундыйларны күп ашау белән бәйләнгән, дип исәплиләр. Организмда туплана барган агулар женси органнарның сәләтлелеген киметә.

Табигый тирәлекне саклау буенча Бөтендөнья «Expo-74» күргәзмәсендәге АКШ павильонында гаять зур бөҗәк эленеп тора, ә аның астына: «Пестицидларны озак куллану аркасында агулы химикатлар тәэсир итми торган (хәтта ун тапкыр артык дозада) бөҗәкләр барлыкка килде», дип язылган. Чыннан да, 1946 елны, пестицид промышленносте үсә башлаган гына вакытта, бары тик йорт чебене генә аңа каршы тора ала иде, ә 1960 елда инде алар 120, хәзер исә 1000 төр санала. Болар элекке елларда пестициддан агуланып һәлак булалар иде. Хәзер агулы химикатларны азык урынына кулланучы бөҗәкләр дә бар.

Бүгенге көндә әле аерым төр бөҗәкләргә генә тәэсир итүче пестицидлар юк. Кагыйдә буларак, алар, эшкәртелгән урыннардагы зарарлы бөҗәкләрне генә түгел, бәлки бал кортларын, кырмыскаларны һәм авыл хуҗалыгы культуралары өчен зарарлы булган бөҗәкләрнең күпләп үсүен тоткарлый торган ерткыч бөҗәкләр — инсектофогларны да үтерәләр. Хәзер кайбер басуларда ерткыч бөҗәк белән зарарлы бөҗәкләр чагыштырмасы бик нык аерыла. Чөнки җирне эшкәрткәннән соң үлән белән тукланучы бөҗәкләр бик тиз үрчиләр, ә ерткыч бөҗәкләр үрчү өчен берничә ел үтү һәм аерым уңай шартлар кирәк. Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, нинди нәтиҗә ясарга соң?

Хәзергә әле без пестицидларны кулланмый булдыра алмыйбыз, чөнки уңышның бик кискен кимүе мөмкин. Аерым урыннарда пестицидлар инде үзләре тарафыннан һәлак булган ерткыч бөҗәкләрне алыштырып, биологик роль уйный башлады. Ләкин агулы химикатларны куллану бик нык контроль астында булырга тиеш, пестицидлардан башка да югары уңыш алырга мөмкин булган урыннарда аларны кулланучы кешеләрне җавапка тартырга кирәк. Иң мөһиме: агулы химикатларны саклый белү. 1967 елда пестицидларны дөрес файдаланмау һәм ачык урыннарда саклау нәтиҗәсендә бер миллионнан артык терлекнең агуланган булуы билгеле. 1975 елның 7—8 январенда СССР Авыл хуҗалыгы министрлыгында үткәрелгән табигый тирәлекнең чисталыгын саклауга багышланган махсус киңәшмәдә химик средстволар белән артык мавыкмаска, аларны башка средстволар ярдәм итмәгән очракта гына кулланырга кирәклегенә басым ясап үтелде.

...Безнең илебез атом-төш коралын сынауны тыю инициаторы булды һәм бу өлкәдә җитди уңышларга иреште.

Биосфераның радиация фоны көчәю кеше өчен зур куркыныч тудыра. Нобель премиясе лауреаты, Калифорниядәге технология институты профессоры, СССР Фәннәр академиясе члены Лайнус Полинг 1960 елда «Сугышка юл куймаячакбыз» дигән китабын бастырып чыгарды. Анда ул кешелекнең киләчәктә яшәве өчен планетабызның радиация белән пычрануы никадәр куркыныч икәнен күрсәтеп бирә. Атом-төш индустриясенең үсеше һәм атом-төш энергетика станцияләре төзү җитди профилактик чаралар таләп итә. Якын елларда Америка Кушма Штатларында гына да 120 атом-төш энергетика станцияләре төзеләчәк һәм ул станцияләр чыгарган ташландыкларның биосфераны пычратуын һәм кешенең сәламәтлеген какшатуын булдырмас өчен барысын да эшләргә кирәк.

...Безнең планетабыз, мөгаен, Кояш системасындагы планеталар арасында иң күп сулы планетадыр. Җир шары өстенең 70,8 проценты су белән капланган һәм суның гомуми запасы 1 миллиард 345 миллион кубокилометр исәпләнә. Ләкин аның 97 проценты тозлы су, 2 процентына якыны Антарктида, Гренландия һәм Арктика бозларында тупланган; бары тик бер проценттан да кимрәге төче суга туры килә.

Әгәр иҗтимагый строй формалашкан вакытта кеше көненә 10 литр су тоткан булса, хәзер инде шәһәрләрдә һәр кешегә тәүлегенә 400—500 литр су планлаштырыла. Җир шары халкы тәүлеккә 7 миллиард тонна су тота. Промышленностьның суга булган ихтыяҗы бик нык үсте. Бер тонна корыч кою өчен, мәсәлән, 250 тонна, бер тонна кәгазь эшләү өчен 200 тонна су кирәк. Безнең республикада нефть чыгару промышленносте һәм сугарулы җирләр гаять зур күләмдә су таләп итәләр. 1961 елда сугарулы җирләр дөнья күләмендә 100 миллион гектар, ә СССРда 9 миллион гектар тәшкил итте. Ә хәзер бу сан икеләтә диярлек артты. Төче суны шул кадәр күп куллануга карамастан, без аны саклауга салкын карыйбыз, аны бик нык пычратабыз. Чистартылмаган тормыш-көнкүреш сулары, завод һәм фабрика ташландыклары һаман да әле безнең елгаларыбызга һәм күлләребезгә ага. Бер кубометр чистартылмаган су 60 кубометрдан артык табигый суны пычрата. Без күлләрне, буаларны һәм сазлыкларны начар саклыйбыз. СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы биология институтының зоология лабораториясе 5 ел дәвамында республикабыздагы 2400 күл һәм буаларның торышын тикшерде һәм аларның һәрберсенә паспорт төзеде. 10 елдан соң кабат тикшерү вакытында күп кенә сулыкларның бөтенләй яшәүдән туктавы, кайберләренең шактый кибүе беленде. Күлләрне һәм сулыкларны югалту — ул җир асты суларының кимүенә китерә, микроклиматны үзгәртә, табигать күркәмлеген җуя.

Америка белгече Д. Бэрд (1915), пычрак суларны чистарту өчен 40 миллиард доллар кирәк, ә хәзергә бары тик 750 млн. гына тотыла, дип яза. Әгәр киләчәктә дә шулай барса, «безне үз пычрагыбыз буачак», ди ул.

Планетабыз суын саклау бурычлары нәрсәдән гыйбарәт соң? Иң элек без шуны аңларга тиешбез: «су кебек кыйммәтле казылма байлык юк» (Академик А. П. Карпинский). Шуның өстенә ул су төче һәм чиста булырга тиеш. Шулай итеп, иң беренче бурыч — суны сак тоту һәм аның пычрануына юл куймау. Промышленностьта су куллануны киметергә, ягъни бер кулланган суны яңадан куллану ысулын кертергә һәм җирне сугарган вакытта суны әрәм-шәрәм итүгә юл куймаска кирәк. Чөнки андый вакытта без үсемлекләргә зарар гына китерәбез һәм суны файдасызга түгәбез. Ябык сулыкларның һәрберсенә кайгыртучан хуҗа булдырырга кирәк. АКШта эшкәртергә җайсыз, ләкин ясалма сулыклар булдырырга мөмкин булган җирләрнең бәяләре бик нык үсә бара. Чөнки аны комплекслы файдаланган вакытта — су үсемлекләре, ике-өч төрдәге балык, үрдәкләр, ондатра, су күсесе үрчеткәндә — аннан иң югары агротехника кулланып эшкәртелгән кара туфраклы җир дә бирә алмаган табыш алырга мөмкин. Сулыкларны комплекслы файдалану методын бәлки безгә дә кертергә кирәктер.

...Туфрак җил китергән тау токымнары кисәкчәләрендә микроорганизмнар үрчүдән барлыкка килә башлый. Алар токым кисәкчәләренең ишәюенә, ваклануына ярдәм итәләр һәм аны үз эшчәнлекләре продуктлары белән туътыралар. Буын артыннан буын үсә барган саен, аның күләмен арттыра баралар. Аннан соң инде, әзер хәлгә килгән бу тирәлектә туфрак барлыкка килү процессын тизләтә торган югары төзелештәге үсемлекләр һәм хайваннар урнаша башлый (Парсен, 1969). Шуны да әйтергә кирәк, уңдырышлы катлам бик озак формалаша. Әйтик, бер сантиметр калынлыгындагы туфрак барлыкка килсен өчен, яхшы үсеш алган үсемлекләр булганда да 100 елдан алып 400 елга кадәр вакыт кирәк. Сөзәклек буйлап сукалаганда һәм аннан соңгы каты яңгырлар нәтиҗәсендә бу катламның берничә минут эчендә юкка чыгуы мөмкин. Француз галиме А. Геррэнның исәпләүләре буенча, җир шарында 2 миллиард гектар, ә СССРның Европа өлешендә генә 50 миллион гектарга якын җир эрозиягә дучар булган.

Безнең илебездә туфракны саклауга зур игътибар бирелә. РСФСР табигатен саклау буенча законда (1960 ел) туфракны саклауга зур бүлек багышланган. 1967 елның 20 мартында КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советы «Туфракны җил һәм су эрозиясеннән саклау буенча кичектергесез чаралар турында» карар кабул итте. 1968 елны СССР Верховный Советы тарафыннан җир законнары нигезе билге-

ләнде. Хәзер күпчелек совхозларның һәм колхозларның туфракны эрозиядән саклау буенча планнары бар.

Әгәр дә туфракны сакламасаң, карамасаң һәм ашламасаң, аны бик тиз югалтырга мөмкин. Эрозия ел саен үсемлекләрнең 92 миллиард тонна төп азык элементларын — фосфор, калий, азот, кальций һәм магнийны алып китә. Шуның өстенә соңгы 50 ел эчендә тузан өермәсе яки «кара давыл» очраклары 5—6 тапкыр артты. 1959 елны илебезнең көньяк районнарында, бигрәк тә Запорожьеда секундына 28 метр тизлек белән тузанлы өермә үтеп китте һәм ул урыны-урыны белән 70 процентка кадәр уҗым культураларын һәлак итте, ә җил аз үтә торган кыр саклагыч урман полосалары янында 2 метр биеклеккә кадәр туфрак өелде (Жеребцов, 1961).

Безнең илебездә туфракны саклау бурычлары нәрсәдән гыйбарәт соң? Иң беренче чиратта, кешене туендыручы җир белән бик сак эш итү, дияр идем мин. Җирне даими рәвештә карап тору, минераль ашламалар гына түгел, бәлки органик ашламалар, ягъни азык матдәләренең барлык комплексын кертү юлы белән аның уңдырышлылыгын күтәрү. Тәҗрибә участогындагы күзәтүләр берничә ел рәттән бары тик минераль ашламалар гына кертелгән туфракның ярлылануын күрсәтте. Бактерияләр массасының авырлыгы туфракның гомуми авырлыгының 0,3 процентын тәшкил итә һәм бер гектарга 5 тоннага кадәр җитә (Мишустин, 1959). Эрозиягә каршы эшләрнең барлык комплексын тайпылышсыз үтәү безнең илебездәге җирдән файдаланучы барлык кешеләр өчен закон булырга тиеш. Соңгы сүз итеп тагын шуны әйтәсе килә: безнең илебездә чокырлар һәм ерганаклар авыл хуҗалыгыннан һәр ел саен 50 мең гектар җирне тартып алалар (Армаид, 1964). Шуның өстенә һәр чокырның ике ягында да 300 метрга кадәр урында җир асты сулары кими, ә ул исә уңышның кимүенә китерә. Шуның өчен чокырлар барлыкка килү һәм аларның киңәюләре белән көрәшү — илебездәге туфрак катламын саклау буенча иң мөһим бурычларның берсе.

Е. АНТОНОВА тәрҗемәсе.

## Эдуард Касыймов

# «ТЫН ТАУЛАР» ИТӘГЕНДӘ...

«Тын таулар» пристане, причаллар... Ләкин «тын»мы алар җәйләрен?

Эссе. Текә тау кашында бигрәк тә...

Түбәндә су читендә бала-чага чапыр-чопыр килә. Үзләре чуен төсенә кереп беткән инде. Җилнең әсәре дә юк диярлек. Әмма вак ташлы ярга әледән-әле шаян дулкыннар килеп бәрелә. Азмыни хәзер елга битенә буразналар салучы юан бүксәле баржалар, аккоштай ыспай шуучы олы теплоходлар һәм җилдәй җитез «ракета»лар, «метеор»лар? Катер, моторлы көймә ишесе тагы...

Җелекләрне киптерердәй дәрәҗәдә кызган һавадан йомшак дулкыннар кочагына чумып колач сала-сала йөзүе яки чалкан әйләнгән көенчә, суның назлы иркәләвен тоеп ятуы, ай-һай, рәхәт тә соң!

Ә Кама ярыйсы ук саеккан. Әнә бит каршыдагы утраучык җәй башында тал бөдрәләренә күмелеп, ничек купшы һәм җыйнак булып утырган иде, ә хәзер соргылт ком аны чамасыз шәрәләндергән. Сул тарафтагы елга уентыгына керергә ниятләгән катерлар, аерата үзйөрешле баржалар, әлеге күгәргән хәнҗәрдәй сайлыкны әллә каян әйләнеп, бик тә абайлап үтә, култыкка җай белеп, ашыкмыйча гына керә.

Якында гына водозабор. Бетоннан коеп эшләнгән гигант бокал! Язгы ташу вакытында ул, бил тиңентен суга чумып, кинәнеп утырган иде. Ә хәзер, елга аңардан шактый ук читенгәч, ул, эссе кояш нурларында коргаксый язып, су кырында суга сусап калган сыман. Ләкин бу — алдану гына. Чынлыкта бетон «бокал» төбе яр астына әллә кая ук төшеп утырган да анда тирәндә эчкәрегә сузылган юан торбасы аша Кама суын төптән суырыпмы-суыра. Көне-төне...

Рәшә, кургаш тузанындай, соры һәм авыр. Ни таралмый, ни сеңми...

Бүтән чакта, шушындый чалт аяз күкле көннәрдә, текә яр кашыннан күз салсаң, каршыңда Кама буе үзенең бар киңлекләрендә һәм чиксез гүзәллегендә күңелне иләсләндереп, ярылып ятар иде. Ә бүген юк. Бүген күп нәрсә томаланган, югалган, ярлыланган. Соры тузанны кемнең матур дигәне бар? Җир туфрагы һәм аны капла-

---

«Кама офыклары» циклыннан.

ган яшеллек дөньясы гына түгел, һава булып һава дымга, яңгырга сусаган. Ул да тазару һәм сафлануга әллә кайчаннан бирле тилмерә.

Ә Кама барыбер гүзәл!

Мәһабәт елга әллә каян, соры томаннарга төренгән ерак урман якларыннан дугайланып, нечкәреп чыга да якынайган саен киңәя һәм яктыра килеп, «Тын таулар»га төртелгәч, ярыйсы ук текә борылыш ясый һәм, ташлы яр итәгенә сыена-сырпалана, барасы юлында ары таба талгын гына ага бирә. «Хафаланмагыз, мин бар бит әле! Табигать көчле әле, ул янә сафланыр, яшәрер, сез туйганчы кинәнерсез әле!» — дигәндәй, көләч нурларда балкый-балкый, күзнең явын алып һәм җаныңа рух өреп китә...

Әйе, матур да, шәфкатьле дә, шифалы да ул безнең Кама! Юмарт та!..

«Кара алтын» дибез, «заманның бәһасез нәрсәсе» дибез. Аны тирәннән, җирнең тыгыз һәм каты куеныннан кысып чыгару өчен иң әүвәл ни хаҗәт? Иртәгә ничек булыр, бүген әйтәләр әнә: «Бер өлешкә ике өлеш су кирәк», диләр. Зур басым астында каты токымнарга йомшак су... Ләкин бер дә бер көнне катламнарга су кудыру тукталды, ди. Ул чагында ничек?

— Андый сорауны без геологларга биреп караган идек, — дип сөйләде миңа бермәлне нефтьчеләрнең су чистарту корылмаларында смена башлыгы булып эшләүче Мөдәррис Мөлеков. — Юри генә сорадык.

— Соң?

— Идарәнең баш геологы Лидия Ивановна Зайцева әйтте безгә: «Әгәренки, диде, су кудыру тукталса, ике-өч көннән үк нефть чыгару дүрт-биш мәртәбә кимиячәк», диде. Шулай, туган...

Хикмәтле дә, үтә җаваплы да хезмәт.

Кама буе нефть һәм газ чыгару идарәсе әллә ни зурлардан түгел. Алай да ул ел тәүлегендә җир куенына ун миллион кубометрдан артык су кудырырга тиеш икән ләбаса!

Чаллы турысында нефтьчеләрнең янә бер водозаборы утыра. Анысының куәте чагыштыргысыз зур. Татарстанның төп нефть районнарына кудыра ул суны. Дистәләрчә миллион тонна нефть алу өчен, җәһәннәм тирәнлекләрендәге катламнарга никадәр су сеңдерергә кирәклеген күз алдыгызга китерәсезме? Шулай, җир астына кысылып керә, анда мәңгегә югалып кала, ә якты дөньяга исә безнең өчен ифрат кадерле булган «кара алтын» кыяфәтендә чыга... Елгадан бер нефтьчеләр генәме бу тикле мул файдалана?

Кама үзенең йомшак һәм талгын агышында, инде канатларын киң җәеп, тиз арада үсеп китәчәк индустриаль төбәк аша уза. Красный Ключ янындагы ярдан аны бик рәхәтләнеп һәм туя белмичә Түбән Кама химкомбинаты имеп ята, ә югарыда, әнә соры рәшәгә күмелгән урманлы борылыш артында, Белоус авылы тирәсендәрәк, янә бер водозабор салынып бетеп килә. Анысы КамАЗ һәм Яңа кала өчен, анысының куәте тагы да иләмсезрәк булачак, ди. Ул гынамы? Шушында Менделеевск каласы янында яңа бишьеллыкта янә зур химкомбинат кору эшләре җәелачәк. Ул да бинибая күләмдә суга мохтаҗ булмас, дисезме? Димәк, тагын бер водозабор.

Гигант төзелешләр. Һәркайсының кендеге Камага тоташа. Нибары җитмеш-сиксән чакрымлык арада елганы никадәр күп имү!

Әйе, Кама чиксез юмарт ул. Тик кадерен генә бел!..

«Тын таулар» кашында басып торган чагымда, әнә нindirәк уйлар айкап узды минем күңелне...

Бетон «бокал». Арада иң бәләкәе. Еректан караганда ул тын гына йокымсырап утыра кебек...

Ләкин шул минутларда югарыдан аңа төбәлгән җирендә, күңелемне янә бер хәл кытыклап торды минем. Хәер, соңгы вакытларда елганың кай төшенә барып чыксам да, хәтер сандыгыннан шундук өскә калкып чыга ул. Кызыклы да, гыйбрәтле дә вакыйга.

Әмма аның нефтьчеләргә дә, зур төзелешләргә дә бәйләнышы юк югын. Ул язга бәйле, Камага бәйле һәм беркадәре шушы «Тын таулар» төбендә туңкаеп утырган водозаборга бәйле.

Легендага тартым. Ләкин чын хәл.

Күз алдыма машинист Илья Бурмистровның чандыр шәүләсе килеп баса, колагымда аның сокланып та, хафаланып та сөйләве янә ишетелгәндәй була...

Каманың күбенгән чагы иде. Икенчеме, өченчеме көн тоташтан боз китә. Шыңгырдап, шаулап!

Көн болытлы, һава дымсу: ул җиңелчә томан белән өртелгән. Эре һәм вак боз кисәкләре куәтле агымда әнә шул сыек томан астыннан шуышып киләләр дә бер-берсенә бәрелә-ышкыла, уала-җимерелә агып үтәләр. Табигатьнең хәйран күренеше!

Без машинист Илья Бурмистров белән водозаборның өске мәйданчыгында басып торабыз. Ул калын гына сырмадан. Аңа җылы, рәхәт. Ә минем өстә юкарак. Ләкин шушындый хозурлыкны манзара кылганда, гәүдәңә салкын йөгергәнлеген тоясыңмыни!

Бурмистровның хәл-әхвәле хакында үземә кирәк хәтлесен сорашкан идем инде мин. Водозаборда инде биш ел, ягъни корылма ходка җибәрелгәннән бирле эшли икән. Аңарчы Бондюг химия заводында паровоз да йөрткән, аннары байтак вакыт котельныйда тир түккән. «Тегендә ярыйсы ук саулык какшаган иде. Хәзер, күрәсез, гелән дә саф һавада, табигать кочагында бит без!» — диебрәк сөйләнде ул.

Күзләр — елгада... Мине хәйран аптыраштa калдырганы шул булды: елга уртасы буйлап сузылган киң һәм чуар тасма эчендә боз кисәкләре генә түгел, төбе-тамыры белән куптарылган тал куаклары да ага иде. Бер тоташ әрәмәлек ниндидер тылсым көче белән үз урыныннан купкан да елга буйлап ил гизәргә чыккан шикелле тоела... Бу ни гаҗәп бу?

— Үткән көздән үк Камада су бик мул калды, уйсу төшләр күмелгән иде. Кышын да әллә ни кимемәде, — дип төшендерергә керешә Бурмистров. — Ә язын аңлашыла инде: боз үзе белән бергә тал-куакларны да куптарган... Нихәтле чүп-чар ага, ә? Тегендә, Куйбышев сусаклагычында изаланырлар инде.

— Минем мондыйны беренче күрүем.

— Минем дә... Кама буенда ни гомер яшим, юкса... Әмма хикмәтнең дә хикмәте кичә булды, кичә... — Бу мизгелдә Илья Константиновичның какча йөзе җанлана төште, күзләрендә очкын елтырады. — Бер бозда өч поши йөзеп килде!..

— Нәрсә-ә-әү? Пошилар! Булмаганны...

— Чәчерәп китим! Дежурда идем мин, үз күзләрем белән күреп тордым... Менә бу төшләрдә хәзер боз юк инде, чистарган, ә кичә монда боз дуамал тыгылган иде. Әнә бит ярга да нихәтле өеп куйган. — Бурмистров кулын киң ишарәләп, сул тарафка таба күрсәтте. Чынлап та култык ягында су өсте инде боздан тазартылган, анда тик төрле чүп-чар гына йөзеп йөри иде. Әмма, аның каравы, кичәге илаһи куәтнең шаһиты сыман, текә яр буе өем-өем калын боз кисәкләре белән тулган, шунда малай-шалай ут ягып азаплана, чыр-чу килә иде. Ир-ат та бар. Кайсы көймәсен сумалалый, кайсы болай гына, эч пошканнан гына төшкән, ягъни боз карарга...— Ә көн шушылай ук аз гына томанлы, пыскакларга җыена иде. Бер заман, ни

ишетик, малай-шалай акырырга ябышты. «Карагыз, кара, бозда пошилар!» — дип шар яралар. Ни күрик, чын бит. Бер бозда пошилар. Өчәү! Болай таба агып киләләр. Якын инде. Ә бозы әллә ни зур да түгел. Төшемме-өнемме, дим... Исләребез китте! Бозлары мондагы тыгылмага килеп төртелгәч, тукталып калды, кысылды. Үзләре шундый чибәр — сурәттәге кебек. Берсе калын мөгезле, икесе мүкләк. Болары ана белән тана булды, ахры.

— Гаҗәп шул. Бозга кайда, ничек эләктеләр икән?

— Үзебез дә аптырашта калдык. Гомердә дә күрмәгән, ишетмәгән хәл бит. Шул чак ярдагы мужиклардан берәү үзенчә аңлатып маташты. «Без, ди, елга буйлап югарыга балыкка йөргәндә, иртәләрен аларга юлыккалый идек. Бозда кунып яткан җирләреннән куз-галып китә иделәр, ди. Кайчагында үзләре күренми, аунаган эзләре генә кала. Ә ни өчен алар төннәрен бозда аунап үткәрергә яраткандыр — анысын кем белсен. Бу юлы, бәлкем, алар елганы кичәргә уйлаганнардыр?.. Шулай баш ватып торганда, ни күрик, арадан бер малай, бер башкисәр, бозга кереп бара. Әлеге хәтәр тыгылмага. Кулында озын гына таяк. Үзе сырмадан, резин итектән. «Тын таулар» малае. Боз шатыр-шотыр килә, су кайный. Хәтәрнең дә хәтәре инде. Без кычкырабыз: «Кая керәсең, тукта, акайган!» — дибез. Тыңламый. Боздан бозга сикерә бирә. Уйламый да... Янәсе, тегеләрне коткармакчы, ярга куып чыгармакчы. Әмма ничек коткарасың аларны? Аңлыймыни ул синең изге нияттә икәнеңне? Изге ният дигәннән, арада бер мужик этәчләнә башлады: «Их, ди, атарга рөхсәт ителсәме? — ди.— Минутында өйдән мылтык белән озынрак аркан алып килер идем. Нихәтле ит әрәм була», ди... Ну, ул хирес җанның авызын шундук томаладык без.

— Канга сусаган бәндә икән... Ә малай нишләде?

— Барып җитә язды бит тәки. Таягы белән селтәнә, сызгыранитә. Без инде хәзер кычкырмыйбыз. Тындык. Ни буласын көтәбез. Ата поши малайны якын җибәрергә теләми, пошкыра, тибәргә чамалап, арты белән борылды... Хәйран да хәл инде! Әмма ул әллә ни озакка бармады: кинәт бөтен тыгылма хәрәкәткә килде. Зуррак боз кисәге килеп төртелдеме-ниме шунда...

— Ә малай, малай! — Минем тәнне салкын дулкын кымырҗытып узды, үз тавышымны үзем ишетмәдем дә бугай.

— Нишләсен? Әпен-төпен кире чыга башлады. Бермәлне ычкынып китеп, күкрәк тиңентен боз арасына суга төшеп китте... Әмма бәхете бар икән — бирешмәде. Ул арада монда яр читендә халык, аңа ярдәм кулы сузмакчы булып, ыгы-зыгы килә башлаган иде инде. Әмма ярга ул үзе чыкты. Күз төпләре мөлдер-мөлдер яшь...

— Курыккандыр инде.

— Куркудан бигрәк, әрнүдәндер. Ярга куып чыгара алмады бит, ярдәме тимәде. Үзе уңлы-суллы төкеренеп, сукрануын белә: «Их, харап булалар бит инде!» — ди...

Хәтеремдә, шул минутта минем күз алдымда ике адәм шәүләсе пәйда булды: берсе, олысы, тазасы һәм кансызы. «Нихәтле ит әрәмгә китә. Их, атарга иде!» — дип теш шыгырдатып тора, икенчесе, бик бәләкәе, җан аямыйча, куркыныч бозлар арасына ташлана, ахырда, пошиларны бәладән йолып алырга көченнән килмәгәч, кайнар күз яшьләренә буыла... Бу күренеш әле дә минем күз алдымнан китми...

— Ә пошилар?

— Семья башлыгы, мөгезлесе, ары каранды, бире каранды да бер заман — лыбырт!—суга ташланды. Боз араларында ачыклыклар күреп алды, ахры. Аннары аның күңелен әнә теге өянкеләр дә тартты бугай. — Мин Бурмистров күрсәткән якка күз салдым. Сул тарафта, елга култыгыннан өскә табарак, әллә ни ерак түгел, өлешчә суга ке-

реп, өлешчә тар гына коры җирдә карт өянкеләр тезелешеп утыра иде. Бәләкәй генә утрау. — Һай, көч-куәт тә үзендә! Бозлар арасында шундый каты агымны кистереп, ярып бара. Үзе йөзә, үзе әледән-әле болай таба башын борып карый. Тегеләр ярдеме-юкмы, ди бугай... Тәки йөзеп чыкты ул карт өянкеләр янына, коры җиргә... Бирешмәде!

— Ә болары, ана белән тана, ярмәдеме?

— Ярмәде. Анасы, бәлкем, суга сикерер дә иде, бер ымсынып та караган иде. Әмма яшь тананы жәлләде, ахры. Шул көе, бозда калтыранып торган килеш, агып киттеләр. Көн кичкә таба авышкан иде инде, җитмәсә, томан да иде... — Илья Константиновичның тавышы кисәк тынып куйды, аңа аермачык кызгану төсмере керде. — Шул томан эчендә күздән югалдылар. Ә семья башлыгы, мөгезлесе, карт өянкеләр төбендә, коеп куйган шикелле кузгалмыйча, карап калды. Бик-бик озак басып торды ул анда.

— Ана белән тана котыла алмады микәнни, бичаракайлар?

— Белмим. Күрүче булдымы икән? Малай-шалай яр буйлап аларны озата бармакчы иде, без: «Өркетеп йөрмәгез!» — дип тыйдык аларны. Түбәндәрәк Богатый Лог тирәсендә яр бераз сөзәкләнә төшә, бәлкем чыга алганнардыр? Ә бәлкем... Каманың котырган чагы шул, шашкан чагы...

Бурмистровның сөйләгәннәре тетрәндерде мине...

Елга язмышында мондый драманың берәр кайчан «төенләнгәне» булдымы икән? Киләчәктә кабатлануы ихтималмы? Икеле...

Арыслан йөрәкле батыр малай кем булды икән? Ә теге бәндә, канга сусаганы? «Тын таулар» поселогында яшәүчеләр, әлбәттә, аларны белеп торганнардыр.

Әйе, бу чын-чынлап булган хәл, һәм ул бер дә әллә кайда түгел, химиклар шәһәре Менделеевскиның елга капкасы исәпләнгән «Тын таулар» пристане янында, тагы да киңәйтә төшеп аңлатсам, Чаллыда автозаводчылар өчен салынып яткан Яңа кала турысыннан Кама буйлап өскә таба нибары ун-унике чакрымнарда булган...

Байтак вакытлар авыр, чишелмәс табышмак булып, бу минем җанны кимереп торды.

Ә бер көнне караңгылыкны якты нур ярып узды.

Җәй уртасы иде. Һава галәмәт эссе. Авыр йөк машинасында Чаллыдан Алабугага барам. Кузовына кызыл кирпеч төягән «КрАЗ» Олы урманны ярып узган тигез асфальттан ыжгырта гына. Кабинаның ачык тәрәзәсеннән тыгыз җил бәрә. Рәхәт!

Шулай, гөжләтеп кайтып килгән чагыбызда, сул кулда зур гына алан күренде. Уртада көмеш төсендәге скважина җиһазлары, читтәрәк газ факелы дөрли, тагын да кырыйдарак, наратлар күләгәсендә, алар! Икесе дә мүкләк. Ана белән тана!..

Йөрәгем шундук атлыгып тибә башлады. Шофер, КамАЗ егете, машинаны туктатты. Дәшми-тынмый гына беравык күзәтеп тордык.

Пошилар безне исләренә дә алмады. Ахырда, болай таба бер генә күз аттылар да ашыкмыйча гына агачлар ешлыгына кереп киттеләр. Урман артында якында гына борыла-сырыла салкын сулы Тойма агып ята. Мондый кызу көнне, мөгаен, алар да сусагандыр...

Юлдашым-шофер:

— Чибәрләр... Гаҗәп! — дип куйды, сокланып.

Ә мин аңа язның тымызык бер көнендә «Тын таулар» турысында Камадагы хәтәр драма хакында шундук сөйләп бирә дә алмадым... Әлбәттә, шулардыр... Исәннәр!

...Бу сөенечне минем йомшак җанлы машинист Илья Константинович Бурмистровка да җиткерәсем килде. Куандырмакчы булдым.

Теге чакны ул да авыр пошаманга бирелгән иде бит. Тик аны водозаборда туры китерә алмадым: ялда икән. Ләкин аптырамыйм: исән булсак, бер күрешербез әле.

«Ә семья башлыгы ата поши белән ничек соң?» — дисез инде сез. Берни дә әйтә алмыйм.

Янә кавышмаганнар, күрәсең. Ә бәлкем ул, мөгезле пәһлеван, үзенә яңа пар тапкандыр? Яңа семья корырга йөри торгандыр, мотлак?

Әмма табышмакның матуры инде бу. Минем күңел аның җавабын эзләми дә...

## ДАНЛЫ ДА, ХИКМӘТЛЕ ДӘ...

Көтә торгач, ниһаять: «Һава ачылды»,— диделәр. Безнең вертолет, җирдән үтә кыюсыз һәм бик тә авыр кузгалып, күккә дөбер-шатыр күтәрелә башлады.

Алабуга нефтьчеләренең Кама аръягына гадәти вахтага барышы... Монтажчылар, электриклар...

— Менә шулай! Җәһәтрәк... Их, куәт тә соң үзендә! — дип кычкырды киң битле бер монтажчы. Утырган җирендә кыбырсынып алгач, ул тагы нидер әйтте, әмма безнең барыбер юньләп ишетмәвебезне шәйләп, таушалып беткән кепкасын зур кулына кыскан көйгә тынып калды. Шундый каты гөрелте — кая монда сиңа сөйләшеп барулар! Бөтен вахта диярлек иллюминаторларга сылана.

Түбәндә — Алабуга. Тау кашында, «Шайтаннар каласы»ның җансыз шаһиты һәм ядькаре булып, юантык һәм базык гәүдәле борынгы манара утыра. Аның артында Каманың зәңгәр тасмасы... Сөзәк үр битенә дә, өстәге киң тигезлеккә дә — төрлечә буташтырып салынган, бүгенге заманның икешәр-дүртәр катлы ак һәм соры чырайлы игезәк йортлары. Бер кырыйда, кызгылт чокырлар һәм яшеллеккә төренә башлаган бакчалар тирәсендә, телевизион ретранслятор озын мөгезен күккә таба төбәгән. Аны гап-гади буровой вышкасын үстереп, шактый биегәйтеп күтәрделәр. Берничә ел элгәре алабугалылар өчен бик тә хаҗәт нәрсә иде. Ә хәзер инде бу биек вышка Кама елгачылары тарафыннан радиорелейный элемтә өчен файдаланыла. Галәмәт зур уйсу төшкә шәһәрнең иске өлеше сыенган. Бай сәүдәгәрләрдән калган чиркәү манаралары, биек ябалдашлы карт агачлар... Әнә шулар арасында, каланың болын ягына караган иң кырый урамында, ике катлы җыйнак кына бер йортта бөек рәссам Иван Шишкин дөньяга килгән. Анда музей-йорт, аңа эзләр суынмый... Бу мәшһүр йорттан әллә ни ерак та түгел, үз гомерләрендә бик күпне күргән тупыл һәм юкә агачлары астында, шәһәр бакчасының сүнмәс нуры булып, атаклы кавалерист-кыз һәм язучы ханым Надежда Дурова һәйкәле уйга талган... Борынгы таш кала бар булган хәзинәсе белән безнең аста артка, сыек рәшә эченә таба акрын гына шуыша бара. Менә инде шәһәр читендәге үр өстендә утырган дүрткел зират урманы да талгын гына йөзеп үтте...

Җәй башы. Җир ала-кола әле. Урыны белән ул көйгән сыман. Бетмәс чокырлар, тирән ерганаклар. Аларның һәммәсе диярлек кырлы-сырлы рәвештәрәк куе-яшел нарат урманнары белән әйләндереп алынган. Тегендә дә, монда да төрле зурлыктагы күлләвекләр елтырый.

Ачык басу битләрен шифалы яңгырлар юып үткәч, дөнья бөтенләй яшәреп, сафланып киткән. Уҗымнар хәтфәдәй. Иген кырлары, күзгә рәхәт яшел төсләрен җуя барып һәм күгелҗемләнеп, ерак офык артына китеп югала.

Минем белән янәшәдә утырган Илдар Бакинский, кара кашларын биеткәләп, колагыма кычкыра:

— Карап туймаслык күренеш бит, ә! Яратам җәй башларын!..

— Әйе, искитмәле! — дип куәтлим мин.

Илдар — участок башлыгы. Кама аръягында Кызыл тау тирәләренә сибелгән дистәләрчә скважиналарга ул хуҗа. Мин аны күптәннән беләм. Төптән уйлап, һәр нәрсәне җиренә җиткереп эшләргә ярата торган тырыш һәм булдыклы белгеч. Өстәвенә, табигать матурлыгына һәрчак гашыйк...

Безнең күзләр янә җир өстен кармалый.

Аста Кече урман. Югарыдан караганда, ул бөтенләй сыек. Бөек пейзажист Шишкинның: «Алабуга тирәсендәге изге чишмә» дигән мәшһүр сурәтен хәтерлисезме икән? Шушында ул...

Соры асфальт тасма Кече урманның куе яшь наратлар баскан итәгенә җиңелчә орынып ала да, аны дугайлап узгач, тураеп, сөзәк үр буйлата түбәнгә сузылып китә. Асфальт юлдан әллә ни кызуламыйча гына автомобильләр чаба. Юл шома, әйбәт, әмма ул күз явын үзенә әллә ни тарта алмый.

Караш үзеннән-үзе еракларга — Кама аръягына юнәлә. Анда, дымсу зәңгәрлектә күк белән җир тоташкан төштә, беленер-беленмәс кенә Афанасово урманы карасулана. Без һәммәбез дә, әлбәттә, данлы шедевр «Кораб урманы»н («Корабельная роща») яхшы беләбез. Хәзер анда ул мәһабәт һәм горур баһадир-наратларның энеләре һәм уллары мәңге тынмас хафада бимазаланып шаулаша... Офык буйлап болай табарак яшьлек каласы Түбән Каманың соры йортлары шәйләнә, ә тагын да якынрак галәмәт зур мәйданда, катнаш урманлык әчләрендә Европа гиганты — химкомбинат колач җәеп һәм куәт җыеп ята.

Безнең аста Олы урман үзе. Аның кулшы итәген бу почмакта бөдрә таллар арасыннан бормаланып агучы Тойма елгасы юып үтә.

Урманнар, куе әрәмәләр, хәтфә тугайлар, көзгедәй күлләр... Табигатьнең искитмәле хозурлыгы! Ул моннан бер ярым гасыр әүвәл дөньяга чиксез зур талант тудырган, аны үзенә каратып, аңарда сүрелмәс мәхәббәт тәрбияләгән, һәм ул егет тора-бара бөек рәссам булып җитлеккән. Ләкин әлеге егет — урман баһадиры үзе дә бурычлы булып калмаган: үзенең полотноларында туган табигатен еш сурәтләгән, аңа җан өреп, мәңгелек тормыш биргән. Кем белми һәм сокланмый аларга дөньяда? Шулай, бөек рәссамның мәхәббәте мондагы табигатьнең үзен дә данлы да, хәтта бөек тә иткән...

Ләкин агымсу ага, вакытлар үтә. Һәм табигать үз язмышында инде бүтән әйләнмәстәй, кабатланмастай үзгәрешләр китергән заманнар кичерә. Юк, монда усал һәм кансыз кизәнеп, аның тамырына балта чабарга күтәрелгән кулда гына түгел хикмәт.

Теге заманда хәтта даһи җан булып даһи җан үзенең туган ягында, җир куенында, бик тә тирәндә чиксез хәзинә ятканлыгын абайлагандыр, дисезме? Янә йөз ел үткәч, әлеге серле хәзинәләргә юл ярырдай, агымсуларны туктатырдай, Кама тикле Каманы буардай искиткеч кодрәт-көч туасын күз алдына китерә алгандырмы? Әйе, бүгенге прогресс, чигенү белмичә, кискен төстә: «Кирәк, туганнар, әйдә, кызулыйк!» — ди.

Ә ул сихерле талант иясе мондый көннәр киләсен, мөгаен, уена да китермәгәндер. Юкса, кайбер артык кызу канлы оныкларының

гайрәтен кимету җәһәтеннән алдан ук ачулы һәм усал иттереп бармак янап куйган булыр иде...

Һәм барыннан да бигрәк зур газаплар гүзәл Олы урманга эләккәндер кебек тоела миңа. Хәер, андый хәлләргә чын-чынлап «бөек» булганнар ешрак дучар итеlә: галәмәт зур урман аркылыга да, буйга да асфальт юллар белән кискәләнгән, нефть үткәрүче трассалар үткән, югарыдан аны сансыз электр линияләре камчылый, һәм тегендә дә, монда да — нефть скважиналары һәм җиһазлары өчен бүленеп алынган, актарылып, туздырып ташланган аланчыклар. Боларның байтагында — газ факеллары туктаусыз биеп, җенләнеп торган ут көлтәләре. Дөрес, соңгы вакытларда әлеге «утлы җеннәрне» акрынлап авызлыклый барып, кирәкле һәм тиешле җирләрдә биергә мәҗбүр итәләр. Ләкин шулай да Олы урман өсләреннән төнге рейс белән — әйтик, Казаннан Чаллыга — очарга туры килгән чагында, күз алдында шактый ук дәһшәтле манзара туа: түбәндә, төн караңгысын ярган зур утлар-учаклар әйләнәсендә, галәмәт дәү лагерь корып, бихисап яу-баскын хәл җыярга тукталган сыман... Тарихта моннан ике гасыр элгәре җир йөзенең шушы бәләкәй генә гүзәл төбәгендә, дөрес, Кече урман тирәсендә, шуңа охшашлырак хәл чыннан да булган: Емельян Пугачевның җитез һәм чая полклары, Алабуга каласын хәйлә белән алып, аның соңында Казан юнәлешенә лава ташкыныдай агылыр алдыннан, урман ышыкларында һәм тын тугайларда зур табор корып, сансыз учаклар ягып яткан. Әмма бу хәл илнең социаль тарихында мәңге онытылмаслык эз калдырса да, табигать язмышында аңа һичнинди зыян китермәгән бер мизгел генә...

Янә дә ГЭС. Плотинаның биек күтәртелеп, ком белән тыгыз түшәлгән бер җилкәсе урман эченә умырып кергән. Шушында ук хәйран киңлектә Олы урманның төптән һәм бетереп киселгән итәге — киләчәктә су басасы җирләр. Бу нәкъ Чаллы турысында, каршыда...

Әнә шулай читләреннән каты кысрыкланып, урталыкта гәүдәсен авыр җәрәхәтләрдә умырттырган хәтфә урман чынлыкта шауламый да кебек, ул яман сызланулардан ухылдый, ыңгыраша сыман. Җиргә күмелгән бихисап тимер торба-тамырлардан бәлки урманның үз каны да агадыр, ә берөзлексез фырылдаган «җенле» факеллар төсендә кайнар күкрәкнең утлы сулышы ургыладыр шикелле...

Укучы күз алдында куркынычрак манзара тудырылды бугай. Ләкин, нишләмәк кирәк соң, чын дөреслек ич бу.

Мин вертолетта бергә барган юлдашларыма күз салам: йөзләре караңгы, кырыс, иреннәр кысылган... Әлбәттә, Олы урман күренешеннән аларның да җаннары әрни. Бәлкем беришесе үзен гаепле дә саный торгандыр?..

— М... м да, — диебрәк шыңшыды сыман күршем Илдар Бакинский.

Безнең бүгенге дөньябызда хәлләр әлегә шулайрак инде: чиксез матурлык белән илнең куәтен-көчен арттыру тырышлыгы бер тыгыз төендә төенләнгәндә, авырту-сызлануларсыз гына булмыйдыр да шул, чөнки һәрчак диярлек беренчесе, ягъни матурлык дигәнебез җәфа чигә. Ләкин артыгын ыңгырашмыйк, шыгырдамыйк, оптимистлар булыйк: адәм баласы акылыннан язмас, рухи сафлыгын җуймас. Инде җилләр дә бүтәнчәрәк исә хәзер — закон көче табигатьнең иминлеген һәм хозурлыгын ныклы саклау ягында... Әйе, гүзәл Олы урман да, аның шикелле үк бүтән чибәрләр дә вакыт үтү белән әлеге авыр җәрәхәтләрдән арыныр, саулыкларын ныгытыр һәм безнең күз алдында яңа төсмерләрдә, инде күркәм индустриаль пейзаж белән баетылган хәлдә балкыр дип ышаныйк...

Тик шулай да, күңелне туктаусыз тырнап торган, йөрәккә кан саудыручы бер нәрсә бар әле. Шушы уңайдан, аның турында да әйтмичә китәргә ярамас. Кайсы җәйләр үтә коры килә. 1972 елның җәен генә искә төшерегез. Яман җәй, дәһшәтле җәй... Янсә 1974 елның галәмәт коры көзе. Янәшәдә генә иксез җирләрне биләп алган тиңсез олы төзелеш. Меңләгән кеше, меңләгән турист саф һавага, яшеллек дөньясына агыла... Әлбәттә, күпчелеге, якын туганыдай күреп, табигатьне ярата һәм хөрмәтли белүче халык. Әмма арада таш йөрәкле, гамьсез рухлы янсә яман ниятле бәндәләр дә очрамыймыни?!.. Төтен көлтәләре... янгын афәте... Үтә коры айларда Олы урманның да, бүтәннәренең дә язмышы кыл өстендә генә сакланып торды дисәк, әллә ни арттыру булмастыр. Чаллы тирәсендәге гүзәл урманнарның берәрсенә барырга туры килсә, анда утрау-утрау булып, ямьсезләнеп утырган, кара көйгән кәүсәле, корыга калган урман өлешләренә еш юлыгасың. Йөрәк әрни. Кеше өчен әрни...

Алабуга урман хуҗалыгы ни сәбәптән урман аланчыкларына, юл чатларына адәм рәтле плакат-мазарлар, белдерүләр язып куя белми икән? Урман сукмакларын аз таптамыйм шикелле, әмма каршыма «яшел патруль» дигәнебез, ичмаса, бер килеп чыкса икән?! Хәер, бүтәннәргә сылтавы — иң ансаты. Бөтен бәла кешенең үзеннән, үз намусыннан һәм үз йөрәгеннән килә бит... һәркайсыбызга кагыла бу!

Инде менә янә җәй. Атналар, айлар тагын корыга китәрме? Хәер, хикмәт бу елда гынамыни? Җәйләр тагын килер, тагын... Ә безнең бәрхет хәзинәбез — яшел туганыбыз исә чиксез пошаманга һәм зур хафага тарып, һаман да үз моңына шаулый бирә: ни китерер миңа, ди, бу җәйләр...

Күр, безнең аста инде Богатый Лог. Анда-монда сибелешкән берничә йорт, ярым җимерек каралты-кура. Бирәдә катнаш урманлы һәм тирән чокырлы биек ярдан югары вольтлы ЛЭП гаҗәп бер җиңеллек һәм җитезлек белән елга аръягына, туп-туры Кызыл тауга атлап чыккан. Кызыл тау — наратлы урман итәгенә орынып, ямьле тугайлар чолганышында утырган тын гына, бәләкәй генә авыл. Аның язмышы инде хәл ителгән: ГЭС корылып беткәч, бу тын авыл урынында да дулкыннар чайпалачак...

Ә Кама көмеш нурларда балкый. Елга өстеннән, аккош балалары сыман тезелешеп, дистәләгән судно җай гына йөзә бирә. Мәһабәт дәрьяның иң мөлаем, иң көләч чагы.

Бу мизгелдә сәфәрдәшләремнең дә хәл-кыяфәте үзгәрде: йөзләр яктыра төшеп, куанычлы-нурлы көлемсерәүдән балкыды.

Ә мин, күз карашымны елга аръякларына ераккарак ташлавыма, тынымны кыстым: андагы гаҗәеп күренеш күңелне тартты. Юк, автогигантның җирдән калкынган галәмәт корпуслары юньле-башлы абайланмый: алар күгелҗем рәшә эчендә басулар зәңгәрлеге белән кушылган сыман. Әмма автошәһәр үзе... Яшь кала бөтенләй якын, ул елга артында янәшәдә генә кебек. Биек-биек йортлар нindидер гадәти булмаган нурларда, саф шикәр-рафинад төсендәрәк балкый. Ә бит нибары өч-дүрт ел әүвәл ул тигез басуларда бөтенләй бушлык һәм тынлык иде. Ә өченче ел яз шушындый ук очыш вакытында мин анда әллә унсигез, әллә унтугыз биек йорт санаган идем. Ә хәзер, бактың исә, тоташтан ап-ак шәһәр ләбаса! Йортларның исәбенә чыгасың юк... Хәйран-тамаша булмый ни!.. Яшь каладагы яңа танышларымнан берәү ничектер беркөнне миңа: «Шулай иттереп, башкалабыз Мәскәүнең бер почмагын мәңгегә бүләк итәбез инде үзегезгә!— диде. — Кама буйларына ак бәхетләр китерсен!..»

Күңелгә тулган хисләрем ташып, мин Илдарның кабыргасына төртәм:

— Ап-ак кала!.. Җиңелдер үзе! Канатларын җәйгән дә менә-менә очып китәр кебек!..

Күршем-юлдашым минем купшы чагыштыруымны ошаттымы-юкмы, бәлкем вертолет гөрелтесендә ул аны юньләп ишетә дә алмагандыр, әмма Илдарның кояшта янып өлгергән какча йөзен бизәп ап-ак тешләре ялтырады:

— Әйтмә, туган... Билләһи, төштәге кебек!

Ул арада түбәндә дә күренеш үзгәрде. Гаять киң үзәнлектә чамасыз олы һәм озын дамба дугаланып яткан. Земснаряд тырышлыгы белән өйдерелгән бу нәрсәкәй нефтьчеләр өчен котылгысыз бер мәҗбүрият: Түбән Кама ГЭСы төзелеп, әйләнә-тирәләрне су баскач та җир маен ничектер суыртырга кирәк! Монда да сирәк-мирәк төшләрдә факеллар дөрли. Кама ярында бүселеп чыккан бәләкәй генә утраучыкта буровой вышкасы тураеп каткан. Төрле машиналар чабыша, кешеләр кайнаша: берәүләре дамба буйлата нефтепровод үткәрә, икенчеләре яңа өелгән калкулыкның яңакларын бетон белән ныгыта.

Ком белән бетоннан корылган бу дамба ун чакрымнарга сузылып, ике башы белән дә нарат урманына төртелә. Якындагы кырыена гидротөзүчеләрнең җыйнак кына поселогы сыенган, ә тегендә, бәләкәй-бәләкәй күлләр күзе елтыраган һәм Кама суы зәңгәрләнгән ераграк төбәгендә, КамАЗның ял базасы урнашкан. Болар артында исә хәтта вертолет очкан биеклектән дә киңлекләрен чамалап булмастай зур урман массивы җәелеп китә...

Безнең тимер кошыбыз, сөзәк кенә элмәк ясап әйләнгәч, зур саклык һәм ип белән, дамбаның махсус киңәйтелгән төшенә кунды. Вахта егетләре берәм-берәм ком өермәсе эченә сикереште. Йөрәк кайнарлыгына зиһен киеренкелеген үрелдереп, иләмсез тирәнлекләрдән җир-әнкәнең кара канын һәм зәңгәр ялкынын көн яктысына чыгарырга сәләтле, көр һәм көчле рухлы егетләр — эшләре уң булсын!..

Илдар Бакинский вахтачы егетләргә бер-ике сүз белән генә нидер аңлатты да, вертолетка кире керде һәм ишекне ябып, келәсен ныгыткач, югарыда кабинада җәйрәп утырган очучыларга җәһәт кенә кул изәде:

— Теркелдәт, туганкай! Киттек!..

Вертолет, дуамал дерелдәп, янә өскә күтәрелә башлады. Без хәзер нефть һәм газ үткәрүче трасса буйлата, Яңа шәһәр кырыеннан үтеп, гигант төзелеш аша очып барачакбыз. Патруль очыш. Меңнәрчә гектарларда актарылып ташланган төзелеш мәйданында «кара алтын» һәм «зәңгәр ялкын» артерияләренә куркыныч туып тормыйдыр, дисезме? Зур байлык әрәм булмасын, афәткә юл калмасын!

Галәмәт озак элмәк ясыйбыз. Түбәндә Боровецк урманы. Бик тә күркәм! Аның да шушы итәгендәрәк җир куенында хәтсез генә «кара алтын» хәзинәсе бар. Әмма монда инде, Олы урмандагы шикелле кыланмыйча, иплерәк һәм акыл белән эш итәрләрдер. Заманыбыз шуңа китерде.

Офык читләренә җитеп эрегән мәһабәт урман зәңгәрлеге. Иге-чиге юк сыман. Хәтерлисеңме икән, бөек рәссамның...

Әмма ишетәмсең, дускаем,— син дә хөрмәтле нефтьче һәм гидротөзүче, син дә чиксез хезмәт батырлыгына гайрәтләнгән кайнар рухлы КамАЗчы — абайлыйсыңмы, нинди гаҗәеп хикмәтле дөньяда яшисең! Бөтен дөньяга мәшһүр гүзәллек кочагында син! Аны, үз күзең карасыдай, тиешенчә кадерле һәм саклый белерсеңме? Үзең хакыңа һәм оныкларың хакына!..

Ильтани Илялова

# ХАЛЫК АРТИСТЫ

Халык артисты. Сәхнәдән башка тормышны күз алдына китерә алмаган кеше өчен шуннан да лаеклырак исем бармы икән?! Коммунист, артист Фуат Халитов ярты гасырга сузылган иҗат эшчәнлеге дәверендә даими төстә тормыштагы яңалыкны һәм матурлыкны раслап килә. Һәр совет артисты кебек үк, ул үзенең уены белән социалистик җәмгыять кешесенең югары мораль принципларын раслый.

Гаҗәп киң диапазонлы бу артист иҗат иткән күп санлы образларда, кызыл җеп булып, кешеләргә зур мәхәббәт, аларны тагын да сафрак, тагын да кешелеклерәк итәргә омтылу хисе сузылып бара.

Әгәр уңай герой образларын иҗат иткәндә ул ачыктан-ачык якты тормыш өчен көрәшкә чакыра, кыерсытылган һәм кимсетелгән кешеләрне уйнаганда бөтен барлыгы белән үткәндәге һәм бүгенге буржуаз тормыштагы социаль изүгә каршы күтәрелә икән, инде тискәре рольләрне башкарганда исә артист вәхшилекне каплап торган бөтен пәрдәләрне ертып ата. Персонажның характерыннан чыгып, Ф. Халитов үзе башкара торган рольләргә карата тамашачыда я кайнар теләктәшлек һәм тирән мәхәббәт, я нәфрәт һәм җирәнү хисләре уята.

Чын совет артисты, актер-гражданинның иҗатын гына сугыш кырындагы солдат хезмәтенә тиңләргә мөмкин. Фуат Халитов — шундый артист.

Бөек Октябрь революциясе җиңгән көннәрдә Фуатка нибары 8 яшь була (ул 1909 елның 18 февралендә туа). Аның дөньяга карашы формалашуга күп төрле факторлар йогынты ясый, әмма барыннан да көчлесе, һәлиткече, әлбәттә, яңа чынбарлык үзе була. Совет иленең һәр гражданы кебек үк, ул да революцион эпоханың көчле идеяләре тәэсирендә үсә.

Мәсьәләгә кайсы яктан якын килеп карасак та, Ф. Халитовның сәнгать дөньясына тартылуы да, актерлык хезмәтен сайлап алуы да очраклы адым булмавын күрербез. Малай укымышлы гаиләдә туып үсә. Аның бабасы Фатих Халиди — беренче татар драматургы, татар халкын мәгърифәтле итү өчен күп көч куйган кешеләрнең берсе. Шуңа күрә Фуатның яшьли театр белән «җенләнеп» йөрүе бу гаиләдә әллә ни гөнаһ эш саналмый.

Фуат абый ул елларны әле дә яхшы хәтерли. Һәм нәрсә турында гына сөйли башламасын, ахыр чиктә сүз барыбер спектакльләргә килеп туктала. Бер елны шәһәрнең татарлар яши торган өлешен (хәзерге Тукай, Нариман урамнары, Кабан күле тирәләре) коточкыч янгын һәлак итә. Йорт-җирсез калган кешеләрне бер таш мәчеткә китереп тутыралар. Фуат шулар алдында нинди тамаша куеп йөргәннәрен хәтерли. Аннан мәктәп еллары. Бирегә инде алар, вак-төяк әйберләр белән чикләнмичә, А. Островскийның «Фәкыйрьлек гаеп эш түгел»ен үк куялар. Спектакльләр түләүле була, җыелган акча ятимнәргә өс-баш алырга тотыла.

Татарстан автономияле совет социалистик республикасы төзелгәч, халык арасында алып барыла торган культура-агарту эшләре бермә-бер көчәеп китә. Театр



сәнгате дә шул эшнең алгы сафына баса. Яшь татар совет театры алдына яңа, массовый тамашачы булдыру мәсьәләсе килеп баса. К. С. Станиславский сүзләре белән әйткәндә, театр үз өстенә яңа миссия ала, ул үзенең ишекләрен иң киң тамашачы массалары өчен, моңа кадәр сәнгать әсәрләре белән ләззәтләнүдән мәхрүм ителгән миллионнар өчен ачарга тиеш була. Һәм үзеннән-үзе аңлашылса кирәк, мондый шартларда театр эшчеләре өстенә төшкән бурыч та бермәбер җитдиләшә.

Алда бер тапкыр әйтелгәнчә, Ф. Халитов үзен белә башлаганнан бирле төрле спектакльләрдә катнашып килә. Шулай да аның чын мәгънәсендәге иҗат юлын 1927 еллардан санап китү дөресрәк булыр. Бу елларда ул Казан шәһәренең Вахитов заводында эшли, һәм без аны әлеге заводның театр «җене кагылган» 17—18 яшьлек егет-кызлары арасында күрәбез. Көндезләрен ул эшли, кичләрен репетицияләргә, спектакльләргә, осталыкны арттыру буенча махсус дәресләргә йөри, буш вакыт табып, академия театрына чабарга да өлгерә, массовый күренешләрдә катнаша, шәһәр урамнарында афишалар ябыштыра. Сирәк эләгә торган буш сәгатьләрдә, еш кына тәүлекнең йокы өлешенә дә кереп, матур әдәбият әсәрләре, театр турында китаплар укый. Бу мәсьәләдә аңа күренекле сәхнә остасы, завод каршындагы драмтүгәрәкнең җитәкчесе Шакир Шамильский зур йогынты ясый. Ф. Халитов аны үзенең беренче остазы дип атый. Һәм гомер буе аның алдында үзен бурычлы санап, аны ихтирам итеп яши.

...Утызынчы еллар якынлаша. Шаулы бишьеллыклар чоры, колхозлар төзү еллары. Авыл киеренке вакыйгалар кичерә, совет властеның дошманнары яңа тормыш төзүчеләрдән рәхимсез үч алалар. Шундый чакта яшь комсомолец гомуми көрәштән читтә калсынмы?!. Юк, ул читтә кала алмый. 1929 елда, авыл яшьләре арасында эшләү өчен, Фуат Халитов Татарстанның Норлат районына җибәрелә. Бирегә килүгә ул яшьләр арасында культура-агарту эшләрен юлга сала, авыл яшьләрен җыеп драмтүгәрәк төзи, спектакльләр куя башлый. Шулай да Фуатка Норлатта озак эшләргә туры килми. Егет торган саен киләчәк язмышы турында күбрәк уйлана. Аңа инде егерме яшь. Ә үзенең тормышта ныклы бер урыны, анык кына һөнәре дә юк. Һәм ул ныклы бер карарга килә: укырга, һичшиксез, укырга кирәк.

Бу елларда Казанда театр техникумы эшли башлаган була. Фуат шунда кереп укырга хыяллана. Әмма, бәхетсезгә җил каршы дигәндәй, ул уйлаганча булып чыкмый. Беренче курска набор юк икән, икенче курска аны алмыйлар. Ләкин кул кушырып утырып булмый: нәрсәдер эшләргә, ничектер яшәргә кирәк. 1930 елда Фуат мехкомбинаттагы тире эшкәртүчеләр әзерли торган алты айлык курсларга укырга керә, соңыннан шунда ук эшкә урнаша.

Шулай да аның театрга мәхәббәте һәммә нәрсәдән көчлерәк булып чыга. Мехкомбинатта эшли башлауга, ул андагы эшче театрына языла. Бу — ярым үзешчән, ярым профессиональ бер театр була. Анда, һәвәскәрләр белән бергә, профессиональ артистлар да уйный. Г. Газизов, М. Миңлебаева кебек яшь артистлар, мәсәлән, театр техникумын тәмамлагач, шушы театрга җибәрелә. Бирегә Фуат эшче театрының әдәби бүлеген алып барган Галиәсгар Камал белән якыннан аралаша. Күренекле драматург махсус алар өчен «Фал ачу» исемле өч пәрдәлек пьеса, мехкомбинат тормышындагы вакыйгаларга нигезләнеп, күп кенә скетчлар, интермедияләр яза.

Көн кадагына суга торган шушы эстрада әсәрләрен башкарганда ук Ф. Халитовның актерлык талантына хас индивидуаль сызымнар формалаша башлый, соңыннан алар аның иҗатының төп сыйфатына әйләнәләр. Сүз бүгенге көн өчен кирәкле нәрсәләрне вакытында әләктерә белү, ягъни заманны тою хисе турында бара. Кем белә, бәлки Ф. Халитовны заманында эстрада өлкәсенә дә нәкъ менә шул хис алып кил-

гәндер. Утызынчы еллар башында Г. Мамай белән икәү алар бик популяр эстрада артистлары булып китәләр. Бу хакта күренекле язучыбыз Ф. Хөсни болай яза: «Халитов белән Мамай, ике яшь егет, ике дус, кайчандыр бөтен республика сәхнәләре буйлап гастрольләр оештырып йөргәннәр иде. Бу ике егетне эшче клубларында, кызыл почмакларда, кыр станнарында, ашханәләрдә, кыскасы, җырларга, биергә, такмак әйтергә мөмкин булган һәр урында очратып була иде» [1].

Шушы җорлык, җырны, биюне, шигырь сөйләүне, кирәк икән акробатик номерларны да башкара алу сәләте, төрле юллар белән тамашачының игътибарын җәлеп итү, тамашачы белән сәхнәдән торып элемтә урнаштыра алу, үзең башкарган һәр нәрсәгә аны ышандыра алу сәләте — боларның һәммәсе артистның киләчәктәге уңышлы иҗат эшчәнлеге өчен ныклы нигез була. Аның талантының күп яклары шул елларда формалаша.

...Утызынчы елларда Ф. Халитовның тормышы гел төрләнеп, үзгәреп тора. Бу хәл аның әле һаман тормышта ныклап үз урынын таба алмавы турында сөйли булса кирәк. Егет анысын эшләп карый, монысына тотына. Ләкин һаман да нәрсәдәндер канәгать түгел. Шул канәгатьсезлек хисе аны бер урыннан икенче урынга күчереп йөртә.

1931 елда ул Кызыл Армия сафларына алына. Әмма күп тә үтми, «Эшче» театры җитәкчесе Ә. Мәҗитовның үтенүе буенча, аны яңадан Казанга кайтаралар. Ләкин, инде чын-чынлап эшкә тотынасы урында, тагы нидер була. Ул Ленинградка китә һәм... Политехника институтына укырга керә. Укый башлый. Әмма шулай да инде бер тапкыр сәхнә тузанын иснәгән, сәхнәгә гашыйк булып өлгергән кешенең башка эшкә күчүе мөмкинмени?!.. Ф. Халитов, институтны ташлап, киредән Казанга әйләнеп кайта.

1932 елда ул ныклап «Эшче» труппасының артисты булып эшли башлый, шул көннән алып бүгенге көнгә кадәр бер генә минутка да театрдан аерылмый һәм акрынлап бүген без белгән, без яраткан Халитов булып таныла, башта Татарстанның һәм РСФСРның халык артисты, аннары СССРның халык артисты дәрәҗәсенә үсеп җитә.

1934 елда, театр белән бергә, Ф. Халитов башкалабыз Мәскәүгә алты айлык курсларга китә. Аларны баш режиссеры булып атаклы А. Попов эшләгән Революция театрына беркетәләр.

Әйтеп тә торасы юк, Ф. Халитовның А. Попов кебек режиссер кулына эләгүе ифрат файдалы була. Яңа заман геройларын гәүдәләндерү, заманча итеп уйнау хакында күптән хыялланып йөргән егетнең бирегә килгәнче бик үк конкрет һәм анык булмаган теләк-омтылышлары Попов җитәкчелегендә практика узган айларда анык бер эзгә төшә. Менә шуңа күрә дә, укытучылары турында сүз чыкканда, Ф. Халитов зур хөрмәт белән А. Попов исемен дә телгә ала.

Мәскәүдә укып кайтканнан соң, труппаның исеме Дәүләт эшче театры дип үзгәртелә. Берничә елдан вакытлы матбугат битләрендә бу театрның ничек оешуы турында махсус мәкалә басыла: «1931 елда турыдан-туры производстводан килгән 6 һәвәскәр шигырьләр, скетчлар белән эшче клубларында, төзелеш мәйданнарында чыгышлар ясый башлый. Ә. Мәҗитов җитәкчелегендәге бу кечкенә труппаның бөтен байлыгы бер гармун була. Татар дәүләт эшче театры әнә шулай барлыкка килә. Алты ел эчендә театр ике миллионнан артык тамашачыга хезмәт күрсәтә, 1800 спектакль куя. Узган җәй беренче тапкыр театр классикларыбыздан Островский, Горький... әсәрләрен куя башлый» [2].

Казанда театрның үз бинасы була. Башта Пассаж йортында, аннары хәзерге Киров һәм Париж коммунасы урамнары чатындагы иске мәчет бинасында уйныйлар. Анда 500—600 кешелек тамаша залы ясыйлар, заманы өчен ярыйсы гына сәхнә коралар.

Эшче театрының режиссерлары Ә. Мәҗитов, М. Вәлиев-Сульва репертуарны төрләндереп торырга тырышалар. Театрның бу еллардагы афишаларында, Ф. Вольф, А. Островский пьесаларыннан тыш, К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл»ен, Ф. Бурнашның «Яшь йөрәкләр»ен, Ш. Камалның «Ут» пьесасын очратабыз.

---

[1] «Кызыл Татарстан» газетасы, 1941 ел, 9 февраль саны.
[2] «Красная Татария» газетасы, 1937 ел, 28 февраль саны.

Фуат Халитовның бу театрда башкарган рольләре арасыннан А. Островскийның «Гаепсездән гаеплеләр» драмасындагы Гриша Незнамовны күрсәтергә мөмкин. Дөрес, ул тудырган образ камиллектән шактый ерак була. Яшь артистның уенына чама хисе җитенкерәми, пафос, мелодраматизм артыбрак китә. Ихтимал, бу законлы күренештер дә. Беренчедән, Незнамов уйнау өчен кыен образлардан санала. Икенчедән, Халитов мондый роль белән беренче тапкыр очраша. Бу беренче рольләрендә Халитов әле эзләнә, тәҗрибә ясый. Бер спектакльдә күпмедер уңышка ирешсә, икенчесендә җитди генә ялгышлар да эшләп ташлый.

1937 елдан алып Ф. Халитов Татар академия театрында эшли башлый. Аның иҗатының беренче этабы шушы төштә тәмамлана диярга була. Иҗат эшчәнлегенең бу беренче унъеллыгы аңа нәрсә бирә соң? Бер караганда, бу чорның ниндидер бер ныклы үзәге юк сыман. Егет бер яктан икенче якка, бер һөнәрдән икенчесенә ташлана. Әмма тыштан караганда гел үзгәреп торган шушы тормышның да ниндидер бер тотрыклы юнәлеше, төпле мәгънәсе булган икән. Без Ф. Халитовның театр сәнгатенә булган чиксез мәхәббәтен күз алдында тотабыз. Кайда гына бармасын, кем булып кына эшләмәсен, шул мәхәббәте аны һәрвакыт сәхнәгә алып килә, башта завод үзешчәннәре янына китерә, аннары кызыларммеецлар һәм авыл яшьләреннән оешкан драма түгәрәкләренә әйди, ниһаять, профессиональ театр сәхнәсенә күтәрә һәм һәркайда Ф. Халитов актер сәнгатенең серләрен үзенә сеңдерә бара, акыл, тәҗрибә туплый, аз-азлап, акрынлап гыйлем багажын тулыландыра — боларның киләчәктә һәммәсе кирәк булачагын ул инде яхшы төшенә. Башкача әйткәндә, күренекле актер иҗатының бу беренче чорын эзләнүләр дәвере, тормышта, сәнгатьтә үз урынын ачыклау дәвере дип атарга мөмкин булыр иде. Ихтимал, бу еллар өчен иң мөһиме әнә шулар булгандыр. Ләкин моннан әле үз-үзен бер тапкач, артист тынычланып калган икән, бер дә эзләнми, газапланмый гына яшәгән икән дип уйларга ярамый. Һич юк. Әгәр иҗатында тынычланып калса, эзләнүдән, уйланудан туктаса, тормышны өйрәнүдән баш тартса, ул Фуат Халитов та булмас иде. Аңа инде 67 яшь, ә ул гомер буе эзләнә, өлегәчә тынгысыз. Аны һаман шул бер уй тынгысызлап-борчып тора: заманнан артта калмаска, картаеп, искереп бетмәскә. Шуңа күрә, алтмышны узганнан соң да, ул иң заманча уйный торган артистларның берсе булып кала бирә.

Ф. Халитовның артистлык язмышы турында сөйләгәндә, аның тагын бер характерлы үзенчәлеген истән чыгармаска кирәк: ул, башка күп артистлардан аермалы буларак, «күчеш» чоры дигән нәрсәне, картаюны белми, яшьтән үк картларны да, яшьләрне дә бертигез уйный. Шуңа күрә аңа яшь герой образларыннан картларны уйнауга күчү кебек авырлыкны кичерергә туры килми. Эш нидә соң?

Иҗат гомерендә Фуат Халитов бик күп рольләр башкара. Ниндиләре генә юк алар арасында! Ул характерлы геройларны да, төп һәм икенче дәрәҗәдәгеләрен дә, эпизодик рольләрне дә, уңай һәм тискәре персонажларны да уйный, бернинди рольдән баш тартмый. Хәзер без белгән киң диапазонлы артист шулай формалаша.

Әгәр, могҗиза булып, Ф. Халитов иҗат иткән образлар кинәт терелеп бер урынга җыелсалар, йөз иллеләп персонаж арасында кемнәрне генә очратмас идек! Биредә без төрле ил һәм төрле чор, төрле яшьтәге һәм төрле һөнәрле, төрле характердагы кешеләрне күрер идек. Беренче рәттәге урыннарны халык бәхете өчен көрәшүче революционерлар, хак эш өчен корбан булган баһадирлар алыр иде. Алар артындагы рәттә бик авыр заманнарда яшәп тә башларын имәгән, кешелек дәрәҗәләрен һәм горурлык хисләрен югалтмаган кыю йөрәкле кешеләр күренер. Монда төрле милләт кешеләре: татарлар һәм руслар, инглизлар һәм французлар, гарәпләр һәм башкортлар булыр, төрле характердагы, төрле темпераменттагы персонажлар бергә очрашыр иде. Аларның һәркайсына күпме көч, күпме вакыт сарыф ителгән, күпме талант һәм фантазия салынган!

Әнә, кайгылы башын түбән иеп, бәхетсез Незнамов утыра, янында гына ваемсыз табигатьле, мәзәкчел Кудряш (А. Островский. «Яшенле яңгыр»), ерактарак беренче татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйри уйланып тора, аның тирәли «Аршин мал алан»дагы Вәли биеп йөри. Калейдоскопны бераз гына бордыңмы, алдыңда бер үк «Миңлекамал» драмасыннан ике образ — гаять кешелекле һәм акыллы райком секретаре

Гыйльманов һәм кылый күзле Хәлим пәйда була. Арада Советлар Союзы Герое Муса Җәлил һәм мәкерле, хәйләкәр Николай Скроботов йөри (Горький. «Дошманнар»), янәшәдә генә тапкыр һәм зирәк Хуҗа Насретдин елмаеп утыра. Рольләр, рольләр, рольләр... Күпме шатлык, никадәр борчу китергән алар артистка. Образның эчке һәм тышкы сыйфатларын табу юлындагы эзләнүләр, характерын ачу юлындагы эзләнүләр. Артист әле олы юлдан, әле тар сукмаклардан атлаучы разведчикка әйләнә, хәзер генә биек тау башына күтәрелгән иде, ул да түгел, тирән упкынга оча: бар, чыгып кара шуннан. Җитмәсә, син уйнарга тиешле роль каядыр кереп кача да сине үртәргә тотына: әле телен күрсәтә, әле колагын селкетә. Куа башлыйсың, менә-менә тоттым дигәндә генә, ул тагын качып юкка чыга. Күпме җәфалый шулай...

Татар дәүләт академия театрында Ф. Халитовка башта ук өмет баглыйлар, ышаналар. Бер-бер артлы эреле-ваклы рольләр бирә башлыйлар. Әле сугышка хәтле үк булып узган бер вакыйганы искә төшерәсе килә. Театр М. Әблиевның «Шәмсекамәр»ен куярга була. Авыл старостасы Сәйфулла ролен танылган артистыбыз З. Солтановка бирәләр. Спектакльдә үзе катнашмаса да, репетицияләргә Ф. Халитов та йөри. Болай гына, карап утыру, өйрәнү өчен генә. Спектакльне тапшырыр көннәр якынлашып килә. Шул чак көтмәгәндә З. Солтанов авырып китә. Спектакль өзелү алдында кала. Шунда Ф. Халитов староста роленә үзен куюларын сорый. Башта театр җитәкчеләре кул гына селтиләр. Янәсе, сиңамы З. Солтанов белән ярышырга. Бераздан Ф. Халитов үтенечен яңадан кабатлый, һәм аңа репетицияләргә йөри башларга рөхсәт итәләр. Шул чак З. Солтанов терелеп эшкә чыга, тик егетнең бик яратып, янып-көеп әзерләнеп йөргүен күргәч, старостаны бөтенләйгә аңа калдыра...

Ф. Халитов иҗатына әле хәзер дә бер мөһим сыйфат хас. Болай ул — чын мәгънәсендә кичерешләр мәктәбе артисты. Рольгә дөрес психологик анализ ясый белү артист хезмәтендәге төп нәрсә икәнен ул яхшы аңлый. Ләкин шулай да мәсьәләнең ул икенче ягын: психологик анализ, тирәнлек белән мавыгып, образның тышкы ягын, форма мәсьәләсен онытып бетерергә ярамавын да истән чыгармый. Бары тик кичерешләр ярдәмендә генә һәр яктан килгән камил сәхнә образы иҗат итеп булмый. Актерлык техникасыннан, тышкы формадан, артистизмнан башка чын сәнгать образы тудыру кыен. Актер карамагындагы барлык тышкы тасвир чаралары — аның тавышы, дикциясе, тән хәрәкәтләре тел тидергесез булырга тиеш. Үзенең гәүдәсе, тавышы һәм эмоцияләре белән ул оста идарә итә белергә тиеш. Һәм актерлык сәнгатенә хас барлык шушы чаралар образның асылын ачуга буйсындырылган булу зарури. Ә бу җиңел бирелә торган нәрсә түгел. Ф. Халитов үз иҗатының башыннан ук, беренче чорларда интуиция аша, соңрак чын-чыннан аңлап, шул таләпләрне җиренә җиткереп үтәргә тырыша. Әгәр без ул иҗат иткән образларны күз алдына китерсәк, аларның төп, асыл сыйфатлары белән генә түгел, ә тышкы портретлары белән дә бер-берсеннән нык аерылып торуларын күрербез.

Академия театрына килеп эшли башлауга аңа ышанып тапшырылган әһәмиятле рольләрнең берсе В. Шекспирның «Ромео һәм Джульетта» трагедиясеннән Ромео образы була.

Әсәр, билгеле булуынча, ике яшь йөрәк арасында булган көчле мәхәббәт хакында сөйли, әлеге хиснең кеше тормышындагы роле мәсьәләсе үзәккә куела. Трагедияне сәхнәгә куйган Е. Амантов артисттан һәр адымда әнә шул төп идеяне, төп мәгънәне чагылдыртуга омтыла. Режиссер яшь артистны да, җайлап кына, түземлек белән, үзенә кирәкле эзгә кертә. Дөресен әйтергә кирәк, Ф. Халитов тудырган образ һәр яктан да камил булмый. Аңа масштаблык, чын мәгънәсендәге трагик күтәренкелек җитми. Шулай да бу роль артистның үзе, аның ул вакыттагы дәрәҗәсе, иҗат йөзе өчен онытылмаслык вакыйга булып кала. Халитов башкарган Ромео турында танылган язучы Гадел Кутуй бер рецензиясендә шундыйрак фикер әйтә: «Ромео һәм Джульетта рольләрендә, — дип яза ул, — театрның яшь артистлары Халитов һәм Миңлебаева чыгыш ясавын уңай факт буларак билгеләп үтәргә кирәк. Хәзергә бу эш башкаларны кабатлау гына да булсын, ди. Әмма шунысы куанычлы: инде хәзер үк Халитов һәм Миңлебаева уенында иҗади башлангыч, образ иҗат итүгә үзләренчә якын килергә омтылу сизелә»[1].

[1] «Красная Татария» газетасы. 1939 ел. 18 ноябрь саны.

Әлеге рольләрнең җәмәгатьчелек һәм тәнкыйть тарафыннан уңай бәя алуы турында тагын шундый факт та сөйли: ике актер да әлеге рольләре белән яшь театр көчләренең 1940 елның көзендә Мәскәүдә уздырылган Беренче бөтенроссия конференциясенә җибәреләләр. Үзәк матбугат татар артистларының уенына югары бәя бирә: «Халитов башкарган Ромео тамашачыларның игътибарын җәлеп итте. Актерны киләчәктә зур иҗат уңышлары көтә — әлеге образ белән танышкач шикләнми шуны ышанып әйтергә була»[1].

1941 ел... Башкалабыз Мәскәүдә уздырылачак татар әдәбияты һәм сәнгате декадасына хәзерлек барган көннәр. Театрларда яңа спектакльләр әзерләнә, иҗат оешмаларында яңа әсәрләр тыңлана, алар буенча фикер алышулар уздырыла. Ләкин уйламаганда, көтмәгәндә бөтенесе тукталып кала. Гитлер Германиясе Советлар иленә бәреп керә. Бөтен тормыш сугыш чорына җайланырга мәҗбүр була. Театрның күп кенә артистлары фронтка китә. Ф. Халитов үзе сугышка эләкми. Дөресрәге, аны, И. Гафуровны һәм А. Зыятдиновны юлдан кире борып кайтаралар, бронь бирәләр. Еллар никадәр генә авыр булмасын, театрны актерларсыз калдырырга ярамый иде. Шуңа күрә биредә калган артистлар җилкәсенә икеләтә артык йөк салына. Һәр актер, хәленнән килгәнчә, фронттагы иптәшләрен алмаштырырга тырыша.

Безнең алда Фуат Халитовның сугыш елларында башкарган рольләре хакында сөйләүче уннарча фотографияләр. Кемнәр генә, нинди персонажлар гына юк алар арасында. Әмма беренче карашка алар ничек кенә чуар булып тоелмасын, актерның барлык рольләре — һәм уңайлары, һәм тискәреләре — буйлап бер төп фикер, бер үзәк тема сузыла. Бу — тормыштагы уңай башлангычны раслау, чынбарлыкка гуманистик мөнәсәбәт темасы. Шул идеяне ул үзе башкарган һәр рольгә салырга тырыша. Үзенә тапшырылган образга Ф. Халитов беркайчан да битараф карамый. Ул башта ук рольгә үзенең анык мөнәсәбәтен билгеләп куя. Алга таба, образның характерыннан, нинди персонаж булуыннан чыгып, аны я яратырга, я күралмаска үзен мәҗбүр итә. Ул башкарган Розенбергны дошман күрми мөмкин түгел, Халитов уйнаган Мусаны яратмый калып булмый.

Әгәр сугыш алды елларында Ф. Халитов яңа формалашып килгән яшь артист булса, сугыш елларының сынауларын үтеп ныклы тәҗрибә тупласа, сугыштан соңгы елларда инде ул чын оста булып өлгерә. Кырыс сынау еллары аның сәяси аңын үткенәйтә, Совет дәүләтенең һәртөрле дошманнарына карата булган нәфрәт хисләрен көчәйтә, аның иҗатында әле сугыш алды елларында ук формалашкан төп сыйфатлар ныклы эзгә төшә.

Сугыштан соң узган утыз ел эчендә ул яшьлектә үзенә өмет баглаган беренче остазларының ышанычын тулысынча аклады. Совет театр сәнгатенең иң яхшы казанышлары белән янәшә торырлык уннарча сәхнә образлары иҗат итте.

Бу исемлектәге беренче урында Н. Погодинның «Мылтыклы кеше» пьесасы буенча иҗат ителгән Шадрин образы тора. Аны иҗат иткәндә артист алдына гаять катлаулы мәсьәлә килеп баса. Хикмәт рольнең уйнау өчен кыен булуында гына түгел. Эш тагын шунда, әлеге рольне Ф. Халитовка кадәр бик күп күренекле артистлар башкарган була. Аларны кабатламыйча, үз Шадринын иҗат итәргә кирәк. Ләкин ничек итеп, нинди юл белән барып?

Артист рольгә керә алмый җәфалана. Коры акыл белән уйлап караганда, аңа Шадринның кем булуы, ни өчен әсәргә кертелүе, нинди даирәдән чыгуы — һәммәсе дә ачык. Бу образга салынган төп идея дә ачык: ул крестьяннарның ничек итеп Совет власте ягына авышуларын күрсәтергә тиеш. Роль аңа ошый да. Тик менә үзенеке түгел. Премьера якынлаша. Каушый ук башлый артист — әгәр булдыра алмаса... Бер көнне иртән театрга репетициягә килгәндә, Ф. Халитов урамда бер солдатны очрата. Шактый өлкән яшьтә, иске шинельдән, обмоткалардан, аркасында кечерәк кенә биштәре. Күрүе була, бармагына ток суккандай катып кала. Күңеленнән «шул үзе, Шадрин» дигән уй йөгереп уза. «Вася!» — дип кычкыра ул, теленә беренче килгән исемне әйтеп. «Мин Вася түгел», — ди солдат һәм китә башлый. Артист

[1] «Советское искусство» газетасы. 1940 ел, 13 октябрь саны.

куып җитеп туктата, сорашырга тотына. Чын исеме кем? Кайсы яктан? Нишләп йөри? Сүз арты сүз китә... Түбәсе күккә тигән артист репетициягә шактый соңарып килә. Шуның өчен кисәтү ала. Ләкин инде аны берни дә куркытмый. Роль табылган, артист өлкән яшьтәге солдатның җанына, күңеленә төшенгән була. Һәм Шадрин шунда ук терелеп, конкретлашып китә, соңыннан Ф. Халитовның иң яраткан рольләренең берсенә әйләнә.

Әйтәсе дә юк, Шадрин үз сүзле, кире беткән кеше. Беркатлы авыл гыйбаты түгел, ә үз акылы үзендә булган гаилә башлыгы. Шуңа да баштарак аны сыер белән ат мәсьәләсе генә кызыксындыра. Рольнең асылы ике күренештә — Ленин һәм Чибисов белән очрашу вакытында ачыла.

Менә Чибисов белән очрашу күренеше. Шадрин аңа маңгай астыннан, салкын һәм төксе карый. Үзенең башында һаман бер уй: «Күпме генә лыгырдама, ышанмыйм булгач, ышанмыйм. Бәйләнеп маташма!» Ул үзен беренче мәртәбә йөгән кигерткән яшь тай кебек тота. Чибисов Шадринның винтовкасына сузыла башлый. Бирмим, дип, башта читкәрәк ала, аннан, бөтен гәүдәсе белән кочаклап, күкрәгенә кыса. Күзләрендә мең төрле шик, ышанмаучылык чаткылары. Чибисов аңа илдә булып узган вакыйгаларны аңлата башлый... Шул минуттан алып крестьян аңында акрынлап сыну, борылыш моменты башлана, Шадрин йомшап кала. Күзләрендәге кирелек, ышанмаучылык очкыннары акрынлап юкка чыга, аларны башка нурлар алмаштыра.

Ленин белән очрашканда ул инде яртылаш сындырылган, Чибисов пропагандасына бирелгән кеше була. Көтелмәгәндә очрашу. Кайнар су турында сорашу. Шуннан әңгәмә куерып китә. Шадрин юлбашчыга кайгысын сөйли, аның сыеры үлгән икән. Бераздан, игътибарлы иптәш очратканга шатлангандай, бөтенләй ачылып китә, сугыш турында, окопта яткан солдатларның ни уйлаулары хакында сөйли башлый. Очраклы рәвештә генә туры килгән кешегә солдат бөтен күңелен ачып сала. Чөнки шый бу кеше аңа. Ахырдан шундагы бер матростан: «Минем белән сөйләшеп торган теге кешене белмисеңме, кем ул?» — дип сорый.

— Кем булсын, Ленин, — ди матрос.

Шадрин бермәлгә тораташтай катып кала: «Ленин...» Шунда ук күзләрендә әйтеп бетергесез үкенеч билгеләре пәйда була. «Нигә әлегрәк әйтмәдең. Мин аңа һәммәсен сөйләгән булыр идем», — ди Шадрин карлыккан һәм үкенгән тавыш белән. Бераздан Шадрин тынычланып калгандай була, тирән уйларга бирелә. Хәзер ул Совет власте өчен икеләнмичә көрәшәчәк. «Халитов Шадринның рухи яктан яңадан туууын... күрсәтә. Ул үз героен һәркемгә якын образ итеп уйный. Тамашачы каршына акыллы, тәвәккәл һәм бай рухлы рус крестьяны килеп баса. Әлеге образны иҗат итү Ф. Халитовны сәнгатьнең тагын да югарырак баскычына күтәрә»[1].

...Билгеле, Ф. Халитовның да иҗат юлы һәр адымында уңышлардан гына тормый. Ниндидер рольләр урта кулдан ары узмый, арада уңышсызлары да булгалый. Шулай да, ялгышлар ясый-ясый, егыла-тора, төрле шешләр ала-ала, Ф. Халитов алга баруын дәвам итә. Дөрес, сугыштан соңгы елларда татар академия театрының үз үсеш юлы да тигез генә булмый. Ул әле дөбердәп аска тәгәри, әле бөтен буйга торып, аякка баса. Мәсәлән, 1957 елда татар әдәбияты һәм сәнгате декадасы вакытында Мәскәүдә күрсәтелгән спектакльләр зур уңыш казана. Декададан соң театрның күп артистларына мактаулы исемнәр бирелә. Алар арасында без РСФСРның халык артисты дигән исемгә лаек булган Фуат Халитовны да күрәбез.

Декада узуга, 1958 елда, артист тагын бер үзенчәлекле образ иҗат итә. Сүз Н. Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясендәге Муса образы турында бара. Герой шагыйрь образын уңышлы башкару артистның ачылмаган мөмкинлекләре булуы, аның иҗади үсә баруы, һаман эзләнүе хакында сөйли.

Трагедиядә күбрәк Җәлилнең әсирлектәге тормышы сурәтләнә. Дошман тылында да, башта концлагерьда, аннан ирекле төстә йөргәндә, тыштан шагыйрь үзгәрми диярлек. Күзләрендәге җылылык бетә дә, аның урынына кырыслык, тәвәккәллек очкыннары арта. Йомшак табигатьле ягымлы интеллигент һәм корыч ихтыярлы коммунист, курку белмәс характерлы сәяси җитәкче. Ф. Халитовның Мусасы әнә шундый.

[1] «Кызыл Татарстан» газетасы. 1947 ел, 7 май саны.



*Ф. Халитов Н. Исәнбәтнең «Муса Җәлил» трагедиясендә Муса ролендә.*

Германиядә барган күренешләрдә, вакытлыча татар эмигранты йортында яшәгән кеннәрдә дә тыштан Муса-Халитов элекке кебек йомшак тавышлы, культуралы кеше булып кала. Тик сез аның күзләренә карагыз. Болай ул көр күңелле, кайгысыз кеше кебек, ләкин шушы көр күңеллелек пәрдәсе артында тамашачы чит-ят киемдә, чит-ят илдә калган кешенең сагышлы хисләрен тоеп утыра. Җәлил образын артист хәрәкәттә, үсештә бирә. Образ күренештән күренешкә үзгәрә, тышкы яктан гына түгел, эчтән дә үзгәрә бара. Төрмәдәге һәм тикшерүче каршындагы күренешләрдә шагыйрь образы аеруча тирән ачыла.

Мусадан соң да күпме рольләр уйнала. Ә. Фәйзинең «Тукай» пьесасында Ф. Халитов бөтенләй сүзсез сәүдәгәр ролен уйный. һәм шундый итеп уйный, аны спектакльдәге төп рольләр белән бер рәткә куярга мөмкин. «Чаткылар» спектаклендәге исерек Мочтак та тамашачы хәтерендә озак сакланыр, дип шикләнми әйтеп була. Бу елларда ул М. Әмирнең «Хөррият» пьесасыннан авыл Советы председателен, Э. Раннетның «Юлдан язган ул»ындагы Март Туйскны, «Гөлҗамал»дан Хафизны, М. Горькийның «Дошманнар» әсәреннән Николай Скроботовны һәм башка рольләрне башкара. Аның ул эшләре хакында матбугатта күп мактау сүзләре языла...

Соңгы берничә ел эчендә Фуат Халитов берсе икенчесенә бөтенләй охшамаган кызыклы образлар иҗат итте. Әйтик, «Шамил Усманов»тагы Сәгъдетдин белән «Соңгы корбан»дагы Поибытковны ничек янәшә куясың?!. «Миләүшәнең туган көне» спектаклендәге Әһлиулла белән «Фатима Сабри»дагы Габделхәмит, «Американ» комедиясендәге Шәехмирза белән «Ир-егетләр»дәге Әхтәм, «Намус хөкеме»ндәге Арсланов белән «Агай-эне ак мыек»тагы Рисположенский да бер-берләреннән бик ерак тора торган образлар. Табигатьтә шулай була бит, бармак башы зурлыгындагы яшел төймә сиздерми-күренми генә үсә-үсә дә, бер көн килеп, күз яуларын алырлык матур алмага әйләнә. Артист хезмәте дә шундыйрак, гомер буе дәшми-кычкырмый гына эшләп йөри дә бер заман хәтта үзен якыннан белгән кешеләрне хәйранга калдырырлык образлар иҗат итеп ташлый. Сүз дә юк, мондый шаккатырыр дәрәҗәдә шәп рольләр иҗат иткәндә артистка элеккеге тәҗрибәсе нык булыша. Әгәр элегрәк Розенберг образын уйнамаган булса, «Фатима Сабри»дагы Габделхәмит бу кадәр төгәл килеп чыкмас иде. Шадрин образын уйнамаган булса, «Шамил Усманов»тагы Сәгъдетдинне дә ул болай ук коеп куя алмас иде, мөгаен.

А. Гыйләҗев һәм А. Яхиннарның «Шамил Усманов» драмасын театр Бөек Октябрьның 50 еллыгына багышлап сәхнәгә куя. Халык күп катнашкан массовой күренешләр белән бергә, бу спектакльдә аерым кешеләр язмышына багышланган урыннар да шактый. Менә беренче пәрдә. Мәчет ишегалды төрле киемдәге, төрле яшьтәге халык белән тулган. Шау-шу, кычкырыш — сәхнә гөжләп тора. Шул ыгы-зыгы, ду килгән халык арасында артык күзгә ташланып тормаган, юаш һәм сабыр табигатьле бер карт күзгә ташлана. Кыска буйлы, бераз бөкрерәк, өстендә кара камзул, аркасында буш капчык. Тамашачы, үзе дә сизмәстән, шул картны күзәтә башлый. Белмим, кай ягы беләндер ул башкалардан аерылыбрак тора һәм синең игътибарыңны үзенә тарта. Мәчет ишегалдындагы шау-шудан карт беразга югалып калгандай тоела. Кемдер аны төртеп җибәрә, ул як-ягына карана-карана эчкәрәк уза. Кысылаэтелә торгач, ниһаять, өстәл янына якынлаша һәм карлыккан тавыш белән үзен батальонга язуларын сорый. Сәгъдетдин карт шушы инде. Спектакльдәге әлеге рольне иҗат итү өчен Ф. Халитов аз гына да көч куймаган, азапланмаган төсле. Ә менә образның эшләнеш дәрәҗәсе теләсә кайсы сәхнә остасын таң калдырырлык. Артист-

ның Сәгъдетдине аз сөйләшә, ул һаман халык арасында, күзәтә, тыңлый, дөньяда ни барганын аңларга тырыша. Аның нур бөркеп торган ягымлы күзләре шуңа да артык игътибарлы һәм сынаучан карыйлар. Шулай дәшми-тынмый гына йөрсә дә, без аның бөтен тормышын күз алдына китерәбез. Артист сәнгатенең көче шунда!

Ф. Халитов иҗат иткән Сәгъдетдин чын мәгънәсендә милли образ. Бу образда пакь күңелле татар крестьянының изелгәнлеге, басынкылыгы гәүдәләнә. Гомерлек изү һәм кабалага төшерү дә, патша Россиясенең башка вәхшилекләре дә ахыр чиктә гаделлекнең барыбер өстен чыгачагына аның ышанычын җимерә алмаган. Шуңа да аның күңел түрендә кемнәргә дә булса ачу түгел, ә инану хисе ята. Бу — аның җиңел карашлы һәм беркатлы кеше булуыннан килми. Киресенчә, акыллы һәм зирәк карт ул. Нәкъ менә зирәк карт булганга да, ул киләчәк матурлыкка инана. Шулай булмаса, инде ашын ашаган, яшен яшәгән кешене яңа тормыш төзү өчен көрәш сафына басарга кем мәҗбүр итә алыр иде икән?!. Крестьян дигәнебез баш ватарга, күп уйларга ярата. Ул башкалар янында да, ялгыз гына калганда да уйлана, хәтта кеше белән сөйләшкәндә дә үзенә якын һәм кадерле нәрсәләр турында уйлый. Кыскасы, Халитовның Сәгъдетдине, нихәтле генә сәер тоелмасын, бай рухлы, эчке культурага ия булган кешеләр төркеменә керә.

Гомумән, сәхнәдә уйлый белү Ф. Халитовның барлык образларына диярлек хас сыйфат. Бу — аның талантының бер мөһим үзенчәлеге. Һәм шул сыйфаты күптән инде алты дистәне тутырган артистны татар театрындагы иң заманча уйный торган артистлар белән бер рәткә куя. Аны, берninди ташлама ясамыйча, заманча уйлый белә торган сәхнә осталары сафына кертергә мөмкин. Үзеннән-үзе аңлашыладыр кебек, бер табигый таланты гына аны шундый артист итмәгән. Ул, алда әйткәнебезчә, гомер буе заман югарылыгында торырга, бүгенге тормыштагы яңалыклардан артта калмаска тырыша. Күп укый, күп эзләнә. Тормыш таләпләренә сизгер булу шуннан килә. Шуңа күрә ул, нинди генә әсәрдә уйнамасын, үзе башкарган һәр рольнең бүгенге тамашачыны тирән дулкынландырырлык бер әр ягын таба. Классик драматургларның пьесаларындагы рольләрен алыйк. Заманында аларны кемнәр генә уйнамаган, нинди талантлар гына башкармаган. Үзенә кадәр уйнаган сәхнә осталары йогынтысыннан, традиция һәм штамплар тәэсиреннән котылу мөмкин дә түгел кебек. Ф. Халитов исә һәр вакыт диярлек шундый йогынтылардан котыла белә. А. Островскийның «Соңгы корбан» драмасындагы Прибытков роле шул хакта сөйли торган ачык бер мисал була ала. «Мин бу актерда искиткеч сизгерлек, бай рухи дөнья барлыгын сиздем, — ди спектакльнең режиссеры М. Новохижин. — Аның Прибытковы искиткеч катлаулы характерлы кеше, аның эчке дөньясы икегә бүленгән. Ул бер үк вакытта кырыс та, шәфкатьле дә»[1].

Прибытковны уйнаганда артист аз сүз белән күп мәгънә белдерергә омтыла. Тыштан караганда, аның герое сабыр холыклы, тотнаклы кеше. Сирәк очракларны искә алмаганда, тыныч кеше. Аның эчке дөньясы хакында, каршылыклы, катлаулы характерлы булуы турында бары күзләре генә сөйли. Халитов иҗат иткән Флор Федуловичның башка купецлар белән уртак бер сыйфаты да юк сыман. Аны исерек Курослеповлар яки Тит Титычлар белән бер өердәге кеше итеп күз алдына китерүе дә кыен. Халитовның Прибытковы интеллектуаль, хәтта интеллигент кеше, башкалардан ул бер башка югары тора. Шул ук вакытта нечкә штрихлар белән артист бер әйберне сиздереп бара: Прибытков шулай ук ерткыч, тик, иске купецлар белән чагыштырганда, күп тапкыр хәйләкәррәк, остарак ерткыч.

Бу җәһәттән спектакльнең икенче пәрдәсе аеруча характерлы. Прибытковның зиннәтле, бай җиһазланган кабинеты. Аның янына Тугина килә, бурычка акча сорый. Тыштан үзен сабыр һәм кырыс тотса да, кабинетына шундый чибәр хатын-кыз килгәнгә Прибытков, билгеле, шат. Аның нинди йомыш белән килгәнен белгәч, ул, Тугинаны яратуына да карамастан, мескен хатынны мыскыл итүдән дә тыелып кала алмый. «Юк, акча бирмим!» — ди. Кара көеп креслосына утыра. Нишләргә белмәгән Юлия, аның тезләренә менеп утырып, читлыклана башлагач, Флор Федулыч аны кискен төстә этеп җибәрә, дулкынланудан карлыккан усал тавыш белән кычкырып, креслосыннан сикереп тора. Бары Юлия аның аякларына килеп егылгач кына При-

[1] «Театральная жизнь» журналы. 1969 ел, 2 сан.

бытков йомшап кала. Ниндидер алты мең сум акча өчен шул кадәр түбәнчелеккә төшергә мөмкинме икәнни?! Ашыкмый гына сейфына килә, акча алып бирә. Юлия, аны үбеп, бүлмәдән чыгып киткәч кенә берничә мәртәбә: «Кыйммәт тора бу үбү», — дип кабатлый.

Бөтен күренеш актер тарафыннан гаҗәп бер тотнаклык белән алып барыла. Берннди ялган хисләр юк. Шуның белән бергә, никадәр дулкынландыргыч, тирән драматик күренеш. Ул соңгы чиккә җиткәнче кысылган пружина төсле, менә-менә ычкынып китәр дә китереп сугар кебек. Тугинаның үзенә кияүгә чыгарга ризалыгын алса да, дөресрәге, аның мәхәббәтен сатып ала алса да, чын бәхетне берннди акча белән дә сатып алып булмаячагын, акыллы кеше буларак, Прибытков яхшы аңлый. Аның тормышында чын шатлык булмаячак. Менә ни өчен тормышының иң шатлыклы минутларында да без аның күзләрендә әйтеп бетергесез сагыш укыйбыз. Һәм ул сагыштан берничек тә котылырлык түгел. Прибытковның трагедиясе әнә шунда...

Укучыларны бер нәрсә гаҗәпләндерергә мөмкин: махсус мәктәп тәмамламаган, башкалар кебек тирән хәзерлек узмаган кеше ничек итеп шундый оста актер була алды икән?.. Бу сорауга җавап бирү әллә ни кыен булмас кебек. Иҗат кешесе өчен — язучымы ул, әллә художникмы, композитор яки артистмы — беренче чиратта, сәләт, табигый талант кирәк. Тик ул гына җитми. Талантны үстерә белү сорала. Бу исә — һәр көн, һәр сәгать тырышып хезмәт итү дигән сүз. Кайчандыр талантлы булып та, ялкаулык, хезмәт сөймәү аркасында берникә ирешә алмаган кешеләрне театр күп белә. Хезмәт төшенчәсенә, шуның аерылмас бер өлеше буларак, театр сәнгатенә багышланган әдәбиятны уку, сәхнә осталарыннан өйрәнү, төрле бәхәсләрдә, спектакльләр тикшерүдә катнашу да керә. Шуларның һәммәсеннән артист үзе өчен кирәкле рухи азык таба, үсү өчен стимул ала. Ф. Халитов — белем алуның бөтен төреннән гомер буе оста файдаланган кеше. Ул үзенең остазлары булган Ә. Мәҗитовка, Ш. Шамильскийга, Х. Сәлимҗановка күңелендә гомер буе рәхмәт хисе саклый.

...Ихтимал, беренче тапкыр сәхнәгә куйганда К. Тинчуринның «Американ» комедиясе башкачарак яңгырагандыр. Бүген Ф. Халитов уйный торган Шәехмирза да башка төрлерәк булгандыр. М. Сәлимҗанов тарафыннан куелган бүгенге «Американ» — жанры буенча фарс, гротеск. Комедиядәге барлык персонажлар җир йөзеннән мәңгегә киткән җан ияләренең балавыздан ясалган сурәтен хәтерләтәләр. Алар арасында беренче урынны, һичшиксез, Шәехмирза алып тора. Башкару алымы ягыннан гаҗәеп кызыклы, моңарчы ул уйнаган образларның берсенә дә охшамаган роль. Сәхнәдә кечкенә генә, хәлсез бер карт йөри, өстендә — кыска пинжәк, ак төстәге гаҗәеп кыска чалбар кигән. Гаять зур пеләш башының чит-читләрендә бер-



*Ф. Халитов — Шәехмирза. (К. Тинчурин. «Американ».)*

ничә бөртек чәч тырпаеп тора. Бөтен кыяфәте кәмит. Үзен бөек галим санаган шушы кеше әллә аксабрак, әллә сикеребрәк сәхнә буйлап атлый. Оратор позасына басып, карлыккан, чәрелдек тавыш белән нотык сөйли. Халитовның «Американ» спектаклендәге роле тагын шул яктан кызыклы, актер биредә бөтенләй яңа алымда уйный. Монда, әйтик, Прибытков, Муса, Сәгъдетдиннәр белән берннди уртаклык юк. Бу —

туры мәгънәсендәге тамаша. Ләкин бу әле актерның реалистик методтан кире чигенүе дигән сүз түгел. Биредә шулай ук дәреслек, реализм бар. Ләкин фарс реализмы, сатирик гротеск дәреслеге.

Соңгы елларда, Шәехмирза һәм Рисположенский кебек гротеск рольләр белән бергә, Ф. Халитов саф психологик пландагы Әхтәм («Ир-егетләр») образын иҗат итте. Әхтәм заманында талантлы архитектор булган. Ләкин әшәке бәндәләр белән көрәштә җиңелеп калган һәм өметсезлеккә бирелгән. Янәсе, тормышта гаделлек юк, намуслы кешеләргә урын юк. Ул, хаксызга рәнҗетелгән кеше позасына басып, «акыллы сүзләр» сөйләп, хәмер эчеп йөри. Көлми, елмаймый. Күзләре — гамьсез һәм салкын. Шушы битлек астыннан вакыт-вакыт аның чын йөзе һәм чын ярасы күренеп китә. Ләкин әнә шул күңел ярасын дәвалыйсы урында, ул аны гел борчып, бимазалап тора... Яңадан ныклап аягына басканчы, Ф. Халитовның Әхтәменә шактый күп нәрсәләр кичерергә туры килә. «Намус хөкеме»ндәге Арсланов һәм «Кан кардәшләр»дәге Хисами образларын да артист шул ук психологик стильдә иҗат итә.

Ф. Халитовның иң яңа роле — танылган журналист Г. Боровикның «Канлы күләгәләр» драмасындагы Карлос Бланко образы. Журналист Бланко язмышы аша әсәрдә күптән түгел Чилидә булып узган трагик вакыйгалар сурәтләнә. Драманың төп идеясе шушы образга салынган. Моннан тыш, Бланко әсәрнең башыннан ахырына кадәр сәхнәдә, тамашачы алдында була. Димәк, бу рольне башкарган артисттан күпме көч һәм энергия сорала!

Спектакльдә сурәтләнгән вакыйгалар барышында Бланко-Халитовның характеры һәм дөньяга карашы үзгәрә, Чилидә барган канлы вакыйгалар аның үз-үзенә булган ышанычын җимерәләр, ахыр килеп, ул үзенең фаҗигале ялгышын аңлый. Ул, Карлос Бланко — бөтен илгә танылган журналист — үзе дә аңламастан, хунтага ярдәм иткән, Альенде хөкүмәтен канга батырырга булышкан икән бит. Бланконың ялгышы әнә шунда.

Бу рольнең Ф. Халитов иҗаты өчен зур әһәмияте бар. Бер яктан, без монда артист иҗатына хас психологик уен алымының дәвам итүен күрәбез. Шуңа да образ тормышчан һәм җанлы булып хәтердә кала. Икенче яктан, артист иҗаты кайнар сәясәт һәм публицистик ялкын белән баеган. Сәяси плакат стилендә язылган бу әсәрне көнкүреш детальләре ярдәмендә генә ачып та булмас иде. Яңа спектакльдәге Бланко роле артист иҗатының яңадан-яңа буяулар белән тагын да байый, үсә төшүе турында сөйли.

...50 еллап сәнгатькә хезмәт иткән олы бер дәвер эчендә һәммәсе дә — шатлыгы да, ачышлар ясау бәхете дә, яңгырлы, болытлы көннәр дә булгандыр. Югарыга омтылу, түбән тәгәрәү, бер көенчәрәк яшәгән чорлар... Ләкин кеше бөтен гомере буе театрны, хезмәтне сөйгән, үз-үзен онытып, бөтен барлыгын биреп сөйгән. Бөтен тормышын театрга багышлаган. Шул мәхәббәте аны без белгән, без яраткан СССР халык артисты Фуат Халитов иткән.

Үз сәнгатен заманга багышлаган, кеше аша, аның эчке омтылышларын һәм эшләрен гәүдәләндерү аша матурлыкны һәм безнең тормышның яңарыш шартларын ачуга багышлаган артист бүген дә тулы канлы иҗади тормыш белән яши.

Инде без күреп үттек: актерның йөзен, аның үзенчәлеген, ул башкарган эшнең характерын һәм формаларын яңа идея-иҗтимагый һәм сәяси эчтәлек билгели икән. Совет актерларын дөнья күләмендә алгы планга куя торган төп принципиаль аерма да әнә шунда. Совет артисты сәхнәдә эстетик бурычлар гына үтәп калмый, идея-иҗтимагый бурычларны да башкара. Шуларның һәммәсе аны чын мәгънәсендә халыкчан һәм партияле актер итеп үстерә.

**Фатыйма Ильская,**
РСФСРның халык артисткасы

# ҮТКӘННӘРДӘН БЕРНИЧӘ СӘХИФӘ

## Һаман эштә

— Фатыйма ханым, сөйләгез.

— Фатыйма ханым, сез истәлекләргә бай,— диләр миңа.

Ә сөйләү минем өчен кыен. Якын, бик газиз кешеләр дә көндәлек тулы сакланмаган, ниндидер бик кирәкле вакыйгалар хәтердә теркәлмәгән кебек. Зур талант иясе белән бергә яшәүчеләр, гадәттә, көндәлек яза баралар. Аларның тормышларын күзәтеп киләләр. Язылган истәлекләр андый кешеләрнең төгәл портретларын тудырырга нигез була... Мин алай булдыра алмадым.

Минем бөтен тормышым сәхнәгә бирелгән иде. Бөтен уй, акыл, йөрәк — барысы образларга тупланган.

Пәрдә төшә. Спектакль тәмам. Әмма артист өчен ул әле бетми. Артист йокысыз төн уздыра. Ул спектакльне җентекләп яңадан күздән кичерә. Я пошына, я куана. Ә иртәгесен аны чираттагы спектакль, я репетиция көтә. Артист үзлексез диярлек образлар язмышы белән яши. Һәр вакыт иҗат итә. Бәлки шуңадыр, кайчагында башкаларга игътибары да азрак кала.

Минем өчен иң якын кеше — тормыш иптәшем, драматург Фәтхи Бурнаш иде. Безнең хәтта хезмәтебездә уртаклык та зур булып, бергәләп сөйләшкән, киңәшкән чакларыбыз эшебезгә күп ярдәм итә иде. Фәтхи күк йөзедәй ачык зәңгәр күзле, коңгырт озын чәчле, озын буйлы. Таза, матур гәүдәле. Ул һаман эштә. Вакытны буш уздырырга яратмый. Көндез ул театрда яки китап нәшриятында, редакцияләрдә була. Көндезге аштан соң бераз ял итә. Төннәрен яза. Тынлыкта иҗат итәргә ярата иде... Яңа әсәренең язылган өлешен шунда ук укырга ярата. Фикер ишетергә тели.

Ул музыкаль сәләтле, ягымлы тавышлы кеше иде. Рояльдә үзе уйнап, үзе җырлый. Халык көйләрен яхшы белә. Аларны ул моң белән җырлый, Салих Сәйдәшевнең көйләрен бирелеп уйный, бигрәк тә үз әсәрләренә язган көйләрен уйнарга ярата иде. Салих — аның иң яраткан, иң якын дусты булды. Безнең өйдә «Хөсәен Мирза» драмасына Сәйдәш язган «Бибисара» җыры бигрәк тә еш җырлана иде. Фәтхи талантлы кешеләрне аеруча ихтирам итә. Андыйларга игътибары да зур булды. Бервакыт, әле яшьрәк чагымда, мин, Шакир Шамильский, тагын берничә иптәш Казаннан китәргә җыендык. Кайсыбыз Уфада, кыйсыбыз Кырымда эшләргә булдык. Шул вакыт Фәтхи Бурнаш безнең белән җайлап сөйләшеп, татар халкына хезмәт итәргә, Казанда эшләргә алып калды.

Фәтхи Татарстанда төрле театрлар тууын тели иде. Әсгать Мәҗит эшче театры оештыргач, ул аңа куана. Шул театрның спектакльләрен кат-кат карый. Драма театры үзенә, опера театры үзенә аерым булсын дигән фикерне яклый. Мәскәүдә Татар дәүләт опера студиясе оештырылгач, аның әдәби бүлегендә эшли башлый. Мансур Мозаффаров белән опера язарга җыена. Шуңа либретто яза. Ул чагында яшь композитор Җәүдәт Фәйзи белән бергә балалар өчен музыкаль сәхнә әсәре «Кызыл чәчәкләр»не иҗат итә.

Зур әдип, җәмәгать эшлеклесе, ул үзен татар дөньясы белән генә чикләмәде. 1934 елны Мәскәүдән язучыларның Беренче бөтенсоюз съездыннан ул бик ялкынланып кайтты. Максим Горький белән очрашу аңарда тирән эз калдырды. Кайту белән ул аның «Давыл хәбәрчесе» дигән әсәрен тәрҗемә итте, «Ана» романын тәрҗемә итә башлады. Ул рус совет язучылары Алексей Толстой, Мариэтта Шагинян белән дә якыннан дус иде. Мәскәүдә чакта Бурнаш Алексей Толстой өендә еш булды. Шагинян белән бик еш хат алыштылар.

Фәтхи бер җирдә генә иҗат итәргә яратмый, кешеләр белән аралашырга, эшләгән вакытында ук аларның киңәшләрен алырга омтыла иде. «Евгений Онегин» поэмасын ул Гаграда, язучылар йортында тәрҗемә итте.

Аның өчен кечкенә, вак кешеләр юк иде. Ул һәр кешегә ихтирамлы булды. Безгә бер бик гади генә, тәбәнәк буйлы кеше килеп йөри иде. Ул вак-төяк йомышларны үти. Без аны мишәрчәләп үзара Кәбәй дип атый идек.

— Фәтхи, нигә вакытыңны әрәм итеп, шул кадәр озак сөйләшәсең ул Кәбәй белән? — дисәм, Фәтхи миңа:

— Мин аны тыңлыйм. Ул бик акыллы фикерләр әйтә. Һәр кеше белән сөйләшү — файда, нинди булса да акыллы фикер ишетәсең, — дип җавап бирә иде.

Без аның белән Бохарада, Сәмаркандта, Ташкентта булдык. Анда ул басмачыларга каршы сугышларда катнашкан кешеләр белән күп очрашты. Бу сөйләшүләрнең нәтиҗәсендә «Лачыннар» драмасы туды.

Улым Фоатның мәктәптә укыган вакыттагы көндәлекләрен карыйм. Анда Фәтхи һәр көнне кул куеп барган. Эше күп булса да, улына аеруча игътибарлы, аңа вакытын кызганмый иде ул. Ватан сугышында батырларча һәлак булган улымның яхшы сыйфатларын искә төшергән саен мин Фәтхигә рәхмәт укыйм.

Бу көннәрне Фәтхи турында күп уйлыйм. Саф йөрәкле, игътибарлы, хезмәт сөючән, һаман эштә. Бурнаш хәтердә шулай калган. Кешеләргә аның турында онытылмаслык итеп әйтәсе килә. Әмма бу эшне бер генә кеше булдыра алмый. Аның хезмәттәшләре, язучылар, композиторлар, артистлар, Фәтхине белгән башка кешеләр дә белгәннәрен сөйләсеннәр, язсыннар иде. Зур әдип, киң колачлы җәмәгать эшлеклесе, чын кеше — Фәтхи Бурнаш моңа бик лаек.

## Соклангыч кеше

Кәрим Тинчурин.

— Күренекле драматург, эшчән режиссер, талантлы артист.

Кәрим Тинчурин исеме әйтелүгә һәркем аны әнә шулай дип, тирән ихтирам белән искә ала.

Әмма көн дә күрешкән, аның белән еллар буе эшләп, аралашып килгән кешеләр Тинчуринны күбрәк беләләр, кыйммәтле истәлекләр саклыйлар. Гаҗәп сөйкемле, саф күңелле, эчке табигате һәм тышкы кыяфәте, үзен-үзе тотышы белән чын интеллигент, талантлы артистлар коллективын тәрбияләгән, үзе аларга гүзәл үрнәк булган чын кеше — Кәрим ага күп вакыт безнең белән бергә булды. Һич онытылмас якын дус, киңәшче, олы иптәш. Безнең күңелләрдә ул шулай яши.

Кәрим Тинчуринны ялгыз килеш күз алдына китерү дә читен. Ул һәр вакыт кешеләр арасында булды.

Менә ул театрга килеп керә. Без барыбыз аның тирәсенә җыелабыз. Чөнки аның нинди дә булса яңалык алып киләсен белеп торасың.

— Менә яңа пьесаның эскизларын алып килгән идем әле, — ди ул. — Акка күчереп чыкканчы, бергәләп укысак ничек булыр икән?

— Укыйк, укыйк, — дибез без.

Без, «Сәйяр» труппасы артистлары, Тинчурин тирәсенә түгәрәкләнеп утырабыз һәм аның укыганын йотлыгып тыңлыйбыз. Аның пьесалары чыннан да бик кызыклы, матур, тормышчан булалар.

Без аларның эшләнеп бетмәгән җирләрен, уңышсыз урыннарын тапсак, шунда ук фикеребезне әйтә идек. Тинчурин һәр сүзне бик җитди кабул итә. «Мин моны уйлармын әле, бу җирен чыннан да карарга кирәк икән», — дип, кулъязмасының читенә язып куя. Хәтта минем кебек әле балалыктан да чыгып җитмәгән артистлар әйткәнне дә игътибарсыз калдырмый иде. Ә без исә, Кәрим Тинчурин белән бергәләп пьеса язган кешеләрдәй, горурланып йөри торган идек.

Ул пьесаларында кайбер рольләрне аерым артистларга атап яза иде. Мәсәлән, «Җилкәнсезләр» пьесасындагы Оркыя — Нәфыйга Арапованы, ә Дилбәр роле минем күздә тотып язылган иде. Соңрак, «Зәңгәр шәл»дәге ишан ролен Зәйни Солтанов өчен язды.

Режиссер Кариев һәм Тинчурин белән бергә иҗат итү — олы бәхет иде. Дөнья булгач төрле хәлләр була. Кайчак репетициягә киләсең, ә рольгә кереп булмый. Берни эшлисе килми. Һичнәрсәгә күңел бармый. Шундый вакытларда Тинчуринны күрсәң, дөнья яктырып киткәндәй була. Ничә еллар бергә эшләп, мин Тинчуринның чытык йөзле чагын, ачулы карашын күрмәдем. Ул һәр вакыт якты чырайлы була иде. Сиздерми-төрттерми генә сиңа рольнең асылын, образның характерын ачып бирә. Син ул фикерләрне Тинчуриннан алгандай түгел, үзең уйлап тапкандай буласың. Дөньяның бөтен борчуларын онытып, рухланып, дәртләнеп эшли башлыйсың. Вакыт узганы сизелми, соңыннан бер-береңнән аерыла алмый аптырыйсың.

«Алар өчәү иде» дигән пьесада шундый бер кечкенә генә эпизод бар иде. Мин эшләпә киеп карыйм һәм:

— Кия-кия зураер, кия-кия зураер! — дип, үз-үземне юатам. Күрәсең, бу эпизод Кәрим Тинчурин күңеленә бик хуш килгәндер, ул кет-кет көлә — рәхәтләнеп, чын күңелдән, тыела алмый көлә. Ә мин әйтеп бетермәслек бәхетле: минем уйлаганны Кәрим Тинчурин кабул итә. Бу юлы яратты. Ошатмаган чаклары да була иде, билгеле. Андый чакта ул дәшми, уйга чума. Без аның янына барабыз да менә бу рольне мин шулайрак аңлыйм дип сөйләп бирәбез. Ә ул, «уйла әле, уйла, болайрак түгелме», ди. Уйланасың, эзләнәсең, табасың... Тагын сөенеч.

Кәрим Тинчурин еш кына үзе дә сәхнәдә уйный иде. «Сәйяр» труппасында ул минем партнерым булды. «Җилкәнсезләр»дә ул Батырханны уйнады. Хәер, «уйнады» дип әйтү дөрес тә булмас, ул сәхнәдә яши иде. Ул образга шул чаклы керә, «Тинчурин бит әле бу» дигән уй башыңа да килми, аның чын Батырхан икәненә бернинди шигең юк. Һәм син дә аңа ияреп үзеңне онытасың. Дилбәр булып кына каласың. Андый партнер белән иҗат итүнең нинди зур бәхет икәнен артистлар бик яхшы аңлыйлар.

Аның «Ревизор»дагы Хлестаковын мин гомергә онытмам. Бу ялганчы, үз ялганына, үз уйдырмасына үзе ышанган кешене ул шул чаклы табигый ачып бирә ки, шул кадәр бирелеп, ихластан, ышандырып сөйли, сәхнәдәге образлар гына түгел, мин тамашачы буларак та Хлестаковка ышанып утырам.

Тинчурин сүзгә бай, аның башында бетмәс-төкәнмәс хикәяләр. Нindидер вакыйгаларны искә ала, кешеләрне сурәтли, ниндидер фикерләрне гомумиләштерә. Болар барысы да артистка иҗади азык, хыялга юнәлеш бирәләр. Шуңа күрә аның театрга килүен һәркем зарыгып көтә. Ул — күңел байлыгын юмарт өләшүчән кеше. Аның бөтен хәрәкәтләрендә, йөрешендә, кешегә мөрәҗәгать итүендә, артистка күрсәтмәләр бирүендә кешегә зур хөрмәт сизелә.

Уен-көлке ярата иде. Менә ул репетициядән соң күзлеген эзләргә тотына. Күзлеге аның маңгаена күтәрелгән була. Ул аны белә, ләкин шаярта. «Күзлегем кая соң?» дип бездән сорый... Менә җыелыш бара. Берәү урынсыз һәм күңелсез сөйли башласа, Кәрим ага, бик әдәпле генә, сөйләүчегә сиздерми генә, кәгазьдән күгәрченнәр ясап очырта башлый.

Кәрим Тинчурин — бөтен җаны белән тормыш сөючән кеше. Күзәтү сәләте анда бик көчле иде. Ул үзе күргән, тормышында очраткан кешеләрдән, ишеткән, күргән

вакыйгалардан сюжетлар кора, образлар тудыра. Мәсәлән, «Җилкәнсезләр» комедиясендә Кәрим Тинчурин үзе белгән, үзе аралашкан кешеләрне сурәтли. Безгә, артистларга, «Җилкәнсезләр»дәге күп кенә образларның прототиплары таныш, күбесен күреп белә идек.

Әмма моннан Кәрим Тинчурин тормыштагы вакыйгаларны сәхнәгә күчерүче гади фотограф дип нәтиҗә ясарга ярамый. Киресенчә, тормыш вакыйгаларының мәгънәсен тирән аңлаучы, киләчәкне йөрәге белән тоя белүче талантлы драматург иде ул.

Зур педагог Антон Макаренко үзенең шәкертләренә иң авыр профессия — чын кеше булу дигән фикерне әйткән. Кәрим ага турында сүз кузгатканда да Антон Макаренконың шул фикере искә төшә. Иң авыр профессиягә ирешкән чын кеше иде ул. Гүзәл кешелек сыйфатлары аның бай драматургиясендә, эшлекле, нәтиҗәле режиссерлыгында, ялкынлы артистлыгында якты чагылыш тапты.

Шуңа күрә дә без аны онытылмас, сокландыргыч Кәрим ага дибез.

## Карашлары киләчәккә төбәлгән

Таҗи Гыйззәтнең таланты Зәйни Солтанов һәм Кәрим Тинчурин йогынтысында ачыла. Элеккеге Самара хәрби округы каршындагы татар драма студиясендә иҗат эшен башлаган, әйбәт артист, талантлы драматург булып җитешкән Таҗиның иҗатына тулы анализ ясауны өстемә алмыйча, үзем күреп белгән берничә сыйфатын гына ачарга телим.

Таҗи Гыйззәт үзе язган пьесалардагы барлык рольләрне яттан белә иде. Аның әсәрләре буенча куелган спектакльләр бервакытта да, теге яки бу артистның авыруы сәбәпле, уйналмый калмадылар. Чөнки ул теләсә кайсы ир ролен уйнарга хәзер булып, сәхнәгә чыга алмаган артистны бик тиз арада алыштыра, ә спектакль ул көнне аеруча бер күтәренкелек белән уза иде. Бу хәлне мин Таҗи Гыйззәт үз әсәрләрен бөтен күңеле белән бирелеп иҗат итүеннән, андагы образларның язмышларын йөрәгеннән кичереп яшәвеннән, алардан аерылгысыз булуыннан килгәндер дип аңлыйм.

Таҗи Гыйззәт Кәрим Тинчуринның драматургия алымнарын җентекләп өйрәнә, аның иҗади принципларын үз әсәрләрендә дәвам итә иде. Кәрим Тинчурин кебек үк, Таҗи Гыйззәт тә музыкаль әсәрләрне булдыруга зур көч куйды. Салих Сәйдәшев белән бергә иҗат иткән «Наемщик», «Бишбүләк» кебек музыкалы драма әсәрләре сәнгатебез тарихы сәхифәләрендә билгеле бер урын алдылар. Халык тормышын чагылдырган тирән эчтәлекле драма һәм комедияләрендә артистлар рәхәтләнеп, ләззәтләнеп уйныйлар. Чөнки аларда вакыйгалар күп, ул вакыйгалар зур тизлек белән үсәләр. Сәхнәдә тормыш кайный, өзлексез хәрәкәт яши, көчле характерлар бәрелешәләр. Каһарманнарның сөйләшүләре үткен. Аз сүз белән күп мәгънә әйтелә. Кыскасы, иҗат өчен артистка мәйдан киң, материал мул.

Миңа Таҗи Гыйззәтнең бик күп әсәрләрендә уйнарга туры килде. Шундый бәхетле очрашуларның берсенә генә тукталып үтәсем килә: Октябрь революциясенең егерме еллыгына режиссер Гомәр Исмәгыйлов җитәкчелегендә «Ташкыннар» драмасы куелды. Миңа бу спектакльдә большевик Мирвәли хатыны Айсылу роле тапшырылды. Башта ул роль эпизодик — сәхнәдә ара-тирә генә чагылып үтә торган роль булып күренде. Монда уйнарга бер нәрсә дә юк дип борчылуга төштем. Ә эшкә керешкәч, Айсылуның матур образ икәнен тоеп алдым. Саф мәхәббәт белән яшәүче, турылыклы, гадел яшь татар хатыны образын — Айсылуны гәүдәләндерү өчен Таҗи Гыйззәтнең күп мөмкинлекләр бирүен аңладым. Һәм Айсылу образын егерме өч ел яратып уйнап килдем. «Ташкыннар» драмасындагы образларны иҗат итеп, байтак артистларыбыз үзләренең сәхнә осталыкларын тулы ачуга, камилләштерүгә ирештеләр.

Драматургның уңышлы иҗат итүенең сере нәрсәдә соң? Бу сорауга җавапны әдәбият белгечләренең фәнни хезмәтләреннән табарга була. Аларга өстәп шуны әйтәсем килә: Таҗи Гыйззәт, Кәрим Тинчурин кебек үк, артистлар фикерен, аларның «догасын» алмый торып, сәхнә әсәрләрен халыкка чыгармый иде. Әсәр өстендә кат-кат эшли. Башта әсәрне артистлар коллективында укый, артистларның, режиссерларның

фикерен тыңлый, әйтелгән киңәшләрне күңеленә салып, пьесаны кире алып китә, төзәтә. Яңадан коллектив хөкеменә тапшыра, яңадан теләкләр, тәкъдимнәр әйтелсә, кабат төзәтүгә керешә. Кыскасы, автор ярты юлда тукталып калмый. Сәхнәдәшләре: «Булган бу», дигәнгә кадәр пьеса өстендә эшләүне дәвам иттерә иде. Драматургның иҗаты бүген дә безне дулкынландыра икән — моның сере, минемчә, сәхнәдәшләренең, әдипләрнең тәнкыйтьләренә колак салуда. Тәнкыйтьне тыңлый белү ул үзе бер осталык. Ә Таҗи Гыйззәт шушы хакыйкатьне үзләштергән акыл иясе иде. Пьеса язганда ул артистларның иҗади үзенчәлекләрен искә алып, аларның сәхнәдә уйнауларын күзаллап, образларын аерым артистларга адреслап тудыруы безгә билгеле.

Сугыш елларындагы һәм гомеренең соңгы көннәрендәге очрашулар искә төшә: 1942 елның көзе. Октябрь көннәренең берсе. Мин Бауман урамы буйлап барам. Каршыйм, каршы якта, «Татарстан» кинотеатры яныннан Таҗи Гыйззәт узып бара. Башы түбән иелгән, адымнары бик авыр, һичкемне күрми. Миңа аның болай баруы бик сәер, көтелмәгән хәл булып тоелды. Урам аркылы булса да ишетерлек итеп аңа дәштем. Игътибар итмәде. Тагын дәштем, аптырап, каршына чыктым. Таҗи тукталып калды. Башын күтәрде. һәм як-ягына каранды да миңа таба килә башлады.

— Таҗи, ни булды сиңа? — дим.

Ул миңа тутырып карады да бик авырлык белән сөйли башлады. Күрәм, аның бугазына төер тыгыла. Сүзен зур паузалар белән, өзеп-өзеп тын алып кына әйтә:

— Хәбәр алдым, улым Үзбәк танк эчендә янып үлгән. Ул бит егерме өченче елны туган егет. Бик яшь иде әле. Унтугыз яшьтә... Синең улың да, Фатыйма, танкист, Фоатыңа хат яз. Иң авыр бәрелешләрдә дә гомерен сакларга тырышсын. Үлем котылгысыз булса да, танк эчендә калмасын.

Мин Таҗиның кайгысын уртаклашам. Ул көннәрдә аларда ешрак булырга тырышам. Таҗи үзен нык тота. Эшкә бирелергә, эш белән онытылырга тели.

1943 елның ноябрендә, Киев шәһәрен азат иткәндә, минем улым лейтенант Фоат һәлак була. Кайгы хәбәрен алуга театр коллективы мине үз игътибарыннан калдырмый. Иң авыр көннәрдә Таҗи Гыйззәт сүзләре мине кайгымнан айныта.

— Фатыйма, син сәхнә кешесе, синең хезмәтеңне халык көтә. Кайгыдан сыгылып төшү — ул дошманга бирелү кебек сүз. Үзеңне кулга ал. Синең кебек улларын югалткан меңләгән аналарның, аталарның күңелен күтәрү, аларны рухландыру өчен эшләргә, иҗат итәргә кирәк. Фоатның якты истәлеге өчен эшләргә кирәк. Бирелмик кайгыга, Фатыйма, бергә эшлик.

Таҗи шулай кешеләрнең йөрәкләренә үтеп керә, аларның фикерләрен иҗатка, киләчәккә юнәлдерә белә иде.

1954 елның ахыры. Таҗи авыру. Без аның хәлен белергә бардык. Гореф-гадәт буенча чәй әзерләнде. Читенлек белән генә булса да Таҗи табынга килеп утырды. Авыруы турында сөйләми. Аның күңелендә иҗат ялкыны.

— Фатыйма, беләсеңме, нәрсә турында уйлыйм. Синең өчен бер бик шәп образ тудырасым килә. Яңа әсәремдә син уйнарлык тагын бер образ булсын, дим.

Ул һәр вакыт шулай, үзе яшәгән артистлар коллективы, аның аерым кешеләре турында уйлый иде. Таҗи белән янәшә булу — ул сәнгатьнең киләчәге, яңа әсәрләр турында уйлану, хыяллану. Драматург һәм артист Т. Гыйззәтнең карашлары һәр вакыт киләчәккә төбәлгән иде.

# ТОРМЫШ һӘМ ӘДӘБИЯТ

**Яшь тәнкыйтьчеләрнең Ә. Еники белән әңгәмәсе**

*«Казан утлары» журналы каршындагы яшь рецензентлар түгәрәге членнары күренекле язучыбыз Әмирхан Еники белән очраштылар. Ул яшьләргә бүгенге тормыш һәм әдәбият турында сөйләде, түгәрәк членнарының бик күп сорауларына җаваплар бирде. Шул әңгәмәнең язмасын урнаштырабыз.*

**Сорау.** Әмирхан ага, без соңгы вакытларда «тормыш үзгәрә» дигән сүзне бик еш куллана башладык. Тормыш, чыннан да, үзгәрә һәм бу үзгәрешкә фән-техника революциясе дә торган саен ныграк тәэсир итә бугай. Ләкин безне икенчерәк нәрсә кызыксындыра: шундый үзгәрешләр тәэсирендә халыкның рухи тормышы да башкачарак төс ала, катлаулана бит. Сез халкыбызның рухи тормышында ниндирәк яңа сыйфатлар сизәмлисез? Ничегрәк үзгәрә ул?

**Җавап.** Бик дөрес, фән-техника революциясе тәэсирендә тормыш үзгәрә. Аның никадәр нык үзгәргәнен без, олы буын кешеләре, аеруча ачык күрәбез. Мисалларын бик күп китерергә мөмкин. Әйтик, без малай чакта ат белән «җенләнә» торган идек. Шәп атка атланып яки җигеп йөрү безнең хыялыбыз иде. Ә хәзерге яшьләрнең хыялында — машина. «Москвич», «Жигули», «Волга» — аларның менә шуларны «иярлисе» килә. Хәер, бүген бу хыял гына түгел инде. Безнең Казанда, мәсәлән, борын вакыттагы атлы кешеләргә караганда, хәзер машиналы кешеләр күбрәктер дә әле. Авыллар арасында да хәзер агайлар мотоциклга атланып чабалар. Үзенең «Жигули»е яки «Москвич»ы булганнар да аз түгел.

Икенче бер мисал. Мин Дим буенда үстем. һәр җомганы без, Дәүләкән яшьләре, Дим өстендә ишкәкле көймәләргә утырышып, гармунга кушылып, җырлап йөрергә ярата идек. Бик күңелле, бик хозур була торган иде. Хәзер дә мин, ел саен булмаса да, еш кына Дәүләкәнгә кайтып, берничә көн торып киткәлим. Ләкин инде Дим өстендә гармун тавышы яңгырамый, җырлап йөрүче яшьләр дә юк. Хәзер инде анда да, Дим ярларын ишеп, моторлы көймәләр чаба... Хәер, нигә ул кадәр еракка китәргә? Менә монда, үзебезнең Кабан өстендә дә кайчандыр — без яшь чакларда — егетләр, кызлар гармун тартып, җырлап йөриләр иде. Ә хәзер сез аны күрәсезме, ишетәсезме? Юк бит, гүя андый күңел ачу гадәтләре булмаган да шикелле... Хәзер инде яшьләр музыканы иңнәренә асып йөриләр. Транзистор һәм магнитофоннар заманы килде... Кыскасы, техника безнең рухи дөньябызга керде, көндәлек тормышыбызга керде. Мин инде көнкүрештә кулланыла торган техниканы санап та тормыйм. Билгеле, бу хәл кешеләрнең нәрсәдән кызык, ямь табуын үзгәртте, теләкләрен, зәвыкларын да үзгәртте. Искеләр бетә, яңалар туа — табигый процесс. Ихтимал, бу процесста кайбер кадерле нәрсәләр дә югала торгандыр (һәрхәл-

дә, безнең кебек олылар өчен), ләкин яшь, яңа буынның моны бөтенләй сизмәве дә мөмкин.

Әмма тормыш шартлары фән-техника революциясе нәтиҗәсендә никадәр генә үзгәрмәсен, шуңа ияреп кайбер эстетик ихтыяҗлар башка төс алмасын, халыкның рухи дөньясындагы төп, нигез сыйфатлар үзгәрми, саклана. Болар — намус, вөҗдан, гаделлек, дөреслеккә омтылу, туган илгә мәхәббәт, эшкә аңлы мөнәсәбәт, интернационалист булу кебек югары мораль сыйфатлар...

Әйтергә кирәк, бу сыйфатлар халыкта электән үк бар иде, алар буыннан-буынга күчеп килә, ә безнең шартларда исә аларны үстерү, көчәйтү тәрбиясе дә өзлексез алып барыла. Дөрес, кеше табигатендә начар сыйфатлар да (комсызлык, көнчелек, ялагайлык, икейөзлелек һәм башка шуның кебекләр) җитәрлек әле. Ләкин өстенлек, һичшиксез, беренчеләр ягында. Кыскасы, халык рухи таза, рухи нык. Шулай булмаса, җәмгыять яши дә алмас иде.

**Сорау.** Соңгы елларда басылып чыккан проза әсәрләренең кайсыларын иң уңышлылары дип саныйсыз? Ни өчен уңышлы дип саныйсыз һәм ул әсәрләрдә соңгы елларның рухи атмосферасы ни дәрәҗәдә чагыла?

**Җавап.** Соңгы елларда күп кенә роман, повестьлар басылып чыкты. Алар арасында шактый уңышлы язылганнары бар, шулай ук йомшаклары да юк түгел. Ләкин, минә бусы барысыннан да өстенрәк, көчлерәк дип, аерым бер әсәрне тотып күрсәтергә кыенсынам. Чөнки бүгенге әдәбиятның гомуми дәрәҗәсеннән бик нык аерылып торганы юк, минемчә. Шулай да соңгы бер-ике ел эчендә басылып чыккан әсәрләр арасыннан минем үземә иң ошаганы Аяз Гыйләҗевнең «Язгы кәрваннар» дигән повесте булды. Сугыш елларын тасвирлаган бу әсәрдә, бик гыйбрәтле контраст рәвешендә, тормышның авырлыгы, бөлгенлеге, газабы белән бергә, колхоз кешеләренең рухи ныклыгы, бердәмлеге, үз бурычларын аңлаулары, иң кыен шартларда саф күңелле, изге җанлы булып кала алулары дөрес һәм бик табигый итеп күрсәтелгән. Кешелекле әсәр дияр идем мин аны. Ә кешелекле әсәр яши ул, һәр вакытта яхшылыкка өндәп тора. Сез әйткән «соңгы елларның рухи атмосферасына» да уңай йогынты ясамыйча калмый ул... Билгеле, бу минем шәхси фикерем.

**Сорау.** Сезнеңчә, бүгенге әдәбият халкыбызның нинди күңел теләкләрен үти алмый? Әдәбият замандашыбызның күңел дөньясыннан нык артта кала диләр. Сез бу фикер белән килешәсезме?

**Җавап.** Бу сораудагы «халык» сүзен «укучылар» белән алыштыру дөресрәк булмас микән?.. Минемчә, укучыларның күңел теләкләрен безнең әдәбият үти аламы-юкмы — сүзне шушы хакта алып барырга тиешбез. Ләкин моны кем генә өзеп әйтә алыр икән? Мин үзем бөтен укучылар исеменнән җавап бирергә җөрьәт итмәс идем. Бердән, укучы ул бик төрле — аңы белән дә, зәвыгы белән дә. Икенчедән, укучы кемне, нәрсәне яратып укый, ни тели, ни көтә ул язучыдан — без моны ачык кына белмибез. Чөнки бу хакта бүген кулыбызда бер төрле дә төгәл мәгълүмат юк. Димәк, башта укучыларның үзләреннән сорарга кирәк. Ә бу эш, ягъни укучыларның теләкләрен, зәвыкларын өйрәнеп белү эше, бездә беркем тарафыннан да үткәрелми диярлек. Әмма бик кирәкле эш. Һич югы, безнең «Казан утлары» үзенең подписчикларына анкета таратып карасын иде — сиксән-туксан мең кешенең теләк-фикерләрен белер идек... Ләкин бер бәхәссез хакыйкать бар: кеше талантлы язылган әсәрне яратып укый, талантсыз язылганны — көчләнеп кенә. (Күп очракта укып та тормыйдыр әле..) Менә шуннан инде гади генә бер нәтиҗә дә ясарга була: сәнгатьчә язылган әсәр укучының күңел теләген үти, ә начар язылган зәгыйфь әсәр, билгеле, үти алмый.

Шушы әйткәннәрдән чыгып, соравыгызның икенче яртысына да җавап бирергә мөмкин. Ләкин аны беркадәр ачыклыйсы бар. Сез: «Бүгенге әдәбият замандашыбызның күңел дөньясыннан нык артта кала диләр. Сез бу фикер белән килешәсезме?» дип сорыйсыз... Моны ничегрәк аңларга? Әдәбият замандашыбызның күңел дөньясын тиешенчә ачып бетерми дипме, әллә булмаса, күңел таләпләрен (яки теләкләрен) канәгатьләндерә алмый диепме?.. Әгәр сүз «ачу» турында барса, әйе, дияр идем мин, безнең әдәбият замандашыбызның күңел дөньясын бөтен тирәнлеге һәм катлаулыгы белән ачуга ирешә алганы юк әле. Һәм моңа артык гаҗәпләнергә дә

туры килми. Кеше күңеле—дәрья, диләр. Бигрәк тә безнең чор шикелле һәм кызыклы, һәм катлаулы, һәм киеренке бер заманда яшәүчеләрнең күңел дәрьясы бик тирән булырга тиеш. Билгеле, «дәрьяның» төбенә җитәр өчен язучыдан бик зур талант та, акыл да һәм, аеруча, тормышны, кешеләрне бик нык өйрәнү, белү дә таләп ителәдер инде. Ә андый язучылар күп булмый алар.

Әгәр дә сүз «канәгатьләндерә алмау» турында барса, мин моңа җавап бирдем шикелле инде. Әйе, ышандырырлык, дулкынландырырлык, чын ләззәт бирерлек әсәрләр күп чыкмый шул әле... һәм бу да гаҗәп түгел, чөнки чын мәгънәсендә яхшы, көчле әсәр еш тумый ул. «Ширпотреб» товары да хәзергә бөтен сорауны да үтәп бетерә алмый. Әнә сарык тиресеннән теккән тун хәзер бик дефицит диләр. Ә бит әсәр язу — тун тегеп чыгару түгел. Әсәр ул — рухи «товар».

**Сорау.** Тормыш — язучы күңеле — әдәбият. Әдәбиятыбызның тормыштан артта калуына шушы компонентларның кайсы «гаепле?»

**Җавап.** Бу сораудагы «гаепле» сүзе, гәрчә, тырнаклар эченә алынган булса да, мине сагаерга мәҗбүр итә. Чөнки ул «әдәбиятыбыздагы бүгенге хәл өчен» тормышымы, язучымы гаепле дигән төстәрәк ишетелә. Нигә, әдәбиятыбызның хәле шулай бик авырмыни? Миңа калса, бер дә алай түгел шикелле. Соңгы 20—25 ел эчендә безнең әдәбият шактый нык үсте. Күп кенә яңа исемнәр өстәлде. Алар арасында бик үзенчәлекле чын талантлар да бар. Бу хәл әдәбиятны сизелерлек дәрәҗәдә җанландырып җибәрде. Элек, мәсәлән, ике-өч елга бер роман килеп чыкса, хәзер елына берничә роман чыгып тора. Повестьлар тагы да күбрәк. Журналларыбызның тиражы ничәмә мәртәбәләргә артты, китаплар тиражы да әкренләп булса да арта килә. Әсәрләрнең күп язылуы — ул темаларның да төрләнүе, тормышны да киңрәк чагылдыру дигән сүз. Әлбәттә, тагы да күбрәк язылса, бик әйбәт булыр иде. һәрхәлдә, сан ягыннан эшләребез канәгатьләнерлек дияргә ярый. Икенче мәсьәлә — сыйфат ягы. Ләкин бу хакта мин алдарак әйттем инде, тик өстәп шуны гына әйтәсем килә: безнең кимчелекләрдә тормышның бер гаебе дә юк. Тормыш бит ул — объектив чынбарлык. Язасыңмы-язмыйсыңмы, ул, тормыш, казакъ әйтмешли, үз агымы белән бара җатыр... Бөтен эш безнең үзебездән тора — «язучы күңеленнән!»

**Сорау.** Соңгы елларда басылып чыккан әсәрләрнең сәнгать дәрәҗәсе нык түбәнәя, сыйфаты төшә бара, диләр. Сез бу фикер белән килешәсезме? Килешсәгез, ни өчен түбәнәя бара дип уйлыйсыз?

**Җавап.** Тулаем алганда, бик үк килешеп бетәсе дә килми. Ара-тирә сәнгатьчә язылган яхшы әсәрләр дә килеп чыккалый бит. Әмма ләкин икърар итмичә дә булмый — урта кул һәм зәгыйфь әсәрләр шулай да күбрәк чыга. Алар, билгеле, яхшы әсәрләрне басып китәләр. Моның сәбәбе, минемчә, тәнкыйтьчеләр һәм, бигрәк тә, язучыларның үзләре тарафыннан таләпчәнлекнең кими баруында булса кирәк... Әсәрне язу бар, ясау бар. Менә без барыбыз да ясарга шактый остардык. Шуның аркасында шома эшләнгән әсәрдән талантлы язылган әсәрне аера алмый башладык. Гадәттә, яңа әсәрнең темасына, эчтәлегенә бөтен игътибарны биреп, аның әдәби сыйфатына, сезнеңчә әйтсәк, сәнгать дәрәҗәсенә юньләп күз дә салмыйбыз яки ул ягы турында бик аз сөйлибез. Билгеле, тема белән эчтәлек әсәрне бар иткән нәрсә, аларның әһәмияте бәхәссез. Ләкин әдәби әсәр, барсыннан элек, сәнгать әсәре бит әле ул. Сәнгать дәрәҗәсе түбән, зәгыйфь булса, бик кирәкле темага язылган әсәр дә озак яши алмый, онтыла, төшеп кала. Күптәнге хакыйкать, ә шулай да кабатларга туры килә. Югыйсә, без, еш кына шушы хакыйкатьне онытып, кайчагында урта кул әсәрне дә чөеп мактарга тотынабыз.

Яхшы язу — намус эше. Шуңа карап, язучының үз иҗатына мөнәсәбәтен белергә була. Ә бу мөнәсәбәт, үз нәүбәтендә, бер генә максат белән билгеләнә: язганыңны укучы кабул итсен, укучы яратсын. Шуңа күрә дә бит кайчагында ак кәгазьгә соңгы тамчы каныңны сыгып тамызырдай буласың!.. Арттырып җибәрү дип уйламагыз... Хәер, төрле кеше төрлечә язадыр инде. Ләкин җиңел генә язып, яхшы әсәр килеп чыгуына мин үзем ышанмыйм.

**Сорау.** Безнең әсәрләргә тормыш дөреслеге җитми дип булмый. Болай тыштан бар да дөрес кебек. Ләкин алар никтер күңелне тартмый, укылмый. Иң кызганычы шунда, алар безне бер яктан да баетмый да, дулкынландырмый да. Нишләп алай икән?

**Җавап.** ...Күңелне тартмый, укылмый дисез. Ләкин «болай» тыштан бар да дөрес кебек» тә икән. Хикмәт нәрсәдә соң монда?... Бәлки шул «кебек»тәдер? Ягъни чын, табигый дөреслек түгел, ә тартып-сузып китерелгән ясалма «дөреслек» кенәдер? Укучы бит аз гына ялган, фальшь сизсә дә китаптан суына башлый һәм еш кына ул әсәрне укып бетермичә ташлый да. Димәк, дөреслеккә ышану кирәк, ә ышану — дөреслек тормышчан, табигый булган чакта гына мөмкин. Бу табигыйлек әсәрнең һәр сүзеннән сизелеп торырга тиеш.

Тик сез моны натурализм дип аңлый күрмәгез. Юк, ул җансыз фото түгел, ул тормыш, тере тормыш... Үзе табигый, үзе сәнгатьчә — менә хикмәт нәрсәдә. Классик әдәбиятның яки совет әдәбиятының югары үрнәкләрен укып карагыз, сез аларда бик оста, сәнгатьчә эшләнгән, шунлыктан бик табигый булып тоелган чын тормыш дөреслеген күрерсез. Әгәр шуның өстенә бу дөреслек тормышның бераәр яңа, гыйбрәтле ягын да ачса, ул чагында әсәр укучыны аеруча кызыксындырачак һәм мавыктырачак... Билгеле, укыла торган әсәрнең сыйфаты болар белән генә чикләнми. Талантлы язылган әсәрнең нечкәлекләре күп аның. Үзенә хас эчке җаны, сулышы, аһәңе дә була әле аның. Шик юк ки, андый әсәр күңелне дә тартачак һәм укылачак та.

**Сорау.** Шома язылган, әмма төссез әсәрләр белән чагыштырып караганда, сезнең әсәрләрнең зурлыгы, көче тагын да ачыграк күренә. Аларда халкыбыз, аның чын кешеләренең рухы бик дөрес һәм тирән сурәтләнә. Шундый әсәрләрнең берсе — «Әйтелмәгән васыять». Аның язылу тарихын һәм бу әсәргә бәйләп бераз гына үзегезнең иҗат лабораториягезне ача алмассызмы?

**Җавап.** Рәхмәт яхшы сүзләрегез өчен!.. Инде «Әйтелмәгән васыять»нең лабораториясенә килгәндә, монда әллә ни ачарлык нәрсә дә юк шикелле. Әсәрнең темасын миңа мәрхүм Баязит Бикбай биргән иде. Дөресрәге, бер башкорт корткасының аяныч үлемен сөйләгән иде. Уйла, бәлки язарсың, синең каләмгә туры килә торган нәрсә бу, дигән иде... Ләкин минем тиз генә эләктереп алып, язып ташлый торган сәләтем юк, кызганычка каршы!.. Бер ел-ел ярым вакыт узгач кына мин аны тәвәккәлләп язарга керештем. Әле керешкәнчегә кадәр үк бер мәсьәләне хәл итү турында нык кына уйланырга туры килде: вакыйганы башкорт җирлегендә язаргамы, әллә булмаса татар җирлегенә күчерергәме?.. Ләкин Баязит Бикбай нәкъ менә башкорт корткасы турында, исемен дә «Акъәби» дип атап сөйләгәч, мин шулай да җирлеген үзгәртмәскә булдым. Башкорт авылын, башкорт картларын яшьтән үк күреп үскәнгә күрә, алар миңа яхшы таныш һәм якын иде. Һәрхәлдә, язып чыга алуыма ышандым. Шуның өстенә әсәрдә кузгатылган мәсьәләләр бер башкортка гына карамый, алар бер үк дәрәҗәдә башка халыкларга да хас нәрсәләр. (Әйтик, туган җиргә мәхәббәт, туган халкыңны онытмау, олыларга хөрмәт саклау, күңел сизгерлеге һәм күңел сафлыгы — болар бит барсы да гомум кешелек сыйфатлары...) Кыскасы, «Әйтелмәгән васыять» әнә шулай язылды. Күптән басылып чыкты, яшн ул. Дөрес, әсәр турында төрле фикерләр булды, берәүләр аны яратып кабул итте, икенчеләр кабул итәргә теләмәделәр. Кем хаклы, кем хаксыз? — бу кадәресен инде вакыт хөкеменә калдырырга туры килә. Вакыт — иң гадел судья!

**Сорау.** Сезнең иҗатта үзегез күргән, ишеткән вакыйганың һәм күңел фантазиягезнең роле ничегрәк? Аларның кайсы күбрәк «эшли» һәм ничегрәк «эшли?»

**Җавап.** Ачык кына әйткәндә, мин үземне фантазиягә бай язучы димәс идем. Миңа «тыштан» кечкенә генә булса да берәр этәргеч кирәк, шуннан соң гына минем хыялым эшли башлый. Күпчелек әсәрләрем я үзем күргән, үзем кичергән, я кешеләрдән ишеткән хәл-вакыйга нигезендә тудылар. Әйтергә кирәк, ишеткән-күргәннәрдән чыгып язганда аяк астыңны ничектер ныграк тоясың, чөнки башлап китәр өчен оеткы бар, нигез бар. Ләкин шулай да «ишеткән-күргән» ул бары этәргеч кенә, ә калганы инде хыял эше, күңел эше.

**Сорау.** Зөфәр Сабитовны сез кайдан, ничегрәк табып алдыгыз?

**Җавап.** Зөфәр Сабитовны табуы читен булмады. Алар бар иде һәм хәзер дә әле беткәннәре юк, минемчә. Ләкин Зөфәр кебек кешеләр бары сәүдә-тәэминат тирәсендә генә йөриләр дип уйламаска кирәк. Аларны барлык тармакларда да очратырга була. Хикмәт бит профессиядә түгел, ә кешенең фәлсәфәсендә. Зөфәр Сабитов, мәсәлән, бөтен кешеләр өчен дә ниндидер уртак, тигез бәхет булуына ышанмый. Ул һәркем үз бәхетен үзе таба, үзе генә аның өчен көрәшә дип карый. Шуңа күрә

шәхси мәнфәгатьне иң беренче планга куя. Ни генә эшләмәсен, ул иң элек шуның үзенә нинди файда китерәчәген уйлап карый. Хәтерлисездер, Зөфәр Рәшидәнең театрга урнашырга бик теләвен белеп торса да, башта аңа ярдәм кулын сузарга ашыкмый. Ә инде Рәшидәгә өйләнергә уйлагач, ул бу ярдәмне күрсәтергә дә әзер. Ә бит ул Рәшидәне ярата, үзенә күрә «мәхәббәт!»

Дөрес, Зөфәр Сабитов акылсыз кеше түгел. Ул үзен тота белә, күрсәтә белә, уңганлык та, тырышлык та бар аңарда. Шуңа күрә ул яхшы исәптә дә йөри. Әмма аның табигатендә иң төп сыйфат — ул да булса саклык. Ул бөтен кешедән, бөтен нәрсәдән сакланырга тиеш. Бигрәк тә үзеннән «көчлеләр» белән конфликтка керүдән ул уттан курыккан шикелле курка. Бик сизгер һәм хәйләкәр кеше. Башкача булырга аңа ярамый да, чөнки ул үзенең асылын яшерергә тиеш, ә асылы аның — үзе өчен генә яшәргә теләүдә.

**Сорау.** «Гөләндәм туташ хатирәсе» исемле әсәрегезне язганда ниндирәк кыенлыклар белән очрашырга туры килде?

**Җавап.** Кыенлыклар булды, билгеле... Ләкин ул кыенлыкларны хәзер сөйләп торуның кирәге бар микән? Әсәр язылган инде, журналда басылып чыкты, халык укый. Минем эшем хәзер фикер көтү, фикер ишетү... Бәлки киләчәктә, әгәр кирәк булса, әсәрнең язылу тарихын сөйләргә дә туры килер.

Ә аның үзенә күрә тарихы бар. Эш шунда ки, әсәрне язуга этәргеч булган материал минем кулыма илленче елларның ахырында бер кергән иде инде. Ләкин ул чакта мин язудан тыелып торырга мәҗбүр булдым. Бары унбиш ел вакыт узгач кына әлеге материал яңадан минем кулыма керде һәм мин тәвәккәлләп язарга керештем. Кыскасы, ансат кына тумады әсәр, кыенлыклар шактый булды. Ләкин бу хакта сөйли башласам, сүз бик озынга китәчәк. Иң яхшысы — хәзергә сабыр итеп тору...

**Сорау.** Яшь язучыларга нинди өметләрегез бар? Алар безнең әдәбиятка нинди яңа сыйфатлар өстәргә тиеш дип уйлыйсыз?

**Җавап.** Өметләр зур. Иң элек яшьләрдән чын талантларның әдәбиятка күбрәк килүен телим мин. Бигрәк тә безнең прозабызга зур, кыю талантлар кирәк.

...Яшьләр картларны алыштыра — бу табигый күренеш. Яңа буын үзе белән ниндидер яңа сыйфатлар да алып килә — бу да бик табигый. Әмма шулай да яшь язучы әдәбиятның моңарчы тупланган байлыгыннан һәм сыналган яхшы традицияләреннән дә аерылмаска тиеш. Беләсезме, чиянең яшь үсентесе дә бит карт агачның тамырыннан тертеп чыга. Башта шул тамырдан туклана, аннары әкренләп үзе тамырлана, үсә, ныгый башлый. Инде тәмам үсеп, ныгып җиткәч, аның чияләре карт агачныкына караганда күбрәк тә, эрерәк тә була. Яшь буынның әдәбиятка килүен дә мин әнә шулай күз алдыма китерәм.

Дөрес, аларның әле тормыш тәҗрибәсе бай түгел, әмма, аның каравы, аларда дәрт, энергия, активлык җитәрлек. Алар тынгысызлар, күп уйланалар, эзләнәләр, үзара күп бәхәсләшә дә торганнардыр... Аннары намус һәм вөҗдан дигән нәрсә дә аларда бик сизгер, бик уяу булырга тиеш дип уйлыйм. Һәрхәлдә, яшь кешенең тормыштагы төрле хәлләргә реакциясе үткенрәк була торган иде. Әгәр бу шулай икән, хәзер әдәбиятка килүче яшь, талантлы, йөрәкле язучы да тормышка кыю керергә, тормышның зур кантарларын күтәрергә, каршылыкларын ачудан куркып тормаска тиештер инде. Тик идеалы саф, таза булсын! Идеалы саф, таза булган язучыга тормышның бер ягы да, бер проблемасы да хәтәр булып күренмәячәк.

Без бит ифрат катлаулы бер заманда, бөек үзгәрешләр, бөек эшләр чорында яшибез. Ә бөек эшләр әфсен укып өрүдән генә тумый ул. Бөек эшләр зур көрәштә, һәртөрле авырлыкларны җиңә-җиңә, бер-бер артлы чыгып торган проблемаларны чишә-чишә генә туа ала. Шулай түгелме? Димәк, язучы да тормышны әнә шулай бөтен катлаулыгы һәм каршылыгы белән ачарга да тиеш. Аннары әдәби әсәр конфликтсыз була да алмый, ә конфликт ул көрәш дигән сүз, яңаның искене, яхшының яманны җиңүе дигән сүз!.. Билгеле инде, бу көрәшнең үзәгендә кешеләр тора — кешеләрнең гамәлләре, хәрәкәтләре, теләкләре аша чагыла ул көрәш!

Әлбәттә, моның өчен язучы булачак кеше күп белергә, күп күрергә һәм бик күп укырга тиеш. Уку кирәклеген аеруча басым ясап әйтәсем килә, чөнки хәзерге шартларда төрле белемнәрдән хәбәрдар булу үзе бер заруриятка әйләнеп бара. (Әйтик, фән казанышларыннан бөтенләй хәбәрсез кешенең язучы була алуына ыша-

нуы да читен хәзер). Инде язучылык «һөнәренә» килгәндә, дөнья әдәбиятының һәм үз әдәбиятыбызның югары үрнәкләре белән ныклап танышмыйча торып, чын осталыкка ирешү турында уйларга да ярамый. Бер яхшы китап уку да күп нәрсәгә өйрәтә... Ә яхшы китап ул бары талант җимеше генә түгел, ә бик зур җаваплылык һәм таләпчәнлек нәтиҗәсе дә... Утәр әле дип кенә язу ул, асылда, халтурщик эше.

Бер уңайдан тагын шуны да әйтергә кирәктер, ахрысы: бездә хәзер роман исеме астында калын язу шаукымы көчәйде. Сыек булса да калын булсын!.. Әлбәттә, роман язу мактаулы эш. Әмма чын сәнгать әсәренең кыйммәте аның калын яки юка булуына карап кына йөрми. Үлемсез хикәяләр бар, күптән онтылган романнар бар, һәм, киресенчә дә — моның мисалларын әдәбият дөньясыннан күп табарга мөмкин... Хакыйкать исә бер нәрсәгә кайтып кала: романмы, хикәяме, әмма ул чын сәнгать әсәре булырга тиеш. Л. Толстой янында А. Чехов барын да онытмаска кирәк.

**Сорау.** Безнең буынның (хәзер 25—30 яшьлекләрнең) сезгә кайсы ягы ошамый? Бу буынның нинди әйбәт ягын күрәсез?

**Җавап.** Кеше олая барган саен, аның яшьләр белән арасы да әкренләп ерагая бара. Шуңа күрә хәзерге 25—30 яшьлекләрнең фәлән ягы ошамый дип әйтергә мин җөрьәт итмәс идем. Болай өзеп әйтер өчен читтән күреп йөри генә җитми, билгеле. Кешенең бит чын йөзе эчендә, эчке дөньясында. Ни уйлый алар, ни телиләр, нәрсә белән кызыксыналар, нәрсәгә омтылалар? 25—30 яшь инде ул аз гомер түгел, кешенең аякка баскан, формалашып җиткән чагы. Аларның кайсылары югары квалификацияле эшчеләр, кайсылары ВУЗ тәмамлаган белгечтер яки фән эшлеклеседер — хәзер бит кем булыйм дисәң дә юллар ачык. Һәрхәлдә, бүгенге яшьләр белемнәре һәм культуралары белән безнең заман яшьләреннән өстен торалар. (Ә яшәү шартлары ягыннан безнең еллар белән чагыштырып та булмый — нужа дигән нәрсә онтылды диярлек). Кыскасы, бүгенге яшьләргә сокланып карарга була. Шулай да минем аларның колагына гына бер сүз әйтәсем килә: белгеч яки галим булу, хәтта язучы булу да авыр түгел, әмма чын кеше булу шактый читен эш. Уйлап карагыз!

**Сорау.** Сер булмаса, хәзер үзегезнең ниндирәк әйбер язуыгыз турында берничә сүз әйтә алмассызмы?

**Җавап.** Алдан шауларга яратмыйм. Хәер, дөресен генә әйткәндә, шауларлык эшем дә юк әле хәзергә. Уйланып кына йөрим.

**Сорау.** Әдәбиятка килергә уйлаган яшьләргә нинди теләкләрегез бар?

**Җавап.** Теләкләрем шул: талантың һәм көчле теләгең булып, инде әдәбиятка килгәнсең икән, дан-дәрәҗә турында уйламый тор, күбрәк укучың турында уйла, борчыл. Син аңа белгәнеңне, ышанганыңны яз, ул да сиңа ышансын. Заманнан артка калма, тормыштан аерылма — бу синең иҗат чыганагың!.. Әдәби осталыгыңны камилләштерү турында көн-төн кайгырт, эзлән, тырыш. Таләпчәнлек, тагын бер мәртәбә таләпчәнлек! Соңыннан бер әсәрең өчен дә үкенерлек булмасын!

**Сорау.** Әмирхан ага, соңгы сорау — ә шулай да язучы өчен иң кирәкле сыйфат, аны заман намусы булган әдәбиятның олы язучысы дип санарлык, аны халык күңеленә иң якын язучы итәрдәй бер төп сыйфат, кеше шәхесенең бер иң көчле ягы ул — нәрсә?

**Җавап.** Шактый четерекле сорау... Ни диеп җавап бирергә? Хикмәт монда талanttадыр инде, дөресрәге, талантның үзенчәлегендә... Чөнки бик талантлы булып та халык күңеленә иң якын язучы була алмаска мөмкин. Бәлки мин әйткән үзенчәлек халык күңелен бик нечкә, бик дөрес сизә белүдәдер?! Менә безнең Тукаебыз бар. Шул ук вакытта аның заманында башка зур талантлы шагыйрьләр дә булган бит әле... Әмма ни өчендер бер Тукай халык күңеленә иң якын шагыйрь булып калган. Ни өчен?.. Мотлака, әнә шул халык күңелен бик нечкә сизә алу, халыкның иң тирәндә яткан өмет-теләкләрен «күрә» алу кодрәтенә ия булуындадыр инде... Башка җавабын таба алмыйм, егетләр, кичерәсез!

Әңгәмәне **МАНСУР ВӘЛИЕВ** язып барды.

# ҮЛӘН ЯФРАКЛАРЫ

Яхшы итеп эшләнгән калын, пөхтә китап. Тышлыгында — куе яшел үләннәр һәм эре ак хәрефләр белән язылган сүзләр: «Үлән яфраклары». Тышлыкның эчке ягына урнаштырылган фотоурәсемнән ак сакаллы, ак чәчле, сабыр һәм үткен карашлы, кай ягы беләндер борынгы китаплардагы пәйгамбәрләрне хәтерләтүче бер карт карап тора. Бу — Уолт Уитменның татар телендә чыккан беренче шигырь җыентыгы [1].

Татар укучылары Америка әдәбиятының М. Твен, Д. Лондон, Т. Драйзер кебек классикларын яхшы беләләр һәм аларның әсәрләрен күптән инде үз телләрендә укыйлар. Бөек Уитменның шигырьләре исә моңарчы татар теленә генә түгел, безнең илдәге башка төрки телләргә дә бөтенләй диярлек тәрҗемә ителмәгән иде. Моның, әлбәттә, үз сәбәпләре бар.

Берьяктан, тәрҗемәчеләрне Уитмен поэзиясенең образлар системасы һәм аның ритмикасының тәрҗемә өчен зифрат кыен булуы куркыта. Уитменның иректе шигыре жанр һәм форма кысаларын, нинди дер калыплашкан кануннарны белми дә, танымый да. Ул я, тау елгасы кебек, ашкынып алга ыргыла, я, ташу вакытындагы елга кебек, күз күрмәстәй киңлекләргә җәелә. Уитмен шигырьләрендәге «прозаизмнарны» бөтен шигърилеге белән бирү өчен, тәрҗемәчегә Америка шагыйренә тиң сулыш киңлегенә, табигый интонация һәм эчке энергиягә ия булу кирәк. Аның әсәрләрен силлабик шигырь төзелешенә нигезләнгән, шигырь юлларында иҗекләр төгәллеген сакларга омтылган төрки телләргә тәрҗемә иткәндә хәл тагын да катлаулана.

Икенче яктан, теге яки бу күләмдә Шәрык традицияләрендә тәрбияләнгән, хатын-кыз матурлыгын һәм табигатьне үтә сак мактауга гадәтләнгән, гөлчәчәк, сандугач, ал таң, былбыл кебек традицион сурәтләргә ияләнгән укучыларга Уитмен шигырьләрендәге ачыктан-ачык бәдәни мотивлар, көчле урбанизм, тән культы артык кыю һәм сәер тоелырга мөмкин. Кыскасы, укучыларга Уитмен поэзиясен кабул итәрлек дәрәҗәгә (тәрҗемә культурасы турында сөйләп тә тормастан) үсеп җитәргә кирәк иде әле.

Шагыйрь М. Шабаев Уитмен шигырьләрен тәрҗемә итү өстендә күп еллар эшләгән. Яратып, мавыгып, җентекләп эшләгән. Бөек демократка мәхәббәт һәм аның таланты алдында баш ию тәрҗемәнең һәр юлыннан сизелеп тора. Шунсыз тәрҗемәче мондый катлаулы эшне башкарып чыга алмаган да булыр иде. М. Шабаев Уитмен поэзиясен туктаусыз пропагандалаучы һәм тәрҗемә итүче К. Чуковский хезмәтләренә, шулай ук И. Кашкин, Н. Банников, М. Зенкевич тәрҗемәләренә таянган. Шул ук вакытта тәрҗемәче инглиз телендәге оригиналларның турыдан-туры үзләренә дә мөрәҗәгать иткән. (Бер уңайдан шунысын да әйтергә кирәк, соңгы елларда дөнья әдәбияты классикларын оригинал теленнән тәрҗемә итү бездә матур бер традициягә әйләнеп бара. Аерым алганда, Шекспир сонетлары, Г. Хәйям робагыйлары һәм Н. Хикмәт шигырьләре нәкъ шулай тәрҗемә ителде.)

М. Шабаев Уитмен поэзиясендәге төп нәрсәне — аның драматизмын, революцион рухын, гади кешегә, башка милләт халыкларына булган мәхәббәтен, кеше белән табигать арасындагы аерылмас бер-

[1] У. Уитмен. Үлән яфраклары. Тәрҗемәчесе — М. Шабаев. Казан, 1976 ел.

дәмлекне бирә алган. Уитмен иҗатына хас күңел киңлеге, акыл тирәнлеге, кешенең рухи һәм физик камиллегенә соклану татарчада да сакланып калган. Иң мөһиме шунда, тәрҗемәче татар телендә Уитмен шигырьләренең ритмик эквивалентын тапкан. Ул рифмасыз тәрҗемә итә, шулай да татар шигъриятенә хас классик үлчәүләрне саклап тәрҗемә итә. Шуңа күрә Уитмен татар телендә рус телендәгегә карaганда эзлеклерәк, аһәңлерәк яңгырый. Әйтик, «Сагышларда, уйга чумып» исемле шигырьнең барлык халыклар һәм милләтләр арасындагы дуслыкка багышланган юллары рус телендә болай яңгырый: «Если бы я мог познакомиться с ними, я полюбил бы их не меньше, чем своих земляков». Мәгънә ягыннан бу — бик төгәл, әмма прозага тартымрак тәрҗемә. М. Шабаев тәрҗемәсендә бу юллар түбәндәгечә: «Тоела миңа, таныша алсам, якташларымнан бер дә ким күрми яратыр идем кебек аларны». Күрәсез, соңгы тәрҗемәдә, мәгънә төгәллеген саклау белән бергә, оригиналның мелодиясенә якын булган яңгыраш та табылган.

Тәрҗемәче өчен Уитменның «образ-каталог»лары аеруча зур кыенлык тудыра. Тыштан карaганда, алар әйбер һәм күренешләрне коры санап чыгу кебек кенә, ә асылда аларда әсәрнең эчке идея тирәнлеге, шигырьнең агым берлеге гәүдәләнә. Оригиналда алар, я күтәрелә, я кими барган каскад кебек яңгырап, укучыларны үз артларыннан ияртәләр. Менә шундый «каталог»ларның татар теленә тәрҗемә ителгән бер үрнәге:

һәрнәрсәгә чиксез шик-шөбһә,
борчылулар: әгәр алдансак?
Әгәр безнең иман, өметләр
бушка булса, һәм теге дөнья
булса бары матур әкият?
Ә бәлки дә минем күргәнем:
җәнлекләре, үсемлекләре,
кешеләре, таулар-үзәннәр,
җемелдәшкән йөгерек сулары,
төнге күге, көндезге күге,
төс-буяулар, тышкы төзелеш
(бәлки болар мотлак шулайдыр)
тик күз буяу булса, алдану,
ә асылы әле безгә һич
ачылмаган, аңлашылмаган.

(«һәрнәрсәгә чиксез шик-шөбһә». 100 бит.)

Бу юлларны укыганда аларның тәрҗемә икәнен сизмисең дә. Әйтерсең бу юллар башта ук татар телендә язылган. Ихтимал, тәрҗемәче адресына әйтелергә тиеш иң зур мактау сүзе менә шушыдыр. Билгеле, китапта аерым төгәлсезлекләр, кытыршы урыннар да очрый. Ләкин иң мөһиме шул, Уитмен саф татарча сөйләшә башлады. Аның әсәрләрен башка төрки телләргә тәрҗемә иткәндә шагыйрьләр М. Шабаев тәрҗемәсенә таяна алачаклар.

«Үлән яфраклары» җыентыгының тагын бер әһәмияте шунда, ул татар шигыренең эчке, потенциаль мөмкинлекләре зур булуын күрсәтә. Берничә еллар элек республика газеталары битләрендә ак һәм иркәле шигырь турында бәхәсләр булып узды. Берәүләр кайнар рәвештә иркле шигырьне яклады, икенчеләре, классиклар иҗатына таянып, иркле шигырь татар теленең эчке табигатенә туры килми дип чыктылар. Миңа калса, «Үлән яфраклары»ның дөньяга чыгуы безнең поэзиянең моңарчы тиешенчә файдаланылмаган сурәтләү һәм ритмик мөмкинлекләре булуын раслый торган аргумент була ала.

**Р. МОСТАФИН.**

# ИҖАТ ҺӘМ ХЕЗМӘТ АКТИВЛЫГЫ

Коммунизм җәмгыяте төзү юлыннан алга барган саен, эшчеләр сыйныфының җитәкчелек роле дә көчәя бара. Эшчеләр сыйныфының саны арта, гомуми белем һәм профессиональ өзерлек дәрәҗәсе күтәрелә. Бу һәм башка төрле үзгәрешләр аларның хезмәт активлыгы күтәрелүгә китерә. Совет эшчеләр сыйныфының, шулай ук колхозчы крестьяннар һәм интеллигенциянең хезмәт активлыгы — җәмгыятебезнең чиксез зур байлыгы ул. Әмма бездә моңарчы шушы бик мөһим мәсьәләне фәнни нигездә тикшергән хезмәтләр юк иде. Шуңа күрә М. Нугаевның «Нык үскән социалистик җәмгыятьтә эшчеләр сыйныфының хезмәт активлыгы»[1] исемле монографиясен фән кешеләре шатланып каршы алды.

Монография композицион яктан ифрат

[1] М. А. Нугаев. Трудовая активность рабочего класса развитого социалистического общества. Рус телендә, Казан университеты нәшрияты, 1975 ел.

җыйнак һәм камил булып чыккан. Автор башта хезмәт активлыгы төшенчәсенең философик нигезләрен ачып бирә. Активлык төшенчәсе, философик категория буларак, үсеш һәм хәрәкәт чыганагы («ирекле үсеш») белән үсеш һәм хәрәкәтнең үзе арасындагы объектив бәйләнешне чагылдыра. Әлеге күренешне конкрет анализлаганда, активлыкның чикләре пространство-вакыт ягыннан төгәл булырга тиеш. Хезмәт активлыгының иң югары формасы — кешенең аңлы эшчәнлеге.

Әлеге гомумфилософик һәм методологик аңлатмадан соң, автор конкрет рәвештә хезмәт активлыгын тикшерүгә күчә. Хезмәт эшчәнлеге — катлаулы төшенчә. Ул активлык һәм хезмәт төшенчәләренең нигезендә туа. Шуңа күрә дә аны югарыда әйтелгән төшенчәләр белән бәйләнештә яктыртырга кирәк.

М. А. Нугаев хезмәт активлыгы белән бәйләнешле күп кенә бәхәсле мәсьәләләрне күтәреп чыга, бу өлкәгә караган төп концепцияләрне фәнни күзлектән үткәрә.

Мәгълүм булганча, хезмәт активлыгын төрле аспектларда карап була (җәмгыять, социализм, хезмәт, җитештерү, шәхес, әхлакыйлык һ. б.). Ләкин үзенең мөстәкыйльлегендә, бөтен бер күренеш буларак, хезмәт активлыгы социаль шартларга бәйле булмаган сыйфатлар җыелмасы булып кала. Кешелек җәмгыяте үсешенең тарихи этаплары бу сыйфатларны үзгәртәләр: аларның беришеләрен интенсивлаштыралар, икенчеләрен йомшарталар, аларның эчтәлегенә яңа төсмер өстиләр. Шулай итеп, хезмәт активлыгына яңа характер бирәләр. Ләкин, ди автор, дисциплина, инициатива, новаторлык, ярыш, аңлы эшчәнлек һ. б. үзгәрешсез кала. Хезмәт активлыгының тәкъдим ителә торган структурасы хезмәтне тарихи яктан анализлаудан да, аны социалистик җәмгыять шартларында караудан да килеп чыга.

Китапның махсус бүлегендә эшчеләр сыйныфының хезмәт активлыгын күтәрүнең объектив факторлары турындагы мәсьәлә карала. Эшчеләр сыйныфының хезмәт активлыгы шартларына, җитештерү һәм җитештерүдән тыш, даими эш итүче күренешләр, кешенең физик, психик һәм әхлакый хәленә, хезмәттә үзенең эчке потенцияләрен ачу мөмкинлегенә турыдан-туры йогынты ясый торган яклар керә. Алар кешене актив хезмәт эшчәнлегенә этәрәләр, аның энергиясен арттыралар. Китапта аннары, эшчеләрнең хезмәт эшчәнлеген активлаштыруның әһәмиятле факторы буларак, турыдан-туры хезмәт шартларын камилләштерү мәсьәләләре анализлана. Автор хаклы рәвештә әйткәнчә, хезмәткә актив, иҗади мөнәсәбәтне билгели торган төп факторларны өйрәнгәндә социаль-экономик факторны да исәпкә алырга кирәк. Хезмәт активлыгының өстәмә факторы сыйфатында, ди автор, хезмәт шартлары алгы планга чыга. Мондый нәтиҗәгә килүнең теоретик яктан да, практик яктан да әһәмияте бар.

Хезмәт активлыгының объектив факторларын караганнан соң, М. А. Нугаев әлеге социаль феноменга йогынты ясый торган рухи факторларны анализлауга күчә. Совет эшчеләр сыйныфының хезмәт активлыгына рухи факторларның йогынты ясавы турындагы мәсьәлә — бик авыр һәм катлаулы мәсьәлә. Аның катлаулылыгы тиешле теоретик материалларның булмавы белән дә тиешле конкрет социологик тикшеренүләрнең үткәрелмәве белән дә бәйләнгән. Авторның фәнни фикерләре мәгълүм дәрәҗәдә бу кимчелекне бетерүгә шактый өлеш кертә. Социаль феномен буларак, хезмәт активлыгын тикшерүгә социаль-психологик яктан якын килү, билгеле булганча, социологик тикшеренүләрдә беренче тапкыр кулланыла.

Китапның социалистик җәмгыятьтә хезмәт активлыгы һәм эшчеләрнең һәрьяклап үсеше мәсьәләләренә багышланган өлеше кызыксынып укыла. Ләкин башка бүлекләрдән аермалы буларак, бу бүлектәге материаллар бераз схематик рәвештә бирелгән.

«Эшчеләрнең хезмәт активлыгы — конкрет социологик тикшеренү объекты» дигән бүлек үзенең оригинальлеге һәм мәсьәләләрне анализлаудагы яңалыгы белән кызыклы. Аның нигезенә 1969—1974 елларда Казандагы промышленность предприятиеләрендә, Кама автомобиль заводы төзелешендә үткәрелгән тикшеренү нәтиҗәләре салынган. Ул нәтиҗәләр, монографиядән күренгәнчә, шактый зур фәнни кызыксыну тудыралар.

Монографиянең соңгы бүлегендә хәзерге буржуаз социологиядә хезмәт активлыгы проблемаларын тикшерүгә багышланган хезмәтләр тикшерелә. М. А. Нугаев әлеге мәсьәлә буенча буржуаз авторларның төп хезмәтләрен җентекләп өйрәнгән. Бу аңа аларның нигезсезлеген күрсәтергә мөмкин-

лек биргән. Моннан тыш, автор совет философларының хезмәтләренә дә тулы күзәтү ясый.

Монографиядә кайбер кимчелекләр һәм төгәлсезлекләр очрый. Аерым бүлекләрдә проблемага кагылмый торган материаллар урын алган (130—135 битләр). Аерым очракта кызыклы гына материаллар теоретик яктан җентекләп нигезләнмәгән. Әсәрнең хезмәт һәм иҗтимагый-политик активлыкның үзара бәйләнеше турындагы мәсьәләгә багышланган өлешен шундыйлар рәтенә кертергә мөмкин.

М. А. Нугаевның хезмәте өйрәнелә торган процесска һәм фактларга кыю рәвештә иҗади якын килү белән аерылып тора. Авторның икенче уңай ягы шунда, үзеннән алдагы хезмәтләрне ул җентекләп өйрәнгән, проблема буенча чит ил әдәбиятын күздән кичергән.

Автор укучыларны социализмның эшчеләр сыйныфын бик зур биеклеккә күтәрүенә, алар алдында рухландыргыч перспективалар ачуына ышандыра. Коммунистлар җитәкчелек иткән әлеге алдынгы сыйныфның төп роле тагын да ныгу — гаять зур иҗат планнарын уңышлы тормышка ашыру, яңа җәмгыятьнең куәтен һәм тарту көчен тайпылышсыз үстерү нигезе. Яңа җәмгыять барлык хезмәт ияләренә социаль һәм политик яктан киң хокуклар, тынычлык, хезмәт һәм уңайлыклар бирә.

**Р. ВӘЛИЕВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

Гайса Гатауллин

# БАБАЙ, НӘКЫЙП, МИН ҺӘМ ВАКЫТ

хикәя

Нәкыйп чана шуа, бабай күлмәк тегә иде.

Нәкыйп:

— Аз гына шуам да кайтам инде. Дәрес әзерлисем бар, — диде.

Ә үзе, йөгерә-йөгерә тагын тауга менеп китте.

Бабай:

— Аз гына тегәм дә ятып ял итәм,— диде.

Ә үзе гел куймый энәсен:

— Аз гына, аз гына калды, — ди, — тегәсем.

Беләсезме шунда нәрсә булды: җилдәй очып таудан төшкән чакта агачка эләгеп Нәкыйп егылды. Ә туны, бабай тегеп биргән өр-яңа тун, ертылды...

— Ах, — диде дә Нәкыйп елап җибәрде...

Беләсезме тагын нәрсә булды:

«Чырт» итте дә бабайның энәсе сынды.

— Ах, — диде бабай да. — Күз арган чагында нишләп ял итмәдем? Энәсе дә нинди энә иде бит әле!

Елый-елый шунда Нәкыйп кайтып керде. Бабай тунны күрде. Ә тегәргә энәсе юк. Нишләр инде?

Әни күршеләргә кереп китте, бабайга энә эзләргә.

Ә үзе болай диде:

— Һәр нәрсәнең үз вакыты була шул. Эшне вакытында эшлә. Ялны вакытында ит. Энә күрәсеңме: берегез тунсыз, икенчегез энәсез...

— Вакыт ул — алтынга тиң нәрсә. Бакырга әйләнә син аны дөрес булмасаң, — дип, бабай да аның белән килеште.

# ИЛНУР

ХИКӘЯ

## I

Илнурның Акбай исемле эте бар. Акбай бик зур, акыллы эт. Илнур аны кечкенә чакта җигә дә:

— На-а, Акбай,— ди.

Акбай әйтә:

— Һау-һау, — ди, — мин ат түгел бит, маэмай, — ди.

Беркөнне Илнур тагын бер көчек күтәреп кайтты. Шундый кечкенә — песи хәтле генә.

— Ай, балам, — диде куркып әбисе. — Тизрәк урамга чыгарып җибәр. Әнисе күрсә тешләр үзеңне.

Илнур көчекне күлмәге эченә яшерде:

— Миңа аны бер абый бирде. Акбайның энесе икән ул...

Шулай итеп, Илнурның ике эте булды. Тырнаклары ак булганга, Илнур көчеккә Актырнак дип исем кушты.

## II

Илнурны әтисе шәһәргә алып барды. Аның шәһәргә беренче килүе иде. Әтисен төрле сораулар белән аптыратып бетерде.

— Шундый зур йортларны ничек салалар?

— Бу урамны нигә шулай киң итеп ясаганнар?

— Нигә шәһәрдә машиналар күп?

Урамда йөргәндә Илнур бик зур эт күрде. Андый зур этне аның беркайчан да күргәне юк иде әле. Бозау хәтле бар!

Илнур куркуыннан әтисенең кулын бик каты итеп кысты.

— Курыкма, улым, — диде әтисе. — Муенындагы тәңкәләрен күрәсеңме? Ярышта җиңгән өчен медальләр биргәннәр аңа.

Эткә медаль? Илнур әтисенең күзләренә карады. Алдамыймы икән?

## III

Авылга кайткач, Илнур малайларга шәһәр турында, бигрәк тә медаль таккан эт турында сөйләде.

Малайлар ышанырга да, ышанмаска да белмәделәр.

— Бик зур идеме?

— Зур. Бозау хәтле!

Кайберәүләр бозау кадәрле этне күз алдына китереп караганнар иде — куркыныч булып китте. Алай зур булгач, медаль дә тагарлар шул...

Медаль таккан эт турында малайлар өч көн сөйләттеләр. Ә дүртенче көнне авыл башына самолет төште. Малайлар узышып шунда йөгерделәр.

Медаль таккан эт турындагы уйлар, тишек кесәдән коелган борчак шикелле, үлән арасында тәгәрәп югалдылар.

# КУЯН НИЧЕК ЭШСЕЗ ЙӨРГӘН

ӘКИЯТ

Бер, ике өч —
Куян киң кырларда.
Бер, ике, өч —
Куян зур урманда...

Тиен үзенең оясын җылыта, чикләвек җыя, гөмбә киптерә.

Керпе дә кышка әзерләнә, оясын җылыта, гөмбә киптерә.

Ә куянның бернинди эше юк. Кайда яшел үлән, кайда кәбестә яфрагы өзә. Теше үтмәсләнә башласа, урманга барып агач кимерә.

Шулай эшсез йөргән көннәрендә бер күңелсез хәлгә очрый.

Бик матур бер айлы төндә, сикереп-сикереп йөри торгач, куян су буена килеп чыга. Суда шәүләсен күрә дә үзенә сокланып карап тора башлый. Бигрәк матур икән бит ул! Колаклары нинди озын, аяклары нинди нәфис! Су — чын көзге түгел. Шуңа күрә күзләренең чалыш икәнлеген күрми ул.

Куян бер колагын селкеткән: алга, артка, уңга, сулга. Шәүлә дә шуны ук кабатлаган. Тагын бер колагын селкетим дигәндә, якында гына кемдер сызгырып җибәргән:

— Фюо-ю-йт!

Куян «шап» итеп суга егылып төшүен сизми дә калган...

Сызгыручы кем дисезме? Йомран инде. Ул куянны бөтенләй күрмәгән дә, болай, кызык өчен генә сызгырган икән. Су чапылдавын ишетеп, йомран оясына кереп качкан.

Ә йомранның оясы — тирәндә. Ул куянның ярдәм сорап кычкыруын ишетмәгән дә.

— Бата-ам, коткарыгы-ыз!

Йөзә торгач, куян хәлдән тайган. Бик тә чыгар иде — яр бик биек икән. Ә зәңгәр күктә кәбестә яфраклары төсле ак болытлар йөзә...

— Коткарыгыз!

Җанварлар һәм кошлар йокыдан уянып ярдәмгә ашыкканнар.

Керпе йөгереп килгән дә озын чыбык сындырып алган.

— Тотын шуңа, — дип, чыбыкның бер башын куянга сузган.

Ике чыпчык куянның ике колагыннан эләктергән, күгәрчен — койрыгыннан күтәргән.

Саескан да куянның койрыгыннан эләктерергә уйлаган икән дә, тик аның койрыгы кыска бит, саесканга тотынырга урын калмаган.

— Әйдә, әйдә! — дип, башкаларга көч биреп тора икән саескан.

Тырыша торгач, куянны ярга чыгарганнар.

Керпе әйткән:

— Ах, син, кылый, — дигән, — эшсез йөрү беркайчан да яхшылыкка булмый.

Керпе акыл иясе, дөрес әйтә дип, кошлар аны хуплаган.

Бу хәлдән соң күпмедер вакыт үткән. Куян инде барын да оныткан. Бер заманны җырлый-җырлый бара икән бу:

Кишер яфраклары төсле
Колакларым минем,
Колакларым минем...

һәм жим чүпләп йөрүче чыпчыкларны пыр туздырып куып җибәргән.

Чыпчыклар үпкәләп:

— Нигә безне кыерсытасың? Без бит сине суга батудан коткарып калдык, — дигәннәр.

Куян әйткән:

— Һи! Сез булмасагыз, керпе, я күгәрчен коткарыр иде әле.

Колаклары озын булса да, акылы кыскарак икән шул куянның. Шулай ярыймы инде?

Куян үз юлы белән киткән. Бара торгач, аңа күгәрчен очраган. Куян кәбестә яфрагы кимереп бара икән.

— Куян, куян, — дигән күгәрчен. — Нәни күгәрченнәргә аз гына кәбестә яфрагы бирсәңче?

— Юк, — дигән куян, — үземә дә җитми әле.

— Ә мин сине суга батудан коткардым, — дигән күгәрчен үпкәләп.

— Һи, — дигән куян. — Син килмәсәң, башкалар килер иде.

Һәм ул җырлый-җырлый китеп барган. Бара торгач, аңа керпе очраган.

— Куян, — дигән ул. — Тиз генә күрше урмандагы сеңелемә барып әйтче: апабыз авырып китте.

— Бик барыр идем дә, керпе апаем, вакытым юк, — дигән куян.

Ә үзенең бер эше дә юк, көн буе тик йөри икән.

— Эх, син... — Керпе бүтән берни дә әйтмәгән... борылган да киткән.

Шулай итеп, тагын күпмедер вакыт үткән. Йөри торгач, куян тагын теге елга буена килеп чыккан, тагын үзенең шәүләсенә сокланып утыра башлаган.

— Фю-й-й-т! — Шул вакыт йомран сызгырып җибәрмәсенме...

Куянның куркаклыгы һәркайсыгызга билгеле инде. Суга егылып төшкәч кенә исенә килгән ул.

— Бата-ам, коткарыгыз! — дип кычкырган.

Керпе аны ишетсә дә, ашыкмаган. Я күгәрчен, я чыпчык, я саескан барыр әле, дип уйлаган.

Чыпчыклар бер күзләрен генә ачканнар да шунда ук йоклап киткәннәр. Икенче күзләрен ачып та карамаганнар хәтта.

Күгәрчен бөтенләй йокысыннан да уянмаган.

Ә саескан.... Аны инде әйтеп тә торасы юк. Каядыр күрше урманга, кошлар бәйрәменә очкан булган.

Куян йөзә-йөзә арып беткән.

— Батам, зинһар коткарыгыз! — дип кычкырган ул тагын.

Тәмам хәлдән тайгач, куян яр буенда үскән агач ботагын тешләгән дә күккә карап тора башлаган. Ә күктә кәбестә яфраклары төсле ак болытлар йөзә ди...

Куян хәзер кычкыра да алмый. Кычкырса, агач ботагын ычкындыра да «пылт» итеп су астына китәчәк.

Менә ай яктысында кемнеңдер шәүләсе күренгән. Керпе бит бу! Үпкәсен онытып куянга ярдәмгә килгән.

Керпе куянның колагыннан эләктереп, ярга сөйрәп чыгарган.

— Р-рәхмәт, керпе апаем, — дигән куян калтырап. Тешләре-тешкә тими икән үзенең.

Керпе әйткән:

— Яхшылыкка яхшылык белән җавап бирә бел. Кошларны үпкәләткәнсең, шуңа күрә коткарырга да килмәделәр үзеңне, — дигән.

Керпе акыл иясе ул!

Ә куян? Ул тизрәк күрше урманга, керпенең сеңелесенә хәбәр әйтергә йөгергән. Үзе йөгерә, үзе уйлый икән:

— Чыннан да, башкаларга ярдәм итү бик күңелле бит!

Әхмәт Рәшитов

## Траллалүли-траллаләй

*Мәҗлестә сөйләнгән кыйссалардан*

Сүз артыннан сүз китте —
Ишмигә чират җитте.
Башлады ул тирәннән:
— Бу троллейбус дигәннән...
Бер көн шулай безне би-ик
Чакырдылар туйга, дип, —
Баҗайның зур улы, дип,
Башлы-күзле булды, дип.
Безме дөнья көтмәгән,
Кемнән килеп китмәгән...
Бүләккә алдык аңа...
Хрусталь савыт-саба.
Култыкладым хатынны.
Белгән дә юк салкынны.
Эчтән җыр сузам, малай.
— Траллалүли-траллаләй!..
Тукталышта, әй, халык,
Торалар хәйран калып.
Троллейбуслар барчасы...
Хет берәрсен алсачы...
Бусы да үтте менә
Сәлам дә бирми генә.
Тик шулай да пошынмыйм,
Кәефемне төшермим:
— Траллалүли-траллаләй...
(Табаннан үтә, малай...)
Вакыт әле бар барын,
Хатын башлады зарын:
— Ни б-б-булган б-бу д-дусларга,
Т-т-трол-лей-лей-лейбусларга?!
...Булыр икән җиһанда—
Мәрхәмәтле бер җан да:
Туктады бит, туктады!
Безне санга чутлады!..
Һәм халык эшне сизеп,
Бер-берсен кысып-изеп,

Ябырылды ишеккә:
Утырырга ничек тә!
Мәхшәр көне диярсең...
Хатын гына иярсен —
Мин дә ташкын эчендә
Талпынам бар көчемә.
Селкенгән сыман нидер,
Тавышы келдер-келдер...
Һәй! Тырыша-тырмаша
Утырганбыз лабаса!
Хатын — уңган, мин — зирәк.
Алга үрләргә кирәк...
Кемдер төртте касыкка —
Янәсе, бик ашыкма!
Кемдер басты аякка —
Имеш, тукта, шаяртма!
Тралләлүли-тралләләй...
Вәт шундый хәлләр, малай...
Сөйләп тормыйм мин барын:
Пәлтәмнең якаларын
Хараплар иткәннәрен,
Вәринҗә түккәннәрен,
Ниләрдер чыпырдавын,
Ниләрдер шытырдавын,
Кемнәр кемне сүккәнне,
Ничек килеп җиткәнне...
Шулай да әле исәп...
Бүләкне бирик, дисәк,
Бар кунаклар каршында...
Чәл-пә-рә-мә барысы да...
Валлаһи, дим, алдамыйм,
Чак-чак кына аумадым.
...Тралләлүли-тралләләй,
Оятка калдык, малай.
Кайчагында, дус-ишләр,
Шулай да була эшләр!

# АБДУЛЛА ГОМӘР

(1906—1974)

Абдулла Закир улы Гомәров 1906 елның 15 июлендә Оренбург шәһәрендә туа.

А. Гомәрнең хезмәт һәм иҗат юлы республикада чыккан әдәби журналлар, шулай ук китап нәшрияты белән якыннан бәйләнгән. Хезмәт биографиясен ул «Безнең юл» журналында техник редактор булып башлый. «Безнең юл»дан «Яңалиф»кә, «Яңалиф»тән «Совет әдәбияты»на күчә. Техник редактордан әдәби сотрудник һәм җаваплы секретарь дәрәҗәсенә күтәрелә. 1943 елдан 1957 елларга хәтле А. Гомәр Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясендә эшли. 1958 елда аны «Совет әдәбияты» журналының җаваплы редакторы итеп билгелиләр. 1963 елдан алып, пенсиягә чыкканчы ул Татарстан Язучылар союзының әдәби консультанты булып эшли.

А. Гомәрнең иҗат эшчәнлеген өч тармакка бүлеп карарга була. Ул китап нәшрияты чыгара торган бик күп җыентыкларны төзүдә һәм редакцияләүдә катнаша. «Татар совет әдәбияты тарихы», Г. Тукайның 4 томлык, Ф. Әмирханның 2 томлык «Сайланма әсәрләре» һәм күп кенә башка җитди җыентыклар аның редакциясендә чыга.

Абдулла Гомәр күп санлы тәнкыйть мәкаләләре һәм рецензияләр яза. Аның «Укучыларга ихтирам белән карарга кирәк», «Таләпчәнлекне киметмәскә», «Бозылган тәрҗемәләр», «Үтәлмәгән вәгъдәләр», «Тукай» романының русча басмасы», «Сугыш хикәяләре», «Игътибарсызлык бәласе», «Бөек еллар тавышы» кебек мәкаләләре үз вакытында шактый зур яңгыраш таба.

Әмма, болардан да бигрәк, ул әдәби тәрҗемә өлкәсендә аеруча актив эшли. Абдулла Гомәр Н. Виртаның «Чит ил кешесе», А. Караваеваның «Корыч коючылар», Л. Лагинның «Хоттабыч карт», Мамин-Сибирякның «Алтын», А. Фадеевның «Яшь гвардия», М. Шолоховның «Алар Ватан өчен сугыштылар» исемле әсәрләрен һәм башка язучыларның күп кенә башка әсәрләрен татар теленә тәрҗемә итеп калдыра.

## ШАГЫЙРЬ ИСЕМЕНДӘ

* * *

Халкыбызның бөек шагыйре Габдулла Тукайның тууына туксан ел тулды. Шул уңай белән Татарстан Верховный Советы Президиумы республикабызның Чаллы районын Тукай районы дип үзгәртү турында карар чыгарган иде. РСФСР Верховный Советы Президиумы үзенең 20 апрелендә игълан ителгән Указы белән бу карарны раслады һәм хәзер Чаллы районы **Тукай районы** дип йөртелә башлады.

* * *

Шул көнне игълан ителгән карарында РСФСР Верховный Советы Президиумы Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының Чаллы шәһәрендә Автозавод һәм Комсомол районнары оештыру турындагы карарын да раслады.

## МУСА ҖӘЛИЛ УРАМЫ

Хезмәт ияләре депутатларының Мәскәү шәһәр Советы башкарма комитеты Кызыл Гвардия районының Орехово-Борисково диган өлешендә төзелеп килгән яңа урамына герой шагыйрь Муса Җәлил исемен бирү турында карар чыгарды.

## ЯҢА ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНА НИГЕЗ САЛУЧЫГА

Яңа татар әдәбиятына нигез салучы шагыйрь һәм публицист Габдулла Тукайның тууына 90 ел тулу уңае белән СССР Язучылар союзы правлениесе секретариаты бу датаны үткәрү өчен Бөтенсоюз комиссиясе төзеде.

Аңа түбәндәге иптәшләр керде: М. Луконин (председатель), М. Хәсәнов (председатель урынбасары), Н. Шундик (председатель урынбасары), А. Карпов (җаваплы секретарь), А. Алимжанов, Г. Ахунов, Н. Бажан, Р. Бикмөхәммәтов, М. Вәлиев, Ю. Верченко, В. Ганиев, М. Горбачев, Ю. Грибов, А. Деревянко, М. Дудин, З. Нури, М. Кәрим, Х. Зәйнуллин, Л. Землянникова, И. Касумов, М. Львов, Л. Матвеев, С. Михалков, Б. Покаржевский, С. Орлов, Н. Свиридов, В. Сомов, В. Сорокин, Х. Туфан, С. Хәким, А. Чаковский, И. Чхиквишвили, Г. Шәрәфетдинов, С. Эралиев, Р. Эсенов, К. Яшен.

## ШИГЫРЬ БӘЙРӘМЕ

Казанда, Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театры каршындагы Тукай һәйкәле янында шагыйрьнең туган көнендә шигъри митинг үткәрү күптән инде традициягә әйләнде. 26 апрельдә үткәрелгән быелгы шигъри митинг аеруча тантаналы шартларда — КПССның XXV съезды карарлары яктылыгында һәм Габдулла Тукайның туксан еллыгына багышлап үткәрелде. Г. Тукай премиясе лауреаты, Татарстан Язучылар союзы председателе Гариф Ахунов алып барган ул митингта шагыйрьләребез үзләренең Тукайга багышланган һәм съезд карарларын тормышка ашыру өчен тырышып эшләүче хезмәт алдынгылары турындагы шигырьләрен укыдылар. Шигъри бәйрәм кичен язучыларның Тукай исемендәге клубында дәвам итеп, анда зур әдәби музыкаль кичә үткәрелде.

* * *

Г. Тукайның тууына туксан ел тулуга багышлап Пермь шәһәрендә әдәби кичә үткәрелде. РСФСР Язучылар союзының Пермь бүлеге тарафыннан оештырылган ул кичәдә журналист Җәгъфәр Камалов шагыйрьнең тормышы һәм иҗаты турында доклад ясады. Пермь шагыйрьләре Тукай шигырьләрен, татар совет шагыйрьләренең яңа әсәрләрен рус телендә укыдылар. Бу кичәдә шагыйрь Мәхмүт Хөсәен һәм прозаик Вакыйф Нуруллин да катнашып, алар бүгенге татар әдәбиятындагы яңалыклар турында сөйләделәр, үзләренең әсәрләрен укыдылар.

## «КАЗАН ЯЗЫ» КИЧӘЛӘРЕ

Язучылар союзы каршындагы әдәбиятны пропагандалау бюросы һәм республикабыз китап сөючеләр җәмгыяте һәр елның апрель аенда әдәби-музыкаль кичәләр оештыра. «Казан язы» дип аталган традицион кичәләр бу елда Казан шәһәренең мехчылар, сәүдә хезмәткәрләре клубларында, төзүчеләр һәм Дербышка эшчеләр поселогы культура сарайларында уздырылды. Ул кичәләрдә әдипләребездән Гариф Ахунов, Сибгат Хәким, Шәүкәт Галиев, Рафаэль Мостафин, Илдар Юзеев, Нури Арсланов, Атилла Расих, Мәхмүт Хөсәен, Галимҗан Латыйп, Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Вакыйф Нуруллин, Роберт Әхмәтҗанов, Мәдинә Маликова, Рөстәм Мингалимов, Равил Фәйзуллин, Фаил Шәфигуллин, Рәдиф Гатауллин, Мөдәррис Әгъләмов, Роберт Батуллин, Габдрахман Минский катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ ПАРТИЯ ҖЫЕЛЫШЫ

Журналыбызда инде хәбәр ителгәнчә, бу елның март аенда КПССның Татарстан өлкә комитеты бюросы Язучылар союзы партия оешмасының эше турындагы мәсьәләне

караган һәм шул хакта карар кабул иткән иде. Язучылар союзы партия оешмасы апрель аенда ачык партия җыелышы үткәрде һәм анда партия оешмасы секретаре Вакыйф Нуруллинның өлкә комитет карары һәм язучылар алдында торган бурычлар турында доклады тыңланды. Фикер алышуларда Гомәр Бәширов, Афзал Шамов, Нәби Дәүли иптәшләр катнашты. Җыелыш язучылар алдына XXV съезд куйган һәм өлкә комитет бюросы карарында күрсәтелгән бурычларны томышка ашыру буенча союз идарәсе һәм партия оешмасы төзегән өч еллык перспектив эш планы кабул итте.

Шул ук җыелышта Язучылар союзының җаваплы секретаре Равил Фәйзуллин һәм оештыру эшләре буенча секретарь Мөсәгыйть Хәбибуллиннарның отчетлары да тыңланды.

## ХЕЗМӘТКӘ — ХӨРМӘТ

Совет әдәбиятын, сәнгатен һәм культурасын үстерүдә, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә һәм тугызынчы бишьеллык планны үтәүдә актив катнашулары өчен:

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артисты **Габдулла Рухулла улы Шамуков Ленин ордены белән,** язучы **Атилла Кадыйр улы Расулов,** Г. Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясе артисткасы **Әлфия Афзал кызы Афзалова,** Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрының баш художнигы **Әнвәр Хәсән улы Нагаев Хезмәт Кызыл Байрагы** ордены белән, Казан дәүләт консерваториясенең доцент вазифасын башкаручы **Вадим Алексеевич Афанасьев,** Бөгелмә дәүләт рус драма театрының баш режиссеры **Павел Васильевич Джапаридзе,** В. И. Качалов исемендәге Казан дәүләт зур драма театры артисты **Юрий Степанович Федотов «Почет билгесе»** ордены белән бүләкләнделәр.

Рәссам **Эмиль Гариф улы Ситдиков «Хезмәттәге батырлык өчен»** медале һәм Татар дәүләт республика күчмә театры артисткасы **Земфира Исхак кызы Досаева,** композитор **Бату Гатаулла улы Мулюков,** Казан дәүләт курчак театры артисткасы **Галия Садыйк кызы Таһирова «Аеруча хезмәт күрсәткәне өчен»** медале белән бүләкләнделәр.

* * *

Халык хуҗалыгына белгечләр әзерләүдә, укучыларга белем бирүдә, аларны коммунистик тәрбияләүдә ирешкән уңышлары өчен В. И. Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының кафедра мөдире, профессор, «Казан утлары» журналының редколлегия члены **Рәфыйк Измаил улы Нәфиков** һәм Алабуга дәүләт педагогия институты ректоры, СССР Язучылар союзы члены **Тәлгать Нәби улы Гатауллин «Почет билгесе»** ордены белән бүләкләнделәр.

## ШАГЫЙРЬГӘ ЧӘЧӘКЛӘР

Ленин премиясе лауреаты, Советлар Союзы Герое шагыйрь Муса Җәлилнең тормышын һәм иҗатын өйрәнүгә, аның иҗатын халык арасында тагын да киңрәк пропагандалауга әдип һәм тәнкыйтьче Рафаэль Мостафин күп көч куйды. Рус һәм татар телләрендә Җәлил турында китаплар бастырып чыгарды, шагыйрьнең иҗаты һәм тормышы хакында күп кенә лекцияләр укыды, радио һәм телевидение буенча чыгышлар ясады. Шушы елның март аенда, илебез җәмәгатьчелеге Муса Җәлилнең 70 еллык юбилеен билгеләп үткән көннәрдә, Рафаэль Мостафин Германия Демократик Республикасында булып кайтты. Ул анда Плетцензее төрмәсендә Мусаны җәзалап үтергән урынга, шагыйрьнең җитмеш еллыгы уңае белән, чәчәкләр кую тантанасына катнашырга чакырылган иде. Бу тантанада СССРның ГДРдагы илчеләре, Көнбатыш Берлиндагы консуллык вәкилләре, Германия-Совет дуслыгы җәмгыяте членнары катнашты. Рафаэль Мостафин чәчәк куярга килгән кешеләр алдында Муса Җәлилнең иҗаты һәм тормышы хакында сөйләде. Шуннан соң ул Берлинның М. Җәлил исемендәге хезмәт коллективлары членнары, ГДР язучылары белән очрашып, әдәбиятлар һәм халыклар дуслыгы хакындагы әңгәмәләрдә катнашты.

Җәлил истәлегенә чәчәкләр кую тантанасы турында Берлин газеталарында да хәбәрләр басылып чыкты.

## ИҖАТ КИЧӘСЕ

Казан шәһәренең Төзүчеләр культура сараенда РСФСРның М. Горький исемендәге һәм республикабызның Тукай премияләре лауреаты шагыйрь Сибгат Хәкимнең иҗат кичәсе үткәрелде. Язучылар союзы председателе Гариф Ахунов ачып җибәргән ул кичәдә Тукай премиясе лауреатлары һәм Татарстанның халык артистлары Айрат Арсланов, Зәһит Хәбибуллин, Ринат Таҗетдинов, ТАССРның халык артисты Эмиль Җәләлетдинов, ТАССРның атказанган артисткасы Нәфисә Васылова, җырчылар Рафаэль Ильясов, Рафаэль Сәхәбиев шагыйрь Сибгат Хәким сүзләренә язылган җырларны җырладылар, аның шигырьләрен укыдылар. Соңыннан Сибгат Хәким үзенең яңа әсәрләрен укыды.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

12 апрельдә Мәскәүдәге Союзлар йортының колонналы залында Бөтенсоюз коммунистик өмәсенә багышланган әдәби кичә үткәрелеп, анда Мәскәү һәм тугандаш республикаларның атаклы шагыйрьләре чыгыш ясады. СССР Язучылар союзы белән берлектә ВЦСПС үткәргән бу кичәдә татар шагыйре Зәки Нури да катнашты.

* * *

Сибгат Хәким һәм Гомәр Бәширов Арча районында чыга торган «Коммунизмга» газетасы каршындагы «Тукай яктышы» исемле әдәби түгәрәк членнары белән очрашып, аларның шигырьләрен, хикәяләрен укып, киңәшләр биреп, үзләренең иҗат тәҗрибәләре белән уртаклашып кайттылар. Алар Арча педагогия училищесы укучылары белән дә очраштылар. Гомәр Бәширов булачак яшь укытучыларга балаларда әдәбият һәм сәнгатькә, туган телгә, туган ил-

гә, халык авыз иҗатына, халык тарихына мәхәббәт тәрбияләүнең зарурлыгы хакында сөйләде. Сибгат Хәким үзенең яңа шигырьләрен укыды.

* * *

Тукай премиясе лауреаты шагыйрь Шәүкәт Галиев белән прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗев, Казан дәүләт университетының тарих-филология факультеты студентлары белән очрашып, аларга бүгенге әдәбиятыбыздагы яңалыклар турында сөйләделәр, сорауларга җаваплар бирделәр.

## ӘҺӘМИЯТЛЕ КИҢӘШМӘ

Казанның Актерлар йортында сәнгать эшлеклеләренең республика киңәшмәсе булды. Анда республика театрлары һәм Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең тугызынчы бишьеллыкта эшләгән эш йомгаклары һәм КПССның XXV съезды карарлары яктылыгында яңа бишьеллыктагы бурычлары тикшерелде.

Доклад белән ТАССР культура министры Ә. Миндубаев чыкты. Доклад буенча фикер алышуларда СССР халык артисты Ф. Халитов, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрының баш режиссеры Н. Даутов, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге правлениесе председателе Р. Җиһаншина, сәнгать фәннәре кандидаты Х. Кумысников, Республика күчмә театрының баш режиссеры Р. Тумашев, ТАССР Художниклар союзы правлениесе председателе Ә. Тумашев, Татар дәүләт филармониясенең художество җитәкчесе И. Мәҗитов катнашты.

Культура һәм сәнгать работникларының 1976 елга социалистик йөкләмәләре кабул ителде.

Киңәшмәдә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев һәм ТАССР Министрлар Советы Председателе урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## ДРАМАТУРГЛАР СЕМИНАРЫ

Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгына багышлап СССР Культура министрлыгы, СССР Язучылар союзы һәм Бөтенроссия театр җәмгыяте 1976—1977 елгы театр сезонында СССР халыклары драматургиясе фестивале үткәрәчәкләр. Шуна әзерлек уңае белән бу елның март аенда Мәскәү янындагы Руза шәһәрендә драматурглар семинары үткәрелде. Анда безнең драматургларыбыздан Аяз Гыйләҗев, Илдар Юзеев, Туфан Миңнуллин һәм Юныс Сафиуллин катнашты. Шул семинарда А. Гыйләҗев, И. Юзеев пьесалары әйбәт дип табылып, РСФСР театрлары сәхнәләренә куярга тәкъдим ителде.

## ЯҢА СПЕКТАКЛЬЛӘР

Апрель аенда Татар дәүләт республика күчмә театры Мөхәммәт Әблиевнең «Шәмсекамәр» пьесасы нигезендә эшләнгән яңа спектакльне тамашачыларга күрсәтә башлады. Спектакльне сәхнәгә ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе режиссер Равил Тумашев куйган. Художнигы — ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Петр Баландин.

* * *

16 апрельдә Әлмәт дәүләт драма театры Аяз Гыйләҗевнең «Кар астында кайнар чишмә» исемле комедиясен сәхнәгә куйды. Спектакльнең режиссеры — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Гали Хөсәенов.

## АЛМАШ КОНЦЕРТЛАР

Казанда Башкортстан сәнгать осталары концертлары булып үтте. Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында, Урицкий, Маяковский исемендәге клубларда, «Юность» һәм химиклар культура сарайларында үткәрелгән концертларда шәһәребез тамашачылары бай һәм үзенчәлекле программа белән таныштылар. РСФСРның һәм БАССРның халык артисты, Салават Юлаев исемендәге премия лауреаты Мәгафур Хисматуллин, БАССРның атказанган артистлары Зәки Мәхмүтов, Рәшидә Әхмәдиева, Нажия Аллаярова, Алик Бикчурин, Радик Хәбибуллин, җырчы Җиһания Рәхмәтуллина, эстрада җырчыларының Бөтенроссия конкурсы лауреаты Илфак Смаков, эстрада артистларының Бөтенсоюз конкурсы лауреаты Рафаэль Галиев башкарган номерларны аеруча яратып кабул иттеләр.

Башкорт дусларыбыз Казанда булган көннәрдә Татарстан сәнгать осталары Уфа шәһәре театрларында, культура сарайларында концертлар бирделәр. Уфа тамашачылары республикабыз сәнгать осталарын шулай ук җылы каршылады.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМ

ТАССР Верховный Советы Президиумының 1976 ел, 20 апрельдә игълан ителгән Указы нигезендә, совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисткасы **Анастасия Петровна Васильевага ТАССРның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исем бирелде.

## ИҖАДИ ДУСЛЫК ДОГОВОРЫ

Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры артистлары бөтен дөньяга атаклы Казан мех фабрикасына барып, мехчылар һәм аларның эшләре белән таныштылар. Шунда артистлар һәм мехчылар үзара социалистик ярыш договоры да төзеделәр.

СССРның халык артисты Фуат Халитовны өлкән мехчылар аеруча куанып, үз итеп каршыладылар, чөнки ул утызынчы елларда шушы фабрикада эшләгән. Зур сәнгатькә алып чыккан юлын шушы фабриканың үзешчән эшчеләр театрында башлаган иде.

* * *

РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисткасы Рәшидә Җиһаншина Буа район культура йорты һәм Түбән Наратбаш авылы үзешчәннәре белән очрашып, аларга агитбригадалар, җыр һәм бию ансамбльләре, драма түгәрәкләре, нәфис сүз осталары алдында торган бурычлар турында сөйләде, үзенең иҗат тәҗрибәсе белән уртаклашты.



*язучы* ӘМИРХАН ЕНИКИ

В. КУДЕЛЬКИН *рәсеме*

(Татарстанның әдәбият һәм
сәнгать осталары циклыннан.)

## *Хөрмәтле укучыбыз!*

Журналыбызның 8 санында игътибарыгызга түбәндәге әсәрләр тәкъдим ителәчәк:

Бу сан Марсель Зариповның «Үзеңнеке — үзәктә» исемле повесте белән ачыла. Рафаил Төхфәтуллинның «Кар күзе» дигән хикәясе, Үзбәк Сатаровның «Кызым хикәяләре» бирелә.

Поэзия сөючеләр Зәки Нуриның «Яңа җыр алып кил» һәм яшь шагыйрь Зиннур Мансуровның «Иделгә хат» дигән шигырьләр бәйләмен укырлар. «Дуслар җыры» бүлегеннән Таулы Алтай поэзиясе үрнәкләре урнаштырыла.

«Очерклар» бүлеге, гадәттәгечә, КамАЗ елъязмасы белән башлана. Д. Гарифуллинның «Игенче улы», С. Закировның «Туган яктан көч алып» дигән очерклары якташларыбызның уңышы турында сөйли.

Республикабыз җәмәгатьчелеге 1977 елда Казан шәһәренә нигез салынуга 800 ел тулган көнне билгеләп үтәчәк. «Казан утлары» журналы шушы тантанага кагылышлы материаллар урнаштыра башлады. 8 санда сез тарих фәннәре докторлары В. Ивановның «Гасырлар аша карап» һәм А. Халиковның «Казан кайчан һәм кайдан башланып киткән» дигән мәкаләләрен укырсыз.

Театрның 70 еллыгына материаллар бирүне дәвам итәбез. Урнаштырылган әсәрләрдән Р. Мөхәммәдиевнең «Театрыбызның беренче тәнкыйтьчесе» дигән мәкаләсе тәнкыйтьче Г. Кәрам иҗаты турында сөйләр.

Тарих фәннәре докторы Р. Нәфиков бу санга «Фатих Әмирхан — публицист һәм җәмәгать эшлеклесе» дигән хезмәте белән катнаша. Филология фәннәре кандидатлары Ф. Хатиповның «Эшче рухы», Р. Ганиеваның «Тирәннән алып», Ф. Сафиуллинаның «Фатих Әмирхан прозасы рус телендә» дигән мәкалә һәм рецензияләре дә бирелә.

Болардан тыш журналның «Төрлесеннән», «Нәниләр дөньясы», «Елмаеп та, көлеп тә...» дигән бүлекләрендә Шәүкәт Галиев, Гәрәй Рәхим, Җәүдәт Дәрзаманов h. б. шигырь һәм хикәяләрен, мәкалә һәм язмаларын укырсыз.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.


# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210